КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Айрат СУФИЯНОВ. Карашыңда янсын чыраг! *Шигырьләр.* ....3
Айдар ХӘЛИМ. Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?.. *Балачак хатирәләреннән. (Ахыры).* ....8
Марат КӘБИРОВ. Автомат һәм... шигырь дәфтәре. *Язылмаган поэма.* ....78
Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Тау башында бүре бар. *Роман. (Ахыры).* ....86
Рәмилә МАЙОРОВА. Бер тамчы моң җитми... *Шигырьләр.* ....136
Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА. Куеныңда ни бар? *Хикәя.* ....140

ЯҢА ИСЕМНӘР

Раян ШАКИРОВ. Яшәешең – каләм чарлау... *Шигырьләр.* ....151

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Данил МАКЕЕВ. Боз сөңгесе. *Хикәя. (Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА тәрҗемәсе.)* ....154

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Лилия ХӨСНЕТДИНОВА. Иҗаты – милләтнең йөз аклыгы *(Айрат Суфиянов лирикасына бер караш).* ....161

ПУБЛИЦИСТИКА

Дания РӘҮПОВА. Бер карлыгач яз ясамый. ....169

ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА – 140 ЕЛ

Фотоархив. *Сәхифәне Айдар ШӘЙХИН әзерләде.* ....171
Һүсәйин БАРГАН. Идел-Урал язучысы Шәриф Камалга Халит Зия Ушаклыгилнең йогынтысы. *(Төрекчәдән Ринат СӘФӘРОВ тәрҗемәсе).* ....173

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ралина ХӘБИРОВА. Француз телендә нәшер ителгән «Хәзерге татар прозасы антологиясе»нә (Париж, 2021) күзәтү. ....181

*Хатлар яздым утырып:* Әдхәт Синугыл, Рәис Зарипов, Җәмит Рәхимов, Фәния Чанышева, Газиз Кашапов-Үзиленең Марсель Галиевка язган хатлары. ....184

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* ....187

*Газиз тавышлар:* Йөрәкләргә «Ялкын» салган язучы *(Роза Хафизованың туууына – 95 ел)* . ....188
Мин үземне әдип итеп тоям... (*Нияз Акмалның туууына – 70 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 2 (1216) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**


✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.01.2024, график буенча 31.01.2024, басылып чыгу вакыты 06.02.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-0135. Тираж 3030.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе иркле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2024 ел



Айрат
Суфиянов

# КАРАШЫҢДА ЯНСЫН ЧЫРАГ!

## Аллаһ кушса...

Тауга менеп, таудан төшсәм төшим, –
Үз сукмагым булсын, үз юлым.
...Чәнечкеле куак арасыннан
Эзләп йөрим таңның былбылын.

Энҗе эзләп чумсам, төпкә чумыйм,
Тыным бетсә бетәр, батармын...
Таш тапсам да, ул үз ташым булсын –
Мин дошманга аны атармын,
Бәддогасы итеп татарның.

Сыенсам да кайнар моң иленә,
Сәҗдә кылып, рухта уянып,
Язмышымның үз күзләре аша
Аллаһ кушса,
Күрәчәкмен бөтен дөньяны.

Ачы булса, әйдә, була күрсен
Туа күрсен, тик үз җимешем.
Каным кайный, әмма вулкан атып
Тукталмасын йөрәк тибешем…

Шагыйрь итеп, үз иләге аша
Үткәрерме вакыт? Билгесез.
…Һәр карышка күчкән сокланычым, –
Җанкаемның тәрәз өлгесе.

Минем чәчәк, ул минеке булсын…
Үзем кушармын да исемен.
Сөюемә төреп дөньялыкка,
Хистән арынмаган бар халыкка
Йоктырырмын аның хуш исен,
Аллаһ кушса…

---

Айрат СУФИЯНОВ (1958) – *шагыйрь; «Кылычлы җил», «Таң калып багам таңнарга» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

## Үпкәләмәм

Таң туганда былбыл тавышыннан,
Ташта үскән гөлләр балкышыннан
Хуш-ис аңкый, сулыйм йотлыгып.
Аңым, җаным, уй-хыялым белән
Мәңгелеккә калсам, йотылып
Шул хуш исле, җырлы балкышта,
Үпкәләмәм кебек ялгыш та...
Кем генә соң җирдә омтылмасын
Таң калырлык матур язмышка.

## Кошмын бит мин!

Чиксезлектән килгән җаным –
Вакытлы кош бу дөньяда.
Аллаһ кушса, сайрый-сайрый
Канат ярмас буш ояда...

Үзләренә дәшә-дәшә,
Мең йолдызлар җемелдәшә.
Туган төнем юллый сәлам…
Фәрештәле айлы галәм
Илһамыма җим өләшә...

Зәңгәр төннең кочагыннан
Суырылып таңга чыгам.
...Авыл карты печән чаба,
Маңгай тирен сыга-сыга...

Кулларымда чалгы уйный
Үләннәрне кырка-кырка.
Уза кәлтә еланнары,
Яннарымнан курка-курка.

Үзем белгән догаларны
Эчтән генә укый-укый,
Тәҗрибә, аң туплый-туплый,
Алга барам туктый-туктый.

Фанилыкның күсәгенә,
Әйтегезче, кем юлыкмый?
...Яши җирдә адәми зат
Берсен-берсе тукмый-тукмый.

Тарлар урынын киңәйтә,
Чын кешене таплый-таплый.
Үлеп китсәң, сөенешеп
Күмәчәкләр таптый-таптый...

Күктә очам... Ярдәм сорап
Инәлгәнне ташлап китмим.
Дошманым да күкрәгемә
Баса алмас... Кошмын бит мин...

Кошмын бит мин!..

## Башым исән!

Ут уйнаткан чаклар артта калды,
Буыннарым сыек, бил тотмый.
Соң чиккәчә ничек аумаска соң,
Тамырларда каным оетмый?
Раббым ярдәм бирсен, ихтыярым
Нокта куйсын тәндә көч юкка.
Ялантәпи балачактагыча,
Яктылыкның үзен коча-коча,
Йөгерәсем килә офыкка!
Язмыш мине төпчек улы күреп
Урамады затлы бәрхеткә.
Һич төкәнмәс шагыйранә газап,
Сагыш төште минем бәхеткә...
Алтын-көмеш чыңын ишетмәдем,
Хәләл бакырыма сыенып.

Яшәдем дә, яшәрдем дә җирдә,
Таштан чыккан чыкка коенып...
Күтәралган сирәкләргә генә
Галәм юллый авыр сынавын.
Өндәү төсле төп-төз булсын сыным,
Сыгылса да телим сынмавын.
Уйлыйм, тоям, күрәм, ишетәм дә,
Яфрак яра язмыш тирәгем.
Кыйбла якка таң кояшы булып
Карап кага олы йөрәгем!
Башым исән! Вакытлыча гына
Буыннарым камыр, бил тотмый.
Шигыремә күчкән үрмә гөлләр,
«Башың имә, көрәш, яшә», диләр,
Кеше икәнеңне онытмый!

## Олуг максатым

Түбәнсенүне – җен күрә җаным…
Чиста килеш кал, намус, вөҗданым!
Сатылмыйм. Сатмыйм. Тамырларымда
Кайный бәһасез йөрәгем каны.
Гайбәт сөйләмим, шымчылык итмим,
Әләк тә язмыйм беркем өстеннән.
…Талчыккан ялгыз сәфәрчемен мин
Якты эзләгән караңгы төннән,
Тулган ай кебек тулы-бөтеннән…
Кешене – кеше иткән кыйммәтләр
Аллага шөкер(!), хәтердә, исән!
…Үземә үзем ләгънәт юлларымын
Кимлек камытын карусыз кисәм…
Гасырның бозын бораулап өскә
Яз күтәрелгән – умырзаямын.
Җирдә беркемгә, беркайчан тимәс,
Салкын кыраулы зарар-зыяным.

Вак-төяк белән шөгыльләнергә
Юк миндә теләк, әрәм вакытым.
Олуг максатым – табасым килә,
Калебем айкап, Мәгънә якутын.
Тоташ серләрнең мәгарәсендә
Ничек кабызыйм гакылым утын?
...Фаразланса да төтен-томанга
Әйләнәчәге галәмнәр суты,
Кадерләү – кыйблам, яшендәй уйнап
Узган гомернең һәрбер минутын.
Йа Раббым, язма, булырга миңа
Тәмуг казанын кайнаткан утын!
Тимер гасырдан аралап алам
Язгы бәйрәмен гөлле хисемнең.
Олуг максатым – өскә күтәрү,
Йөрәкләр аша нурдай үткәрү,
Бүленмәс, бердәм татар исемен!

## Өшим мин

Җиргә ялганмаса кендекләр – ташка үлчим безнең кемлекләр...
Эзәрлекләр гомер буена таянычсыз, үксез кимлекләр.
Үз асылын җуйган кешедән каһкаһәләп көләр киңлекләр.
Елмаймас та ихлас ачылып шагыйранә хискә тиңлекләр.
Кара туфрак ашын корытса, җимерелеп төшәр ил-йорт та.
Мөмкинме соң тыныч яшәргә, Җир-анаңны имеш, оныт та?..
Танырбызмы аның кадерен кайтып ауган соңгы сулышта?..
Ярларыннан чыгып ташмасмы? – Шаша-шаша күңел тулыша.
Сарут баскан кырлар өстендә дәртле йөрәк-тургай сайрамый...
...Канатлылар оя корырга сүнгән төбәкнеме сайламый?..
Баш очында чеплә кояшы... Ник калтырыйм, нигә өшим мин? –
Шәһәр ташы безне бастымы, хыялны чор дарга астымы,
Кеше иткән хисләр качтымы, караңгылык кочак ачтымы,
Язмышыбыз булып? Төшенмим... Өшим мин...

## Колын чаба

Нигә икән җаным күккә ашып,
Мөлдерәпләр тулды шатлык белән?!
Исәнләштем балкып, балачактан
Кире урап кайткан сафлык белән.

Ялан тулы ап-ак ромашкалар –
Таңгы чыклар керфекләрен үпкән.
Офыклар – ал, әллә таңым туды
Гомер буе зарыгыплар көткән?!

Беркемгә дә, рәнжү, үпкәм дә юк,
Әйтерсең лә мин гөнаһсыз, изге.
Явызны да кичерергә әзер
Матурлыкка гашыйк шушы мизгел...

Татлы төшемдәге халәтме бу?
Һәр тарафтан күзләр бәхет таба.
... Кояш чыккан якка кешни-кешни,
Җилне узып сабый колын чаба!

## Бишек

Силәсендә сәмави нур
Уйнаган көйле бишек...

Ак биләүдә сабый йоклый
Төш күреп, тирләп-пешеп.

Аллаһ белән бәйләнеше
Өзелмәгән, җаны – бай.
Тешсез авызы елмаеп
Ачылган таң таҗыдай.
Татлы җәннәт җимешләрен
Сузамы фәрештәсе?!
«Сөбханалла, күз тимәсен!» –
Дип пышылдый әннәсе.
Уянып китә дә сабый,
Биләвен чишеп ата.
Һаман хәтере багында
Бәйсезлек чәчәк ата…
Күгәрченнәр гөр-гөр килә
Нарат өй кыегында.
Киләчәк яшәр шикелле
Сәгадәт куенында.
…Көн күзендә ил-көн көткән
Көләч кояш кабына.
Ашлы болыт кәрваннары
Ага кыйбла ягына.
Безме, сабыйлык сафлыгын
Җир үземе сагына?
…Силәсендә сәмави нур
Уйнаган бишек аша
Үткән, бүгенге, киләчәк,
Мәңгелек аралаша.

## Кайтыр

Гөл калырмы бездән тузгып, көлме? –
Гомер аты уза чаптырып.
Кызганудан мәхрүм үлем – дәрья
Һәркемне дә куя батырып…

Патшаны да алмаштыра вакыт, –
Тәхетеннән колак кактырып.
Гөнаһлысын хөкемгә дә тарта,
Соң булса да... үрә катырып.

Дөнья кендегедәй йөргәнне дә,
Иңдерәләр җиргә... яткырып.
Әүвәле Сүз булган... Шагыйрь генә
Гаделлекнең йөрәк хәтеренә
Үткәннәрдән кайтыр яктырып!

## Соңгы чик

Күкрәп-күкрәп җаным яшьнәсә дә,
Аңым белән бер үк вакытта
Ачылмыйча кала мең йозаклы
Билгесезлек, күпме шакып та.

Билгесезлек – тыю куелган чик.
Үтәм диеп,
Талпынсаң да ярсып, кешелек –
Уңыш көтмә... дөнья вулкан аткан
Тау шикелле төшәр ишелеп.

И кешелек, бар ачысын татып
Адәм кулы өзгән алманың,
Син һаман да юлсыз, бер чарасыз,
Кодрәтеннән курыкмый Алланың,
Үткәнеңнән сабак алмадың.

Уздың инде, уздың золым чиген.
Ялварыплар сорыйм, кире чиген!
Ни югалттың, эзлә артыңнан!
Син тилмерткән дөнья ук элдерткән
Җәя керешедәй тартылган.

Җәя сынар, кереш өзелерме,
Атылырмы угы, кем белгән?..
Сорауларым кылы, җавап көтеп,
Соңгы чигенәчә киерелгән.

## Үс, күтәрел, исән халык!

Йолкып атсам, чәнчи, диеп,
Үткәннең һәр гөлчәчәген,
Бөтенлектән мәхрүм калып,
Корыр кебек киләчәгем.

Үткәннәрнең орлыгында, –
Туфрагында, зурлыгында, –
Күрәчәгем, күкләр язган.
...Батмас өчен хурлык татып,
Аныклансын хаклык-ялган...

...Үзебезне акларгамы –
Үткән чорны гаепләдек?
Гарасатын кузгаттык та,
Аста калып гарипләндек.

«Бүгенгегә – бүгенге юл
Фикер-кояш кирәген дә,
Аңла», дигән кисәтүле
Мәсләк яши йөрәгемдә.

Карашыңда янсын чыраг!
Күтәрел син, исән халык,
Чордан чорга югарырак!
Син – баһадир, мәгърур Алып.
Торсын дөнья таңнар калып.

Раббым очкыны – җанымны
Кыса алмас мәкер-калып.
Дошман аска тартканда да,
Үткәннәрдән гыйбрәт алып,
Үс, күтәрел, исән халык!

## Узып барышлый

Ничек кабул итсәң, дөнья шундый…
Халәтеңә карап үзгәрә.
Шатлыгы да, инде сагышы да,
Алмаш-тилмәш керә күзләргә…

Мизгелләрне тоту сәләтенә
Ия гомер – алкын агышлы.
Аң иясе булып яшәвемә
Нинди генә җыр соң багышлыйм?!

Котсыз диеп мине әрләмәгез!
Мин – кәрләмен
Ак сакалы кырык карышлы…
…Үзем теләп түгел, фанилыкка
Кереп чыктым узып барышлый…

## Тормыш дәвам итә

…Бәйле язмышымның көен уйный
Тереклекнең көйгән пәрәвезе.
Кай арада, белмим, көзләр җиткән?
Һаваларда киткән кошлар эзе…

Чәчләрдә – чал… Картайдым ла бугай,
Кысынкылык тоеп һәр адымда.
Бәйсез киңлекләргә омтылсам да,
Ирешмәдем кебек морадыма…

Әмма табынмадым халкын изгән
Мордарлыкның горур колларына.
Хәрәм мөлкәт бәхет китерерме,
Ул-кызлары, оныкчыкларына?

…Сары яфрак булып аунап ята
Йөрәгемнең әллә соңгы сүзе.
Заманага, илгә кирәкмәгән
Үзем түгелменме – моң газизе?

Ник кайгырам? Тормыш дәвам итә…
Өрелмәгән әле сур мөгезе.
…Язларымда язган җырларымнан
Карый һаман яшел яшен күзе.

Ахирәткә күчкәннән соң үзе –
Кадерләнер әле шагыйрь сүзе...

Айдар
Хәлим

# ӘТИ-ӘНИ, МИҢА НИЧӘ ЙӨЗ ЯШЬ?..

БАЛАЧАК ХАТИРӘЛӘРЕННӘН

**Мин ничек комсомолга кердем**

Минем бу хакта «Бүре теше» дигән хикәям дә бар. Әмма хикәя хикәя инде ул, ни дисәң дә, әдәби әсәр: монда өстәмә тасвирлау – метафора, гипербола, ирония һәм башка шундый чаралар киң кулланыла. Аны халык кыска гына итеп «арттыру» яки «шомарту» дип атый.

Бер үк сюжетның берьюлы хикәядә һәм публицистикада, бу очракта аның бер төр булган истәлекләрдә файдаланылуы мөмкин, әгәр дә алар жанр үзенчәлекләренә хезмәт итеп, үз-үзләренә каршы килмәсәләр. Биредә нәкъ шундый очрак, мин бу истәлегемне «коры хәтер»емә таянып кына сурәтләячәкмен, Алла боерса.

1956 елның апрель азаклары иде. Комсомолга керүнең 22 апрель – Ленин туган көн, ә бәлки 1 Май – ул чакларда модада булган бәйрәм хөрмәтенә дә оештырылуы мөмкин дип уйлыйм. Числосы-көне ачыктан-ачык хәтердә калмаган. Иң мөһиме – җылы, нурлы кояшның нәкъ сәндерәгә менгән чагы иде. Урам буйлап ерганаклардан язгы якты сулар ага. Әле генә кар астыннан тәүдә караеп, аннан яшәреп чыккан җиргә җәяүлеләр тарафыннан ләп-леп китереп, шома сукмаклар салына. Безне, Олы Кәркәле җидееллык мәктәбенең 7«а» һәм 7«б» сыйныфлары укучыларын район үзәге Кыргыз-Миякәгә комсомолга керергә алып бардылар. Кемдер болай аерып әйтүемә аптырап та куяр. Әмма аптырарга кирәкми, моның үзенә күрә мәгънәсе бар: «А» сыйныфында Олы Кәркәле авылының үз балалары, «Б» сыйныфында исә аларның күршеләре Бәләкәй Кәркәле, Җидегән, Яшьләр, Камышлы авыллары балалары укый иде.

Безне комсомолга керергә алып барган, безнең өчен җаваплы берәр «вожатый» дигән кеше булдымы-юкмы, болары бөтенләй дә хәтердә калмаган.

Өстебездә, көннәр җылы торгач, җиңелчә – йә пинжәктән генә, йә җиңел бишмәттәнбез. Комсомол өшеми, өшетми һәм өшетергә бирми! Аякларыбызда – резин итек, күбебез кирза итектән. Без Җидегәннән Илфак дустым Сафиуллин белән җиңелдән булсын, шәп атлатсын дип, яңа чабаталар кигән идек. Миякәгә барып җиткәч, тузган чабатамны ташлармын

*Ахыры. Башы узган санда.*

да, кайтыр якка итек киярмен дип, мин аркамдагы токчайга кирза итегемне дә салган идем. Кыргыз-Миякәгә Олы Кәркәледән егерме биш чакрым чамасы. Унбиш яшьләре тулганнан соң гына комсомолга керергә хокукы булган үсмерләр бу шатлыктан әүвәлдә мәңге арымаслык булып җимертеп атласалар да, Бәләкәй Кәркәлене үтеп, Хлеборобка җитеп барганда, шактый арыдылар. Безнең якларга XX гасыр башында ерак Полтава тарафларыннан килеп урнашкан бу «кахул» авылы украинча «хлеба робить», ягъни «иген игүче» дигән сүздән алынган. Әле шактый иртә булганга һәм рус-кахул халкының иртәнге йокыны үлеп яратканлыкларын истә тотканда, әле хлеборобларның күпчелек «хаталары» (татарча «ихата») әле ут алмаган иде. Ә без, тырыштан да тырыш татар балалары, таң тишегеннән комсомолга керергә барабыз. Шулай булсын. Керсеннәр. Чыкмасыннар гына. Шулай яшәве кызыклырак, мәгънәлерәк була. Безнең алда ун чакрымлык калын урман ята. Урман авызыннан соң дәвам итәчәк юлыбыздан безне Йәрлекәү (Ерлыково) дигән катнаш рус-кахул авылы каршылаячак...

Аяктагы чабаталар шундук юешләнеп, мыеклар чыгара башлады.

Ачыктырганы да сиздерә. Без арыганлыгыбызны яшерергә тырышсак та, ул адымнарыбызның сүлпәнәюеннән күренеп тора иде.

– Әйдәгез, капкалап алыйк, малайлар!.. – диде кемдер. – Токчайдагы ипи катысы мине сагынып, «Сарман»ны җырлый!..

Ипи искә төшкәч, без бер ауган каен янында туктап, аны сырып алдык та, токчайлардан ипи кисәкләрен чыгарып, бер кырыен сындырып алып, аны мәңгелек сагыну белән кимерә дә башладык. Безнең Илфак белән икебезгә инәкиләребез бәрәңге дә пешереп салган иде. Өйдән килгән бәрәңгебез ерак яланда җылыкай иде. Капкалап алганнан соң, көч кереп киткәндәй булды.

Яңадан юлга кузгалып, урманны чыкканчы йөгерә-атлый барырга тырыштык. Ләкин мондый тизлек безне тиз арытты.

– Карашларыгызны җирдән күтәрмичә, адымнарыгызны санап атлагыз! Барганың сизелми! – дип кычкырды арттан Илмир Хәсәнов. – Бер... Ике... Өч...

Юл читенә салынган сукмак буйлап кыр казлары кебек бер генә рәт булып сузыла салып, без, иртәгәсенең яшь ялкынлы комсомоллары, кызышып һәм бер-беребезне кызыктырып, урманның караңгы төпкеленә килеп кердек. Минем алдан моңа кадәр тавышын чыгармый атлый биргән сыйныфташым Гөлбестан кинәт әрнегән тавышлар чыгарып пышылдады:

– Итек аякларымны кырды, Бар-рыйс! Сезнең шикелле чабата киясем калган... Туктыйк әле...

Моны ишетеп алган кайбер укучылар: «Чабаталарың исеңә төштеме? Купшылык шулай кыйммәткә төшә ул», – дип, үзара көлешеп тә алды.

Без туктап, кызлар биргән кулъяулыклар белән Гөлбестанның «аякларын төреп» кидердек. Ул сакланып, бераз сикереп атлый һәм күзгә чатанлаган булып күренә иде. Һәр ауган агач, һәр төпсә янында туктап, ниһаять, урман авызыннан чыкканда, без инде аруның соңгы чигенә җиткән идек. Йәрлекәү күренгәч, куанычыбыздан тагын бер тапкыр капкалап алдык. Адымнарыбыз шәбәйде дә, шундук сүнде дә. Без бер тын белән егерме-егерме биш чакрым җир үтә алган бала-чага бер-беребезне култыклап барыр хәлгә җитеп талчыккан идек.

Чабаталы тула оеклар тәмам чыланды. Баскан саен алардан балчыкта сытылып, юеш эз кала.

Миякәгә без, иртәнге тугыз сәгатьтән чыгып, төштән соңгы уналты сәгатьләр чамасында күтәрәмгә калган хәлдә барып җиттек. Телләребезне әйләндерерлек чамабыз да калмаган иде. Миякә буйлап «кем-кайда» дигән фатирларга таралыштык. Әле гомердә беренче тапкыр күргән район үзәгендә инәй өйрәтүе буенча мин «больнис каршындагы Гафирә түтки» йортын эзләп табарга, аңа күчтәнәчкә инәй биргән бер йомарлам майны тапшырырга һәм шунда кунып, иртәгесен комсомол райкомына барырга тиеш идем. Гафирә түтки йортын чагыштырмача җиңел эзләп таптым. Аның минем шикелле сугыш ятимнәре – кызы Венера, Рамил, Ринат дигән уллары бар икән. Фатирымда беренче тапкыр эшләпәле радионы күреп тә, тыңлап та хушлангач, бигрәк тә Гафирә түтки пешергән тәмле токмач ашы ашагач, күңелләр күтәрелеп китте. Тетелеп беткән чабатамны мал абзары артына ыргытып, аягыма кирза итегемне киеп, иртәнге тугызга комсомолның Миякә район комитетына киттем.

Менә без барыбыз да райкомга җыелдык. Ул урамнар почмагындагы бик җыйнак бинадагы бик җыйнак бүлмәләрдә урнашкан, аралык-коридорлары тарихыбызда бик зур батырлыклар кылган пионерлар һәм комсомолларның фотосурәтләре белән бизәлгән иде. Күбебез итек-читектә: булачак комсомолецларның байтагы кичәге чабатасын кимәгән. Шулай да чабаталылар да күзгә чалына. Шул чабаталардан саркып, идән сайгакларыннан буй-буй кар сулары аккан. Без, бер төркем булып укмашкан Кәркәле балалары, стеналардагы сурәтләрне йотлыгып карый-карый, үзебезне комсомолга кабул итә башлаганнарын да сизми калганбыз. Менә безнекеләрне фамилиясе ишегенә матур итеп «ВЛКСМның Миякә район комитетының беренче секретаре Галиәкбәров» дип язып куелган бүлмәгә берәм-берәм чакырырга тотындылар. Комсомолга кабул ителеп чыкканнарны әллә каян танып һәм табып була – йөзләре кояш кебек нурланып балкый. Безнең, әлегә кабул ителмәгәннәрнең, йөзләре генә борчулы сүрән: комсомолга эләгерменме, алырлармы? Гүя коридордагы халыкның яртысы куанычыннан шалтырый, яртысы куркуыннан калтырый иде. Адәм балаларының сабый чактан – комсомол каршында ук ике биләмә, ике лагерьга бүленә башлавы мине шул чакта ук сискәндергән иде. Әмма мин шундук айныдым. Дөресрәге, айныттылар. Менә асаба кабинетка мине чакырдылар. Кердем. Өстәл башына утырган Галиәкбәров дигәннәре «гластук»тан, туры борынлы, якты, ачык йөзле кеше икән. Мин аңа эчемнән «Матур абый» дип исем куштым. Өч-дүрт өстәлне бергә терәтеп утырган сигез-тугыз кеше, соңыннан беленүенчә, бюро дип атала икән.

Матур абый мине күзеннән кичерде, аннан алдында яткан кәгазьләрдә актарынып, исем-фамилиямне атады. Тагын да миңа карады.

– Син Борисмыни?

– Әйе.

– Рус түгелдер бит?

– Юк. Атам шулай кушкан.

– Яхшы. Атаң исән-саумы соң?

– Юк. Сугыштан кайтмады.

– Һм... – диде ул. – Кызганыч...

Һәм бер генә секундка уйланып калды. Мин аңардан устав, демократик централизм буенча иң авыр сорауларны көттем. Әмма ул мине тагын бер тапкыр күздән кичерде дә көтмәгәндә:

– Математикадан ничәлегә өлгерәсең? – дип сорады.

– Өчлегә. Чиреккә дүртле дә чыккалый.

– Дүртле һәйбәт. Шулай да синең кебек булган егет бишлегә генә укып барырга тиеш. Туган көнең-елың кайчан?

– 1942 елның беренче гыйнвары.

– Әле бүген нинди ел? Ничәнче елда яшәп ятабыз?

– Бер мең тугыз йөз илле алтынчы елда.

– Дөрес. Илле алтыдан кырык икене алгач, ничә була? Йәле, җәһәт кенә башыңны эшләтеп, математикаңдагы өлгерешеңне күрсәт.

Мин күз алдыма китергән вакланмада алтыдан икене алгач дүрт, биштән дүртне алгач, бер, димәк, ундүрт яшь була дип шартлатып әйтеп салдым.

– Дөрес, ундүрт яшь була. Ә устав нәрсә ди? Син уставны өйрәнмәдеңмени?

– Өйрәндем...

– Ул нәрсә ди? – Матур абый уставта актарынды да тиешле урыныннан ярып салды:

– Устав комсомолга унбиш яше тулган яшүсмерләр генә алына, ди, энекәш!.. Син моны күрмәдең-белмәдеңмени? Сине, яше җитмәгән үсмерне, комсомолга кертү өчен җәяүләп егерме биш чакрым атлаткан абый-апаларың сиңа бу хакта әйтмәдемени?

Эсселе-суыклы булып китте. Чынлап та!..

– Юк. Әйтмәде... – дидем, куркып кына.

– Үзең дә күрмәдең-укымадыңмыни?

– Укыган идем дә... Комсомолга бик нык керәсем килгән иде... Сыйныфташларым белән бергә... Берьюлы...

– Монысы һәйбәт, әлбәттә. Тик без уставны боза алмыйбыз. Әле сиңа комсомолга керер өчен тагын да сигез аең җитми, энекәем...

Матур абый күз алдымда бозыла, ямьсезләнә башлады.

Мин чак-чак елап җибәрмәдем. Матур абый бу минутта мине кызганып та куйды бугай.

– Әйдәгез, бюро әгъзалары белән киңәшик, болай булгач... Бәлки алар башка берәр чара тәкъдим итәрләр? – дип, ул бүлмәдәшләренә мөрәҗәгать итте. – Йә, әйтегез, без бу очракта нәрсә эшли алабыз? Әмма мин комсомол уставын бозуга юл куймаячакмын...

– Тавышка куярга кирәк!.. – диде бюро әгъзаларыннан бер кыз. – Алыргамы-юкмы? Кем дә кем алырга ди, шулар кулларын күтәрә...

– Туктагыз!.. Ленин комсомолы рәтләре алыргамы-юкмы дип сатулашып утыра торган урын түгел! – дип, кискен бүлдерде аны Беренче. – Устав һәркем өчен мотлак үтәлергә тиешле канун!.. Закон!.. Язгы шыекта яше җитмәгән укучыны комсомолга кертәбез дип, егерме бишәр чакрым арлы-бирле йөртергә мәктәп дирекциясе... комсомол оешмасы, пионервожатыйлары нәрсә караган? Бу инде башка чакта тикшерелергә һәм җавабын алырга тиешле гамәл, шулай бит, җәмәгать? Юк, иптәш Хәлимов, без сине әле генә комсомолга ала алмыйбыз... Иртәрәк!..

Бу сүзләреннән соң минем каршымдагы Галиәкбәров атлы Матур абый бөтенләй дә ямьсезләнде.

– Комсомолга керер өчен киләсе 1957 елның гыйнвар башыннан килерсең, энем, яме? – дип дәвам итте ул. – Уставны өйрән! Әле вакытың җитәрлек!..

Бу сүзләрне ишеткәч, якты көнем тәмам караңгыланды. Яшисем килми башлады. Ундүрт яшемдә иптәшләрем алдында мондый кимсетелүне кичерү һич кенә дә җиңел түгел иде.

Әмма теге кыз һаман да бирешергә уйламый иде:

– Әйдәгез инде, иптәшләр, тавышка куйыйк та алыйк! Бер кешене комсомолга ярты елга иртә алудан җир җимерелмәс, беркем дә картаймас, шулай бит? Фронтовик улы, ятим... Егерме биш чакрым килгән. Тагын да егерме биш чакрым кайтасы бар. Әйдәгез инде, алыйк!..

Ул елап җибәрде.

– Тынычланыгыз, Светлана... – диде Галиәкбәров, көтмәгәндә килеп чыккан хәл өчен уңайсызланып. – Устав бозган өчен ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршында җавап тотасым килми... Анда сезне дә бастырасым килми. Нәрсә ул сигез ай? Хәзер килеп җитә бит ул, Хәлимов! Кабаттан килерсез, алырбыз! Әлегә хуш!..– Беренче секретарь ишек каршында утырган бюро әгъзасына эндәште:

– Чираттагы кандидатны кертегез!..

Миякәгә барган вакыйгадан башка бернәрсәне дә хәтерләмим. Чачакланып тузган чабатамны абзар артына ыргытып калдыруым гына онытылмас.

Ничек итеп кайтканыбызны да хәтерләмим. Әмма минем өчен җир җимерелгән иде. Илфак дустым раславы буенча кайтып җиткәнче елаганмын. Яшем җитмәгән килеш мине шундый ерак юлга алып чыккан кешеләрнең никадәр мәгънәсез һәм җавапсыз булуларын әле булса башыма сыйдыра алмыйм...

Менә шул чордан алтмыш җиде ел үтеп тә киткән. Бу очракны бәлки искә төшереп тә торырга кирәк булмагандыр. Әмма кирәк шул. Ул гаделлек хәнҗәре булып, минем барлык биографиям аша үтә. Тормышымның авыр борылышларында исемә төшеп айныта да, уйландыра да иде мине бу сирәкләрдән-сирәк вакыйга. Нәрсә, өлкәннәр мине бу хакта кисәтеп, мин үзем комсомолга иртәләп керергә барганмынмы, әллә ташып барган көчемне кая куярга белмичә, шулай эшләгәнменме, хәзер әйтүе кыен. Хәер, мәсьәлә монда да түгел. Иң мөһиме – булган хәл бу. Нишлисең, сабыйлыктан яратылган язмыш!..

## Безнең авыл тегермәне

Белмим, ни сәбәпледер, миндә тегермәннәргә карата аерым мәхәббәт саклана. Тегермән – иманлы, иманга инандыра торган корылма. Ул иген орлыгын тартып, он ясый, кешене тукландыра. Мин үземне белә башлаганнан алып, каядыр тегермәнгә иген тарттырырга бару турында хыяллана идем. Тарттырырга игене булмагангамы? Миңа дүрт яшь булды микән, юк микән, авылдашларыбыз җәй көне, сабыйларына кадәр кузгалып,

Өязенең Качаган тугае башланган тәңгәлендә су тегермәне төзеде. Хәзер уйлыйм да, тагын бер тапкыр, тагын мең тапкыр хәйран калам: тегермәннең буасын һәм куласаларын, алгычларын һәм башка салгычларын диңгез өсте тигезлеге белән чагыштырып, кирәк сәгатьтә буаның авызын ачып, кирәк вакытта ябып куяр, берьюлы яки тәнәфес белән гади авылымның гади суының ихтыяры ярдәмендә биш килодан 500 килога кадәр (саннар шартлы) иген тарттырып алыр өчен минем авылдаш «мажикларым» нинди фәннәрдән нинди югары белемнәрне үзләштерергә тиеш булдылар икән?! Фин сугышын да кертеп, биш ел дәвам иткән Бөек Ватан сугышыннан соң, бер тиенсез, малсыз-киемсез һәм иганәсез килеш шушындый олы төзелешне башкарып чыгу Кәркәлетамак халкы һәм төбәктәге башка халыклар өчен Мисырның Хеопс пирамидасын күтәрүенә тиң булгандыр. Сугыштан соң һәр авыл диярлек үзенә тегермән төзеде. Инешең-чишмәң генә булсын – тегермән, күр дә тор, булачак! Кызык бит: халык сугыштан соң үзе, тыштан караганда, ифрат хәлсез – әмма үзе эчтән хәлле: тегермән төзи. Каян килгән бу көч?! Безнең Өязе елгасы, дөресен әйткәндә, Өязе инеше тегермәннәр йолдызлыгы – анда уртача һәр биш чакрым саен бер су тегермәне иде. Тегермән аралары баланлык-шомыртлык, таллык, өянкелек һәм болынлык белән тулган. Мәсәлән, турыдан ун чакрымлап тарткан арада елга буйлап, сигез тегермән: чукынмаган чуваш авылы Дубровка өстендәге чишмәдә, аннан бер чакрымга астарак Җидегән авылында, тагын да өч чакрымнан – безнең Кәркәлетамакта, тагын да биш чакрымнан Качаганда, ике чакрымнан – Ишледә, җиде чакрымнан – Баязитта һәм унбиш чакрымнан Җилдәрдә ике тегермән иде...

Һәм шушы күренеш 70-80 чакрым буена – Өязе Димгә кушылганчыга кадәр дәвам итә иде.

Су тегермәннәре һәм аларның буалары халык хуҗалыгына бетмәс-төкәнмәс өлеш кертә. Милләтнең саулыгын саклауда алар искиткеч зур роль уйный. Балык үрчетү, азык нигезен ишәйтүдә бәяләп бетермәслек ярдәм күрсәтә. Кичләрен тегермән буасының ярына утырып, рәткә тезелеп үткән балыклар парадын карау, андагы сафлык белән кинәнү үзе генә дә ни тора иде!

Безнең авылның тегермән буасы 1946 елның җәендә буылгандыр дип фаразлыйм. Төшемдә кебек кенә инәмнең тегермән буасын бууда катнашкан бөтен халык өмәсендә төшке аш пешергәнен хәтерлим. Әнә ул, тирләп-пешеп, халыкка аш тарата. Без вак таллыкта тапалган табырда аш ашыйбыз. Күз алдында авылымның аксакаллары. Безнең авылда берүк исемле кешеләр еш очраганлыктан, аларны кушаматлары белән атап йөртәләр. Исемә төшкән очракта миңа да шулай насыйп иткән, димәк. Менә ул Минебай, Ярыяхмәт, Шәрифҗан, Кое Төбе Минәхмәт, Шытыр Фәрвәҗ, Әндри Фәрвәҗ, Йомыйк Фәрвәҗ бабайлар... Менә каршы рәттән Күркә Зәйнулла, Төрек Галимулла, Төрек Халыйкъ, Гайнулла, Бәдыйк бабайлар... Менә нәселләре белән Саескан Габдулла, Саескан Габдрахман һәм Саескан Шиһабетдин бабайлар... Фәтхулла, Лотфулла, Гайнулла абзыйлар...

Менә инде буылып беткән буа өстендә яңгыраган азан. Тегермәннең куласаларын да хәрәкәткә китереп, эш башлар алдыннан нәселдәшем Минебай бабай Хәлимов әйтә ул азанны. Азан авазлары тирә-як сазлыктагы

күрәннәр, су өсләрендә җәелеп тарала. Соңыннан, тегермән эшли башлавы уңаеннан яшьләр кәнсирт куя. Әмма тегермәнгә озак кына юньле тегермәнче табылмый тора. Мин халык чак сыйган, һавасында көнбагыш чирткән тавышлар яңгырап, тәмәке исе аңкып торган шартларда үземнең «Безнең авыл тегермәне» дигән шигыремне укып ишеттерәм. Аңа халык котырып кул чаба. Ул заманында Миякә район газетасында басылып та чыккан.

Авылыбызда тегермән бар,
Табалмыйлар бер хуҗа.
Шул хуҗаны табалмыйча
Ярты кыш инде уза.
Рәхимҗан чыгып, Хәлим керде
Тегермәнгә хуҗа булып.
Хәлиме дә кыйратмады –
Озак тормады кереп.
Бүген Гани хуҗа булса,
Иртәгә Фәһим була.
Каһәр суксын! Алышынган –
Бүре Хәйдәр килгән куна...
Эченә кер... Хәйран булма:
Сызгыра җил-бураннар.
Түбә тишек, яңгыр үтә –
Ашлык чери идәндә...
...Бәлки шушы шигъри юлдан
Персидәтел уяныр?
Аның башын җитешсезлек
Аз булса да уйлатыр?..

Дөрес чамалаганмын: персидәтел чынлап та уянган һәм чынлап та уйланган булып чыкты. Тегермәнгә хуҗа да табылган. Фәрвәҗ (Шытыр) абзый эшләгәндә, тегермәнгә баш була белде. Халык чит авыллардан килеп тә тегермән тарттырды. Җәйге чилләләрдә буасында су кереп савыкты, ял итте, балыгын тотып та кинәнде. Өлкән абзыйларга ияреп, тегермәнгә мин үзем дә бара идем. Бер тапкыр биш кило чамасындагы үзем җыйган башак борчагын алып барган идем. Әмма Шытыр Фәрвәҗ абзый: «Бу борчак тегермәннең ташына да йокмый», – дип, табышымны тарттырмады. Мин аңа үпкәләмәдем, алып килгән игенемнең аз икәнлеген шунда гына аңладым.

Халык бер ун ел чамасы тегермәнгә тиенеп яшәде. Әмма безнең юлбашчылар халыкка тыныч кына хезмәт күрсәтүне «башларына сыйдыра» алмый бит, кашына башлыйлар. Шундый кашыну чире безгә дә килде. Ул чир «мелиорация» дигән спекулянтлар уены астында таллык-тугайларны корыту сәясәте иде. Беренче итеп, тегермән ташларыннан, аннан тегермәннәрнең буаларыннан үч алып, буаларны ерып җибәрделәр. Тугайлар-таллыклар кипте-корыды, кош-кортлар утызынчы елларда Ташкентларга качкан бабаларыбыз шикелле туган илдән качып китте. Бу үткән гасырның җитмешенче еллар башы иде. Минем ул заманда халык фикерен уяткан, һич арттырмыйча әйткәндә, тетрәткән мәкаләм кемнеңдер хәтерендәдер әле. Ул чакта мин үзем «Совет Башкортостаны» газетасында эшләсәм дә, башкорт газетасы бастырырга курыккач, аны «Родники моего детства» дигән исем астында русчага тәрҗемә итеп, «Советская Башкирия» газетасында чыгарган идем. Мәкаләне газетага Башкортстан матбугатының

талантлы журналисты Мадриль Гафуров әзерләгән иде. Бу вакыйгаларга илле елдан артык вакыт үтеп киткәч, мин аңа шушы җаваплы адымны кирәкле җирдә, кирәкле сәгатьтә ясаганы өчен рәхмәтләр укыйм.

Мадриль дустым, исән генә була күр!

Тегермәннәрне, тегермән буаларын саклау өчен син күпме тырышлык салган идең! Синең истәлек, синең хәтер Өязе һәм Дим дулкыннарында тирбәлә! Мәңге шулай булсын!

## Уналты юллык, кырык еллык бер шигырь «аламасы...»

Миякә урта мәктәбенең ир балалар интернатында яшәп, сигезенчедә укыганда, Ишле авылы укучыларының һәр ялда, авылларына кайтып килгәч, берсе икенчесе белән ярышып, авыл кибетенең эшенә зарланулары мине шактый җиләтте. Көтмәгәндә генә бер шигырь аламасы язылды да куйды. Мин андый җитәр-җитмәс рифмада эрегән шигырь кисәкләрен «аламалар» дип атый идем. Белмәгән-күрмәгән, очраклы рәвештә кибеттә эшләп азапланган ниндидер Нажидә дигән апаны куркыныч тәнкыйть утына тоткан «шигъри аламам»ны Ишле егетләренә укыдым. Алар бик ошаттылар. Менә ул:

Йомышымны үтимен дип,
Киттем кибет ягына.
Тагын бикле. Ача бит ул,
Барып чакырсаң гына.
Нишләмәк кирәк, тоттым да,
Туры киттем өенә.
Нажидә апаның эше күп:
«Ача алмыйм, – ди, – тиз генә».
Яхшы әйберне шылдыра
Дусларга, танышларга.
Башта алар белән расчёт –
Калганы халыкларга.
Җитәкчеләр ни карыйлар –
Начар эшләр Ишледә.
Йомышларын үти алмый
Җәфалана кешеләр.

Безнең өчен эш шуның белән беткән иде дә бит. Әмма ул бетмәгән булып чыкты. Ишле укучылары, миннән рөхсәт сорап тормыйча, «әсәрне» күчереп алганнар да район газетасы редакциясенә илтеп биргәннәр һәм редакция аны «үзләренең шагыйрьләрен» куандырырга ашыгып, күрәсең, бастырып та чыгарган. Йә, хуш. Партия һәм аның матбугатының ифрат та көчле заманы. Бер-ике атна тыныч кына үтә. Көннәрдән бер көнне сыйныфташым, Ишле егете Ильяс авылыннан елап кызарган күзләрен уып килеп керә. Баксаң, аның әтисен ул чакта миллионер данын тоткан «Динамо» колхозының идарәсенә чакыртып кыздырганнар икән. Шигырьдә «дан җырланган» кибетче Нажидә апаның ире, җитмәсә, бу атаклы колхозның персидәтеле дә икән. Һәм бәйләнәләр: «Син генә язгансың. Бездә синнән башка аны язарлык кеше юк». Гаепләрлек урыннары да бар: шигырьнең авторлык култамгасы Б.Хәлимов. Алар уйлавынча, моны язучы – авылдашлары

Бәдыйк Хәлимов булырга тиеш. Җыр-бәет дигән нәрсәгә һәвәслеге дә бар. Улы Ильяс, Ильяс Бәдыйкович, шигырьнең минеке, аның белән бергә укыган Кәркәлетамак егете Борис Хәлимовныкы икәнлекне аңлатып карый – әмма, юк, идарә ышанмый. Бәдыйк тек Бәдыйк. Бу вакыйга агымдагы башка вакыйгалар белән күмелеп калды, бөтенләй онытылды кебек.

Әллә тугызынчыда, әллә унынчыда укыганда, минем бу вакыйганы инәмә сөйләгәнем хәтердә.

– И-и-и балам! – диде ул миңа. – Нажидә апаң үзебезнең Нургали тыкрыгындагы Суфиян бабаң белән Мәдинә әбиеңнең Ишлегә кияүгә биргән олы кызы, ягъни дустың Вәриснең бертуган апасы бит. Авылдашың лабаса! Аның «Динамо» колхозының персидәтеле булган кияве – Вәкил Хәбиров сиңа пәке бирергә тиешле җизнәң!.. Бар, Ишлегә йөгер, чаптырып барып кер дә, исәнме түткием, исәнме җизнәм, диген!.. Бирегез миңа пәке, бирегез миңа кулъяулык, диген!..

Әмма пәке дә сорамаганмын, кулъяулык та. Тормышның үз агышы бар шул. Һич кенә дә акланмыйм. Мин, яшьлегем ашыктыру сәбәпле, Ишле авылына туктап, «Динамо» колхозының шул чактагы җитәкчесе, бар булмышы белән яхшы күңелле кеше, очраклы рәвештә генә Бәдыйк абзыйны шик астына алып рәнҗетергә мәҗбүр булган Вәкил абзый Хәбиров һәм Бәдыйк абзый Хәлимовның үзләре белән танышып чыгарга форсат тапмаганмын. Тора-бара дөнья мәшәкатьләре белән күмелеп тә калган. Дөрес, берме-икеме тапкыр безгә Вәкил һәм Нажидә Хәбировлар белән Кәркәлетамак авылындагы мәҗлесләрдә катнашырга туры килде. Нажидә апаның кибетне «оныткалаган саен» ябык тотуында үзен гаепләве, йә булмаса гаепләвем белән килешүе нәтиҗәсе дип аңлапмы, без урыннарыбыздан торып, якыннан танышып күрешмәдек һәм сүзсез генә аерылыштык. Мин калмык далаларына, аннан Совет Армиясенә, Ильяс исә Стәрлетамак тарафларына китеп югалган булып чыктык. Шулай да аларны онытмадым. 1997 елда, теге вакыйгаларга кырык ел тулгач, мин Ильясны күрү өчен махсус рәвештә Уфадан Стәрлетамакка юл тоттым. Исән булса, Бәдыйк абзыйның да кулын кысармын, дип хыялландым. Ильясны барып таптым. Без аның белән зур йортта үткәннәрне искә төшереп, икәү генә кундык. Серләшеп, сүзләр бетмәде. Ни кызганыч, Бәдыйк абзый бакыйлыкка күчкән иде... Ильяс сөйләвенчә, авторы үзе булмаса да, ул бу «Начар эшләр Ишледә» шигырен, язмышы кушкач, кызык итеп, яттан укый торган булган. Миңа карата бернинди дә үпкә сакламаган. Икебез дә Б.Хәлимов булып калган идек...

Без Ильяс Хәлимов белән икәүләп, барлык якыннарыбыз рухына үзебез белгән догаларны кылдык. Илаһи амин!

Бу мәкаләне мин татар дөньясында шигырьнең, хәтта аның оеп бетмәгән «аламасы»ның да, искиткеч көчкә ия булганлыгын раслау өчен генә яздым. Тетрәндерә бит!..

## Утынга урман кисәбез

Урман дигәндә, миңа рәхәт булып, тыным киңәеп китә. Ул мине ашатты-эчертте. Киендерде. Урман миңа ватаным, «лесниклар» тарафыннан бүленеп бирелә торган «автономиям» булды. Урман витаминнары мине,

«пашпорт сорамыйча», иманлы, ныклы кеше итеп үстерде. Урманның һәр кәүсәсе минем өчен скрипка, урман исә түбәләре белән барысы берьюлы чайкалып гүләгәндә, симфоник оркестр булып хезмәт итә иде. Урман катгый дөрес тәрбия бирде. Мин урман шаулавын тыныч кына тыңлый алмыйм. Җылыйм. Елыйм түгел, илаһи амин, җылыйм. Аның эссесендә суынам, суыгында җылынам, кайнарланам. Аны тере кеше кебек сагынам, юксынам. Безнең якта битләүләрдә яткан урманнарны «кул» диләр. Кул. Җылы уч төбе. Кая гына барсам да мине якташ, авылдаш урманнарым – Мендәрле Кул, Озын Кул, Кыска Кул, Биптәш Кулы, Әнәч Кулы, Сәнкә Кулы, Урман арты һәм башка бихисап «кулларым» озатып йөри. Бу исемнәр барысы да милләт байлыгы бит.

Инәм дигәндә, аның кояшта янган борчулы йөзе, сул кулына чалгы, уң кулына агач төпләреннән сыдырып алынган бер учма үлән тотып, Кралов урманнары эченнән кышлыкка печән берәмтекләп йөргән рәвеше – буйсыны хасил була. Кралов – падишаһ өчен зур хезмәтләр күрсәткән һәм шул хезмәтләре өчен безнең басып алынган урманнардан мең гектарлы дача белән бүләкләнгән падишаһ полковнигы Королёвтан халык атаган атама ул. Мең гектардагы урман-печәнлек һәм кышкылыкка сыер асрап булмасмы дип, эш арасында урманчылардан кача-поса агач төпләреннән җыештырылган печән учмасы тотып килгән тол инәй-мәрхүмә... Кышкылыкка печән хәстәрләү авыл кешесе, аеруча, ирсез хатын өчен искиткеч авыр хезмәт иде. Урман Аллаһ кодрәте белән шәхсән аныкы, димәк Аллаһныкы, җәмәгатьнеке, әмма гамәлдә аныкы түгел, Королёвныкы иде. Безнең ел фасылларыннан чыгып караганда, октябрь-апрель айларында, ягъни сигез ай буена мал ашату өчен кимендә җиде-сигез фурман (фургоннан алынган) печән кирәк. Кәҗәң дә бар икән, тагын бер фурман печәнне өстә. Сарыгың да бар икән, тагын өстә. Сыерга дигән һәрбер йөкне дүртәр центнердан исәпләгәндә, бу 28-30 центнер, ягъни якынча өч тоннага барып баса. Атың юк, печәнлегең юк, ирең дә юк. Берсеннән-берсе бәләкәй балаларың бар. Кая барырга? Кемгә барып сөялергә? Колхозчыга печәнлек бирелми. Ул агач арасында сакланып калган калдык-постык, уңышы җыеп алынган басудагы салам камылын чабып, кайда мөмкин, урак белән урып, урганны үз җилкәсендә ташып (печәнгә көн биргән көндә генә), җир тырнап өстерәп, малын асрарга тырыша. Урманнарда әүвәлдә «кулына үлән учмасы тоткан Минсорурның башы», аннан гына гәүдәсе күренер иде. Мин үземне белгәннән алып авылдан чыгып киткәнче, димәк, 19-20 яшькә кадәр егерме ел – инәмне югалтканчыга кадәр – гомерем инәм белән бергә урманнарда агачлар арасында калган үлән сабакларын эзләп үтте. Шуңа күрә мин урта мәктәпне тәмамлагач, ике дә уйламыйча, авылга бөтенләйгә дип кайткан идем. Урманнарга җырлап керә һәм җырлап чыга торган идем. Һәр каен, һәр усак туганым, аш-суга чакырыша торган якын кардәшем иде.

Югарыда әйткәнемчә, урман миңа һәрчак мич башы кебек җылы иде. Көзләрен, октябрь айларында, без гаилә белән дәүләт урманнарында кышкылыкка утынга дип урман кисә идек. Дөресен әйткәндә, октябрь аен уңайлы, бушрак вакыт санап, урманны – «дәүләтнең күзе алдында!» – кистерәләр иде. Дәүләт аны фәнни тел белән «сирәкләтү», ягъни «прочистка» дип атый. «Утынга урман кисү» дию белән минем арка

үзәгемнән салкын яңгыр суы агып төшә. Бр-р-р! Әмма мин өшемим. Без өшемибез. Янәшәдә генә инәбез. Аның аркасыннан тегермән ташындагы сыман җылы бу күтәрелә, йөзеннән учма-учма яктылык коела. Ул тамак ялгар өчен алган икмәкне тычканнардан һәм яңгырдан яшереп, чүпрәккә, аннан гәзиткә төрә (ул заманда целлофан дигән нәрсә төшкә дә керми!) һәм корырак урын табып, яфраклар астына күмеп куя. Безнең өстебездә сәләмә пинжәк йә бишмәт аламасы, ул кайчакта яңгырдан лычма су була. Әйе, лесхоз октябрь аенда халыктан кышкылыкка дип, урманын сирәклəттерә. Шул эшкә барыр алдыннан без Ингель абыем белән ике йомырка тотып, Нургали бабабызга барабыз, йомыркаларны аның Гөлҗиһан дигән карчыгына бирәбез һәм «шул хакка» Нургали картның рөхсәте белән аның таш чарында балталарны үткерлибез. Мин комганнан су салам, чарны әйләндерәм, имеш, туң тимерне үткерлибез, әмма балтаның йөзе килми, ул бармакка да, тырнакка да капмый, киресенчә, үтмәс ташта йөзе тагын да бозыла, чарлаган саен болай да тупас балта тагын да тупаслана гына төшә. Урман кисүнең нечкәлекләре бар – беләк юанлыгына кадәр агач кәүсәсе өеңне җылытырга дигән чыбык-чабык өеменә, беләктән юанраклары – «деловой», имеш, эшкә яраклы төзелеш агачы өеменә китәргә тиеш. Әгәр бу шартларны үтәмәсәң, лесник тарафыннан кышка утынсыз каласың. Әйе, иртәдән бирле сибәләп, салкын спас яңгыры ява, аяктагы чыланып өзгәләнгән чабаталар лач-лоч килеп ыңгыраша; утырып ял итәр шартлар кая, ди; бу салкын яңгырдан тизрәк котыласы килә; туң балтаңны күтәреп, кәүсәнең төбе-тамырына тондырасың, туң балта агачка капмый; дерелдәп калтыранган агач ябалдашларыннан өскә салкын кара сулар түгелә... Ул арка үзәге буйлап юл сабып, ят җирләр – койрык сөякләренә кадәр агып төшә...

– Тамак ялгап алыйк, балалар...

Балалар бу мизгелне күпме көткәннәр иде!

Гүя көн ачылып китә, яңгыр туктый, юештән күшеккән өс-башыбыздан пар күтәрелә, каяндыр чыланып өлгермәгән көзге яфраклар астыннан кояш кебек яктырып, инәйнең һәрчак мәшәкатьле йөзе ялтлап килеп чыга, аның кулында тагын да яктырак булып икенче кояш – түтәрәм булып Галәйһиссәлам ИПИ ХӘЗРӘТЛӘРЕ калка һәм шешәдәге сөтле чәй пәйда була...

Сөтле чәй. Татарның сөтле чәе. Һәм якты йөзе, якты чырае. Татар сөтле чәй эчкәне өчен талантлы халык ул. Бу безнең инәй һәм аның ахирәтләре турында әйтелгән булырга тиеш. Берәр кешегә аш табынына чакырсалар, инәм мөкиббән китеп халыкны сыйлаучы, мәҗлесләрдә көрәгәче була торган иде. Еш кына аның мәҗлестән кайткач: «Кеше карап, кеше ашатып, үзем ач калам», – дип, өйдә тамак туйдырган чакларын хәтерлим. Табынга кышын каз, җәен каклаган каз кебек сирәк ризык чыкса, аны телемләп, тигез, беркемгә дә артык, беркемгә дә ким итмичә бүлгәләп бирүче кеше – безнең инәкиебез булыр. Әгәр табынга чит-ят тарафларның өрек, йөзем, бохар чикләвеге кебек күчтәнәчләре чыкса, алар берәмтекләп гадел бүленер, кечкенә ит калҗасы белән бергә «өлеш» дип исемләнеп, кулъяулыгы читенә төрелеп, өйгә – безгә, балаларына кайтыр. И-и-х, бу авылдаш ятимә хатыннарның күз нурларын түгеп көткән сабыйларына мәҗлесләрдән алып кайткан «өлешләренең» шигърияте!.. Борын кычытмаслык куанычы!

## Аягым «чыкты»

Бишенчегә кергән кышта, малайлар белән «котырганда», аягым чыкты. Әдәби тел белән әйткәндә, «каймыкты» дию урынлырак булыр иде кебек. Шул шаян вә тиктормас наян булуым аркасында инде. «Чыкты» сүзен ничек кенә кабатламаска тырышсам да, биредә кабатламыйча булмый икән шул: монда шулай килеп «чыкты».

Без, Олы Кәркәлегә җәяү йөреп укучы Бәләкәй Кәркәле балалары, таң белән күзебезне тырнап ачкач та, тәрәзәгә томырыла идек: һава шартлары ниндирәк? Безнең шатлыкка, безнең куанычка, безнең зарлы өметкә күз ачкысыз буран кузгалмаганмы? Бит очларын чеметеп алган егерме-утыз градуслы суык түгелме? Була гына күрсен иде!.. Шулай булса, без тауларны уятып, Олы Кәркәлегә «менеп» маташмыйбыз, юрганы булганнар кире җылы юрганнары, булмаганнар ябынып яткан чүпрәк палас, чикмән асларына кереп чумабыз. Ул көнне яшь, яңа туган декабрьнең нәкъ шундый чатнама суык көне иде. Без, Олы Кәркәле укучылары, бүген мәктәпкә бармаска дигән хәбәр алып, аңа чиксез куанып, өйләребезгә кире кайтып таралыштык. Ихатабыз каршында үзебезнең авыл мәктәбенә баручы, былтыр минем белән укып, дүртенчедән күчми калган, һаман дүртенчедә утырган «Олыдөрес»ләр (күчми калучыларны шулай атыйлар иде) – кечәге сыйныфташларыма тап булдым.

– Әйдәгез, көрәшәбез! – дидем мин, укырга бармау шатлыгын кая куярга белмичә. – Кем кемне?

Һәм үзем үк аларның берсен биленнән алып көрәштерергә тотындым. Малайлар арасында мин иң көчлеләрдән саналсам да, аларның дүртесенә берүзем каршы торалмый идем. Алар күмәкләшеп, миңа ташландылар. Без урамдагы чана юлын һәм көртне бер итеп өерелешә, әүмәкләшә башладык. Көчләр тигез түгел иде. Мин аякларым тездән бөкләнгән уңайсыз хәлдә аста торып калдым. Аяк буыннарым белән шыртлап нәрсәдер булганын ап-ачык тойдым, ләкин җиңелгәнемне сиздермәс өчен малайлардан ярдәм сорап «вакланмадым». Кичәге сыйныфташларым, күрәсең, «аларны ташлап, олы авылга укырга йөргән малайдан без көчлерәк» дигән кебегрәк фикердә булып, җиңүче адымнары белән мине ташлап китеп тә бардылар. Таң иртәсендә урамда кешеләр дә күренми. Инәм дә чыкмый. Ул минем хәлемне белми. Аның уенча, таң белән җылы аш ашатып, юлга чыгарган улы «Олы Кәркәлегә укырга киткән». Мин салкын кар өстендә ярты сәгать чамасы ятканмындыр. Әнә, ниһаять, каршы яктан Гобәй бабайның карчыгы Фәхерниса әбием безгә кереп килә. Аңа аяксыз калуымны аңлатам һәм инәм мине урамга чыгып алсын дип әйтүен үтенәм. Менә Фәхерниса әбием кире чыгып та килә. «Инәңә әйттем, ди, – ул ачуланды. Бер мәгънәсезгә малай-шалайлар белән котырмас. Үз аягы белән мәктәпкә китте, үз аягы белән кайтсын. Бер нәрсә дә булмагандыр әле, диде», – ди...

Әлбәттә, инәм минем нинди хәлдә калуымны күз алдына да китерми. Вакыт ифрат та сузылып уза. Авыл бәләкәй, урамнан килүчеләр юк, дидем. Тагын да егермеләп минут үткәндер. Менә, ниһаять, инәм килеп чыга һәм мине аягымны кузгата алмаган хәлдә күреп хәйран кала. Мине күршеләрем ярдәмендә өебезгә күтәреп кертәләр.

Аякларымның чыккан буыннарын урыннарына утырта алмыйча бер-ике ай ятканмындыр, дип уйлыйм. Авылда табиб та, хастаханә дә, хәтта фельдшер да юк. Хәер, Олы Кәркәледә Зәйнәп дигән фельдшер апа (сугышта аягын югалткан бу апаны халыкта «Чатан Зәйнәп» дип йөртәләр) бар иде. Аны олы авылдан алып төштеләр. Вишневский маеннан башка ул бер нәрсә белән дә ярдәм итә алмады. Сул аягым май яза торган гөбе кебек күпереп шеште. Барлык дәва әбиләрдән генә иде. Авылның мине дәваламаган бер генә әбисе дә калмады. Барлык дару аякны төрле-төрле май-мазь белән уу, ышку иде. Сыер мае, каз мае... Ышкыган чакта аягым кагыла да алмас дәрәҗәдә авырта-әрни иде.

Инәм чыккан буыннарымны утырту өчен мине «Биккол мулласы»на алып барырга булды. Җир йөзендә шундый исемле халык табибы бар икән. Башкорт бабае. Мәңгелек рәхмәт төшкере. Ул һәр якшәмбе көнне Кыргыз-Миякә базарына килә һәм сөяк-санак утыртырга мохтаҗ кешеләр аны шунда табып, йомышларын үтәтәләр икән. Минем инәм дә шулай итәргә булды. Бүгенгедәй хәтердә: суыктан зәңгәр төскә кергән иртә. Әле яктырып җитмәгән. Инәм таң белән колхозның бригад абзарына барып, ат җигеп кайтты. Мин аның кулбашына таянып, сикерә-сикерә, өйдән чыктым. Инәм мине толыпка төреп, чанага яткырды һәм без иртәнге сәгать алтыларда икәүләп, шыгырдап күктән коелган йолдызлар астында, чана табанындагы тимерне яшь карларда чыелдата-чыелдата, «Түгәрәк Имән»нәр, урманнар һәм таулар аша егерме чакрымлык сәфәргә чыктык. Йолдызлар ифрат та эре иде. Чанада яткан килеш мин аларны исәпләп – бер урыннан алып, икенче урынга салып бардым. Башым чана табанының оч ягында булып, чана табаны җырлаган җырлар миңа тезелеп һәм терәлеп ишетелә иде...

Минем турыда шулай кайгырткан, ат янында, хатын-кыз булуына карамастан, ир-аттан да ким кайнашмаган инәмә ул заманнарда күпме иҗтиһат һәм ихтыяр көче кирәк булган!

Чана табаннары җырлаган җырлар астында изрәп, мин йокымсырап та китәм.

– Өшемисеңме? – дип сорый инәм. – Өшесәң, чанадан төшереп йөгертәм!..

Беләм, ул шаярта. Минем йөгерә алмавымны, шул «йөгерү артыннан» Кыргыз-Миякәгә баруымны белгәнгә шаярта ул.

– Өшесәң, җырлыйм!.. Атаң яраткан җырны!..

Һәм җырлап та җибәрә:

Озата барма, бәгърем, озата барма...

Ак карлар, офыктан сызылып барган кара урманнар, якты эре йолдызлар, чыелдап калган чана эзләре... Һәм әнкәмнең җыры...

Мин нинди бәхетле! Ватанлы булуым белән бәхетле!

Мин чынлап та йоклап киткәнмен. Нindидер чит тавышлардан уянып китәм. Кыргыз-Миякәгә кергәнбез икән. Якшәмбе көн. Базар көн. Безнең Биккол мулласына килгән көнебез. Миякәдәге гаиләбезнең дусты Гафирә түтки һәм аның балалары безне бертуганнарыдай җылы каршылый. Сикертә атлатып, мине курчак кебек кечкенә өйгә алып керәләр. Инәм озын-озак

сузып тормыйча базарга китә һәм шулай ук озак көттермичә «Биккол мулласы» дигән бабайны алып та килә. Ул түгәрәк йөзле, кытай чынаягы кебек җыйнак, матур бабай иде. Инәм аңа тагын бер тапкыр җентекләп гозеребезне җиткерде. Бабам мине сәке өстенә утыртып, догаларын укый-укый өшкерде һәм бармаклары белән үзенә генә хас хәрәкәтләр ясап, бер әби дә кыландырмаган рәвештә минем бармак буыннарымны барлый, тәртипкә китерә башлады. Урта белеме дә булмаган, хәтта мәдрәсәдә дә белем алмаган, бернинди институтларда укымаган авыл карты миңа хәзер сөякләрнең яшәеш физиологиясе турында гомерлек лекция укый һәм аларны минем күз алдымда гамәлгә ашыра иде. Иң кызыгы шунда: белемсез булсам да, миңа мөкиббән китеп ярдәм итәргә тырышкан әбиләремнең нишләргә белмичә аптырашка калып кыландыруларыннан арыган, шул ук вакытта аларга рәхмәтле үсмер, инде хәзер килеп, һич авыртынмыйм, киресенчә, рәхәтләнеп ял итә идем... Бабам бармаклары белән йомшак кына итеп буыннарымны капшый, кинәт кенә буынга баса һәм буын шуны гына көткәндәй, «шырт!» итеп йомшак наганнан атып, урынына утыра, аннан ул икенче буынга күчә, баягы хәрәкәтләрен яңадан кабатлап, шул буынга баса, анысын да «шырт!» итеп оясына утырта, шулай итеп ул минем бишме-алтымы (хәзер инде хәтеремдә юк!) чыккан буынымны төзәтә, урыннарына кайтара һәм:

– Бүдәнәнән – май, ябалактан – йон, бар, этҡә-кошка тоттырма! Башкаса малай-шалай менән кtorma! – дип, бүдәнәләрне-ябалакларны башкортчалап исемә төшереп, аркамнан этеп, идәнгә төшереп җибәрә һәм мин, айлар буе аягыма баса алмыйча газапланган малай, гүя гомеремдә беренче тапкыр йөгереп китеп тә барам...

– Карагыз әле, ничек тиз булды! – дип кычкырып җибәрде инәм. – Без күпме гомер азапландык! Сезләрне ничек кенә бәхилләтик икән, Мулла абзый?

– Борчылмагыз, бар нәрсәм җитәрлек! – диде Бабай. – Биргән тел садакагыз Аллаһы Тәгалә ризалыгына булсын! Нинди матур хыяллар, нинди матур теләкләр белән килгән булсагыз, шуларның барысы да тормышка ашсын, амин!..

Аякларым тышта да йөри микән, дигәндәй ышанмыйча, ачык һавага чыктым һәм үз адымнарым белән вак кына атлаштырып, атыбыз янына бардым. Ул да вак кына, сизелер-сизелмәс омтылыш белән печән чемчи иде. Күк йөзендәге ай – көпә-көндез! – атыбызның ике колак янчыклары арасына кереп оеган иде. Минем аягымның буыны да урынына кереп утырган иде. Мин сәяхәтебездән канәгать калып, бисмилла әйттем һәм шул ук йомшак адымнар белән өйгә кердем.

Гафирә түтки белән инәм «Биккол мулласы»н чәй белән сыйлаганда, аның артыннан килеп тә җиттеләр. «Халык мулласы» эшсез һәм буш тормый. Тагын кайдадыр кемнеңдер кулы каймыккан икән. Аны атка утыртып, башка кешене дәваларга алып киттеләр.

Язмышымда күпне күрелде. Күп сызланулар онытылды. Әмма алар арасында шушы «кеше дәвалаучы Мулла бабай» иң якты бер истәлек булып сакланды.

Һәм инәм дә. Һәм күк йөзендәге якты йолдызлар.

## Тол хатыннар мәҗлесе

Инәм – җырчы. Ул эшен җырламыйча эшләми. Аның моңы ягымлы, тамак төбеннән, күкрәк түреннән сайланып һәм сайралып чыга. Шуңа күрә эш дигәне сизелмичә ырамлы бара. Нинди генә җырлар җырламый иде ул! Иң яратып, еш җырлый торган җырлары «Идел», «Сарман», «Җирән-кашка аткаем» һәм «Хафизалам-иркәм» иде.

Ул җырларын йөрәксегән аһәң, тирән борылышлар белән җанны айкалдырып башкара. Минемчә, инәм «Җирән-кашка аткаем»ны фронтларда башын салган әтиемә багышлап, аны гына күз алдында тотып җырлагандыр. «Җирән кашка аткаем, башын чайкый малкаем, сугышлардан исән кайтса, укалармын ялкаен...» Шунда ук: «Җирән-кашка аткаем, башын чайкый малкаем. Алларында солысы бетсә, сызыла йөрәк майкае...» Ул борынгы озын җырларны йөрәккә үткәзеп башкара. Сүзләренә игътибар итегез. «Йөрәк башларына кан саудырып, йөрәк ярып ла чыккан бала икән...» Кайдан табарга мөмкин хәзерге заманда мондый тирән әхлакый сагышлы дастаннарны? Мин инәмнең мәҗлесләрдә ялгыз һәм башкалар белән кумәкләп җырлаганын хәтерлим. Сыер җигеп, җир сөргән, явыз Гитлерга каршы икмәк колонналарын алып барган ятим хатыннар авыр хезмәттә ифрат та изелә, кайвакыт шул кайгы-борчылулардан бер генә сәгатькә булса да онытылып тору теләге белән үзара берләшеп, уртактан берәрсенең мич башында, кызыл чөгендерне ачытып булса да, «бал» коя һәм форсатын табып, «яшерен» мәҗлес үткәреп ала... Миңа шундый мәҗлесләрнең берсенең шаһиты булырга туры килде. Мине шунда алып барган өчен инәмә рәхмәт. Безнең бакча башында яшәгән Гөлзифаттәйнең (Гөлди) шырпы кабы кебек кечкенә өендә булды ул. Аңа Кәркәлетамакның безнең оч хатыннары кунак итеп, күрше Җидегән авылының ятимә хатыннарын чакырганнар иде. Бүгенгедәй күз алдымда: ике кечкенә тәрәзә чүпрәк палас белән капланган. Түшәмнән өйне җиделе лампаның сыек уты яктырта. Сугыш беткән. Мин бу вакыйганы йә 1945 елның, йә 1946 елның җәендә булгандыр дип уйлыйм. «Җиңү бәйрәме» килгән. Әмма бик тизләтеп үтеп тә киткән. Ирләре генә сугыштан кайтмаган. Идәндә берсе икенчесенә каптагы шырпы шикелле сыенып утырып, мондый сирәк очрашу шатлыгын, чиксез газаплар аша кабул итеп, Җиңү шатлыгын кая куярга белмичә, теле телгә йокмый серләшкән, гөрләшкән, җырлашкан һәм җылашкан апалар... И-и-и җаныкайларым! Ничек шулай килеп чыккандыр, бала-чагалардан мин биредә үзем генә идем. Йокысыздан күзем тырнап, сәке өстендә ауныйм да моңлы җырлар астында йокымсырап китәм, ауныйм да йокымсырап китәм. Шунда табында каяндыр боерык кебек төшкән күрсәтмә яңгырый:

– Җырла, Сорур!

Барысы тына. Мин күз кабакларымны киерә-киерә, инәмнең җырлаганын көтәм. Җырлар микән?

– Башта үзегез җырлагыз әле! – дип ялындырган була ул. – Гел миңа гына димәгән... Җидегәннәрне без аларны җырлатыр өчен чакырдык...

– Әүвәлдә хуҗалар үзләре җырласын!.. Без өлгерербез!..– дип карышкан була кунаклар.

– Җырла инде, Минсорур!..

Инәм озак сатулашмый. Андый кеше түгел. Бәхәсләшер урыны да бу түгел. Аннан минуты да кадерле. Секунд саен, силсәвитләр килеп, «эш өстендә бу ниткән мәҗлес кору?!» дип, тәрәзәне шакырлар кебек...

– Нәҗметдинем хакына... Рухына димим... Кайтыр кебек!.. Ул миннән шушы җырны бик яратып җырлата иде...

Озак та үтми, кечкенә өйдә инәмнең моңлы тавышы аваз сала... Ул йөрәкне телеп, тирәннәрдән-тирәнгә төшә һәм шушы уч төбе кебек, инде тәмам эсселәнгән бүлмәне чиксез океаннарга алып чыга, гүя татарның шушы «Бәләкәй Кәркәле»се Җир шарының кап уртасындагы милли Үзәккә – Дөнья Капитолиена әверелә...

Җыр мәҗлестәшләрен үзе таба. Хатыннар җырның азагын күтәреп ала.

Күзем йомсам, күз алдымда
Хафизалам-иркәм шәүләсе...

Кемдер тәрәзәгә капланган паласны бер кулы белән чеметеп кенә, тышка карый. Силсәвитләр күренмиме тагын?! Кечкенә генә ярыктан тәгәрәп, өйгә тулган Ай керә... Керә дә табынга утыра. Без барыбыз да айлылар нәселеннән...

Балалык халәтемдә йокы аралаш булса да, нинди генә акыллы сүзләр, онытылмас яңалыклар ишетмәдем, нинди генә гүзәл җырлар тыңламадым мин! Әгәр үз иҗатымда кечкенә булса да кабатланмас үзенчәлек, ниндидер эчке таушалмас тойгы, үзара сагыну сагышлары сурәтләнгән икән, болар барысы да миңа шушы мәҗлестән күчкән. Мин аннан балачакның шушы көтелмәгән өлешеннән дә саулык-сабырлык алдым. Мин аңардан ятимлек белән көрәшү әлифбасын өйрәндем. Мин аның тимерлегендә акылымны-хиссиятемне чарладым. Тол хатыннарның шулкадәр дә матур вә батыр йөрәклеләр икәнлегенә инандым. Мин бу мәҗлестән бергәлекнең искермәс көчен танып чыныктым.

Соңгы чиктә минем бу мәҗлестән соң чәчкә атып утырган бәрәңгеләр арасындагы ызаннан, инәкием җитәгендә, йокы басканлыктан чайкала-чайкала, үз өебезгә кайтканым хәтердә. Дөньяда таң ата, мин әнкәм җитәгендә идем. Теләгән кеше, минем ошбу мәҗлес сурәтләнгән «Табындагы камчы» дигән хикәямне табып укыса, бәлки җаны-тәне, кальбе белән баер-баегыр иде!..

## Тамагыбызны Җәлил туйдырды

Үсмер егетләр өчен бер уңайсызрак урыны булса да, мин бу тарихны сурәтләмичә калдыра алмыйм. Гадәттән тыш, ачыктан-ачык керсезлек, хәтта сабыйларга хас беркатлылык күрсәткәнем өчен гафу үтенәм. Башкача мөмкин түгел. Ул адәм баласының нинди генә хәлләргә тарымый кала алмавыннан бер сабак, бер мисал. Әлбәттә, алар барысы һаман да шул ятимлек калдырган тыйнаклык, керсезлек, ихласлык, йомыклык, артык сабырлыклардан килә...

Мин 1956–1959 елларда Миякә урта мәктәбенең ир балалар интернатында яшәп укыдым. Кыз балалар интернаты аерым, башка урында иде. Көн тәртибебез шулайрак: иртәнге аш дигән нәрсәне үзебез кулыбыздан

килгәнчә этмәллибез; төшкә тамак ялгар өчен, булган хәлдә, арасына май сылап, ике телем ипи алабыз; кичке ашны шулай ук үзебез тырыштырабыз. Кичен интернатның бөкресе чыккан әби шикелле шыксыз юан миче, аның чүлмәкләр куя торган галанкасында («голланд» дигән сүздән) күрше Җидегән авылы егете, минем белән бергә укучы дустым Илфак Сафиуллин белән бер чүлмәктә уртак аш пешерәбез. Минем пешеренүдә әллә-нинди осталыкларым юк, күбесенчә ашны җыйнак һәм төгәл булган Илфак хәстәрли. Бер атна укыганнан соң, һәр шимбә көнендә, укудан соң, аркабызга бушап калган капчыкларыбызны асып, моннан егерме чакрымда яткан авылыбызга шул буш капчыкны һич кенә дә буш итмәс өчен азык-төлек артыннан кайтабыз да якшәмбе көнне төштән соң, ипи, май, бәрәңге, суган һ.б. белән баеган капчыгыбызны тагын да аркабызга йөкләп, Миякәгә юлга чыгабыз. Мин – авылдан, Илфак исә Җидегәннән килеп, Хлебороб дигән кахул авылында очрашабыз һәм уртак юлны Миякәгә таба дәвам итәбез.

Атна саен кырык чакрымлык җәяүле гимнастика.

Ничек ялкау буласың? Мөмкин түгел. Ничек өшисең? Мөмкин түгел. Ничек җырламыйсың? Мөмкин түгел!

Атна саен кабатланган бу шөгыль безне шактый алҗыта иде. 1958 елдан башлап, безнең хәлебез ярыйсы гына җиңеләйде: югарыдан кемнеңдер кайгыртуы буенча, аңа рәхмәт төшкере, безгә, интернатта яшәгән фронтовик балаларына, район үзәгендәге бердәнбер «Ашханә»гә төшке һәм кичке ашка йөреп ашар өчен талоннар бирә башладылар. Күзләребез ачылып китте. Безнең мондагы ак икмәкне, кетердәп торган кәтлитләрне, компот дип аталган җимеш суларын күргәнебез дә юк иде. Ашханәгә тамак өчен бер-беребезне узышып чапканда, өстәлгә куелган ипине савыттан ике телем генә түгел, андагы җаваплы апалар күзенә ташланмасын дип, яшертен, ашык-пошык өч, хәтта дүрт телем чәлдереп, җиң эченә яшереп калдыру безнең изге бурыч иде....

Ял көннәренә талон бирелми. Шулай ничектер бер тапкыр миңа авылга кайтырга насыйп итмәде. Сәбәбен хәтергә төшерә алмыйм. Сигезенче, тугызынчы, унынчылар өчен аерым булган өч бүлмәгә бер ялгызым калганмын. Салкын кыш. Ашарга валчык та ризык юк. Бик ачыктым. Ашказаным тегермәне ташларны гөрелдәтеп әйләндерә дә суыра, әйләндерә дә суыра, мин сезгә әйтим. Нишләргә? Миякәдә мине ашка чакырып торган туганнарым да юк. Шулчак Миякә район газетасының мөхәррире, озын буйлы, «гел сурьёзный» Хәлфин абзый искә төшә. Моннан биш-алты көн элек мин ул газетага үземнең җәйге каникул вакытында, печәнгә төшкәч, колхозчыларга инәй белән бергә пешергән төшке ашны ашаганнан соң язылган «Чагыштырып карыйм үземне...» дигән шигыремне биргән идем. Муса Җәлилгә багышланган. Илленче еллар башында Җәлил сатлык җан булган дигән хәбәр безне, татарларны, бик рәнҗеткән, изгән иде. Әмма соңгы вакытларда аның аклану хәбәре рухыбызны ифрат та күтәргән һәм мин Җәлил һәм җәлилчеләрнең батырлыкларына багышлап, бер-ике шигырь дә язган идем. Аларны тартып-сузып кына шигырь дип атыйм. Әмма. Шулай да. Ашказаны суыра бит әле, җәмәгать. Редакциядә шигырьне укып чыкмадылар микән, дип уйлыйм. Бүген бит якшәмбе көн! Минем

күңелем күккә күтәрелгәннән күтәрелә бирә, һич кенә дә төшәргә уйламый. Әгәр мин шул Хәлфин абзыйны Миякәдән эзләп тапсам, шигырьне бастырырга уйламыйсызмы дигән булып кызыксынгандай итсәм? Өенә барсам? Уңайсыз бит әле. Өйләренә кергәч, ашаган вакытларына туры килмәм микән? Табынга мине дә утыртмаслар микән? Тик аны, Хәлфин абзыкайны, ничек табарга? Ник өенә үк бармаска? Чынлап та? Хакым юкмыни? Бар бит! Хакым да бар, халкым да бар! Җитмәсә, миңа бит әле былтыргы матбугат көнендә партиянең район комитетына чакырып, яшь хәбәрче буларак, газетада актив катнашканым өчен Мактау кәгазе дә биргәннәр иде. Онытмаганнардыр әле. Хәлфинга барам! Адресын белешәм!

Шушы кызулыгым белән күлмәкчән генә килеш интернаттан тышка йөгереп чыктым. Урамда теләсә нинди кешедән тотам да кирәкле адресны сорыйм. Әнә! Күрәм, көтеп кенә торгандай, урамның теге, безгә каршы ягында яшәгән унынчы сыйныф укучысы Дамир Әбләев килеп ята!.. Белештем. Хәлфин дигән редактор кеше шушы урам буйлап барган хәлдә, Сатый очының башында яши икән. Кире интернатка кереп, шигырь дәфтәремнән шигырьне күчереп алам да бәлки кирәк булыр дип, кесәмә тыгам һәм аягыма кешелеккә генә кия торган резин итегемне киеп, Сатый очына таба юнәләм...

Менә ул «шигырь кисәге»:

Җәлил кебек сизеп,
Рәттән куеп,
Чагыштырып карыйм үземне.
Җитмәс батырлыгым,
Түзмәс ихтыярым
Кебек тоела минем йөрәккә.
Аһ, мин юк!
Без икебез батыр халык улы,
Совет иле безне үстергән.
Партиябез алга җитәкләгән,
Рухландырган, бетмәс көч биргән.
Сине сөям, Җәлил!
Якын күрәм!
Әтием дип атыйм үзеңне.
Синең шигырьләрең
Йөрәк түрләремдә саклана.
Рух бирүче матур юлларыңны
Яшь йөрәгем укып сафлана...

Күп тә үтми мин бу авыл очындагы йортны эзләп таптым. Ихаталарыннан үтеп, ишегалларына керсәм, анда – өермәле өмә: ир-ат халкы кызышып, аркылы пычкы белән дзең-дзең китереп, утын кисә һәм колун дигән тупас тимер белән утын түмәрләрен ярып өя. Йа Ходай, «Бирәм дигән колына, чыгарып куйган юлына» дип, минем халәттәге кешеләргә әйткәннәрдер инде. Файдаланып калырга кирәк! Хәлфин абзый үзе күренми әлегә. Бик яхшы. Аны-моны сорашып тормыйча, мин дә өмәчеләргә кушылып утын яра, аларны штабельгә ташып өя башлыйм. «Ач кешенең ачуы яман, дигәндәй, хәлсез тырышлык белән бирелеп эшләгәч, шыбыр тиргә төшәм. Менә пыяла савытында сыекланган ап-ак әйрән күтәреп, Хәлфин абзам

үзе дә чыкты. Минем белән кул биреп исәнләште. Хәлләрне сорашты. Рәхмәт, дим, әйбәт кенә. Күңелгә җылы керде. Мин үземнең бу атнада Кәркәлетамакка кайтмавым, редакциягә бирелгән шигырьнең язмышын белер өчен аның үзенә үк килгәнемне аңлаттым. Кирәк булган хәлдә дип, шигырьне үзем белән алып килүемне дә өстәдем. Мондый көтелмәгән үтенечтән стенага терәлгән редактор беразга югалып калды, аннан үзен кулга алып:

– Мин ул шигырьне әлегә укып өлгермәгән идем шул, энем... Хәзер, күрәсең, шигырь укып утыра торган чак та түгел. Аны син редакциягә килгәч, бергәләп укырбыз, яме?..

И-и Ходаем, безнең очрашу шулай такыр гына тәмамланыр микәнни? Тамак туйдырып, бу өмәнең әҗерен алып булмас микәнни? Сөмсерем коелды. Ул моны тойды һәм үз белемен сиздерергә тырышкандай, миңа ярдәмгә килергә ашыкты:

– Шигырьне аны, урамнан эзләп кенә табып булмый... Шигырь ул, энем, ике нәрсәдән тора – метафора һәм образ. Син шуларны үз шигыреңдә табып, редакциягә алып килә алмассыңмы? Син шул нәрсәләр турында беләсеңме?

– Белмим, – дидем. – Ишеткәнем генә бар.

– Аларны мин үзем дә юньле-рәтле белмим. Ишеткәнем генә бар. Хәер, сезнең әдәбият укытучыгыз Гыйззениса Гыйззәтуллина да аңлата ала инде сиңа ул метафора, образ дигән нәрсәләрне, шулай бит?

Шулчак хуҗабикә-җиңги болдырга чыгып, өмәчеләрне төшке ашка чакырды.

Юк, булмады, каһәрең. Мин «Ярар, ашамаган аш түгелдер әле» дип, сер бирмичә, кайтып китәргә дип, капкага юнәлгән арада Хәлфин абзый, рәхмәт төшкере, Аллаһтан килгән ниндидер сигналлар белән мине туктатты:

– Син кая, понимаешь? Татарда пешкән ашны ташлап китү илне ташлап китүгә тиң! Син өмәгә килгән өмәче бит... Әйдә, кер!

Мин Хәлфин абзама эчемнән генә рәхмәтләр әйтеп, өмәчеләр белән өйгә керсәм, колакка табада пешеренгән чаж-чож тавышлары, борынга итле аш исе килеп капланды. Ашказаны тегермәне тагын да ныграк тарта башлады. Ниһаять, өстәл артына утырттылар. Беренче итеп токмачлы аш килде. Кыстагандай иткәч, кыстатмадым, ике тәлинкә сыптырдым. Әле вакыт төшке аш тирәсендә генә, сыйныфташым Илфак авылдан килеп, тамагымны туйдырганчы бер тәүлек вакыт бар, форсаты булганда, үзеңнең ач икәнеңне сиздермичә, «культура» белән генә мөмкин кадәр мулрак ашап калырга кирәк. Өстәлдә коштабакларга ике урынга турап куелган сарык ите, катык-сөт, урталай ярып пешерелгән ярмалы бәрәңге, тозлы кыяр-помидор, мин гомердә дә күрмәгән, инәмнең «Их, шул борычны ничек кулга төшерергә?» дип өзгәләнгән тәмле кара борычы, сарымсагы, тагын да әллә нинди тәмләткечләр... Үзем ашыйм, майлы итне сыйдыра алганча согынып согынам, үзем уйланам: минем мондый аш-суга бай өстәлне күргәнем юк иде, билләһи! Күрәсең, газета редакторлары гына шулай сыйлы тукланадыр...

Өстәл тулы ит-бәрәңге булса да, хуҗабикә өстенә эре итеп суган турап, шулпалы итле аш китерде. Кара борыч сибеп, анысын да бер тәлинкәне тутырып йоттым. Майлы шулпадагы бәрәңгеләрне сыя алганча катык

белән сыптырдым. Өй дә эсселәнә башлагач, борыным ямьшекләренә тир бәреп чыкты. Аннан өстәлгә йөзем-өрек кебек җимешләрен ияртеп, сөтле чәй, корыт, каймаклы сөзмә һәм коймак килде. Тешләр арасына кергән ит җепселләреннән котылыр өчен махсус шырпылар да килеп җитеште. Җир йөзендә мондый кирәк-яраклар да бар икән, Ходаем!

Шактый вакытка сузылган аш-су галәмәте тәмамланды. Мин, рәхмәтләр укып, чак-чак кына урынымнан күтәрелдем. Өмәчеләр, авыр эштән соң, эчке якка үтеп, берәр сәгатькә дип ялга талдылар. Миңа бу үзем теләп төшкән коллыктан котылырга һәм ничек кенә булса да интернатыма кайтып егылырга кирәк иде. Берүк вакытта минем эчтән күп ашаганым өчен хуҗалар алдында уңайсызланып, гафу үтенәсем, минем чынлыкта андый бирәнтамак булмавым, мине ятимлек язмышым, бу ялда авылга кайта алмавым гына шулай ачкаклатканын аңлатасым килә иде...

Мин күп ашаудан һәм аның өчен гарьләнүдән янып-пешкән, кызарып төшкән идем. Безне ашаткан-эчерткән җиңгәчәйгә һәм Хәлфин абзама чын күңелдән рәхмәт әйтеп, соңыннан, редакциягә килеп, Муса Җәлилгә багышланган шигырьне бергәләп тикшербез дигән фикерне сеңдереп, тегермән ташы сыман шыгырдап, җай гына кайтыр якка кузгалдым. Әмма кызулыгым белән ашыгып, бу кадәр кунакчыллыктан тизрәк котылырга тырышып, мин бәдрәфкә кереп җиңеләергә онытканмын. Менә бит!

Урам буйлап кайтыр якка бераз баргач, үтә дә кискен итеп бәләкәй хаҗәтем килде. Түзеп торырлык әмәл юк иде. Бу бурычны Хәлфин абзыйларда чакта ук үтәмәгәнем өчен үземне тиргәп алдым. Шулай да көч-хәл белән теләгемне тыеп баруымны дәвам иттем. Авыл җирендә мин теләсә кайсы ихатага кереп, хаҗәтемне башкарып чыга ала идем, әлбәттә. Бу теоретик яктан караганда. Гамәлдә исә мин чит-яттагы ялгыз бер бала идем. Үзем өчен борчылудан мин кинәт кенә ихтыярсыз кешегә әверелгән идем. Әмма шушы кадәр ашаганнан соң, шундый «урынсыз, оят» йомыш белән кешегә керү дигән адымга күңелем тартмый, гүя минем бу «җинаятем» һәркемгә дә билгеле, гүя алар минем һәр адымымны күзәтеп торалар иде кебек. Гүя мин мондый «намуссыз, җинаятьчел» адымым өчен барлык прогрессив кешелек, хәтта өлкән абзам, якташым Муса Җәлил алдында да гаепле идем. Аннан, Миякә кебек «дөнья читендәге шәһәр җирендә» мин, әйткәнемчә, чит-ят зат, ул чактагы фикеремчә, рөхсәтсез-нисез бер генә ихатага да турыдан-туры барып керә, бу кадәр кысталган халәттә, икенче бер бөтенләй дә таныш булмаган кешегә, зиһенемне туплап, үземнең «шундый ямьсез һәм әхлаксыз» адымымны аңлатып тора алмый идем. Үтерепләр бәдрәфкә барасым килә, сидек куыгым шартлар чиккә җитеп, түзә алганча түзеп, «менә ычкынам, менә ычкынам» дип төйнәлеп баруымны белә идем. Барлык ашаган-эчкәнем гаурәтемә төшеп, әрнетте. Әгәр дә бик бәләкәй чагымда аякларымны туңдырмаган булсам, бу кадәр кискен итеп кысталмаган булыр идем. Шулай дип уйлап та өлгермәдем, бер эт кисәге кинәт чаттан чыгып, һау-һаулап өреп, миңа ташланмасынмы! Куркуымнан аңа дип, буш кулым белән селтәнгәндә бәвелем ычкынып китеп, бот буеннан җибәреп тә өлгердем. Китте! Минем кунакка йөри торган резин итек эчләрем сидек белән тулды. Җиңеләеп калдым.

Көтмәгәндә, урам чатында үз алдыма көлеп җибәрдем! Мин шат идем. Мин чынлап та тук идем! Минем тамагымны Муса Җәлил абзый үзе тукландырган иде. Хәзер исә үзем өчен үзем җавап бирә идем...

Интернатка кайтып, ишекнең йозагын ачып кердем. У-у-у, өйдә тыштан салкынрак күренде! Беренче эш итеп, мич арасыннан каен утыннарын чыгарып, тузларын суеп, мичемне кабызып та җибәрдем. Безнең башлар нәрсә генә күрми! Мичем миннән кызу алып, тиз генә үрләп китте. Кызып яна да башлады. Сандыгымнан инәм биргән коры эчке ыштанымны алып кидем. Су кайнарлатып, өстемдәге ике кат ситса чалбарымны салып, инәм өйрәткәнчә чайкаттым, аларны инәм өйрәткәнчә, мич арасындагы утын агачларына киптерергә элдем... Күңел күтәрелә башлады. Яшибез!

Ә менә Җәлил турындагы шигъри язмамны, йомшаклыгы өчен үземне битәрләп һәм кызганып, беркайчан да чыгармам. Чын шигърият үзеңне кызганудан башлана да инде. Ул шигырь ядкаремдә генә сакланыр. Хәлфин абзый белән очрашып, без ул мәсьәләгә кире әйләнеп кайтып та тормабыз. Әдәбиятта мондый вакыйгалар тулып ята. Минем ул шигырем дә әле генә, шушында гына басылып чыгар. Гүя ул Миякәнең «Сатый очы»ннан очып төшеп, нәкъ менә шушы көнен-сәгатен көтеп яткан, диярсең.

Мин бу хикәятне нигә яздым? Язмаска да мөмкин иде, шулай бит? Бүгенге яшьләребезнең сугыш ятимнәренең ничек исән калганнарын белсеннәр өчен. Матур җырлар белән берьюлы алар менә бу хәйләсез такмакны да белергә тиешләр:

Ыраз, дуа,читири,
Бездә кызлар хитири,
Яулыгын артка бәйләгән,
Башларында бет йөри...

## Авылдан китәргә мәҗбүрмен

Коммунистлар партиясенең ул чорлардагы Беренче секретаре Никита Хрущёв урта мәктәпне тәмамлаучыларга производствода ике ел эшләгәннән соң гына ВУЗга керергә хокуклы булу тәртибен кертте. Мин мәктәпне тәмамлаган 1959 елда ул бер яктан гадел, икенче яктан кансыз тәртипнең котырган чагы иде. Мин авыл тормышын үлепләр дә ярата, үз күрә идем. Шуңа күрә ике елга түгел, ә бәлки гомерлеккә авылда калу хәл ителгән иде. Шулай итеп, «унны бетереп, чучка көтәр өчен авылда калды» дип, формаль яктан кимсетмәсеннәр өчен без Илфак дустым Сафиуллин белән Октябрьск нефть техникумына математикадан бер имтихан – анысын да «икеле»гә тапшырып маташкан булдык та икебез дә ике дә уйлап тормыйча, туган колхозыбызның Кәркәлетамак һәм Җидегән авыллары бригадаларына колхозчы булып кайттык. Яшьләр минем дә авылда калуыма куанып бетә алмыйлар. Мин җаным-тәнем белән бирелеп, колхоз эшләрендә йөрим. Шулай бер тапкыр печән өстендә, караңгы төшеп килгәндә, авылымның бер унлап «мажигы» шаулашып һәм даулашып, минем ишегалдыма килеп керә:

– Уттай печән өстендә син нишләп ятасың?! Колхозның баш бухгалтеры, пнимаете ли, халыкка дигән печәнлекләрне райпотребсоюзга сатып эчә, ә

син кәррисбандит башың белән мыегыңны да селкетмисең!.. Әйдә, киттек силсәвиткә, яздыраек гәзиткә!..

Һәм алар мине үзләре белән атка утырталар да печәнлекләргә алып олагалар. Печәнлекләр чынлап та чабылган булып чыга. Мин, кичә генә авылга бөтенләйгә кайткан үрнәк «яшь колхозчы», арытаба тикшереп тә, белешеп тә тормыйча, авылдашларым кыздырган кайнар кан, эссе баш белән район газетасына мәкалә сыман язма язарга утырам. Төн уртасына ул әзер дә була һәм йөрәгем кайнарын да конвертка салып, редакциягә юлга да чыга...

Газета редакциясендә ул Закиров атлы (исемен хәтерләмим) бик сәләтле журналист кулына эләгеп, ирония һәм арттыру исәбенә эчне катырырлык кызык фельетон рәвешен алып, астына «Авыл хәбәрчесе Б.Хәлимов хатына нигезләнеп язылды» дигән өстәмә белән дөнья да күрә... Авылда, колхозда гына түгел, барлык районда диярлек хәрәкәт туктый. Телләрдә бер генә сүз: «Укыдыгызмы? Ф.Г.-ев «Победа» колхозының печәнлекләрен сатып эчкән! Булдыра бит кешеләр!»

Кызганычка каршы, бу мәкалә чыккан газета бите минем архивта сакланмаган. Мин бу вакыйгаларны хәтердән генә язам.

Инәм бу вакыйгалар турында ишеткәч:

– Балакаем, нишләп үз карындашың белән ямьсезләшәсең? – диде, чын-чыннан борчылып. – Ф.Г.-ев. синең атаң ягыннан бик якын абзаң бит!..

Колхоз һәм партоешма җитәкчелеге бу шау-шудан соң бер атна чамасы тавыш-тынсыз торды. Район комитетыннан да борчымадылар. Бу тынлык давыл алдыннан була торган тынлык иде. Чакырганнарын көттем. Ул замандагы иҗтимагый тормыш һәм партияле чынбарлык мондый адымны җәзасыз калдыра алмый иде. Ниһаять, колак телефоны хәбәр җиткерә: минем хат буенча басылып чыккан материалны тикшерү өчен колхоз идарәсе белән партоешма утырышка җыя икән. Әмма мине чакырмыйлар. Утырыш карарының нинди булачагы әллә каян билгеле – мин колхозга «дошман». Персидәтел генә түгел, хәтта бригадирлар да сәлам бирми, мин биргән сәламне алмый уза. Үз авылыңа бөтенләйгә дип кайтып, үз акылыңнан качып яшәү тиз туйдырды. Озак кына, бәлки берәр ай чамасы, песиле-тычканлы уйнап маташканнан соң, ниһаять, мине дә колхоз идарәсенә чакырталар. Монда җиткерәләр: Ф.Г.-ев абзыйны район комитеты карары белән колхозның баш бухгалтеры вазифасыннан бушатканнар, ул авылны ташлап, каядыр чыгып та киткән, имеш. Мин үз хатым буенча һич көтелмәгәндә кузгатылган мондый тавыштан соң, Ф.Г-ев. абзыйны эчемнән генә кызганып тетрәнәм. Әмма соң иде инде. Колхоз идарәсе белән партоешманың бергәлектәге утырышында минем тетмәмне теттеләр. Бу хезмәт биографиям башында мәңгелеккә алган сабагым иде. Утырышның төп бурычы шикаятемне җитәкчелек белән килештермичә язуымда, «киңәшеп эшләмәүдә» гаепләү иде. «Нишләп син мәсьәләне идарәгә, партия оешмасына килеп ачып салмадың? Баш бухгалтерның бер пакус печән өчен эчкән бер ярты аракысын, тикшермингтми, нигә алай кыйммәткә куйдың? Нишләп шундук редакциягә торып олактың? Һәр шылт иткән нәрсә турында киләчәктә газетага хәбәр итеп торыр булсаң, синең белән ничек бергә яшәрбез?» Һәм башкалар, һәм

башкалар... Кыскача әйткәндә, миңа кичектергесез рәвештә үз туган авылым, бөтенләйгә дип кайткан туган колхозымнан чыгып китәргә генә кушмыйлар иде.

Бу минем өчен «уеннан чыккан уймак», көтелмәгән нәрсә иде. Лермонтов теле белән әйткәндә, «Не вынесла душа поэта» дигән халәт иде бу. Яшермим, бик түбәнсендем, гарьләндем. Илфак дустым белән мәсьәләне төрле яклап уйладык та килеп туган ситуациядә авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булуыбызны тәмам аңладык. Башкача юл юк иде. Татар авылының юкка чыгуында, таралуында һәм таркалуында менә шушындый тупас ысуллар белән җитәкчелек итүнең хәлиткеч роль уйнаганлыгын соңга калып булса да төшенә башладык. Ләкин соң иде шул, соң иде!..

Без авылдан Октябрьск каласына юл алдык. Андагы икенче санлы техник училищеның бораулаучылар бүлегенә укырга кердек. Ярыйсы гына стипендиягә алты ай белем алганнан соң, Әстерхан бораулау эшләре конторасына, аннан Калмык Республикасының Каспийск эшчеләр бистәсендәге Стрелец бораулау конторасына эшкә киттек. Хәтердә, ел ярым чамасы эшләгәннән соң, мин беренче тапкыр туган авылыма ялга кайттым. Кыш иде. Буранлы гыйнвар башы. Әнкәмә, туган-тумачаларыма атап алынган кием-салым белән шыплап тулган ике чумаданым арасындагы кар өермәсендә басып торган егет каршына, дилбегәсен отыры тыеп, пар атлы кашавай чана килеп туктый. Аннан һавага төртелеп, толып эченнән күккә чөелгән горур борын күтәрелә. Күрәм, минем кардәшем, теләмәсәм дә, партия органнары ярдәмендә мин эшеннән алдырган Ф.Г.-ев абый күренә:

– Нәрсә, бу чумаданнарыңда да гәзитме, энекәш?! – дип кычкыра ул буранның авызыннан чыгып. – Кәркәлегә гәзитеңне җигеп кайт, ярармы!.. На-а-а!.. – Һәм ул дилбегәсен кагып, урыныннан куптарыла һәм кар тузгытып торып та чаба...

Ф.Г. абыйны Миякә совхозы бүлекчәләренең берсенә идарәче, ягъни управляющий итеп алганнар дип ишеткән идем, хак икән. Шулай гына була күрсен. Хезмәтеннән игелек тапсын. Илаһи амин! Бер гаепсездән аның белән беррәттән үземне дә рәнҗеткәнем өчен кичерсен!.. Бездән соңрак авылга кайтканнар киләчәктә авылдан китмәсен. Авылда калсын. Авылны сакласын.

Туган җирдә, ыжгыр буранда, юллар чатында ялгызым торып калсам да, мин Ф.Г. абый язмышы өчен чынлап куанган идем. Дөресен әйткәндә, әллә эчкән, әллә эчмәгән, монысы минем өчен караңгы булып, авыл «мажиклары» сүзенә икеләнүсез ышанып, нindидер «шикле шешә» өчен шушындый авыр сынаулар үтәргә мәҗбүр булган Ф.Г. абый алдында җир тырнап гафу үтенергә риза идем. Безнең бүләрлек малларыбыз юк иде. Шунысына шөкер, Аллаһы Тәгалә яхшы күңелле инсаннарга җир йөзендә һәрвакыт һәркайда исәп-хисап алып бара. Шул хисап кешеләрне кешелекле итә...

## Инәмнең бердәнбер сурәте

Ул заманда сирәк очракларда сирәк кешеләр генә фотосурәткә төшә алган. Фотокөндәлек ихтыяҗ һәм сәнгать төре булып, киң күләмдә егерменче гасырның утызынчы елларында гына тарала башлый. Мондый сирәклектә

шартлары җитешмәү беренче сәбәп булса, икенче сәбәп – мөселман диненең сурәткә табынып, сын катыру күренешен тыю. Нәтиҗәдә нәселебездәге фотошаһитлык күренеше бик сирәк очраклардан гына теркәлеп кала алган: атамның ике һәм Гали, Нияз абыйларымның бердәнбер сурәтләре генә. Анамның сурәте бердәнбер, анысы да башкалар тарафыннан бозылган очрагын исәпләмәгәндә, бөтенләй дә юк. Ул, мәрхүмә, бу хакта, мөселман кешесенә сурәттә сынланырга ярамаганлыгын яшермичә, турыдан-туры әйтә иде. Әмма анам яктылык ярдәме белән сурәткә төшүне тыймый, ләкин шартлары җитешмәгәч, төшә дә алмый иде...

Минем сезгә аның нәкъ менә шул бердәнбер сурәте тарихын сөйлисем килә. Бу очрактан мөселман хатынының үзенә һәм ул инанган диненә карата никадәр таләпчан булуы, теләсә нинди шартларда да Бер Иман шартын үтәргә тырышуы турында аерым мәгънәви нәтиҗә ясарга мөмкиндер. Күз алдыгызга китерегез: кеше туа, гомерен җиргә һәм илгә хезмәттә үткәрә, бала һәм оныклар үстерә, аларны өйләндерә, кияүгә бирә, төрле язмышларга – очракларга, хәтта хокукыннан мәхрүм ителү күренешләренә тап була, әйтик, сиксән, аннан да ары яшькә җитә, тормыш белән хушлашып китеп тә бара, әмма сагынганда карарга бер генә сурәте дә калмый... Ифрат та катгый, безнең күзлектән караганда, үтәлә дә алмаслык таләпләр кебек. Каты бәгырьлелек һәм иманга тугрылык, тормышта вакчыл теләкләргә буйсынмыйча саклану, бер иманда сафлану һәм башка, һәм башка бөек тойгылар!..

Җитмешенче еллар башында мин Ингель абыйдан хат белән шушы фотоны алдым. Инәбезнең безне ташлап киткәненә ун елдан ашса да, без бу югалтуны әле һаман да җаныбызга сеңдерә алмыйча газаплана идек. Без хәтта аның сагынганда карап, күңелне юату өчен ичмасам бер генә дә фотосурәте булмавы белән килешеп тынычланган идек. Һәм менә көтмәгәндә авылдан килгән ошбу фото. Хатында абыемның куанычының чиге юк: «Инәбезнең бердәнбер фотосы табылды! Әмма шунысы кызганыч: инәбезнең бу кечкенә, үзешчән фотограф төшергән сурәтенең йөз өлешендә карадан тамган тап бар. Син аны, туган, ничек кенә булса да чистарттыр, йөзендәге шул таптан арындыр да, яңадан эшләтеп алып, миңа да җибәр...» Ул фотоны күргәч, куанычымнан коелып төштем. Әйе, бу безнең газиз инәбез! Мин бу фотога төшкән мизгелне (үзем ни сәбәпледер кадрга кермәсәм дә) беләм, хәтерлим. Аны шул заманда фото белән шөгыльләнеп, безгә сирәк сурәтләр калдырган күршебез Фәтхетдин абзый Зиннуров төшереп алган булырга тиеш. Без Җидегән авылына, анда тегермәнче булып эшләгән Мосавир җизнәмә, якын туганыбыз Фатыйматтәйләргә кунакка барган идек. Ямьле җәй көне иде. Сурәттәге кешеләрнең, исемнәрен онытсам да, рәвешләреннән таныйм.

Әйе, куанычымның чиге юк иде. Мин, ул заманда яшь шагыйрь буларак, шактый таныла башлаган кеше, шул куанычымны йөрәктәй йомарлап, Бауман урамындагы тарихи йортыбыз – хәзерге көндә ябылган Матбугат йортына йөгердем. Һәм моннан иртәрәк үзем диплом практикасы үткән «Социалистик Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан») газетасының рәссамнар бүлмәсенә хуҗаларча җилләнеп барып кердем һәм анда, гадәттәгечә, гел төшрифүн, гел кызмача булган рәссамнарга, аны-моны уйламыйча һәм бернәрсәдән шикләнмичә, кайгымны ачып салдым.

Егетләрем, татлы ис сизгәндәй, уянып китә һәм минем сурәтне кулларына алып:

– Һи-и, без моны – хәзер! – диләр куанып. – Бар, шешә артыннан йөгер! Син килгәнче әзер булыр!

Куанычым тагын да арта төшә. Менә, насыйп иткәч, ретушь дигән нәрсә буенча сирәктән-сирәк осталар кулына эләктем бит, Ходайга шөкер! Әмма ни кызганыч, шешәне алып килеп керүемә инәмнең – фронтовикның ятим хатынының «осталар» кулындагы бердәнбер сурәте, аның нурлылардан нурлы йөзе, бернинди саклык, кызгану дигән нәрсәне белмичә, келәшчә кебек тупас пинцетлар белән чукылып-чокылып, бозылып, ашалып беткән иде...

– Нишләттегез?! – дип кычкырдым мин, ачынып. – Инәмнең бердәнбер сурәтен! Әйткән идем бит сак кыланыгыз дип! Ник аны шулай мәрхәмәтсез чокыдыгыз?! Ул тапны ретушь сыекчасы белән юешләп, сөртеп тә бетереп була иде бит!..

Мин үземә һәм туганнарыма, һич арттырмыйча әйткән хәлдә, барлык милләтемә шундый зур югалту алып килгән исерек рәссамнарны тере килеш ашарга әзер идем. Әмма алар кеше хәлен күрә һәм бәяли белми торган кызганыч бәндәчекләр иде. Мондый мәгънәсез, еш кына ярымисерек халыкны мин соңыннан Казанда бик күп күрдем. Шундый рәнҗедем, аларны башкача атый алмыйм һәм гафу итмим. Һәм бу югалту тәэсиренең миннән мәңге китмәячәге көн кебек ачык. Әмма бозылган сурәтнең чын кыяфәтен аякка бастыру инде мөмкин түгел иде. Ничек кенә тырышып карасам да, булмады. Шулай итеп, кешелек инәмнең йөзен күрүдән мәхрүм ителде...

Кешеләргә шулай җиңел ышанганым өчен мин әүвәлдә үземне тиргәдем. Бүген дә тиргим. Һәм тиргәячәкмен.

## Атта барабыз, печән чабабыз

Хәрби комиссариат биргән белешмә буенча әткәм 1942 елның 10 гыйнварыннан хәрби хезмәттә исәпләнә. Ул заманда һәр гаилә кебек әнкәм искиткеч күп авырлыклар күрә. Кырыгынчы еллар башында картинәй белән картәтәйнең икесен берьюлы өянәк сугып, урынга сала. Шул ук чорда мин кышкы суыкта хәҗәтемне үтәү өчен тышка чыккач, кире керергә дип, күгәненнән туңган ишегемне ача алмыйча, аягымны туңдырганмын. Караватта кемнеңдер кымшанмыйча да ятканын төшемдә кебек кенә хәтерләгәндәй итәм. Ул паралич суккан карттәм булган икән. Бу хакта бераз алдарак язган идем.

«Инәй» дигәндә, миңа беренче булып, аның кояшта янган якты, әмма борчулы йөзе һәм ул җиккән атларның сабыр күзләре пәйда була, дигән идем бугай. Әйе, өчесе берьюлы: кояшлы һәм һәрчак борчулы-мәшәкатьле инәй һәм көмеш балдак кебек түгәрәк күзле ат. Гүя мин беренче итеп тормышка күз ачканда, инде атка атланган идем. Нидән болай икән? Әле үземне аңлый башлаган елларда аттан егылып төшкәнгә шулай микән? Ул болай булды. Күршебез, бригадның ягулык ташучысы Чыпчык Вәли бабай (авылда, беләсез, һәркемнең үлемсез кушаматы бар!) мине еш кына колхоз

абзарыннан атын алып кайтырга җибәрә иде. Мин моны зур теләк белән башкара идем. Чөнки мин аны, буем бәләкәй булу сәбәпле, фурман үрәчәсе канатыннан сикереп менеп, үз җае белән атлатып кына алып кайта торган идем. Әлегә кадәр атта ыргып чапканым юк иде. Бер көнне, шулай ук ат менеп кайтып килгәндә, безнең очтан миннән дүрт яшькә зур Кыяметдин, атын ыргып чаптырып, җитмәсә, минем атка камчы белән суктырып узып китте. Чаптарым да ыргып чаба башлады һәм мин каушавымнан тезгенне кулымнан ычкындырып, атымнан очып төшеп тә калдым. Аңымны югалтканмын. Башкасын хәтерләмим. Һушыма килгәндә мин – өйдә, башым исә тишелгән җиреннән ак чүпрәк белән бәйләнгән иде. Аттан болай очып төшү гарьлегемә тиде. Үземнән үзем оялдым. Йә, әйт, шундый пешмәгән кеше «җегет» санала аламы?! Абыйларым белән инәм атка кемнең арттан куалап үтүен белергә тырышып карадылар, әмма мин, «әләкче» кушаматы тагылуыннан куркып, аның Кыяметдин икәнлеген әйтмәдем. Мин трактор ергалап үткән буразна катысына башым белән төшкән булганмын. Соңыннан, егет корына кергәч, аеруча, Николо-Берёзовкада бергә урман кискәндә, без Кыяметдин дустым белән бу вакыйганы еш искә ала идек.

Мин инәйнең хезмәте гел генә атка бәйләнгән булуы, аның, хатын-кыз вәкиләсенең, ир-ат төшенчәсе белән аеруча горурлануына әйләнеп кайтам. Ир-ат аның өчен алтын бәрабәренә тиң иде. Ул атны, атлы эшне яратты. Ул ат күзендә тормышның шатлыгын һәм фаҗигасен укый иде. Үзе дә ат кебек җигелеп, колхоз эшен тартты. Әмма җәйге, аеруча печән өсте, урак чорларында бар авыл өчен берүзе «кашавар» булып аш пешерде. Кая гына барса да, нәрсә генә эшләсә дә, аны һәм аңардан калмаган сабыйны, мине, йөзьяшәр юан өянкеләр, бөдрә таллар, шомырт-баланлы табигать һәм чишмә буендагы сазламадан пошкырган ат тавышлары озата бара иде. Инде җиде-сигез яшьтән үк – ун яшьлек чагым турында әйтеп тә тормыйм, ул вакытта үземне ир-егет итеп тоя һәм тота идем – атлар абзарына барып, ат караучы абыйлар ярдәме белән тиешле атны тотам, атланам, аны ихатабызга алып кайтам, арбага менеп, инәй ярдәмендә атка камыт кидерәм, шулай ук инәй белән икәүләп, йөз-йөз илле кешене туйдырышлы зур чуен казанны һәм тозыннан алып бәрәңгесенә кадәр барлык кирәк-яракны төйим-төяшәм дә, инәмне утыртып, яланга юлга чыгам. Минем бурычым – аңа ярдәм итү. Инәмнең йөзе, әйткәнемчә, һәрчак кояшлы да, борчулы да. Берүк вакытта ул якты да. Ничек шулай якты була алды икән ул? Аны гел кешеләр турында кайгырту яктырткандыр. Берүзе, аның теле белән әйткәндә, «чи утын һәм шушы малай белән» йөзләгән кешене аш пешереп ашатырга – кайчан һәм ничек өлгерә диген? Ул без табырга төшү белән – безнең якта халык төшлеккә төшкән урынны «табыр» диләр – урманнан мин сөйрәп чыгарган, туң тимер балта белән аны чапкалаган һәм каен тузында тергезелгән учактан ипләп, савылып кына һавага күтәрелгән учак төтенендә йөзеп, бәрәңгесен әрчи, әгәр булса, суганын турый (ул заманда суганны бик сирәк, «артык хәлле» кешеләр генә үстерә иде!), шимбә-якшәмбе өмәләрендә йөзләгән кешегә җитәрлек итеп, камырын баса, җәймәсен җәя, токмачын кисә... Инәмә бу эшләрен башкарырга ярдәм иткәннән соң кулыма арбабызда берьялгызы моңаеп, мине көтеп яткан олы тугызлы чалгыны иңемә салам да печәнчеләргә килеп кушылам. Өлкән абзыйлар, егет корына кергән

авылдашларым белән бер пакуста булу – бәхетле минутларым. Печән чабу – минем өчен зур шатлык булды һәм шулай булып калды да. Мин чапкан чакта үләннең корыч чалгы астында дәррәү авуын күреп барырга яратам. Ул хакта «Печән чапканда» дигән поэмам да, хәтта шул исемдәге китабым да бар. Хәтердә, чираттагы печән өмәсендә халыкны ашатканнан соң, Ләвән дигән пошмас, бот арасына ут төртсәң дә ашыкмас атыбыз белән кайтырга чыктык. «Кыска Кул» түбәсендә туктап, астыбызга – арбабыз буш кайтмасын! – үлән чабып салмакчы булдык. Тау битләвендә куе кондырак үлән, өстәвенә кояшта җиз төсенә кереп какланган, ифрат та каты, бирешеп бармый. Мин үземнән дә зур чалгыны алып, үләнне кыра башлыйм. Инәм тау битләвенә кунаклаган да сиздермичә генә миңа сокланып утыра. Бу манзарадан күңелем күтәрелеп китеп, җиз үләнне тагын да тырышып кыра-кытырдата башлыйм. Үлән бөтерелеп-бөтерелеп, пакуска ята. Инәм килә дә аркамнан сөя: «И-и-и, балакаем! Атаң күрсә, ничекләр генә куаныр иде икән?!»

Инәм сәбәбе чыккан саен менә тагын нәрсәне исенә төшерә һәм күңеле йомшарып, күзендәге яшьләрен сөртә-сөртә елмаеп ала иде. «Атаң кайтса, нишләр идең?» дип соравына мин сабый ике дә уйламыйча, шартлатып: «Әй-әй, кайтмый торсын әле, үзебезгә дә ашарга җитми», – дип җавап биргән булганмын икән...

Без менә шундый буын. «Атам кайтмасын. Ашарга ипи үзебезгә дә юк». Бу аллегория түгел. Коточкыч чынбарлык бу. Кызганычка каршы, тиешенчә сурәтләнмәгән чынбарлык. Тәүбә, тәүбә! Тетрәткеч халәт. Сугышларны ятимлек озатып йөри. Сугышның барлык телләрдә дә тәрҗемәсе – ятимлек. Җир йөзендә сугышлар да, димәк, ятимлек тә кабатланып торган. Әмма без кичергән ятимлек, бәлки кешелек тарихында шул кадәр дә масштабтагы беренче ятимлектер әле. Йа Хода, кешелеккә бүтән күрсәтмә! Киләчәктә атаклы драматург Таҗи Гыйззәтнең бер драмасындагы Гайнавал түткичә «Үлмәсен дә, кайтмасын да, килеп торсын акчасы» дип такмакларга язмасын. Шунысы кызганыч, без, татар әдәбияты вәкилләре, мондый куркынычтан да куркыныч ятимлек, социаль трагедия күренешен зур, тирән, күппланлы, масштаблы әсәрләр белән сурәтләп калдыра алмадык. Ятимлек турында шактый язсам да, монда минем дә үтәлмәгән бурычларым бихисап кебек...

Монда ат телгә алынды. Ул без үскән авыл шартларында иң зур байлык – тере капитал иде. Бригадтан үзеңә бер генә көнгә булса да җигеп торырга ат алу – сирәкләрдән сирәк күренеш иде. Мин атларны ифрат та ярата, әйтерсең аларның бер колакларыннан кереп, икенче колаклары аша чыга идем. Атлар аз, ә менә ятимә хатыннар, кемдер уйлавынча, ихата саен – бихисап иде. Ат галәйһиссәламне һәркемгә дә тоттырып бармыйлар, кайбер ерткыч бригадирлар ятимә хатыннарны күз яшенә батырып, «Башта дилбегә тотарга өйрән», дип кенә җибәрәләр иде. Инәй белән теләсә нинди «каты» председатель дә, теләсә нинди бригадир да исәпләшә иде. Аның авылдагы һәм колхоз күләмендәге абруе, ягъни авторитеты искиткеч зур иде. Авылның бер башыннан килеп яткан инәмне шул ук авылның икенче башындагы адәмзат, берәр бәхәс чыкса, «Әнә, Сорур килә! Аның белән киңәшик!» – дип, авызын ябар иде. Берәр йортта гауга, савыт-саба

тавышы чыкса, аларны килештерер өчен киңәшкә шундук инәй янына килерләр, йә аның үзен гауга чыккан йортка алып барып, тегеләрне тынычландырырлар иде. Шушы искиткеч яхшы булуы, җан сафлыгы, күңел яктылыгы һәм дәрәҗәле кешелеклелеге нәтиҗәсендә аны еш кына, югарыда әйткәнемчә, авыл советына депутат итеп сайлыйлар иде. Әмма ул депутатлыкка сайланырга яратмый иде «Гел мин генә димәгән, әйдә, үзеңне сайлыйк әле!» дип, ул үзе урынына ахирәтләрен күтәрә иде. Менә шушындый сыйфатлар аны рухи көчлелеге, түземлелеге, тышкы һәм эчке матурлыгы һәм батырлыгы белән кешенең иң якын җан иясе булган ат малына якынайталар иде. Бригадирлар аңа атны «ат-елкы җанлы» булганы өчен ныклы ышаныч белән тапшыралар иде. Инәй белән мин бригадтан алган ат белән ике тапкыр бездән утыз чакрымда яткан Зәйпәкүл авылына, бер тапкыр илле чакрымдагы «Дим» совхозына кунакка бардык. Бу соңгы сәяхәттәге ат фаҗигасе – абзарыбызга дала бүресе төшеп, атыбызның аягын яралады – минем «Өч аяклы ат» дигән әсәремдә сурәтләнгән. Аны режиссёр Нурания Җамали, рәхмәт төшкере, кинофильм итеп тә куйган һәм ул фильм Мөселман фильмнарының Казандагы дүртенче халыкара фестивалендә җиңеп тә чыккан иде...

## Яраткан («йөргән») кызларым яки Беренче мәхәббәт турында уйланулар

Мин бу урында үземдә мәхәббәт, сөю тойгысының кайчан һәм ничек яралуын сөйләргә телим.

Татарда сүгенүдән дә яманрак «И-и, мәхәббәтсез!» дигән сүз бар. Иң зур бәхетсезлек – мәхәббәтсез калу. Чын мәхәббәтне вакытында сиземләп, бәяли алмау һәм очсызлана барып, кешелексезлеккә чыгу. Насыйп итмәсен.

Мәхәббәт – кешелек гомеренең чишмә башы. Ул тумыштан килгән иң бөек иҗтиһат. Сабый чактагы беренче сөю тойгысыннан алып, җир-су белән хушлашып китеп барганчы, адәм баласы, телиме ул аны, әллә теләмиме, бер мәхәббәт даирәсендә яши. Аны җир йөзендә мәхәббәт каршылый һәм каберенә кадәр озата бара. Адәм баласының кешелек сыйфатлары мәхәббәт аша камилләшә. Рәвешләре-сынланышлары, конкрет затлардагы чагылышлары, ягъни объектлары күп, хәтта бихисап булса да, мәхәббәт дигән илаһи тойгы Аллаһ тарафыннан адәм баласына бер генә тапкыр һәм үзе яшәгән чорда мәңгелеккә бирелә. Гадиләштереп әйткәндә, кеше егерме тапкыр (!) үзенчә «яратып» өйләнсә дә, аның яшәешкә булган мәхәббәте берәү генә булып кала. Мәхәббәт тойгысы – җир йөзе тарихында иң зур капитал. Аның исәп-хисабы банк сейфларында түгел, йөрәк сейф-сыйныфларында. Адәм баласында мәхәббәт тойгысы никадәр саф, көчле булса, андагы Илгә, Ватанга, милләтеңә, халкыңа, өммәтеңә, нәселеңә, туганнарыңа, кешеләргә-күршеләргә карата бирелгәнлек, гражданлык тойгысы да шул кадәр саф һәм көчле була. Минем «Печән чапканда» дигән поэмамда беренче мәхәббәт, аңа хыянәт хакында шундый юллар бар:

Бетте, бетте!..
Каеннарым чүкте.
«Түзеп, йөрәгеңне өзмә син.

Җимертеп бер эч тә, – диде дуслар, –
Ташла, башка ярны эзлә син...»
Хәтеремдә, шәраб касәсенә
Тәүге кабат иренем тигәне, –
Бер ялгызым, каеннарны кочып,
– Син гафу ит, Ватан! – дигәнем...
Нигә «Ватан»? Монда «ул» гына бит!
Юк,
Гражданин булып Ватанны
Тәүге тою миндә бер вакытта
Тәүге сөю булып яралды...

Тәүге сөю кешенең, ягъни инсанның, тумышыннан ук яратыла. Ул аны иртәләп, яки соңлап сизенүе мөмкин. Ул кешенең кешелек холык-фигылен түгәрәкли. Ул булмаган («алданган»), ягъни ялгыш идеаллаштырылган очракларда, кешене-инсанны үзара берләштерми, якынайтмый – киресенчә, ерагайта, бәрелештерә, дошманлаштыра, хәтта сугыштыра да. Беренче мәхәббәт тойгысы, бәлки кешедә беренче тапкыр сагыну дигән сирәк күренеш – феноменны гамәлгә куя һәм иманга китерә. Аның көче җаны сабый калган килеш Ватан тойгысына тиңләшә.

Ышан, Зөһрә, сөю тыштан гына
Артык шәхси булып күренә.
Сөю китсә, ник соң табигатькә,
Яшәүгә дә кадер сүрелә?
Айныдым да, җирнең сазлыкларын
Яндырып, йөзләргә теләдем.
Яндырам дип ешрак үзем яндым,
Шунда тынгы тапты йөрәгем...
Сау бул, идеал!
Алиһәмне үзем
Җиргә орып, төштем упкынга.
Каспий белә...
«Ярыймы соң, исәр?!»
Мине ярга бәргән дулкыннар...

Әйе, беренче тойгы – беренче мәхәббәт хыянәт кебек фаҗигаи тойгы белән бергә яратыла. Алар еш кына бер-берсен озатып йөри. Ул кемнең кемгәдер «ошавыннан» башлана. Ошау беренче мәхәббәтнең бакча башы – башлам башы була. Бу тойгы бөтенлеккә, бердәмлеккә, кыскача әйткәндә, камиллек белән, идеал аша бергә булуга – кавышуга ашыга. Кавышуга ашыккан саен ул аңардан читләшә, ераклаша. Биредә, ошбу язмамда, беренче мәхәббәт төшенчәсе артык гомумиләштереп, зурайтылып алына. Аның нәтиҗәсе кавышу белән тәмамланган очраклар бик сирәк – меңнән берәүдер бәлки. Бу күзлектән чыгып караганда, беренче мәхәббәт тойгысы «яратып карау» – җитәкләшеп, култыклашып «йөреп карау»дан ары китәлми. Ул еш кына кыска вакытлы була. Аларның бер-берсенә «күзләре төшә», алар «йөриләр» ягъни.

Үземнең кеше булып өлгерү, гомерем башында (1951–1968 елларда) дүрт тапкыр «күзем төште» – дүрт кыз белән «йөрдем» дип әйтә алам. Мин аларның матурлыгына табындым, алардан да матуррак кыз күргәнем юк иде. Мин аларны «сайлаган», дөресрәге, аларга тап булган чорларда, аларны

инәм сыны, инәм табигате белән чагыштырып, аның ниндидер тышкы сыйфатларыннан чыгып бәяли һәм «сайлый» идем. Яраткан кызларымның беренчесе – авылдашым, минем инәм кебек ятимә-солдатка Рафигаттәйнең 1941 елгы ятимә кызы Һәдия иде. «Казлар көткәндә» дигән поэмамда мин, салкын иртәдә казларын көтүгә куган яланаяклы малай, аның белән шулайрак таныштырам:

Ошый миңа классташ Һәдия.
Торды микән әле йокыдан?
Кыш буена ничәмә хат яздым,
Бер җавап язмады, чукынган...
Хат кынамы? Чыпчык Вәли кызы
Рәмзия аша шырпы кабында,
Инәй киштәсеннән кәнфит чәлеп,
Посылкалар салдым тагын да...
Шулай – гарьлек – аңа дигән хатны
(Гашыйк хәтере, ахры алама!)
Ялгыш җибәргәнмен Ташкентларда
Бәхет эзләп йөргән агама...

Һәдиянең йөз чалымы инәйнекенә охшаш иде. Һәрхәлдә, миңа шулай булып күренә иде. Инәйнең бит алмасындагы алсулык, йөзендәге кояш ялкыны Һәдиядә дә бар иде. Мин аңарда, аның гаиләсендә, аның йорт тирәсе – ихатасында үзебезнекенә охшаган сыйфатлар, күренешләр эзлим, табам һәм моңа чиксез куана идем. Хәтта бакчаларыбыздагы бәрәңгеләрнең бер үк вакытта бертөрле чәчкә атулары да чиксез шатлыкка сала иде. Бу хакта якын дустым-фикердәшем, «яшерен киңәштәшем» булган Вәрискә сөйли идем. Мин Һәдиягә, арттырмыйча һәм киметмичә дөресен әйткән хәлдә, беренче мәхәббәтемә рәхмәтле идем. Урамда да, өйдә дә аңа ошарга тырыша, аңа күренеп, матур булырга, батыр булырга ашкына идем. Икебез арасындагы охшаш якларны эзләп табып куана идем. Әйтик: Һәдиянең әтисе дә сугышта үлгән. Минеке дә. Бередә югалтуларның тиңлеге калкып чыга. Шәхси кайгы социаль кайгыга әверелә. Һәдияләр гаиләсендә – дүрт кыз, безнекендә – дүрт малай. Аларның да сыеры ала төстә, безнеке дә. Аларның да ике баш кәҗә, безнеке дә. Аларның да ике баш сарык. Безнеке дә... Без дүртенчедән бишенче сыйныфка Олы Кәркәле мәктәбенә барырга тиеш идек, әмма сыйныфыбызда куптарылган «хулиганлык» күренеше безне аерды – Һәдия дүртенчедән бишенчегә күчми калды. Безнең юллар аерылды. Ә мин сагына идем! Балачак тойгысыннан зур мәхәббәт эзләү дөрес тә түгелдер. Еш кына ул сүнеп-сүрелеп кала. Һәр нәрсәнең үз вакыты була. Безнең дә шулайрак килеп чыкты. Һәдия кайдадыр чит-ят якларга чыгып китте, аннан кайтып, Олы Кәркәле егете Бориска (монда да Борис!) кияүгә чыгып, Свердлау якларын үз итте, бергәләп балалар үстерделәр. Ә без Һәдия белән борынгы дуслыкны югалтмадык, очрашкан саен балачакларыбызны искә төшереп хозурлана идек...

Яраткан кызым Һәдия хәзер юк инде. Никадәр үкенеч! Кеше туа. Яши. Акыл һәм, мөмкин булган очракта, матди байлык туплый. Һәм үлеп китә. Минем аңа булган балалык мәхәббәтем никадәр шатлык китергән булса, аны югалту мине шулкадәр кайгыларга салды. Хуш, Һәдиям!..

## Комсомолец янгын сүндерә

Ут-күршебез Мөсаббихә әбиемнең улы Мөхәммәт абзый бездән дүрт-биш чакрымда яткан Качаган авылыннан Фәүзия апага өйләнгән иде. Бишенче-җиденче сыйныфларда укыган чагымда Фәүзия җиңгәмнең сеңлесе Ф. аларга утырмага килә иде. Мөхәммәт абзыйлар төп өйләреннән бүленеп чыгып, күршеләрендәге келәт кебек кечкенә өйгә күченгәннәр иде. Шушы уймак кебек кенә «куышта», Мөхәммәт абзыйлар Качаганга кунакка киткән очракларда, аңа вакытлыча хуҗа булып кала торган Ф. минем «күзем төшкән» икенче кыз була. Аның түгәрәк йөзе, җыйнак сыны инәйнекенә охшаган. Елмаюы да аныкы шикелле ирен читендә эленеп тора. Ул заманда минем Гали абзам бүләк иткән унике телле тальяным да бар, мин аңарда Кыяметдин дустым ярдәме белән уйнаштыра, кызларны биетештерә дә башлаган идем. Бүгенгедәй хәтердә: кышкы салкынча, берүк вакытта җылымса кич. Шулай да була бит! «Күзем төшкәнгәме?» Ф.ләрдә аулак, кичен куанышып барыр җиребез булгангамы? Аның Фәүзия апасы белән Мөхәммәт җизнәсе, рәхмәт төшкере, Качаганга киткәннәр. Без, Риф, Зыя, Камил, Кыяметдин, Вәрис, Вәкил, Хәләф дусларым белән аулак йорттан уты нәзберек кенә сирпелгән кечкенә тәрәзәне шакыйбыз. Әмма анда җыелган кызлар, утлары урамга артык яктыртмасын дип, тәрәзәләрен палас белән каплап куйганнар да, ишекне ачарга теләмәгән булып ялындыралар. Үзләре палас читләрен ышырып кына, безне күзәтәләр. Каяндыр карларны туздырып, өянке башларын кузгатып, адашкан җил ярсып куя. Гармун телләрендә «Галиябану»ны шыңгырдаткан булабыз. Кем Хәлил дә, кем Исмәгыйль? Ни өчен алар? Шуның өчен: без авыл клубында куяр өчен «Галиябану» тамашасын әзерлибез, безнең эчке вә тышкы халәтебез бүгенге бу мизгелгә тиң. Имеш, бу безнең төнге «репетиция». Егетләребез тыелып кына җырлый:

Урам аша чыккан чакта
Бүрәнәгә абындым.
Минуты – ай, сәгате – ел,
Галиябануым, сылуым-иркәм,
Шул кадәре сагындым...

Кызларыбызның безләрне бик тә кертәселәре, бергә уйныйсылары-җырлыйсылары килә, әмма алар тыйнаклардан тыйнак татар кызлары буларак, ялындыруны мәгъкуль күрәләр. Ниһаять, без теләгәнебезгә ирешәбез, ялына-ялына, ярым ачык ишеккә кысыла-кысыла, аулак өйгә үтәбез. Анда инде болай да таныш кызлар белән «танышу», кочакларга тырышу гамәле башлана. Ф.нең, аулак хуҗасының «егете» буларак, үземне эрерәк, Ф.гә якынрак тотарга тырышам. Әмма Ф. үзен бик мөстәкыйль күрә. Мин аптырап калмыйм, «болар болай да булдыралар икән» дип горурлансыннар өчен, гармунны кулга алган һәм кулымнан килгәнчә, үзем уйнарга яратмаган бию көен мәтәштергән булам. Кызларыбыз, шуны гына көткәндәй, бер-берсенә китереп басып, парлап бии дә башлыйлар. Биергә малайларны да чакыралар, әмма ир-ат халкы биергә дигәндә өзлегеп бармый. Аннан кулга каеш сугышлы, йөзек салышлы уйный башлыйбыз.

Бу уен бик тә кызык, ул хәрәкәтчән, кызларны «үтеп барышлый» кочаклап өлгерергә дә мөмкинлек бирә.

Аулак уеннары ике-өч көннән ары бара алмый. Туйлар белән бәйләнгән зур кунакларда гына биш көнгә сузылуы мөмкин. Шул арада без «урнаш» та пешереп өлгерәбез. Ул инәйләрдән яшереп алынган һәм үзебез хәстәрләгән ризык төрләре. Мин аны үземнең «Урнаш» дигән шигыремдә тәфсилләп сурәтләгән кебекмен.

Ф. белән «йөрүебез» өч-дүрт елга сузылгандыр. Ул Кәркәлетамакка җизнәләре кунакка киткән чорда гына килгәли, ә мондый форсат еш кабатланмый иде. Аулакта, аеруча азагында зурларга ияреп, «кызлар белән куну» теләге дә күперми калмый иде. Хәтта ул егетлек корыбызга керү чорына туры килгәнгә күрә, шактый көчле чагыла иде. Малайларның алгы якка чыгып, үзара «Син кемне тотасың, әй», «Син кемне тотасың, әй», дип, сүз берләштерүләре хәтердә калган. Кызларыбызның бик тыйнак, тәрбияле булулары, үзләренә якын да җибәрмәүләре нәтиҗәсендә «куну» дигән нәрсә бик тә сирәк, гадәттән тыш хәл буларак очраштыра иде. «Кызлар белән куну», кочаклашып яту бер-берсен яхшы белгән, инде шактый якынаеп, еш кына берсе икенчесенә ярәшелгән хәлдә генә мөмкин санала иде. Гомумән алганда, кара төн уртасындагы аулак, кызларның төнгелеккә аулакта куна калып, үсмерләрнең өйгә таралышуы белән тәмамлана. Бу хакта халыкта такмак та бар:

Ыраевка, Шафыран,
Әтәйләр кунакка киткәч
Сине куна чакырам...

Ф. белән булган бер-ике истәлек хәтердә калган. Беренчесе тагын да шул «клуб сәхнәсе»нә бәйле. Бер тапкыр без ниндидер уен куйдык. Исеме хәтердә калмаган. Мин эчемнән сызып-көеп, бу тамашаны ничек кенә булса да, Качаганга алып барып, халыкка, иң мөһиме – беренче эш итеп Ф.гә күрсәтү турында хыялландым. Спектакльдә катнашкан иптәшләрем – Зыя, Дарига, Вәкил һәм Кыяметдиннәр ни сәбәпледер бу авылга барырга ашкынып тормыйлар иде. Ф.не күрү уе шулкадәр көчле иде ки, мин Качаганга бару мәсьәләсендә иптәшләремне сындыра алдым. Йә, хуш. Менә без ул авылга барып, сәхнәгә дә күтәрелдек. Ф.-матурым да залда, минем ничек уйнавымны карап утыра. Әмма бу сәхнә миңа шактый зур үкенеч китерер һәм мин көлкегә калырмын дип кем уйлаган! Әйе, пьеса текстында минем икенче геройга сугарга дип, урындык күтәрү һәм бар дөньясын онытып, артлы эскәмиягә шап итеп утыру күренеше бар. Мин көндәшемә сугам дип, урындык күтәргән уңайга җан көчемнән урындыкның очлы почмагы белән кашыма кундырдым. Күзләремнән очкыннар чәчрәде. Инде үзебезнең авыл клубы сәхнәсенең арткы ягы стена булып, аркам белән сөялергә мөмкинлек бирсә дә, Качаган клубы сәхнәсенең артында бары тик алдаткыч чаршау гына булганлыгын онытып, артка түнкәреләм һәм аякларымны чатай-ботай китереп, караңгылыкка очып төшәм... Бу шулкадәр табигый килеп чыкты ки, залдагы халык, моны спектакльнең үзе итеп кабул итеп, миңа шулай ошатып, үземне

кызганмыйча уйнаганым өчен рәхмәт әйтеп, мин караңгы чокырдан килеп чыкканчы кул чапты...

Минем күз кашы-ние белән күгәренгән иде. Ф. белән очраша да алмадык бугай. Кәефем китеп микән, хәтеремдә дә калмаган. Шулай итеп, мин «Сәнгать корбан ярата» дигән классик аксиоманы тагын бер тапкыр раслап, Качаган авылында Ф.-матурыма «чын уен» күрсәтеп кайттым...

Икенче истәлек болайрак.

Ул Миякә район комсомол оешмасының ниндидер бер җаваплы конференциясеннән соң булды. Мин үзебезнең урта мәктәпнең сигезенче сыйныфыннан, Ф. Качаган җидееллык мәктәбеннән килгән делегатлар идек.

Мин ул чакта мәктәбебез интернатында яши идем. Шимбә көн булып, башка укучылар авылларына таралганлыктан, анда мин ялгызым идем. Мине Ф.не ничек кенә булса да, интернатка «куна»га алып килү уе котыртты. Тәүдә аның үзе белән сөйләшеп карадым. Ул теләмәде. Әкчин очындагы танышларыма барам, шунда кунам, диде. Аны озата киттем. Әмма танышларының ишекләрендә йозак иде. Без кире интернат тарафына киттек. Шактый гына ык-мык итеп торганнан соң, ул «куна» керергә килешеп тә куйган кебек булды. Мин аны ай-ваена куймыйча, интернатка алып кердем. Булган байлык-барлык белән чәй эчкәннән соң, без кияү белән кәләш кебек салкын интернатның ике-өч кат одеалы астына кереп чумдык. Үсмерчакның бу керсез гамәлендә күпме шигърият! Мин ифрат та шат идем. Ул чактагы татар егетләрендә «куну» дигән йола ничектер гадирәк, «була торган хәл» итеп кабул ителә иде. Иреннән үбешү, Алла сакласын – була торган нәрсә түгел. Бер унбиш-егерме минут, шулай кочаклашкан хәлдә, йөрәкләребезнең дөп-дөп тибүен тыңлап тыныч кына ятканда, каршыбыздагы урамнан атлылар дөпелдәп узды:

– Пожар! Янабыз!! Пожар!!!

Мин бу көтелмәгән куркыныч хәлдән соң Ф.не инде кочаклый да, күземне йома да алмадым. «Кешеләр котырып яна, ә син, комсомол токымы, бернәрсә булмагандай, дәүләт биргән интернат мендәрендә кызлар кочып ятасың. Оят түгелме сиңа?» Нәрсә турында уйласам да, колак төбемдә шушы разбой салган тавыш яңгырый: «Пожа-а-ар!.. Оят түгелме сиңа? Пожа-а-ар! Оят түгелме сиңа?..»

Мин, уйлавымча, Миякә комсомолының лаеклы улы, ары таба түзеп ята алмый идем. Сикереп торам да:

– Ф.! – дим. – Син дә йоклый алмыйсыңдыр. Анавы пожарны гына сүндереп кайтыйм булмаса... Тиз кайтам! Син курыкма!.. Мин – хәзер!..

Һәм чыгып та ычкынам. Ике сәгать чамасы үткәндер, янгынны сүндереп, шыбыр су булып, чыланып, мин, комсомолец, интернатка Ф. янына кайтам. Ул урынында, берни булмагандай, җылы одеаллар астында «мине көтеп ята». Миңа аның менә шушы «көтүе» кадерле.

Мин аңа, өлкәннәрдән ишетеп, Миякә тарихында иң дәһшәтле янгынны сүндерүдә катнашуымны, анда тулы бер урамның, шул исәптән хәтта дәүләт банкы, госстрах кебек оешмаларның да көлгә калып юкка чыгуын, минем үз кулларым белән ут эченнән акча сейфларын, капчык-капчык акчаларны коткаруымны хәбәр итәм.

– Үзеңә алдыңмы соң бераз? – ди ул йокымсыраган тавыш белән.

– Кая ди анда акча алу? – дим мин үз чиратымда. – Анда бит адым саен милиция...

– Милициягә дә яшәргә акча кирәк инде... – ди ул тыныч кына. – Милиция дә акча ярата...

Мин моның белән килешәм һәм аның одеалы өстеннән кулым белән каккалап ятам да янәшәсендә урын алам...

Тугызынчы-унынчы сыйныфларда укыганда, имтиханнар вакытында, кемнәндер сорап торган велосипедта берме-икеме тапкыр Качаганга, Ф.не күрергә барганым хәтердә.

Аннан Октябрьскига юл алып, Каспий тарафларына киткәч, безнең Ф. белән аралар суынды. Күңелемне яңа, башланып килгән егетлек чорының икенче тойгылары биләде. Мин Ф. белән бүтән беркайчан да очрашмадым. Әмма аның турында кызыксынуым мине ташламады. Мин аны үземчә яраттым. Аның хакына батыр һәм матур булып яшисем килә иде. Аның Айдарәле-Тәтер якларына кияүгә чыкканлыгын беләм. Ә менә ул үзе исәнме-юкмы, әйтә алмыйм. Исән була күрсен иде. Балаларына, балаларының балаларына да исәнлек бирсен. Миякә интернатында аны буш бинада ялгыз калдырып, янгын сүндерергә чыгып киткәнем исемә төшкән саен мин Ф. алдында оялып, үзем өчен уңайсызланып куям. Кичерә күрсен. Комсомолец янгын сүндергән бит. Ул минем балачак-үсмерчак чорының бер якты өмете, бер истәлекле ядкаре буларак хәтердә калды. Хуш, Ф.!

## Уфага сәяхәт

Тугызынчыда укый башлагач булса кирәк, минем Әнәч (Миякәбаш) авылыннан Венера дигән кызга күзем төште. Ул да минем кебек ятимә, сугышта һәлак булган Әсхәт абзый һәм Әнәч урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән Галия апаның кызы иде. Ул да минем кебек ятимә кызлар интернатында яши, минем кебек, хөкүмәт исәбенә «Ашханә»гә йөреп, ятимнәр талонына туклана. Тик шунысы гына күңелне китә, ул миннән ике яшькә диярлек өлкәнрәк, унынчыда укый. Димәк, бергә укымагач, аны туйганчы күрә алмыйм. Ә менә туйганчы күрергә дигән теләк, ай-бай, зур. Шуңа күрә, еш кына аның үзен күрә алмасам, киемнәрен булса да күрермен дип, кызлар интернатының тәрәзәсе аша Венерамның карават башында эленеп торган бәс төстәге күлмәген күрү ниятеннән кыска вакытка гына булса да, тәрәзә рамына капланып карап тора идем. Әлбәттә, безнең «йөрүебез», гадәттәгечә, кичен янәшәдән (сирәк кенә җитәкләшеп!) йөрүебез белән чикләнә иде.

Венера башка авыл балаларыннан үзенең үткерлеге, сабырлыгы, техник белемнәргә һәвәс, гадәтләре белән тумыштан ук Европага тартылган булуы, рус телен яхшы белүе белән аерылып тора иде. Атасы һәм Рәхмәтуллина дигән фамилиясе белән ифрат та горурлана иде. Мин аның сабырлыгында, бит алмаларының төсендә, иркен итеп елмаюында инәм чалымнарын таба идем. Моннан ике ел элек Миякә урта мәктәбен тәмамлаган апасы Юлия Уфаның беренче санлы техник училищесында токарьга укырга кергән иде. Ул аның белән хат алыша һәм үзе дә, унны тәмамлагач, шул училищега урнашырга хыяллана иде. Бу хыял минем үземдә дә тамырланып

маташканга күрә, без үзебезнең киләчәктәге язмышларыбызны бер-беребезгә охшатыбрак та күргән кебек була идек.

Венера яхшы укыды. Унынчыны алтын медальгә тәмамларга берничә генә балл җитми калды. Урта мәктәптән соң ул, шул алдан сөйләшенгәнчә, апасы янына Уфага китте һәм техучилищега укырга урнашып, аның белән бер үк гомумторакның бер койкасында йоклап яши башлады. Без аның белән актив кына хат та алыштык. Унынчыда укыганда, яңа елдан соң, кышкы каникулда, янына барып күрергә теләгем булуын яздым. Ул «ярар» дип тә, «юк» дип тә җавап бирмәде. Мин тәвәккәллегем белән аның эндәшми-тынмый торуын үзем белән килешү дип аңладым һәм теләгемне, нинди генә каршылыклар булмасын, тормышка ашырырга ният кылдым. Үз гомеремдә район үзәгеннән ары чыкмаган үсмер өчен кинәт кенә «чаптырып» йөзләгән чакрымдагы Уфага барып килү хыялы җиңелләрдән түгел иде. Әгәр матди ягын да исәпкә алсаң, аеруча. Беренчедән, өскә-башка кеше күзенә күренерлек кием кирәк. Икенчедән, Уфа безнең Миякәдән ничә чакрымда? Ике чакрымдамы? Әллә ике йөз чакрымдамы? Белешәм. Әкчин стансасы һәм аннан соң Раевка, Дәүләкән кебек биш-алты зур стансадан соң юллары-борылышлары белән өч йөз чакрым чамасына тарткан шактый ерак ара. Ул заманнарда хулиганнар, төрле бандитлар мыжлап торган Уфада бер кешең, танышың да юк. Ашарга-эчәргә акча кирәк. Юлга акча кирәк. Үзеңнең кирәк-яракларыңны салыр өчен төзек тә, матур да булган сумка, яисә капчык кебек нәрсә дә кирәк. Иң кискен проблема менә шушы акчага килеп төртелә иде. Минем белешкән исәп-хисабым буенча миңа кимендә егерме биш сум акча кирәк булачак иде. Ярар. Хәерле сәгатьтә! Минем кебек егетләр өчен башланган эш – беткән эш. Мин егерме биш сум акча артыннан илле чакрымга барып басачак җәяүле юлга кузгалам. Авылга. Төнге уннарга авылга кайтып төшәм. Инәйгә аңлатам. Шулай-шулай, димәк. Мине, уку отличнигын, имеш, яшь химиклар олимпиадасына (ул заманда ишетелә башлаган яңа сүз). Нигә химиклар? Минем иң яратмаган, аннан, ифрат та мокыт фәнем булган өченме? Юк. Мәхәббәтем шул фән исеме белән нужа тарттыра. Инәм куаныч аша коелып төшә:

– И-и балакаем, бер тиенем дә юк бит. Әмин абыйларыңнан гына сорамасаң. Алар миннән 25 сум акча алып торганнар иде. Хәзер бик соң, караңгы төнгә каршы бит әле, – ди инәм.

Һи-и, миңа дигәндә, бу караңгы гына нәрсә ул? Әйе, инәм тәкрарлаган кара төнне ерып, күптән түгел генә төп йорттан аерылып чыккан ике туганым Әмин абыйны һәм Миңнегөл җиңгәмне уятып кереп, теге «мине көтеп сайраган» 25 тәңкәне каерып алам һәм шуннан, Түгәрәк Имән янәшәсеннән, турыдан, өемә дә кайтып тормыйча, кирегә – урманнар һәм таулар-яланнар аша тагын да тыкрыклары белән егерме биш чакрымга барып баскан Миякәгә юлга чыгам. Таң атуга килеп тә җитәм. Интернат басылып йоклый әле. Кирәк дусларымны пышын-пышын гына уятып, берсеннән ул заманда модада булган кыска «Москвич» пәлтәсен алып торып, шуңа өстәп, үземнең урман кисеп алган кәчтүмемне, аякларыма кешегә күренерлек кирза итегемне кунычларын бөкләп киенәм һәм иртәнге җиде сәгатьтә Әкчин стансасына юлга чыга торган ябык почта машинасының кузовына сикереп өлгерәм һәм Уфа тарафларына кузгалам. Хәтердә калуынча, Әкчин белән Уфа арасындагы

электричканың билет хакы ике сум илле тиен иде. Исәп башланды. Тиененә кадәр сак тотын. Уфага – тау башыннан җимерелеп төшеп урнашкан икән! – килеп җиткәндә караңгы төшкән, төн иңбашларга кунган иде. Такси яллап (бу 1959 ел, онытмагыз!) үзем белмәгән-күрмәгән-ишетмәгән Черниковкага юлга чыгам. Ул Иске Уфадан егермеләп чакрымда икән. Җаныкайларым яшәгән Кольцевая урамын табабыз, ләкин күпме генә эзләсәк тә, кирәкле йортны таба алмыйбыз. Таксист, рәхмәт төшкере, – татар егете! – мине үзенә кунарга алып китә. Тыныч булмаган күңелем мине таң аткан мәлләрдә төртеп диярлек уята. Йокысыз кызарган күзләремне уып, күз кабакларымны ачам, аннан бауга эленгән вак шакмаклы күлмәгемне сыдырып алып киям һәм бу рәхмәтле йорттан шыпырт кына чыгып сыпырам.

Венераны күрергә дигән теләгем тауларны җимерерлек көчкә ия иде. Таксистны уятасы, йә уянганын көтеп утырасы урында, мин, йокыдан айнымаган күзләрем белән кабаланып, юньләп тикшереп тормыйча, таксистның минем күлмәгемә бик тә охшаш күлмәген киеп сызганмын икән! Чынлап та, ул күлмәкләрнең охшашлыгын күрсәгез! Кешеләрдән сораштырып, Черниковка бистәсенең кайсы якта ятканлыгын сораштырып, кайда чамалап, тугызынчы санлы трамвайга утырып, юлга чыгам. Килеп табам мин боларны. Ашка төшкән таракан ролен үтәмәсәм дә, минем кебек чакырылмаган кунакның килеп төшүе боларны бик куандырмады бугай. Өч йөз кыз яшәгән гомумторакта бердәнбер ир заты икәнмен бит мин! Әмма дә, рәхмәт үзләренә, караңгы чырай да күрсәтмәделәр. Теш арасына кыстырырга дип, ниндидер күчтәнәч биргән булдым. Венераны күрүем, аның белән җитәкләшеп йөри алуым минем өчен иң зур куаныч иде. Анда, әлбәттә, кызлар гына яшәгән бүлмә идәнендә, мин икенеме-өчнеме кундым бугай. Без һәр көнне якындагы кинотеатрга бардык. Бу чактагы популяр актёр Борис Житков (исемен ялгышуым мөмкин) катнашындагы бер кинокомедия каравыбыз хәтердә калган.

Җырчы-шагыйрь Михаил Матусовский сүзләренә композитор Михаил Исаакович Дунаевский язган «Чёрное море» дигән җыр да әле булса онытылмыйча күңелдә саклана:

Самое синее в мире
Чёрное море моё...

Менә бит «ябрәй кавеме» нинди акыллы: бер «Кара диңгез»дә «чёрное» белән «синее»не капма-каршы куеп, шигърият ясый.

Капма-каршы җенес вәкилләренең бергә сыешып яшәү очракларында кыенлыклар очрамый калмый. Алар миндә дә булды. Кызлар алдында – миңа, аларга минем алдымда чишенүләр-киенүләр уңайсыз иде. Кызлар гомумторагы бәдрәфенә кереп, бик тә табигый булган хаҗәтләремне «кәтигәрически» үти алмый идем. Мин кызларны «бәдрәфкә йөрми торган халык» дип уйлый идем. Дөресен әйткәндә, алардан ояла идем. Ышанасызмы-юкмы, андый мәшәкатьләрем барлыкка килгәндә, үзебездән бер-ике чакрымдагы жираф кебек муенын сузып торган төзелеш краннары астындагы эшчеләр бәдрәфенә йөгерә, артык кысталган чакта җан-фәрман чаба идем... И-и үсмер чак! Һәр мизгелең хәзер кадерле!

Кабатлап әйтәм, мине яңа дөньяга алып чыккан Венерага һәм Юлиягә мин бик рәхмәтле. Уфага барганда, мин бер төрле кеше булган булсам, тау башындагы Уфадан кайтканда, бөтенләй дә икенче төрле кеше идем.

Уфага Венера янына бару минем тормышымда дөньяга чыгуымның беренче баскычы булды. Ул дусларны низагка, фикер аерылышына, үзара салкынаюга, читләшүгә куып кертмичә, «кешеләргә күрсәтмичә» генә өлгерткән. Ялан кул белән Миякәнең почта машиналарына утырткан. Йокымсыраган күзләр белән кеше күлмәкләрен киеп, урамга ташланганчы ашыктырган ул мине. Ул минем кардиологиямә сиздермичә, авырттырмыйча гына физиологик үзгәрешләр китергән. Мине почтаның ачык машиналарында Миякәдән Уфага китертеп, беребезнең икенчебезгә ни дәрәҗәдә якын, ни дәрәҗәдә чит икәнлегебезне ачыклаган. Миякәдә рухи исереп, Уфада гамәли айныганмын. Венера миннән ике яшькә зур иде. Шулай итеп, безнең «йөрүебез» мәхәббәткә әверелеп китә алмады. Мин күкләрнең җиде, кеше күңеленең җитмеш кат икәнлеген таныдым.

Унынчы сыйныфны тәмамлап, Октябрьскига, аннан Каспий якларына, аннан армия сафларында хезмәт итү мине кеше һәм гражданин буларак өлгертте. Венера бу арада Уфа нефть институтын тәмамлап, фәнни эшкә бирелде. Кияүгә чыкты. Ул хәзер – фән докторы. Профессор. Бер-ике тапкыр кыска вакытлы очрашуны исәпләмәгәндә, без бүтән очрашмадык. Әмма мин аның йөзен, аның җанының эчке һәм тышкы температурасын һәрвакыт тоемлап яшәдем. Без тоткан имани хакыйкатебез белән төрле кешеләр булганбыз. Мәхәббәт берәү булса да, аның кешелек юлларындагы маяклары һәм субъектлары санап чыккысыз күп шул...

Илле елдан соң без очраштык. Аны күрер өчен фатирына килдем. Ире белән улы да өйдә иде. Бу хакта мин «Илле елдан соң очрашу» дигән шигырь яздым. Ул кешенең ата-бабадан калган гореф-гадәтеннән баш тартып, нәселсез-затсыз калуы турында моңсу баллада. Менә ул:

Илле ел күрмәгәч, күрмичә түз.
Түзмәдем шул. Кердем. Тансыкка.
Һәм кинәттән Европаны ачтым
Компьютерга чумган карчыкта...

Чап-чал карчык... Мин таныдым. Ул – юк.
Гүя мин, отылмый ядәчкә,
Аны бер күрергә ат ялында
Килеп тә йөрмәгән Әнәчкә[1]!..

Гүя кими чиста күлмәген дә,
Чатнап чәчкә атканда шомыртлар,
Беренче хисләрдән шау исереп,
Ярсымаган булган өметләр!..

«Бу... сезме? – диде ул һушын җыеп. –
«Ирем – Саша... ә бу – танышым...»
«Таныш» диде мине, аттан төшми
Янып сөйгән тәүге табышым...

[1] Әнәч (икенче исеме Миякәбаш) – Венераның туган авылы.

Ә бу – улым Святослав була... –
Башын да бормады анысы.
Базар килгәч... Милек билгеләүче
Бизнес ачтык... Яшибез ярыйсы...»

Галия апа белән Әсхәт абзый
Ыңгырашты кебек кабердә.
Әнәч урманнары үкси-үкси,
Ятып аунадылар бәгырьдә...

Ә мин, шагыйрь, милләт милкен эзләп,
Табалмыйм, җан-канда буталыш!
«Матур сөйләп, читкә этсәләр дә,
Авыр әйтмә!» –диде бер тавыш.

Ят кавемгә иргә чыктың? Чык син.
Анысы аның «бик вак» мәсьәлә.
Вак мәсьәләләрне олыгайткан
Мәсьәлә бит менә нәрсәдә:

Иманыңнан, бисмиллаңнан чыкма.
Аннан чыгу – тукка чыгу ул.
Аннан чыгу белән җиргә чүгеп,
Нәселең белән юкка чыгу ул...

## Рауза

Бу минем иң кечкенә хикәятем булмакчы.

Тормыш үзе тудырган хикәят.

Хәкимова Рауза Әмир кызы...

Туган авылымнан мин яратып йөргән икенче кыз. Ул авылның аргы яктагы, Качаган очында яши иде. Миңа аларның тәрәзә капкачларына кадәр якын иде. Миннән ике яшькә зуррак. Коңгырт күзле. Кара-кучкыл йөзле. Гүя кояш нуры әллә каян түгел, нәкъ аның бит алмасыннан яктырып чыга. Тешләре вак. Ап-ак. Рауза торганы, тәне-гәүдәсе, хәтта хәрәкәтләре белән авыл кызы иде. Аны инәй бик тә ярата, хәтта кайвакыт «Мин сине Әмир Раузасына өйләндерәм», – дип әйтеп тә куйгалый иде. Үзем дә форсаты чыккан саен «Миңа авылдан ике кыз – Һәдия һәм Рауза ошый», – дип ычкындыргалый идем. Әмма ул ошаса да, нишләптер аның белән «соңга калыбрак йөри» башладым. Бу Каспийскийдан беренче тапкыр ялга кайткач, 1960 елның кышында булды кебек. Хафаса әбинең Фәүзияләрендә аулак иде. Аулак хуҗасы булып, аларның күршесендә яшәгән Рауза калган. Мин тальянымны күтәреп, бер атна буе шул аулактагы яшьләр уенында, кулымнан килгәнчә биеткән-җырлаткандай иттем. Бу Рауза белән якыннан беренче һәм соңгы тапкыр очрашу булган икән. Мин армиягә хезмәткә киткәч, икебезнең арада вәгъдәләребез әлегә бирелеп өлгермәгән булгач, әле ул хакта уйлап карарга да насыйп әйләмәгәч, җиткән кызлар тормышның табигый агымында туктаусыз ярәшүләр йоласына дучар була. Ул үзенә күрә шатлыклы күренеш. Раузаны да Тәтер-Арыслан авылыннан Рәис дигән бер бик уңган егеткә ярәшәләр. Рауза ялындырып азаплый. Ахирәтләре раславынча, ул миннән тәкъдим көткән. Әмма мин, хәрби хезмәттәге егет, ул чорда мондый җаваплылыкны үз өстемә алырга өлгермәгән булганмын.

Ниһаять, ике як, Горбачёв әйтмешли, «консенсуска килә» һәм Рауза Рәискә кияүгә чыга. Рауза аңа гомере буе ышанычлы ир хатыны булып хезмәт итте. Ялгышмасам, утыз елдан артык колхозның алдынгы савымчысы рәтеннән дәүләт бүләкләренә ия булды. Күптән түгел Рәисе тормыш белән хушлашып китеп барды. Аның белән өч бала, оныклар үстергән Рауза бүгенге көндә Тәтердә ялгыз яши.

Рауза турында уйланганда, Өязе буйларына кайткан кебек булам. Мәңгегә үтеп киткән яшьлекне кире кайтара алмау тойгысыннан елыйсыларым килеп китә. Рауза миңа яраткан кызым гына түгел. Ул табигатьне, Өязе буйларындагы өянке-талларны, андагы үләнлек-күрәнлекләрне, кошлар сайрауларын берләштергән катлаулы хис. Авылны бөтенләй югалтудан саклап калырга тырышу кичерешләре саклана анда. Кышкы бураннарда өянке башлары булып гүләшә алар. Раузаны аларның якты тәрәзә рамнары белән бергә сагынам. Аны гына түгел, туганнарын – тыйнак, тырыш һәм бик тә тырыш Хәкимовлар нәселен, шул исәптән нефтьче-галим Зәбир дустымны сагыныплар сагынам.

## Бианам туфрагыннан

Мин инәмнең гүзәл холкы-фигыленең сыйфатларын санап бетерә алмыйм.

Минем инәм туры сүзле иде.

Минем инәм якты йөзле иде.

Минем инәм сагынычлы һәм сагышлы иде.

Минем инәм аш-су остасы иде. Сугыштан соң, илленче еллар башында, тамагыбыз ипигә туйганнан соң, ул пешергән кош телләре, чәкчәк, бавырсаклар, мулла бәләкләре, катламалар, кыстыбый-кабартмалар, крәндилләр, бәлешләр, кызыл эремчек, корыт, сөзмәләр һәм башка камыр-сөт ризыклары телеңне йотарлык дәрәҗәдә тәмле булалар иде.

Минем инәм моң чишмәсе иде. Ул көйләмичә-җырламыйча эшләмәс иде.

Минем инәм бердәнбер ирен сугышта югалтып та, барлык малын дошманга каршы заёмга бүләк иткән ватанпәрвәр хатын иде.

Минем инәм аркаларын салкын мичкә терәп, җылы эзләгән һәм шул халәттә дә моңлы җырлар җырлаган дүрт ир баласын канаты астына алып юаткан сабырлардан сабыр ана иде.

Минем инәм хезмәтне шигърият биеклегенә күтәргән каһарман Хатын иде.

Минем инәм кеше өчен утка-суга керә торган батыр йөрәкле чын шәхес иде.

Минем инәм күз алмасы кебек бердәнбер сыерыбыз бозаулый алмыйча җан биргәндә, күз яшен утлы яшеннәргә яшергән ир йөрәкле Зат иде.

Минем инәм угрылар йортыбызга басып кереп, әйберләребезне урлап чыкканнан соң, шул угрыларның кайчан да булса ятимнәр өлешенә кергәнлеген аңлап, гафу үтенәчәкләренә инанган бер керсез Фикер Иясе иде...

Инәм улларының сөекле, таләпчән, йомшак күңелле, катгый бәгырьле анасы иде. Киленнәренә авыр чакта да авыр сүз әйтмәс, кешенең, аеруча

кайчандыр бөтенләй дә чит-ят булган, әмма хәзер гаиләи яктан туганлашкан, хәтта береккән кешенең беркайчан да күңелен биздермәс «икенче ана – биана» иде. Ул хакта замандашым, фикердәшем күренекле шагыйрь Фәрит Габдерәхимнең төрле матбугат басмаларында дөнья күргән шигыре дә бар. «Биана туфрагыннан» дип атала. Аның героинясы Венера Нәгыйм кызы Галимова (Хәлимова), минем «дүртенче йөргән кызым», ягъни өйләнеп, бүгенге көндә гомер иткән хәләл җефетем була. Шулай итеп, сүз авторга:

БИАНА ТУФРАГЫННАН

*Мәшһүр татар әдибе Айдар*
*Хәлимнең хәләл җефете Венера*
*ханымга*

Миңлесорур түтәйнеке кебек изге күңелең.
Исән булса, әйтер иде: «Иң яраткан киленем!»
Рәнҗетсәләр дә үзеңне, рәнҗетмисең беркемне,
Гел саваплы эшләр кылып үткәрәсең һәр көнне.
Сынаулардан булмый качып, язмыш, әйдә, сынасын.
Миңлесорур килене син! Инша Аллаһ, сынмассың.
Син бит, сеңлем, сабырлыкның коеп куйган һәйкәле.
Бу кадәрле җан җылысын каян алдың, әйт әле!
Яшеннәрдән, күкрәүләрдән, давыллардан качмадың.
Син бит Борис Хәлимовтан Айдар Хәлим ясадың.
Һәркемне якын итәсең, тиң күреп туганыңа.
Ифрат хак сүзләр: «Киленнәр Биана туфрагыннан...»

**Фәрит ГАБДЕРӘХИМ**

Рәхмәт, Фәрит абзый. Син минем «дүртенче йөргән кызым» Венерага шигырь багышлап, мине андый бурычтан коткардың.

## Тәхәллүсем тарихы

Тәхәллүсемнең тарихы болайрак. Үткән гасырның алтмышынчы еллары уртасында шигъри дөньяга беренче аваз салып, чагыштырмача танылган яки таныла башлаган яшь авторга, ягъни миңа була инде, «Нишләп син, шагыйрь башың белән «Борис» исеме йөртәсең?», «Нишләп син Борис дигән чит-ят исем алдың?!» дигән һәм башка сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләр ифрат та еш очрый иде. Мондый сорауларга ниндидер гаепле кеше сыман, аклангандай җавап бирүләр саруымны кайната башлаган иде. Мондый сорауларга җавабым да була алган, әлбәттә. Беренчедән, мәсьәләнең төбенә төшеп әйткән хәлдә, «Борис» рус исеме түгел. Ул – Барис, Барыйс дигән сүздән. Ягъни төрки-татар теленнән рус үзләштергән лексема – «Барс, Акбарс»тан килә. Ләкин без аны, үзебезнекен гел башкага «бүләк итеп» өйрәнгәч, кызганып тормаганбыз. Икенчедән, мин әдәбият өчен аерым исем – псевдоним алу турында уйлана, әмма конкрет адым ясарга базмый идем – ни дисәң дә, фронтларда ятып калган газиз атамның биргән исеме бит!.. Мин атам кушкан исемнән беркайчан да баш тартмаячакмын. Һәм баш тартмадым да. Туган-тумачаларым, нәселем өчен мин «Барис, Барыйс» булып калам. Һәм калдым. Һәм калачакмын да. Сүз әдәбият өчен генә алынган исем турында бара. Шагыйрьлек – кешегә төшкән сирәк бүләк. Сәләтеңнән килмәсә, икенче исем алып кына шагыйрь булып булмый. Син

ике исемне дә онытылмаслык итеп күтәрә алырсыңмы? Көчең җитәрме? Чамала. Бу – бик җаваплы мәсьәлә. Артыңда туган авылың, нәселең, халкың, укыган мәктәпләрең, хезмәт иткән эш урыннарың һәм башкалар, һәм башкалар алдындагы җаваплылыгың бар. Исем белән «уңарга да», «туңарга да» мөмкин. Әмма икенче исемем мәсьәләсе – куркыбрак торуым мин көткәннән күпкә җиңелрәк рәвештә хәл ителде дә куйды.

Ул болай килеп чыкты. Казан университетында укыганда, мин Профсоюз урамындагы Укытучылар йортына (хәзер анда синагога) – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәбиб Хәбибович Хәбибов (искиткеч сирәк туры килгән исем-фамилиясенә игътибар итегез!) – җитәкчелегендәге үзешчән театрда уйный идем. Ул көннәрдә без Гамир Насрыйның «Яшел эшләпә» спектаклен куя, мин анда баш рольне башкара идем.

...Язгы сынаулар вакытында Лобачевский исемендәге китапханәдә әзерләнеп утырган булам. Мин, тәмәке белән агуланган тәмәжник, ярты сәгать саен пыскытырга чыгам. Шулай бер тапкыр тәнәфескә чыккач күрәм, бакча яклап, яшел үләнгә җыйнак кына җәймәсен җәеп, танышым, минем белән Укытучылар йортының үзешчән театрында уйнаучы, минем кебек шардай яктырып килгән яшь пеләшенең бөдрәләрен җилдә тирбәтеп, телче, фән кандидаты Хәлиф абзам Курбатов китап укып ята. Күптәнге танышларча сәлам бирешкәннән соң безнең арада шундыйрак сөйләшү булып ала:

– Синең шигырьләрең миңа бик ошый. Ә менә исемең бер дә ошамый. Борис. Борис дигән татар шагыйре. Һм. Үзе үк капма-каршылык бит бу. Ал башка исем! Псевдоним ал! Тәхәллүс! Кинәнеп яз, рәхәтләнеп яшә!.. Татарда исем беткәнмени?!

– Ә ниндине? – дим, кызыксынып китеп. – Миңа дигән псевдонимнар юлда аунап ятмый...

– Менә Айдар дигән исем! Матур яңгырый бит. Тапталмаган, сирәк исем. Татарда бар. Башкортта да, хәтта казакъ, төрек, төрекмән, азәрбайҗанда да бар!.. Яз гына! – дип көлде ул.

Баш миемдә нәрсәдер ялт итеп кабына һәм басып торган җиремнән:

– Рәхмәт, яме! – дим дә ук булып аска, Бауман урамындагы Матбугат йортына таба атылам.

Матбугат йортының «Казан утлары» урнашкан икенче катына бер сикереп, ике атлап килеп керәм. Анда, мине көткәндәй, редакциянең шигърият бүлеге мөдире, шагыйрь Нури Арслан:

– Килүең бик яхшы булды әле, – ди, эчкерсез куанып. – Менә корректуралар килде. Укып китәрсең...

Бәхетле көннәр!.. Журналның сентябрь санында чыгачак шигырьләремнең корректурасын бик күрәсем килсә дә, җанымдагы борчылу тынгы бирми – псевдонимны Нури абзый кабул итәрме? Ул бит ифрат та милли рухлы кеше!

Дулкынланудан тирләп-пешеп, әле матбугатта беренче тапкыр чыгып барган «Колмак җыя кызлар», «Тальян моңы» дигән шигырьләремнең корректурасын ашык-пошык укыйм да шигырьләрне Нури абзамның алдына салам һәм имзасын көтеп ручкасын да куям...

Ул аптыраган карашлары белән укталып карый. Мин:

– «Борис»ны сызыгыз, – дим.

– Син чынлапмы?! – Нури абзыйның күзләре шар була. Ул мәсьәләне шундук аңлап ала. – Төптән уйладыңмы?

– Әйе.

– Кара аны. – Нури абзый «Борис»ны сыза.

– Хәзер «Хәлимов»ның «ов»ын сызыгыз, – дим.

Ул бүлмәне балкытып елмаеп җибәрә. Сүзсез канәгатьлек белән «ов»ны сыза, аннан кабат-кабат кабатлый:

– Айдар Хәлим... Паспорт буенча Хәлимов Борис Нәҗметдинович... Китап нәширләре өчен Айдар Хәлим... Һәйбәт бит! Бара бит! Хәерле сәгатьтә!.. Коттаем! – ди ул, казакъчага күчеп.

Мин менә шулай итеп, атам Нәҗметдиннең исемен-фамилиясен саклаган хәлдә, күренекле телче Хәлиф Курбатов табып биргән һәм остазым Нури Арслан күтәреп алган шагыйрь Айдар Хәлим булып киттем. «Колмак җыя кызлар» белән «Тальян моңы» мине Айдар Хәлимле итте. Хәзер инде мөхтәрәм тел галиме Хәлиф Курбатов та, сагынычлы шагыйрь Нури Арслан да юк, алар гына түгел, хәтта Бауман урамындагы барлык рус һәм төрки һәм башка милләтләрне җылыткан һәм гыйлемле иткән атаклы Матбугат йорты да, бөек Тукай яшәгән «Болгар нумерлары» да юкка чыгарылган. Сорамый булмый: кем тарафыннан юкка чыгарылган? Ни өчен? Урынлы сорауларга урынлы җаваплар гына юк.

Никадәр кызганыч!..

Минем өчен тәхәллүс алу дигән зур әһәмияткә ия бу вакыйга 1966 елның июнь аенда булды. Атам кушкан исемем белән янәшәдән икенче исем – тәхәллүс алу минем өчен Аллаһы Тәгаләдән төшкән табигый күренеш булган икән. Иң мөһиме – хезмәтләрең белән таныл. Минем бу тәхәллүс дигән төшенчәне акладым дип әйтерлек хокукым бар бугай. Атамның рухы, аның исеме һич тә рәнҗетмәстән, мине гомер бакый озатып йөрде. Атам биргән исем белән дә, җәмәгатьчелек табып биргән исем белән дә беркемгә һәм беркайчан да зыян һәм гаеп салмадым. Гомеремдә бөек бер разыйлык һәм шатлык белән бары тик кешеләрне куандырырга тырыштым. Бу хакта әдәби тәнкыйть тә үз сүзен әйткән. Татар әдәбиятының агымдагы тарихында мин, Айдар Хәлим дигән, тулаем һәм гомумән алганда, шагыйрь, прозаик, публицист һәм тәнкыйтьче, хәлемнән килгән барлык жанрларда шактый танылган әсәрләр тудырдым, дип раслый алам...

Үзем белән беррәттән туган-тумачаларым барысы да, Борис Хәлимов белән Айдар Хәлимгә бербөтен итеп карадылар һәм карыйлар. Шуңа күрә безнең авыл өстендәге йолдызлар эре һәм гадәттән тыш якты яналар кебек. Бер үк вакытта Кояшым һәм Аем, йолдызларым һәм галәмзат-планеталарым, тауларым һәм яланнарым, агачларым һәм үләннәрем, җир йөзендәге барча тереклеккә һәм җир астындагы барлык кара һәм кызыл балчык катламнарына кадәр берсе дә Беристан баш тартмады һәм Айдар Хәлимне чынлап та тере, ихластан да үзенеке итеп таныды. Мине сабый чагымнан, кулыма чыбыркы биреп, ашаткан-эчергән, минем белән бергә абыйларыма көтү дә көтешкән Мендәрле Кул дигән чишмәм дә беркайчан да Борисны читләтмәде. Әнә, юл буенда исән юлчыларга маяк булып утырган мәгърур Түгәрәк Имәнем мине каршыларга чыккан. Ул миннән исем сорамый. Җисем сорый. Бу хакта шушы яшькә җитеп, беренче тапкыр

аваз салам. Түгәрәк Имәнем янәшәсендәге басуларда көн җиләс. Биредә җилләр дә кайнар түгел, җиләс. Мин алар өчен яшәгән көндәлек шәхси һәм гомуми-иҗтимагый тормышымдагы язмышыма, аның көтелгән һәм көтелмәгән борылышларына тугры булдым һәм тугры калдым. «Йөзен күрмәгән улыма сәлам» дип хатлар язган һәм Бөек Җиңүгә дүрт ай кала фашистлар белән мыжгып торган Словакия тауларында дошман ядрәсеннән егылган һәм мәңгегә шунда ятып калган атам кабере гүя минем өчен Европа уртасындагы Зволен каласыннан якты шәм булып сүнми-сүрелми яктыртып җәйри...

Мин аның җәсәден, корбан булган хәлдә дә, Ватаныма кайтару, алып кайту мөмкинлегеннән мәхрүм идем һәм әле дә мәхрүм. Ул хәрби көрәштәшләре – Икенче Бөтендөнья сугышының барлык Чехословакия буенча җыелган меңләгән совет һәм румын солдатлары зиратында ята.

Аңа һәм корбаннарның барысына Түгәрәк Имәнемнең сагынычлы кочагыннан иманлы догаларымны юллыйм...

## Түгәрәк имән җылытты

Түгәрәк Имәнебезне үз гомеремдә күп тапкырлар телгә алырга һәм аның турында күп тапкырлар язарга туры килде. Ул, табигать калкулыгында үсеп утырган «гади агач», үз күркен кеше күркедәй югары мәртәбәгә куя. Җир йөзендәге барлык халык һәм милләтләр, үсемлекләр һәм һәммә төр агачлар, кайсы илдә, кайсы кыйтгаларда булуларына карамастан, аңа карата рәхмәт, ихтирам һәм зурлау тойгыларын саклый һәм яклый.

Имәннең кәүсәсендәге боҗраларын санамый торып, яшен төгәл билгеләү мөмкин түгел. Җир йөзендә аны саный алырлык һәм төгәл итеп ачыкларлык көч бар микән? Боҗраларының санын ачыклыйбыз, аның гомеренең озынлыгын билгелибез дип, тәүбә-тәүбә, аны «аяктан егарга», кисеп аударырга тырышкан очраклар булмады түгел, булгалады. Агачның яшен беләбез дип, кәүсәсеннән аудару – аны турыдан-туры юкка чыгару, ягъни үтерү булыр иде. Түгәрәк Имән халык тормышы белән кендегебез кебек аерылгысыз бәйләнгән. Аның табигый абруе дөньякүләм масштабта расланган. Түгәрәк Имән язмышына кагылышлы һәр шылт иткән тетрәнеш, һәр адым, кечкенәме ул, әллә бик зурмы, Берләшкән Милләтләр Оешмасы һәм аның мәдәният мәсьәләләре буенча вәкиле – ЮНЕСКОда исәптә тора һәм бары тик аларның рөхсәте белән башкарылырга тиеш. Үткән гасырның илленче еллары уртасында колхоз җитәкчелеге карары белән басу җирләрен «чүпләп утырган» агачлардан, бу уңайдан, Түгәрәк Имәннән һәм хәтта аның кебек сирәк реликвияль исемлеккә кергән агачлардан тазарту бурычы куела. Имәнне төбе-тамыры белән төпләргә дип ажгырып килгән бульдозерга Кәркәлетамак авылының гадиләрдән дә гади аксакалы – төбәкнең үзешчән тарихчысы, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы ветераны Газиз Мөхәммәтвафа улы Вафин балта күтәреп каршы чыга һәм саклап кала.

Аксакалның шушы җаваплы мизгелдә тракторчы егеткә әйткән сирәк сүзләре бүгенге иген кыры уртасында дөньяның иң атаклы опера ариясе кебек яңгырый:

– Әй углым!.. Бу Имәнгә беркайчан да кул күтәрәсе булма! Аның яшен беркем белми. Без әле исән чакта ул безнең өчен мәңгелек! Син дистәләрчә канкойгыч сугышларга Туган Илебезне яклау, саклау өчен үзләре белән истәлеккә куен кесәләренә шушы тарихи имәннең яфракларын алып, шушыннан яуга киткән һәм яу кырында ятып калган миллионнарча корбаннарны бирегә кайтар, алар алдында Имәнне тамырлары белән төпләп ташларга базнат иткәнең өчен тезләнеп гафу үтен, ирсез калган ятимә хатыннарны, кияүгә чыкмый калган яшь кәләшләрне, әле өйләнешергә дә өлгермичә һәлак булган яшь егетләрне дә бирегә китер һәм аларны да Түгәрәк Имәннең уңдырышлы туфрагына тезләндереп, сине һәм синең кебекләрне матур яшәргә һәм мул иген үстерергә рухландыр! Түгәрәк Имәнеңне сакла! Мәңгегә сакла! Ул сине саклый! Ул синең табигый бәхетең!..

Газиз Вафинның үткән юлларын язу, фаҗигале язмышын сурәтләү өчен бихисап китаплар язарга кирәк булыр иде. Моннан чирек гасыр элек аның һәм авылдашларым, Дим-Өязе тарафларыннан булган якташларым турында «Минем Түгәрәк Имәнем» дигән тарихи-публицистик хезмәт язган идем. Халык тарафыннан ул бик яратып кабул ителде. Андагы мәгълүматны кабатлап тормыйм. Теләгән кеше китапханәләрдән табып укый ала. Кирәкле детальләрне мин язмаларымның ошбу урыны таләп иткән микъдарда гына кабатлап китәм. Газиз бабай, әйткәнемчә, гражданнар сугышы аша да, Бөек Ватан сугышы аша да үтә. Әйтүе генә җиңел: ул хәрби хезмәттә сигез ел була. Шулай туры килгән, диярсең, ул хәрби хезмәттә еллары санынча, ел саен бер тапкыр, ягъни сигез тапкыр яралана. Менә ул каршымда, Түгәрәк Имән алдында, Ырынбурның ерак Җаек, Тукчоран якларына карап басып тора. Калган 156 авылдашы белән бергә фронтка аны биредән Түгәрәк Имән озатып калган. Алар белән шушы бердәнбер имәннең 156 яфрагы да киткән сугышка. Шуларның 83е яу кырларында ятып калган. Нәселләр арасында иң күп һәлак булып кайта алмыйча калган яфраклар – Хәлимовларныкы. 13 данә.

Алар арасында минем атам да бар.

Алар арасында гражданнар сугышы кызылармиясе, Бөек Ватан сугышы герое, полковник дәрәҗәсенә ия булган нәселдәшем, олуг хәрби командир, полковник Мәҗит Гайнулла улы Хәлимов та бар. Бу нәсел аерым бер китапка лаек. 1919 елдан компартия әгъзасы, бригада комиссары, дивизиянең политбүлек начальнигы, 28нче армиянең тыл начальнигы урынбасары. Ростов янында авыр яраланып, тәненнән 22 ярчык алалар.

Бу – аның белән бергә Түгәрәк Имән дә 22 тапкыр яраланган дигән сүз.

Ул ике тапкыр Ленин ордены, ике тапкыр Кызыл Байрак, икенче дәрәҗә Ватан Сугышы, ике тапкыр Кызыл Йолдыз орденнары һәм башка бик күп медальләр белән бүләкләнгән.

Әмма авылда икенче «истәлек»не дә яхшы хәтерлиләр: утыз җиденче елның хәтәр сыйнфый чечләсендә аның белән бергә уйнап үскән «авыл малае», көнчелеген кая куярга белмичә, СССР Кораллы Көчләренең Генераль штабына «Мәҗит Хәлимовның бу званиегә лаек түгеллеге, аның «кулак баласы булуы» турында «сигнал» җибәрә. Килеп җитә сигнал. Аның шаукымы булып, Мәскәүдән авылга комиссия дә килеп төшә. Уттай эш

өстендә халыкны җыеп, клубта җыелыш үткәрәләр. Расланмый сигнал. Халык аны, урта хәлле игенче баласын, яклаган.

Бөек Ватан сугышын башыннан азагына кадәр үтә ул. Тагын берничә тапкыр яраланып, госпитальләрдә ята. Җиңү бәйрәменнән соң Германиянең Мекленбург һәм Көнбатыш Померания җирләренең коменданты урынбасары вазифасын башкара.

Әйтелгәнчә, каты сугышларда тәнендә ярасыз урыны калмаган Мәҗит абый 1947 елда отставкага чыга. Түгәрәк Имәнебез яраткан улын кулыннан җитәкләп диярлек Ватанына кайтара. ДОСААФның Башкортстан Өлкә комитетын җитәкли. 1955 елдагы вафатына кадәр шушы җаваплы хезмәтне башкара. Миңа бәлки ун яшьләр булгандыр, ул туган авылыбызга кайтып китте. Безне, балаларны, машинасына утыртып йөртте... Безнең, ул чакта мондый «хәрби вездеход» түгел, гади машина да күрмәгән авыл баласының никадәр куанганын күз алдыгызга китерсәгез иде!

Түгәрәк Имән аның җәсәден туган авылына алып кайтты. Атасы Гайнулла бабай 104 яшькә җитеп, шулай ук Түгәрәк Имән туфрагында җирләнде. Аның икенче улы, Мәҗит абыйның энесе Габдулла абый, сугышта һәлак булды. Өченче улы Әхәт тә, фронтлар аша үтеп, капитан дәрәҗәсендә иленә кайтты. Дүртенче улы Әгъләм дә сугышларда катнашты. Бишенче улы Кәррам, Яңа Уфа нефть эшкәртү заводының цех начальнигы, «Башкортстанның атказанган нефтьчесе» исеменә лаек булды. Алтынчы улы Рифгать гомере буе Стәрлетамакта эчке эшләр бүлегендә эшләде. Җиденче балалары Яүһәрә нефть эшкәртү заводында өлкән лаборант булып, лаеклы ялга чыкты. Болар барысы бер гаиләдән – Гайнулла бабай һәм Мәбрүрә әби балалары бит!

Менә кемнәрне үстереп бирде Түгәрәк Имәнгә безнең нәсел асабабыз Гайнулла бабай Хәлимов!..

Менә кемнәрне үстереп бирде илебезгә безнең Түгәрәк Имәнебез!..

«Европада татар каберләре» дигән шигырем нәкъ безнең нәсел турында язылган дип уйларсың. Мәҗит Хәлимов белән авыл мәдрәсәсендә бергә укыган Газиз Вафин исә сигез тапкыр үлемнән калган да, сигез тапкыр Түгәрәк Имәненә кайтып, көч алып килгән. Имән аны баш очында басып торып саклаган һәм фронттан 67 исән кайтучының күкрәк кесәләрендә исән кайткан 67 яфракны санаган. Сугышларда бу кадәр җимереклек-теткәләнүләр кичкән адәм баласының ничекләр итеп исән йөреп ятуы гына түгел, дөнья күтеп ятуы мөмкин?! Газиз бабайның һәр ярасы, һәр җәрәхәте Европа парламентларына шаһитлык җибәрер дәрәҗәдә абруйлы медицина комиссияләре тарафыннан расланган. Янбашы җимерек. Бер бөере юк – алып ташланган. Теш казнасы җимерелгән. Уң аягының тез башы шулай ук җимерек. Чатанлап йөри. Сул кулы юк – өздергән. Ике сул кабыргасы һәм сул як күкрәк читлеге шулай ук алып ташланган. Ике тапкыр аңын югалтып, контузия кичергән...

Түгәрәк Имәннең чын яшен беркем белми. Халык аның үз тарихындагы зурлыгын, олылыгын гына белә. Аның ябалдашы циркуль белән сызган әйләнә кебек түгәрәк.

– Гүя аңа кемдер югарыдан боерып, шушы түгәрәктән чыкмаска кушкан, – ди аксакал. – Үземне белә башлагандагы йөзьяшәр бабайлар да аны

шушындый түгәрәк һәм шушындый зурлыкта иде дип әйтәләр иде, – дип дәвам итә сүзен Газиз бабай. – Минем фикеремчә, Түгәрәк Имәнебезгә өч йөз яшьтән дә ким түгел... Хәзер менә минем күз алдымда гына да ул йөз елга якын яшәп өлгерде... – дип елмаеп ныгыта Милләт Бабасы үзенең фикерен...

Авылым Түгәрәк Имәнгә өч үр аша күтәрелә. Өч үр – өч сынау.

Хезмәттә һәм яуда. Беренче үр.

Акылда һәм мәгариф-мәдәнияттә. Икенче үр.

Җыр һәм моң – иҗатта. Өченче үр.

Беренче үргә күтәрелгәндә, ул үз юлы белән үзе каплана барып, шактый вакыт күренми тора. Ниһаять, үрнең иң биек ноктасына җиткәч, кинәттән борынгы бабаларыбыз бәйгеләрдә ыргытып уйнаган таш ядрә-дисколга әйләнеп канатлана да киләчәккә оча. Биредә беренче үргә күтәрелгән юл төйнәлә. Ул «Кыргыз юлы» дип атала. Биредән татар һәм кыргыз-казакъ кардәшләребезнең кәрваннары Казанда басылган дөньяви китап-әсбаплар, Коръәни Кәрим һәм башка иман шартларын төяп, көнбатыштан – көнчыгышка, көнчыгыштан көнбатышка үткән.

Мин шушыннан башланган иң озын үрне авылдашларым – «Әткәмнәр үре» дип атыйм. Алар биредә атларыннан төшеп, Түгәрәк Имән белән, гаиләләре, бала-чагалары, туганнары белән хушлашканнар. Имәннең яфракларын күкрәк кесәләренә салганнар. Бу яфракны минем әткәм дә үзе белән алган. Нәрсәләр турында уйланган икән ул бу минутларда? Нәрсәләр әйтергә теләгән иде икән фронтка киткәндә, шәхсән миңа, «йөзен күрмәгән» улына? Бу үрне «Җиңү үре» дип атап булмый. Ул югалтулар үре. Хушлашулар үре. Кем белә, ул бәлки мәңгегә хушлашу үре дә булыр, дип чыкканнар алар бу җаваплы юлга.

Бу әнкәм тарткан бәләкәй чанада әткәмне күрер өчен Абдуллин тарафына юлга чыккан үрем. Ул мине Икенче үргә – Татарстан белән Башкортстанны бердәм сыйдырган үргә алып чыккан. Алар минем кулыма кашык тоттырып, ач итмәгән. Ашаткан-эчергән, киендергән, укыткан, югары белем биргән.

Алар мине сау-сәламәт килеш Өченче Үргә – барлык дөнья үренә алып чыккан. Мин бу язмаларымны да шушы гомуми үрдән торып язам. Аллага шөкер, телем исән. Җаным-иманым исән. Тәнем исән. Исән булырга тиеш. Түгәрәк Имәннең сугышлардан кайтмый калган яфраклары миннән һәм барлык дөньядан нәкъ шул телемнең, нәкъ шул җаным-иманымның, нәкъ шул тәнемнең исән саклануын таләп итә. Мин алар өчен башым белән җавап бирәм...

Китапның беренче, инәмә багышланган өлеше, укучым үзе күреп-укып инанды, бер инәм белән генә чикләнми. Ул, гомумән, сагынуга – әткәмә дә, нәселемә дә багышланган. Әнкәм өлешен чын-чынлап истәлекләр, хәтерләүләр дип атарга мөмкин. Һәм шулай атарга кирәк тә. Чөнки аларда сурәтләнгән сюжетлар әнкәм белән минем арадагы конкрет вакыйгаларга нигезләнгән. Алар тормыш агышы, хәрәкәт һәм тарих тупланышына бәйле. Ә менә хәзер әткәмә багышлап язарга җыенган өлешен нәрсәләргә нигезләнеп язарга? Боларда бит хәрәкәт тупланышы, хәтер дигән мондый бөек байлык юк. Мин бит – аның «йөзен дә күрмәгән» улы. Сурәтләр өчен хәрәкәт истәлеге кирәк, ә биредә хәрәкәт була алмый. Мин «хәтерсез».

Истәлексез. Бу нинди куркыныч халәт! Үзем бар, Түгәрәк Имәнем бар, ә минә, нихәл итәргә, истәлегем, ягъни «хәтерем юк». Бу хәтерне миннән бишек биләвендә яткан чагымнан ук фашизм тартып алган. Мине ятим, бер канатлы иткән. Мин киләчәккә оча алмыйм. Талпынып, сыңар канат белән очарга тырышып карыйм да, икенче канатым да ярдәм итмәгәч, лапылдап, кара җир өстенә егылып төшәм. Бу минем сугыштан алган иң зур югалтуым...

Тыңла, тарих, хәтерсез килеш сине эзлим!..

Аның, әтиемнең, хәтерләвемчә, ике фотосурәте бар иде. Алар ул замандагы тормыш өчен ятрак – галстукта төшкән интеллигент кыяфәтендә иде.

Сугыш яланыннан җибәргән хәрби фотосы юк. Булса, хәтерләр идем. Фотоларга төшеп калу өчен анда, мәхшәр эчендә, тын алырлык та форсат булмагандыр, дип уйлыйм.

Әтиемнең тормышта нинди киң күңелле кеше булуын фронтка китәр алдыннан кылган гамәлләре генә дә ап-ачык исбатлап тора... Аның юмартлыгы турында туган ягыбызда әле булса хикәят-риваятьләр яши. Аларны үзе укыткан укучылары гына түгел, укучыларының укучы балалары, ягъни балаларының балалары буеннан буынга тапшыра килә иде. Дистә еллар буе атамда укыган укучыларының «Мине Нәҗметдин абый укытты!» дип горурлануларын беркайчан да онытмам. Бу горурлык миңа, мин укыган мәктәпләр бусагасына изгелек булып кайта килде. Менә ничек була бит ул!.. Сугышка китәр алдыннан ул авыл балаларын өенә җыеп, чәчләрен ала: кайсын плитуа (бритва) белән кырып, кайсын авылда тик аңарда гына булган машинка белән төптән кистереп. Аннан – авылда бары тик аңарда гына була торган хушбуйны чәче алынган такыр башларына сиптереп. Аннан үзенең өлкән яшьтәге ятим балаларга ярарлык киемнәрен тарата. Үз балаларына бары тик ике күлмәген, бер чалбарын һәм ак тунын гына калдыра. Ул тунны яхшы хәтерлим. Ул сәке өстендәге чөйдә эленеп тора, без күрше балалар белән качышлы уйнаганда, шул тун эченә кереп кача идем...

– Кеше балаларына үз балаларың киемнәрен таратып, үзеңнекеләрне шәрә итәсең түгелме, Нәҗметдин? – дигән аңа инәй. – Фронт үз балаларыңа да киләчәк бит!..

– Дөрес әйтәсең, әнкәсе, – дип җавап биргән аңа әтәй. – Фронт аларга килде инде. Әмма минекеләрнең әле яннарында аталары бар – мин бар. Нәрсә, булган кием-салымымны кулыма учмарлап утырып, ятимнәрне шәрә йөртимме?! Мин булганда, аларның берсе дә шәрә дә, ач-ялангач та булмас, Аллаһ боерса!..

Бу үзе хәтер дигән сүз түгелмени?!

Әткәм, тере булмаса да, ул бар!

Минем хәтерсез буласым килми!

Әткәмнән хәбәрсез буласым килми!

Мин аны эзләп, үләннәргә, яланнарга, басуларга, тауларга-ташларга, чишмә-елгаларга, соңгы чиктә, кешеләргә мөрәҗәгать итәм. Алар сөйли, алар атам турында нинди микъдарда белсә, шул микъдарда алар әткәм турында миңа да сөйли...

Риваятьләр раславынча, чыгышым белән мин Пугачёв каторжнигы Әкри (Әкрәм) нәселеннән. Җиде буын бабамнарның килеше Әкрәм-Габделхалыйкъ-Габделхәлим-Габделгалим-Габделвәли-Нәҗметдин-Борис була инде. Минем атам Нәҗметдин Габделвәли улы Хәлимов 1905 елда Җилдәр олысының Кәркәлетамак (икенче исеме Бәләкәй Кәркәле) авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Картинәм Гайнекамал, чыгышы белән күрше Олы Кәркәле авылыннан аеруча хәлле Фәррәхетдин Рәхимкулов кызы. Әткәм егерменче еллар уртасыннан 1942 ел башына кадәр укытучы булып эшләгән. 1941 елның маеннан ВКП(б) әгъзасы. Кәркәлетамак, Качаган, Баязит, Канбәк авылларында балалар укыткан. 1940 елда Бәләбәй педагогия училищесын тәмамлаган. Әнием Минсорур Шиһабетдин кызы Хисамова белән 1928 елда өйләнешкән.

Гаиләдә барлыгы алты бала дөньяга килә: Гали (1930), Нияз (1934; 1946 елгы ачлыкта үлә), Ингель (1936), Зыя (1938; үлә), Ләлә (1940; үлә), 1942 – мин – Борис Нәҗметдин улы, булачак Айдар Хәлим туам...

Әүвәлдә ул Тамбовтагы кече политсостав командирлары курсларында укый. Аннан курсларны Воронеж фронтына күчерәләр. Бу турыда архивта кызыклы документ сакланган:

*«В приказе войскам Воронежского фронта по личному составу № 020/ п от 31 января 1943 года значится:*

*«...окончившим курсы подготовки политсостава при Политическом управлении фронта присвоить воинские звания:*

*«лейтенант»*

*8. Халимову Низм (так в приказе) Абдуловичу»*

*ОСНОВАНИЕ: оп. 2847, д. 127 л. 32*

*Личного дела на ХАЛИМОВА Н.А. – на хранении нет.*

*Начальник 6 отдела ЦАМО СССР ПУЗЕНКО.*

*Печать, подпись».*

Шушында ук Архивның 6 бүлеге начальнигы Красильников биргән икенче документ:

*«Его личного офицерского дела на хранении в Архиве МО нет.*

*По учёту погибшего и пропавшего без вести рядового и сержантского состава СА ХАЛИМОВ Н.В. не числится.*

*В списке от января 1942 года на учётные карточки коммунистов, выбивших по мобилизации в советскую Армию из Миякинского РК Башкирской АССР значится:*

*«ХАЛИМОВ Назмий Валиевич, партбилет № 3705491».*

Безнең татарда кушма исемнәр еш кына эшне үтә дә катлауландырып куя. Милли исемнәрне кулланган чакта рус телле генә булган «телсез» писарьларның татар-башкорт исемнәрен бозып язган очраклары тулып ята. Мәсәлән, бер урында атасының исеме «Габделвәлиевич» дип алынса, икенче урында «Абдулович», өченче урында «Валиевич» дип алына. Миңа атам зиратын эзләгән чорда, аның үз исеменең «Назмий», «Назмий Валиевич», «Низм» рәвешендә, атасының «Габделвәли-Абдулвали» исеменең «Абдулович», «Абдулвалиевич», «Валиевич» дип алынган очракларын да очратырга туры килде.

1944 елның май азагында фронттан картәтиемнең өлкән улы – зурәтием Әхмәтвәлинең һәлак булу хәбәре килә. Җитмеш яшь өстендә паралич сугып еккан картинәм бу кайгыны күтәрә алмыйча тормыш белән хушлаша. Шушы уңайдан әтием язган хаттан бер өзек китерик. Аның сәйлән кебек җыйнак сүз-җөмлә төзелешләренә игътибар итегез, туганкайларым, ул – торганы белән язучы!.. Минем язучылыкка тартылуым атам сәләтеннән килгән икән бит!..

«...Шунысы йөрәгемне өзә: мине табып үстергән әнкәмнең вафат булды дигән хәбәрен, бер анадан туган агам Әхмәтвәлинең һәлак булды дигән хәбәрен аңлаткан җөмләне укый башлагач, йөрәгем калтырап, хәлем бетеп, басып торган урыныма утырып, шул сүзләрне аңлаткан җөмләне кабат-кабат укыдым. Һич күңелем ышанмый, үткән гомер, рәхәт үткән көннәр күз алдыма килеп, кыяфәте белән юаш булган изге агамны, кешеләргә дөньяда бер генә булган газиз әнкәмне кызганып, күземнән яшьләр тамганчы 13 июньдә язган хатыгызны укыдым. Әйтергә генә ансат: агамның биш баласы, минем дүрт балам бер җитмеш яшьлек карт тәрбиясендә калды...»

Икенче хатын ул шушы ук дулкында дәвам итә. Анда үзенең – ата-ана баласының һәм шәхси аталык тойгысының сагышы чагылыш тапкан. Ул гаиләсе өчен өзелепләр өзелә. Мине дә телгә ала. Бомбалар астында, тарихта бердәнбер тапкыр булса да, мине телгә алып өлгергән! Бу, үзе әйтмешли, исемемне «кайгы катыш» бер тапкыр телгә алынып кала алуыма быел 79 ел була. Ягъни бердәнбер сүзнең – исемемнең атам тарафыннан телгә алынуының Җитмеш Тугыз Еллык датасы. Бу минем кайгылы симфониям. Ятимлек метрикам. Ятимлек паспортым.

Анда хатны сирәк язган (яздырган) җәмәгатенә – инәмә үпкәсе дә бар. Хатны тулысы белән китерәм:

*«Сау гынамы минем кадерле семьям!*

*Фронттан – окоптан кадерле әтиемә, иптәшем Сорурга, газиз балаларым Гали, Нияз, Энгельгә, Бориска миннән аталарча кайгы катыш сәламнәремне җибәрәм. Минем өчен ачык түгел, әни мәрхүм озак чирләдеме, нинди чир белән чирләде, чирләгәндә тамакка аптырамадымы, үлгәндә теле булдымы? Мине искә алдымы? Ничек җирләдегез? Әти мескен дә сәламәт түгелдер инде, эшкә йөриме? Абзыйның үлгәне кайчан килде, әллә үзе белән булган иптәшләре яздымы? Әти! Хәлең ничек? Авырмыйсыңмы? Көчең җитмәгән эшне башкарырга тырышма. 70 яшьтәге картны көчләмәсләр. Балалар янында бул. Аларның күңелен тап. Әти, сиңа бик авыр хәл, мин аңлыйм, нишлибез соң? Бәхетле кешеләр туган илендә семьясы белән. Белмим, ул көннәр безгә насыйп булырмы? Сыер зыянлаган икән, анысы дөнья малы, сыерның нәселе калдымы? Акка бик аптырыйсыздыр инде. Ашау яклары ничек?*

*Гали улым! Миннән озак хат булмаганга аптырамагыз, сугыш хәле бит. Инәң мине бер дә искә алмый мәллә? Инәң минем хакта, үзе хакында хатына бер нәрсә дә язмаган. Хатка Энгельдән, Бористан сәлам язмагансыз, әллә алар исән түгелме?*

*Нияз улым! Үз кулың белән бәләкәй генә булса да хат яз, исән булсам, кулъязмаңны күрермен. Улым, язарга сүзләрем күп иде, һушым таралды.*

*Хатны язганда, күп итеп яз. Бу хатымны туп, снаряд тавышлары астында окопта яздым. Снаряд ярылудан язган кәгазем өстенә туфрак төшеп, кәгаземне каралтты.*

*Сорур!*

*Мине оныттың мәллә? Гали улым булмаса, миңа хат язучы да булмас иде. (Румын телендәге бухгалтерлык хисап кәгазенең чиста ягына язылган хатның читенә әти өстәгән):*

*Мин язарга...(сүз җуелган) Сездән аерылганга тиздән өч ел була. Авыл хәлләрен барын да ишетәсем килә. Әллә оныттыңмы? Ярый, хат яз. Рәхмәт, улым Гали, хат язуыңа. Хатны еш яз! (Румын телендәге шул ук кәгазьнең буш урынына ул тагын да өстәп куя): Авылда кемнәр укытучы, үткән хатымда да сорап язган иптәшләрнең исәнлекләре хакында язгыз. 1943 елның февралендә 2500 сум акча салган идем, шуны алдыгызмы? Нияз ничек укый? Елларның килеше ничек? Бәрәңге чәчтегезме? Печән чабарга тырышыгыз.*

*Үзем фронтта. Хәзергә саумын. Сагынып, кулыгызны кысып калучы, әткәем – улың (Нәҗми). Яздым 25.VI.44.*

*Сорур, мине бар дип танысаң, мөмкин булса, үзеңнең, балаларның рәсемен җибәр».*

Кайгылардан иртә картайган инәмнең иртә үлеп китүе, үземнең яшьлегем, киңәш бирерлек кешем булмау аркасында күп нәрсәләрне вакытында сорашып-белешеп кала алмадым. Бу хакта күп тапкырлар телгә алырга туры килде. Гаилә архивы, хатлар, кирәкле документлар, хәтта әтәйнең үлемтек кәгазе дә (похоронка) абыйның сабый балалары кулына эләгеп юкка чыккан. Бу хакта язган идем. Әтәйнең кайда үлүе-күмелүе турында эзләнүләремне үткән гасырның алтмышынчы еллар уртасында ук башлаган идем. Әмма хәрби архивлар үзләренең дистәләгән җавапларында гади «отпискалар»дан башка бер генә дә ышанычлы мәгълүмат табып бирә алмый иделәр. 1974–1987 еллар арасында мин Подольскийдагы Үзәк Архивтан дистәләгән «Нет, не значится»дан башка уңай хәбәр ала алмадым. Дөрес, Архивның бүлек мөдире подполковник Костылёв әле миңа 1967 елда ук «Сообщаю, что по учётным данным отдела рядовой Халимов Назим, 1905 года рождения, значится погибшим 15 января 1945 года. Похоронен: Чехословакия» дип җавап биргән иде. Әтәйнең Чехословакияда үлгәнлеге миңа элек тә билгеле булса да, биредә җавапларга караганда сораулар күбрәк иде. Ни өчен «Назим»? Ни өчен «рядовой»? Ул бит офицер булган! Җитмәсә, ул бит әле коммунист кеше!

Эзләнә торгач, «озын арбада» әтәйнең Воронеж фронтының кече командирлар комсоставы курсларында укуы турындагы үзе җибәргән белешмәсе табылды. Читендәге штампы бик һәйбәт укылса да, текстының бер генә сүзе дә укылмый. Башкортстан прокуратурасының криминаль-тикшеренү лабораториясе егетләре, рәхмәт, анысын да укып бирделәр. Анда түбәндәге хәбәрләр теркәлгән иде:

*«Для кадрового состава КА*

*Дано Халимову Назми Абдуловичу в том, что он состоит с 10 января*

*1942 года на действительной военной службе в кадрах Красной Армии в должности курсанта курсов политсостава.*

*Справка дана для получения т. Халимовым Н.А. и членами его семьи льгот, установленных кодексом (бу сүз анык укылмый – А.Х.) о льготах для офицеров, солдат и сержантов К.А. и флотов.*

*Удостоверение действительно по 1 мая 1943 года.*

*Нач. штаба курсов гв. лейтенант Лихацкий (Имза) »*

Мин бу белешмәне Подольскийдагы Үзәк архивка юлладым. 1973 елның ноябрендә мине Уфаның Ленин районы военкоматына чакырттылар. Һәм җавапны, ничек сәер тоелмасын, кулыма бирмичә, текстны пышылдагандай итеп кенә, телдән әйтеп торып яздырдылар:

*«Стрелок 13 гвардейского стрелкового полка 1 гвардейской воздушно-десантной дивизии, рядовой Халимов Назим, 1905 года рождения, уроженец Башкирской АССР, призван в ряды Красно-Окнянским РВК Одесской области. погиб 15 января 1945 года г. Модри-Камень, 3 км. севернее высоты 503. Чехословакия.*

*Жена – Халимова Срульшиль, проживает – Башкирская АССР, Маяковский район, с. М. Каркалы.»*

Мине күпме таң калырлык «яңалыклар» көткән! Биредә сүз һичшиксез әтәй турында бара.

Тик... нигә стрелок? Әтәй – элемтәче. Нигә рядовой? Әтәй офицер булырга тиеш. Нинди Красно-Окнянский район Одесской области? Ул нинди «Маяковский район»? Киргиз-Миякинский район булырга тиеш. Одесса өлкәсеннән «Бездә андый район юк» дип җавап бирделәр. Иң кызыгы, инәй турындагы мәгълүматлар тулаем туры килә иде. Срульшиль – Сорур Шигаповна. Авылыбыз да урысча шулай йөртелә: «Малые Каркалы». Красно-Окнянский – әйткәнемчә, Одесса өлкәсенең Красно-Окнянскиенә әйләнгән Киргиз-Миякинский булып чыга инде ул! Мин Чехословакиянең Мәскәүдәге илчелегеннән Модри-Камень дигән бистәнең илнең кайсы тирәсендәрәк булуын ачыклауларын теләп хат юлладым. Илнең консуллык бүлеге мөдире Г. Ветенгль әфәнде «...г. Модри-Камень находится в районе Лученец Словацкой Социалистической Республики на половине расстояния от Праги до пограничного пункта Черна над Тиссоу. Более точные данные о захоронении Вашего отца могут дать в районном национальном комитете города Лученец или в Чехословацком союзе борцов против фашизма этого города», – дип җавап бирде. Лученец шәһәре җитәкчелегеннән дә, ««Фашизмга каршы Чехословакия союзы»ннан да шундый ук эчтәлекле җаваплар алдым. Атамның зиратының кайда икәнлеге ачыкланды кебек. Ләкин әле алда иң мөһим бурыч тора иде – аның ничек үлгәнен ачыкларга кирәк! «Миякинский»ның ничек итеп «Красно-Окнянский»ларга әверелүенең төбендә нинди сер ята?..

Эзләнүләр дәвам итте. 1979 елның җәендә Уфага Словакия компартиясенең үзәк басмасы булган «Правда» газетасының үзхәбәрчесе Рудольф Ниттман килеп китте. Мин аның белән очрашып, атамның анык булмаган язмышын сөйләдем. Ул атам турында өстәмә материаллар да соратып алды. Күп тә үтми словак туганнарның «Правда» газетасында Рудольф Ниттманның (1979 елның 17 август саны) минем атамның каберен

эзләвем турында мәкаләсе дә басылып чыкты. Ул миңа бу санны берничә данә җибәрде дә.

Шунысы кызганыч, әтәйнең партия билетының номерларына кадәр билгеле булса да, ул һәлак булганнан соң теркәү карточкаларының ничек гамәлдән чыгарылуы турында партия архивларыннан һаман да бернинди мәгълүмат килми-күренми иде.

1983 елның сентябрендә мин Башкортстан Язучылар берлеге тәкъдиме белән СССР Язучылар берлегенең Мәскәүдәге ике еллык Югары Әдәби Курсларына укырга килдем. Ике ел вакытымны әтәй язмышын мөмкин кадәр тулырак ачыклауга багышларга булдым. Моның иң дөрес, хәтта бердәнбер юлы – матбугат, Мәскәүнең берәр үзәк газетасында, атап әйткәндә, «Правда» газетасында чыгыш ясау иде. Шактый зур сынаулар, сабырлыклар аша үтеп, минем туган ягыма багышланган «В середине земли» дигән очеркым, ниһаять, 1985 елның 26 февраль санында «Правда» газетасының чит илләр өчен чыга торган иң зур – 16 миллион тиражлы санында дөнья күрде. Материал, бу санның иң уңышлы язмасы булып танылып, махсус премия белән бүләкләнде.

*«...Щедры, красивы душой наши люди – и это от тебя, Круглый Дуб,* – дип язганмын мин анда. *– На твоих листьях – сотни фамилий и дат... Вышло так, что отец ушел на фронт, не увидев меня. Мать, едва окрепнув, решилась ехать к нему в прифронтовой городок, чтобы показать сына. Отец взял меня, двухмесячного, на руки и сказал, посветлев: «Похож. Пусть будет учителем, как я». И ушел в бой. А я никогда, никому не сказал слово «отец». Да, во мне есть боль, понятная сиротам войны; и есть гордость – отец видел мое лицо.*

*Я ненавижу фашизм. Знаю, что эта ненависть отзовётся в моих детях и внуках... А свинцовые слова «похоронки» все еще сжигают сердце: «...погиб 15 января 1945 года, г. Модри-Камень, 3 км. севернее высоты 503, Чехословакия».*

*Даже с вершин Гималайских гор невозможно увидеть весь земной шар. Но рядом с Круглым Дубом мне представляется, что я действительно вижу все континенты мира. Потому что невысокая возвышенность, где он стоит, для меня есть вершина мира и согласия, середина земли. У каждого человека должна быть такая середина.*

*Люблю гармонию круга – в нем великая простота. Лицо человека, открытое миру; глаза, полные радости или печали, луна, солнце, освещающие и согревающие землю; обручальные символы любви – все они круглые... 360 градусов есть круг, 359 градусов – уже не круг. Разрыв может быть опасен, как траектория снаряда, ракеты... И пусть женевские столы, за которыми скоро начнутся, быть может, самые ответственные в истории человечества советско-американские переговоры, окажутся круглыми, а не угловатыми. Народы мира так хотят.*

*Стоя в снегу под разлапистой кроной древнего дерева, мысленно с душевным трепетом ступаю на брусчатку Красной площади. Площади мира и разума. Надежды. И вижу: на ней люди – как листья в лесу. А рядом со мной мой Круглый Дуб...*

*«Правда», 26 февраля 1985 г.»*

Мин газетадагы мәкаләмә теләктәш хатлар көттем. Әмма алар килергә ашыкмады. «Правда»да чыккан мәкаләм кисентесен күбәйтеп, архивларга җибәрдем. Атамның кайда күмелгәнлеген ачыклау өчен мин Мәскәүнең «Кузнецкий мост» тыкрыгында урнашкан Кызыл Хач (Крест) һәм Ярымай җәмгыятенә мөрәҗәгать иттем. Анда миңа җавапның урап килүен ике ел көтәргә куштылар. Бу инде ышанычка өмет бар дигән сүз иде. Берүк вакытта Башкортстан партия оешмасы архивы җитәкчесе Г.Иргалин җибәргән җавапта әтәйнең хезмәт юлы, кайларда эшләве, укыткан авыллары, партия сафларына керү вакыты (бераз алдарак әйтелде) ачыкланды. Озак та үтми, СССР Кызыл Хач Һәм Ярымай җәмгыяте башкарма комитетының бүлек мөдире В.Фатюхинадан килгән хатта атамның (сөякләре дип аңларга кирәк) Словакия республикасының Зволен каласындагы совет солдатлары зиратында җирләнүе, каберенең (дөресрәге күчереп күмелгән сөякләренең) номеры 3912 санлы булуы хәбәр ителгән иде. Аның икенче урынга – Зволенга күчереп җирләнүе бер яктан күңелемне төшерсә, икенче яктан күтәреп тә җибәрде шикелле. Хәзер атам зиратына юл ачылды, әнкәм зиратыннан туфрак алып, Зволенга барасы һәм аны атам туфрагына саласы – сугыш аерган гаилә хатирәсен кавыштырасы гына калды. Зволен чит илдә булганлыктан, бу бик тиз генә эшләнә торган эш түгел иде. Ни өчен дигәндә, тәүдә, әле 1945 елда, һәлак булган көннәрендә үк, атамның гәүдәсе (барлыгы өч совет сугышчысы) Модри-Камень бистәсенең үзәк мәйданында җирләнгән булган. Җитмешенче-сиксәненче елларда Чехословакиядәге совет солдатларының зиратларын тәртипкә китергәндә, Модри-Каменьдәге өч совет солдатының җәсәде дә Зволен каласындагы зур зиратка күчерелә. Бу хакта миңа Совет-словак дуслыгы патриотлары сөйләде. Анда барлык Чехословакия буйлап җыелган совет сугышчыларының сөлдәләре җирләнгән. Словак патриотлары миңа икенче хакыйкатькә дә юл ачты. Аларның раславынча, Чехословакиянең ул төбәгендә – ягъни югарыда телгә алынган Лученец районында, Власов армиясе башбаштаклык итә. «Лученец операциясе» дип аталган бу локаль операция, гомумиләштереп алганда, Көнбатыш Европада Америка-Англия гаскәрләре ачып җибәргән «Икенче фронт»та – 1944 елның 16 декабреннән 1945 елның 25 гыйнварына кадәр барган «Арденн операциясе»нең кушылма өлеше булып тора.

Игътибар итегез, фронтлар, державалар, генералиссимуслар, Президентлар катнашында алга килгән планетар вакыйгалар менә ничек итеп окоптагы гади сугышчы, гади офицер, бу очракта минем әтием, безнең әтиләребез язмышы – чамасыз күп корбаннар аша тормышка ашырылган.

Күз алдына китерик. Мәсьәлә болай килеп чыга: генералиссимус Сталин да, Премьер-министр Черчилль дә, Президент Рузвельт тә әлегә тыныч кына үзләренең эш кабинетларыннан фронтлар белән җитәкчелек итеп яталар, диик. Әмма 1945 елның гыйнвары башында немецлар Нормандиягә бәреп кергән инглиз-американ гаскәрләрен Атлантик океанга сибереп төшерү өчен җимергеч һөҗүм башлыйлар. Союздаш гаскәрләр авыр хәлдә кала. Черчилль белән Рузвельт тынычлыкларын югалта. Алар ашыгыч ярдәм сорап, Сталинга мөрәҗәгать итәләр. Сталин коллегаларының бу үтенечен ничек кенә булса да үтәргә тырышып, Көнчыгыш фронтта планлаштырылган Висла-Одер операциясен сигез көнгә срогыннан алда,

тулаем әзерлексез килеш, инде 12 гыйнварда ук башлап җибәрергә һәм Татра таулары районында ашыгыч десант төшерергә мәҗбүр була...

Әтиемнең һәлак булырына нибары өч кенә көн калган...

Лученецта власовчылар һәм немец фашистлары тарафыннан ике яклап оештырылган «туралыш казаны» барлыкка килә. Бу вакыйгалар билгеле булгач, шушы операция турында мәгълүматлар җыештыра башладым. Атаклы дипломат П.Владимиров «Особый район Китая» дигән китабында Лученец районында барган канлы сугышлар турында болайрак яза: *«В Чехословакии советские войска преодолевают упорное сопротивление противника. Взят город Лученец и множество населенных пунктов».* Сугыш ветераны Е.Горелов «Правда» газетасының 1985 ел, 16 февраль санында басылган көндәлекләрендә: *«12 марта 1945. Я недалеко от города Лученец. Здесь круглые сутки слышен гул войны. Ухо так привыкло к нему, что становится странно, когда наступает затишье»*, – дип яза. Анда власовчылар суеш оештырып, немец фашистларыннан да артык кансызлык күрсәтә. Словак патриотлары Модри-Каменьнең 503 нче биеклегендә һәлак булган совет сугышчыларының пычактан үткәрелгән булуын раслыйлар. Бу фикергә мин үзем дә кушылам: гомере ничек кенә өзелмәсен, атамның күкрәк кесәсендәге документлар укый алмас дәрәҗәдә канга буялган булгандыр дип уйлыйм. Менә шуңа күрә «Малые Каркалы»да яшәгән анам «Сорур Шигаповна» бөтенләй дә аңлашылмый торган мәгънәсез «Срульшиль»гә, «Киргиз-Миякинский» әллә кайлардагы Одессадан «Красно-Окнянский»га әйләнгән дә инде! Лученец операциясенә һавадан төшерелгән десантта катнашкан офицер «Халимов Назметдин»ның дошман тылына «рядовой Халимов Низм» буларак та катнашуы мөмкин бит әле! Һәм башкалар, һәм башкалар!..

Әйе, Словакияның 503 нче биеклегендә яткан атамның җәсәде мине көтә иде. Инде шул биеклеккә илтә торган юлларны эзли башладым. Аны Аллаһы Тәгалә үзе табып бирде.

Һәм менә ничек итеп.

1985 елда Мәскәүдәге Югары әдәби курсларны тәмамлап, кире Уфага кайттым. Анда көтмәгәндә генә үземә иңгән бер сихри рух татар-башкорт мөнәсәбәтләрен гармоник камилләштерүгә чакырган «Язык мой – друг мой...» дигән күләмле хезмәтемне язарга насыйп итте. Ул «Дружба народов» журналының 1988 ел, июнь санында басылып чыкты һәм илдә милли мөнәсәбәтләрнең торышын объектив яктырткан әсәрләр рәтендә зур кызыксыну уятты. 1991 елның маенда литвалы туганнарыбызның ярдәме белән кулъязма 20 мең тираж белән «Книга печали или Записки аборигена» («Сагыш китабы») дигән исем алып, литва һәм рус телләрендә дөнья күрде.

«Дружба народов»та басылган мәкалә миңа Чехословакиядәге атам каберенә дә юл ачты.

Мин туган авылым Кәркәлетамакка кайтып, әнкәм кабереннән ерак илләрдәге әткәм каберенә салыр өчен аннан туфрак алырга рөхсәт сорап, догалар кылдым.

Журналның редколлегия әгъзалары, атап әйткәндә, баш мөхәррир Сергей Баруздин, аның урынбасары Игорь Захорушко, әсәрне басарга әзерләгән публицистика бүлеге мөдире Бронислав Холопов, СССР Оборона

министрлыгының Генераль штабы хезмәткәре генерал-майор Юрий Кучкин Тышкы эшләр министрлыгы аша миңа, хатыным Венерага, кызым Зөлфиягә Чехословакиягә барыр өчен визалар тутырттылар. Бу вакыйгаларга 35 ел үткән көннәрдә без, Хәлимовлар нәселе, аларга рәхмәтләр юллыйбыз!

Менә 1988 елның 25 августында, без Белорус вокзалыннан Москва-Прага поездына утырып, юлга чыгабыз. Егерме җиденче августта иртәнге сәгать биштә килеп тә җитәбез. Ул чакта, инде 1968 елда ук, Чехословакиягә совет гаскәрләренең Үзәк группировкасы кертелгән иде. Вокзалда Совет комендатурасын эзләп таптык. Бирედән безне махсус микроавтобуска утыртып, совет гаскәрләренең Прагадан 40 чакрымдагы Миловице каласында урнашкан Үзәк штабына китерделәр. Анда безне полковник Михаил Романович Лесников каршылады. Чехословакиядә булган вакыт эчендә безнең тормышыбыз – ашау-эчү, экскурсия һәм башка яклар шул иптәш карамагында булды. Ул үз бурычын җиренә җиткереп башкарды. Чит илдә шушы кадәр зур югары вазифалы офицерны безгә «вак» булып күренгән мәсьәләләр буенча «йөгерткәнебез» өчен безгә бик уңайсыз иде. Әмма нишлисең, хәрби тәртипләр шулай куелган иде. Һаваны ярып, күктә истребительләр куыша. Җирне тетрәтеп, якыннан гына танклар гөрелтесе ишетелә. Лесников тумышы белән Воронеждан икән. Әтәйнең дә кече командирлар курсында офицер дәрәҗәсен Воронежда алуын ишеткәч, «Коренной земляк!» – дип, кулымны кысты.

Үзәк группа гаскәрләре музеен дә карап чыктык. Дукла сыртында булган атаклы кырылыш тарихы белән таныштык. Анда бер яктан фашистлар, сатлык җан генерал Власов, икенче яктан Кызыл Армиянең Конев һәм генерал Свободаның чех-словак гаскәрләре бәрелешкән. Музей стеналарында шушы мәгълүматларны күргәч, чирканып куйдым: эткәмнең власовчы фашистлар кулыннан үтүенә дә ышангандай иттем. Монда Надыршин Харис абыйның ядрә тишкән комсомол билеты саклана. Атамның канга баткан партия билеты да бу музейга куела алган булыр иде. Менә батыр санитар Әхмәт абзый Нуриев фотосы. Сугыш яланыннан йөздән артык яралыны өстерәп алып чыккан...

Мин музейда да атам рухы белән киңәшләшеп йөри идем. Татра тауларындагы каберләр миңа татар тауларындагы җир белән тигезләнгән каберләр булып күренде. Татра – Европада татар дигән төшенчәдән яратылган тау бит ул! Полковник Лесников безне Үзәк группировка гаскәрләре командующие генерал-полковник Уткин утары-резиденциясенең өч бүлмәле канатына урнаштырды. Утар үзе мәһабәт имәнлек эчендә утыра. Гүяки меңләгән Түгәрәк Имәннәр үз Нәҗметдиннәрен күрер өчен Җир шары буйлап шушы урманга җыелган. Чехословакиядә җирнең адымы да исәптә. Миловицедә иген басулары балконнарга килеп егыла да башакларын суза. Монда рауза чәчәкләре бәйләмнәре белән балконнарны кочып утыралар...

Безнең күңелебез Модри-Каменьга ашыга. Әмма хуҗаларыбыз күбрәк һәм киңрәк итеп илне күрсәтергә тырыша. Шулай кушылгандыр дип уйлыйбыз. Аерылып, үз юлың белән китеп булмый. Икенче көнне безне Праганы күрсәтергә алып киттеләр. Шофёрыбыз кече сержант Павел Праганы яхшы белә. Дүрт сәгать эчендә шәһәрне аркылы-буйга үтеп

чыктык. Шәһәр буйлап үткәндә-сүткәндә, безгә берничә тапкыр йодрык янап калдылар. «Номерны күреп, безнең совет машинасы икәнен таныйлар да йодрык күрсәтеп калалар, – ди Павел. – Монда русларны җеннәре сөйми...» Прага «Грады»ндагы хөкүмәт сарайларының матурлыгын сөйләп кенә аңлатырлык түгел. Чынлап та, кемнеңдер уңышлы чагыштыруы буенча, «архитектураның ташта катырылган моң» икәнлегенә ышанасың. Берничә музейда, картина галереясендә булдык. Ресторанда тамак туйдырып алдык. Бездәге кебек, «ник алай түгел, ник болай түгел» дип, «права качать» итмичә генә дә тамак туйдырып була икән. Ризыклары телеңне йотарлык тәмле. Кыйммәт тә түгел.

Вацлав мәйданын таптык. Мондагы матурлык, төзеклек хәттин ашкан иде. Минем бу кадәр архитектур камиллекне күргәнем юк иде. Вацлав мәйданы – чехларның милли горурлыгы. Аны алып ташласаң, чех халкының йөрәге тибүдән туктаячак. Алла сакласын!

Без өченче көндә дә Миловицедә булдык әле. Без хуҗаларыбызны, ничек кенә теләсәк тә, әйткәнемчә, ашыктыра алмый идек. Көндезге ашка дип чыккач, гарнизон мәдәният йорты каршындагы паннода бер метрлы хәрефләр белән «Встреча с поэтом Айдаром Халимом» дигән реклама тактасын укып шаклар каттык. Мин бу очрашуның булачагы турында белә, әмма шул кадәр олы хәрефләр белән олыларлар дип уйламый идем. Кинәт миңа кемдер атам кушкан исем белән:

– Исәнме, Барыйс абый, – дип эндәшә.

Мин тагын шаккатам: Прага янында!

Әлбәттә, яшь кенә солдатны танымыйм.

– Мин Рамил туганың булам, – ди ул. – Олы Кәркәледән. Вәли Хәлимовның улы...

Вәли абый – безнең «Чулпан» колхозының рәисе. Минем өч туганым. Без кочаклашабыз. Менә сиңа, мә! Чехословакиядә, Праганың янәшәсендә! Аның белән бергә Татарстан-Башкортстаннан дистәгә якын солдат хезмәт итә икән. Полковник Лесников аша без аларны кичке әдәби очрашуга һәм аннан соң үзебез оештырган аш-су мәҗлесенә дә чакырырбыз. Туймазыдан Фәрит Әмирҗанов, Яшел Үзәннән Рим Сабитов, Балакатайдан Камил Сөендеков, Октябрьскидан Павел Семёнов һәм башкалар катнашыр. Мәҗлесебезнең түрендә хатыны Светлана Егоровна белән Лесников үзе утырыр... Михаил Романович – тумышы белән тугыз балалы гаиләдән чыккан авыл кешесе. Ашарга утырганда, уникe кашык күтәргәннәр. Мин мәҗлестә катнашкан һәркемгә һәм гарнизон китапханәсенә үземнең күптән түгел Мәскәүдә рус телендә чыккан «Ветер листьев» дигән китабымны бүләк иттем. Ул берүк вакытта Рәсәйдән килгән якташларыма Түгәрәк Имәнемнән килгән бүләк иде...

Ниһаять, Зволенның үзенә юнәлеш алып Ружемберок дип аталган гарнизонга киттек. Зволенга юл, һич арттырмыйча-киметмичә әйткәндә, кочак-кочак рауза чәчкәләре белән түшәлгән иде. Зволен үзәнлеген күңелемнән «раузалар үзәнлеге» дип атадым.

Безне часть замполиты майор Андрейчук каршылады. Бу инде минем Зволенга илткән юл өстем һәм атам азат иткән Словакия тарафлары иде. Түбән Татра таулары. Аларның Татрасын Карпат һәм берүк вакытта

безнеңчәгә күчереп, әйткәнемчә, «татар» дип аңларга кирәк. Диңгез өсте тигезлегеннән 2000 метр биеклектәге киң асфальт юллар. Шарылдап агып яткан тау чишмәләре. Юлларда микроскоп белән эзләсәң дә, бер чүп әсәре тапмассың. Без Карпатның унсигез чакрымга сузылган тау сыртына күтәреләбез. Бу миңа Урал-тауның Ерал дип бозып руслаштырылган атамасын хәтерләтә. Сыртның түбәсендә Банска-Бистрица каласы. Йөрәкләр дарс-дарс тибә. Зволенга, атам йөрәге яткан җир куенына унтугыз чакрым калды...

Менә ул Зволен!

Уенчык кебек җыйнак Европа шәһәре!

Словакларның иң зур милли үзәге. Ул тарихта уникенче гасырдан ук билгеле. Венгер корольләренең ял сарае булып хезмәт иткән. 1944 елның августында фашистларга каршы кузгалып киткән атаклы «Словак фетнәсе»нең үзәк штабы була биредә. Фетнәне мөмкин кадәр киңрәк совет ихтыяҗларында файдалану, аны халыкара статуска чыгару өчен Сталин Икенче Белоруссия фронты гаскәрләренең Башкомандующие Родион Яковлевич Малиновскийга (милләте белән кырым караимы, ягъни кырымтатар яһүдие, кыяфәте белән ифрат та татарга охшаш) Татра тауларына берничә меңнән торган «совет партизаннары» десантын төшерергә күрсәтмә бирә. Бары тик Модри-Камень кергән Вълки Кртиш районында гына да словакларның капитан Ноград, советларның капитан Воробьёв, майор Хвостиков җитәкчелек иткән партизан берләшмәләре, венгер һәм француз партизаннары отрядлары хәрәкәт итә. Безгә билгеле булган барлык мәгълүматлар атамның нәкъ шушы десантта булуын раслый...

Безне шәһәр һәм хәрби часть җәмәгатьчелеге ипи-тоз, зурлау сүзләре белән каршылый. Каршылаучылар арасында Ульян өлкәсенең Кулаткы районыннан татар егете майор Рәфкать Курамшин да бар. Без аның белән берничә җөмлә татарча да сөйләшеп өлгердек. Безне укчы полк командиры подполковник Виктор Гребенников һәм аның урынбасарлары кабул итте. Зволендагы солдатлар клубы начальнигы майор Александр Графскийга безне шәһәр белән таныштырырга кушылган икән. Ул бик мавыгучан кеше булып чыкты. Алып бармаган җире, күрсәтмәгән урыны калмады. «Кунак булсаң, тыйнак бул» дигән әйтемгә тугры калып, без теләгәнебезне үтенә дә алмый һәм ул безгә килешми дә иде...

Биредә Зволендагы туганнар каберлеге тарихының үземә билгеле булган өлешен кабатлап китү сорала кебек. Әгәр Иосиф Сталин, сугыштан соң Чехословакиядә совет системасына хас коллективизация үткәреп, аның тере гражданнарын бер тапкыр «колхозга керткән» булса, үз территорияләрендә һәлак булган совет гражданнарының сөякләрен (каберләрен) кузгатып, бимазалап, яңадан казытып, ягъни яңадан көнгә күрсәтеп, яңадан-яңа каберләргә күчереп күмдереп, аларны инде күмелгән җирләрендә дә икенче тапкыр «колхозга кертте». Колхоз дигән гуҗга, билгеле булуынча, СССРда гына түгел, Прага, хәтта Парижда да җир җитми иде. Күпме уңдырышлы җирне күпме зиратлар биләп ята, имеш! Аларны җыйнакларга, кушарга, коллектив-колхозлаштырырга кирәк, имеш: иген үстерер өчен күпме «буш яткан» җир өстәләчәк!.. Сталин әле 1947 елда ук совет солдатларының сөлдәләрен Чехословакиянең барлык шәһәр, бистә һәм авылларындагы,

шул исәптән Зволендагы, каберләреннән чыгарып, гомуми «туганнар каберлегенә» күмдерде. Бүгенге көндә Золенда 17 мең совет солдаты һәм 11 мең румын солдаты җирләнгән ике зур зират бар. Бу саннарның да якынча гына булуы мөмкин.

Менә ул гектарларга сузылган каберлекләр. Аларны күрү белән минем тыным кысыла. Совет һәм румын каберлекләре янәшә урнашкан.

Тимер тактага словак телендә түбәндәге сүзләр язылган. Графский аларны миңа тәрҗемә итә:

Пусть эту надпись слава кроет.
Песня, за нас ты говори:
Спасибо матерям героев
От Волги, Урала и Москвы...

Каберлек чәчкәләргә күмелгән. Рәт-рәт булып савыр (туя) агачлары тезелгән. Андагы чисталык, тазалык һәм ташларда чагылган туганлык тойгысы! Мин саннар язылган бетон плитәләр буйлап әтәй каберен эзләп китәм. Мине туктаталар. Бу гади генә адым Словакиянең Кызыл Хач җәмгыятенең сагы астында ясалырга тиеш, диләр. Аннан бүген эш көне дә тәмамланып килә икән.

Иртәгәсен миннән полкның бер мең ике йөз солдаты басып тыңлаган разводында катнашуымны үтенделәр. Атам каберен эзләп килүем турында сөйләдем, Түгәрәк Имәннән сәлам җиткердем һәм ике шигырь – русча һәм бер шигырь – «Колмак җыя кызлар»ны татарча укыдым. Разводтан соң мине якташ солдатлар уратып алды, бик җылы теләкләр әйттеләр.

Алар арасында Чаллыдан Марат Маннапов дигән егет тә бар иде. Шунда ук Рамис Гыймалетдинов. Ульяннан икән. Танклар төзәтүче. Ружемберокта китапханәче булып эшләгән якташыбыз – Уфа кызы Наилә Җиһангирова белән танышырга насыйп итте. Шагыйрь Якуб Колмыйның туганнан туган сеңлесе икән. Илдар Мияссәров исемле егетебез миңа аеруча ошады. «Айдар абый, колакка гына булса да, «Кара урман»ны җырла әле!» – ди ул миңа. Минем күзләремә яшь бәрә. Шулай сагындыра шул ул туган тел һәм туган моңнар! «Нигә, мин әйтәм, колакка гына? Мин аны күкрәк киереп тә җырлыйм!» «Булдыра аласыңмы?» «Нигә булдырмаска?» Һәм мин җырлап та җибәрәм. Күп тә уйламый, Илдар үзе дә җырга кушыла... Полк командиры Гребенников елмаеп, кул чаба...

Боларның барысы белән әтием калдырган эзләр табыштырды-таныштырды бит!..

Замполит йөгереп килеп җитә: Модри-Камень местечкосы кергән Вълки-Кртиш район комитетының беренче секретаре иртәгә иртән безне кабул итәргә тели икән.

Беренче секретарь Ян Будай белән безнең арада ике сәгатьлек әңгәмә булды. Ул үз халкының чын патриоты иде. Тугандаш чех һәм словак халыкларының мәдәнияте, хуҗалык тармаклары турында илһамланып сөйләде. Мин исә татар һәм башкорт халыкларының кичәгесе һәм бүгенгесен сурәтләргә тырыштым. Аңа «Ветер листьев» дигән китабымны һәм Түгәрәк Имәннең рам эченә куелган сурәтен тапшырдым.

Ян әфәнде русча бик яхшы сөйләшә. Моннан Австрия һәм Венгрия бик

якын икән. Секретарь Модри-Каменьнан Венгрия чигенә нибары егерме генә чакрым дигәч, минем күңелемдә атама кагылышлы истәлекләр яңарып куйды. Бу хакта Будай әфәндегә сөйләдем. Әле сабый чаклардан ук күңелемә сеңеп калган, яттан сөйләгән юлларны яңадан кабатладым: «...лейтенанту Назми Абдуловичу за освобождение городов Клуж и Сегед приказом Верховного Главнокомандующего Сталина объявлена благодарность». Һәм Сталинның сурәте. Аны әтәй безгә үзе җибәргән булган. Бу шәһәрләр Вълки Кртиш, Модри-Каменьга терәлеп кенә тора икән.

Ян Будай совет-чехословак дуслыгы, чехословак партизаннары комитетлары җитәкчеләрен чакыртып китертте, минем белән таныштырып, алардан миңа кирәк булачак барлык ярдәмнәрен күрсәтүләрен үтенеп, урамга кадәр чыгып озатып калды.

Модри-Камень – бик төзек словак шәһәрчеге. Ул Зәңгәр Тау (Таш) дип тәрҗемә ителә. Без совет-чехословак дуслыгының Модри-Камень милли комитетында булдык. Комитет рәисе Милан Туранский, шәһәрнең партия оешмасы рәисе, «За свободу славян» исемендәге партизаннар отряды сугышчысы Штефан Слосиарит, партия райкомының ревкомиссия рәисе Арпад Ковач, Словакияне фашистлардан азат итү тарихын язган язучы Ян Фекете безгә биредә булып үткән канкойгыч сугышлар турында сөйлиләр. Моннан Венгриягә таба Сегед-Зволен юнәлешендә Икенче Белоруссия фронтының генерал Манагаров җитәкчелегендәге 53 нче армиясе үтә. Модри-Каменьны азат итүдә катнашкан Ватан сугышы ветераны Д.Наумов Җиңүнең 20 еллыгы уңаеннан Модри-Каменьда була һәм кунаклар кенәгәсенә түбәндәге сүзләрне язып калдыра: «Дорогие друзья! От всего сердца приветствую вас от имени бойцов и командиров 779-ого Севастопольского полка 227-ой Темрюкской стрелковой дивизии, который освободил ваш город в январе 1945 года. Пусть вечно живёт дружба, скреплённая кровью в нашей совместной борьбе против фашистских захватчиков. Д.Наумов. 10 мая 1965 года». Элеккеге партизан Штефан Слосиарит раславынча, биредә фашистларның махсус «ТИРЦ-ХГ» («Тау боланы») дивизиясе, румын полкы һәм сатлык генерал Власов РОАсының аерым бригадасы сугышкан. Әтәй егылган 503 нче биеклектә нәкъ әнә шул Власов башкисәрләре ныгынып алган булган. Модри-Камень 6 гыйнварда азат ителгән исәпләнсә дә, аның якын-тирәсендәге сугышлар әле озак – тагын бер ай буе дәвам иткән. Ян Факете язган тарихта биредәге сугышларның аеруча канкойгыч булуы совет командованиесенең баш күтәргән словакларга тизрәк ярдәм итәргә теләп, Карпат тауларына әзерлексез килеш десант төшерүе белән аңлатыла. Минем күз алдыма СССР Министрлар Советы Рәисенең Британия Премьер-министры Черчилль һәм АКШ Президенты Рузвельт белән алышкан хатлары калкып чыга. Анда Генералиссимус Сталинның 15 гыйнварда Рузвельтка язган стратегиясе белән гади сугышчы, ягъни минем атамның 15 гыйнвардагы «окоп стратегиясе»нең үзара бәрелеше ачык сурәтләнә:

*«Лично и строго секретно*
*От премьера И.В. Сталина*
*Президенту г-ну Рузвельту*

*...После четырех дней наступательных операций на советско-*

*германском фронте я имею теперь возможность сообщить Вам, что несмотря на неблагоприятную погоду, наступление советских войск развертывается удовлетворительно. Весь центральный фронт, от Карпат до Балтийского моря, находится в движении.*

*Немцам... придется... отказаться от наступления на западном фронте... Я рад, что это обстоятельство облегчит положение союзных войск на западе.*

*... Что касается советских войск, можете не сомневаться., что они, несмотря на имеющиеся трудности, сделают всё возможное для того, чтобы предпринятый ими удар по немцам оказался наиболее эффективным.*

*15 января 1945 года».*

Бу атамны юк иткән һәм башкаларны да юк итәчәк сценарий. Рузвельт белән Черчилль үтенече буенча Сталин башлаган совет гаскәрләренең һөҗүме тоткарланып кала, ягъни «наступление советских войск развертывается удовлетворительно». Шуңа күрә 15 гыйнварда кул куйган хатын Сталин ничектер уңайсызланыбрак, акланыбрак язган кебек. Һөҗүмнең «эффектив» булачагына «көчләп» диярлек ышандыра ул. Гүя юлбашчы бу хатка кул куйган сәгатьтә атамның берүк числода – шул ук 15 гыйнварда һәлак булганын белгән кебек. Окоптагы гади сугышчы өчен ике капма-каршы идеологик система җитәкчеләре язып куйган пьеса – фаҗига сценарие бу. Әгәр Карпатка ашыгып-кабаланып, әзерлексез килеш десант төшерелмәгән булса, андагы корбаннар бу кадәр күп булмаган, атам һәм атам кебек меңләгән сугышчылар да исән калган булырлар иде кебек...

Рәсми исәп буенча Модри-Камень өчен сугышта барлыгы 68 совет, 129 румын солдаты һәм офицеры һәлак ителгән.

– Алтмыш сигез! Бик күп бит бу! – дип кычкырып җибәрәм мин. – Кечкенә шәһәрчек өчен!..

– Совет ягыннан корбаннар арасында дүрт офицер – ике майор, бер капитан, бер кече офицер булган, – ди Милан Турианский. – Шул офицерның сезнең әтиегез булуында шик юк...

– Һәлак булган 68 совет сугышчысы беренче тапкыр кайларда җирләнгән булган соң?

– Шәһәр уртасындагы паркта...

– Аларның исем-фамилияләре язылган булганмы? Алар сакланганмы?

– Кызганычка каршы, юк. 1947 елга кадәр аларның исемнәре постаментта сакланып килде, аннан соң бу зират югарыдан төшкән күрсәтмә нигезендә Зволендагы туганнар каберлегенә күчерелде. Сугыштан соң да байтак совет сугышчыларының гәүдәләре табылып җирләнде. Мәсәлән, өч ел үткәч, урманда бер солдат мәетен таптык. Билендә корулы пистолет. Бернинди документы юк. Димәк, һөҗүмгә барыр алдынан документларын, шул исәптән сезнең әтиегезнекен, җыеп алулары мөмкин. Мәрхүмне гүргә керткәндә, без шушы пистолеттан атып салют бирдек. Татрага десант төшерер алдыннан анда катнашкан сугышчыларның шәхси документлары җыеп алынган булган, дигән фикер белән исәпләшергә кирәк... – ди Милан Турианский.

– 503 биеклектә ныгынып алган фашистлар һәм власовчылар Модри-Камень азат ителгәннән соң да өч атна буе биеклектә оборона тоталар.

Модри-Камень 6 гыйнварда азат ителгән булгач, сугышлар, димәк, бу өч атнаны да исәпкә алып, әле 20-25 гыйнварларга кадәр дәвам иткән... – дип сөйли Штефан Слосиарит. – Мәгълүматларда офицер рядовой дип аталган кебек ялгышлыкларның очравы – табигый күренеш... Аннан, документларның буталуы, югалуы, юк ителүе, йә булмаса, сезнең әтиегез очрагында канга батып, авыр укылуы, йә укыла алмавы да мөмкин...

Әйе, атам Модри-Камень өчен барган сугышларның казанында кайнаган!..

– 503 биеклекнең власовчы гаскәрләрнең кул астында булуы, аларның анда аеруча кансыз кылануы хәзер инде расланган факт, – дип, сүзгә кушыла каләмдәшем Ян Фекете. – Анда «Урманчы йорты» булган. Хәер, ул әле дә бар. Анда күп тапкыр канлы бәрелешләр була... Без хәзер анда барырбыз һәм үз күзләребез белән күрербез...

Дулкынлануымнан баш түбәмдә лепкәм йөри башлый. Зөлфия кызым һәр адымыбызны сурәткә төшерергә тырыша. Рәхмәт инде сабыйга. Картатасы эзләреннән кайгы йотып йөри бит! Фотолары чыкса гына ярар иде. Менә без, ниһаять, әтәйнең беренче тапкыр җирләнгән Модри-Камень туфрагында басып торабыз. Аркамнан салкын тир ага. Без – мин, хатыным һәм кызым, бисмиллаһ әйтеп, дога кылабыз һәм әтәйнең биредә калган җаныя рухын күптән инде вафат булган инәбезнең җаныя рухы белән кавыштырабыз. Мин шушы ике җаныя рухтан бар булган йөрәк бит.

Модри-Камень өчен барган сугышта һәлак булган 68 рух өчен дә дога кылабыз һәм каршыбызда яткан 503 нче биеклеккә юнәләбез. Хәрби карталарда ул хәзер 501нче биеклек дип билгеләнә икән. Тау булып тау да ике метрга чүккән. Биредәге күз яшьләреннән һәм авыр кайгыдан таулар да чүгә икән.

Соры туфрак, вак ташта ишелеп үскән караҗимеш агачлары аша, шул агачлардан коелган җимешләрдә тая-тая, без җайлап кына биеклеккә күтәреләбез. Җиргә вак кына чәнечкеле үлән түшәлгән. Моны терновник диләр. Мин күз алдыма китерергә тырышам. Гыйнвар, юеш, дымлы словак кышы. Мондагы салкын җепшек безнең Урал салкыныннан «уңайсызрак». Туңган булып та, һөҗүмдә кузгалган йөрәк өянәгеннән җепши төшкән кара җимеш куаклары аша сикереп-атлап, атам аркасындагы катушкасыннан элемтә чыбыгын калдыра барып, автомат тыкылдаулары, бомба шартлаулары астында шул заманнан минем заманга элемтә чыбыгын суза. Ул юеш шинельдә һәм юеш итекләрдә. Аның белән мин дә янәшәдән шуышып, дошманга каршы күтәреләм...

– Күрәсезме, окоплар, траншеялар? – ди Фекете, алда яткан чокырларга күрсәтеп. – Биеклекне өч оборона сызыгы саклаган. Аста беренче, монысы икенче, өстә, түбәдә – өченче сызык булган...

Диңгез өсте тигезлегеннән биш йөз бер метрга биегрәк биеклек...

Мин беразга туктап, тын алам. Әйтергә дә газап – атамның ауган, атамның соңгы «Аһ!» дигән авазын ишеткән, минем мәңгегә ятим калган җир бит бу! Һавада шул авазның электроннары әле булса йөзеп йөридер бит! Күрәм, миннән адым да калмыйча, минем белән рәттән булган Түгәрәк Имәнебез дә елый. Күз яшьләре чык тамчысы булып, яфракларыннан тәгәри. Шушы адымда гөрселдәп ауганда, атама нибары утыз алты яшь

булган. Инде миңа кырык алты. Кече кызым, атамның оныгы Зөлфиягә уналты! Атам бит һәр адымым Җиңүгә якынайта дип уйлаган. Шуңа инанган. Шуңа хезмәт иткән. Ул чакта Җиңү бәйрәменә дә өч ай ярым гына калып барган. Сугыш гарасатында, ядрә давылында кайнап өч ел ярым буе исән-сау йөре дә, 45нче – Җиңү елының унбишенче гыйнварында кайчандыр үз ватандашлары булган власовчы-мордарлар кулыннан... – әйтеп бетәргә хәл җитми!.. – гомереӊ өзелсен диген!

Без нинди «җиңү»гә килдек соң, әтәй?!

Синең монда гаебең юк.

Яфраклар түшәлгән җирдә кыргый дуңгызларның тояк эзләре. Өерләре белән тыпырдап үткәннәр.

– Алар биредә күп үрчеделәр, – ди Арпад Ковач. – Әллә туп тавышларын сагыналар инде?

Кыргый дуңгызлар өере миңа бу минутта Власов фашистлары булып күз алдыма килә.

– Арпад, әйдә без кунагыбыз Айдар Хәлимгә берәр дуңгызны атып алыр өчен рөхсәт лицензиясе бирик, – ди Фекете. – Модри-Камень тауларында аның моңа тулы хокукы бар...

– Әнә, «Урманчы йорты»! – дип кычкырып җибәрә карт партизан Штефан. – Әнә!..

Тау түбәсендәге ачыклыкта бер катлы соргылт бина пәйда була. Кирпечтән. Як-якка чыккан өч тәрәзә...

Атамның үлеменә шаһит бина... Атамның «Аһ!» дигән соңгы авазын ишеткән бина!..

Минем әтәйгә, аның яудашларына фашистлар шушы тәрәзәләрдән атканнар...

Тәнемне кайнар ялкын көйдереп ала. Бу тәрәзәләрне кан белән юганнар кебек күренә. Венера белән Зөлфия кичерешләреннән ап-ак булганнар. Мин йортның күпне күргән-кичергән диварларын сыйпыйм. Алар мине энә булып чәнчә. Тәрәзә яңакларын капшыйм. Алар мине энә булып чәнчә. Яфрак шавына колагым салам. Тын алышым шаңдау булып һаваны тетрәтә...

– Әтием-әтекәем! Мин килдем! Син мине ишетәсеңме?!

Тавыш-тын юк.

Әти-әни, безгә ничә йөз яшь?

Йортны бар яктан әйләнеп чыгам. Андагы карт алмагачлар белән сөйләшәм. Аларның берәрсенең шул замандагы фаҗигане кичергән булуы мөмкин бит?! Ул вакыйгаларга әле 43 кенә ел үткән иде бит! Кызык, алмагачлар гомере ничә ел икән?!

Минем алмагачка әйләнәсем килеп китә... Тирә-ягымдагы дотлар, дзотлар, окоп казындыларына төшәм. Яфрак катламнарын актарам һәм словак җиреннән, әтәй яраланып ауган төштән бер уч туфрак алып, юл капчыгыма салам...

Колагымны туп шартлаулары, танклар гөрелтесе баса...

Мондагы кошларның күплеген чамаласагыз иде! Гүяки әтәй каны тамган туфракта өрелеп пешкән кара җимешләрдән авыз итәр өчен бирегә барлык Европаның кошлары җыелган.

Алар сайрый! Көннәр көзгә тартса да, алар яздагы кебек сайрый иде!

Бу кошларның тынычлык оркестры уйнаган тормыш симфониясе иде!..

Словак дусларым үләндә кечкенә табын оештырып ала. Словак җиренең кандай кызыл шәрабын телемә тидереп, мин бу җиргә, бу халыкка халкымның, җиремнең һәм минем Түгәрәк Имәнемнең шәрәфәтле сәламнәрен җиткерәм. Йөрәктә беркемгә бернинди дә кара нәфрәт юк. Адәм баласының күңеле нишләп шулай кичерүчән икән? Яхшыгамы, начаргамы бу? Югыйсә анда нәфрәттән башка бер нәрсә дә булмаска тиеш бит?!

Мин ятим. Кат-кат кабатлыйм: мин дөньякүләм ятим. Мин планетар ятим. Әмма минем мине дөньякүләм ятим иткәннәргә карата аларны күрә алмас дәрәҗәдәге нәфрәтем юк. Исемә төшә: моннан ике ел элек Германиядә булып, Галле шәһәре хакимиятендәге кабул итү мәҗлесендә дә шулай дип әйткән идем. Йөрәктә ятимлек моңы, күкрәктә ятимлек моңы, колакта ятимлек моңы. Әле мине сырып алып сайраган, куанып чыркылдашкан словак кошлары үзләре бу кадәр моңга ничек түзә икән?

Без калкулыктагы «Урманчы йорты»ыннан әкрен адымнар белән, җай гына, түбәнгә төшә башлыйбыз. Мин яңадан артыма борылып карыйм. Бу якларга тагын да килергә язсын. Абыйларым, туганнарым белән килеп күрергә язсын! Хуш, атам һәлакәтенең шаһиты булган почмак!

Безнең юл өстендәге һәр куактан пырылдап, кошлар күтәрелә. Аяк асты һәркайда да кап-кара кайгы җимешләре белән түшәлгән. Атам кайгысыннан, безнең кайгылардан, Советлар дип аталган илнең дистәләрчә миллион толларының, ятимнәренең кайгысыннан шулай караеп пешкәннәр алар. Уфаның Ленин районы хәрби комиссариатында әтәйнең үле хәбәрен миңа телдән генә, «почти пышылдап» яздыруларының серен бүген килеп кенә, менә әле генә аңладым кебек. Хакыйкатьне янә дә кабатлап булса да әйтим: «Башкирской»ның «Одесской»га, «Киргиз-Миякинский»ның «Красно-Окнянский»га, «Сорур Шигаповна»ның «Срульшиль»гә әйләнү сере менә шушында ныклап ачыла да инде. Беренчедән, безнең командование власовчылар хәрәкәте турында гына түгел, аларны тар-мар итүдә катнашкан гаскәрләр турында информация бирүне дә чикләгән, болар хакында мөмкин кадәр «колакка пышылдап кына» җиткергән, икенчедән, документлар барысы да канга баткан булган, аларны төптәге документлар белән чагыштырып, дөресләп тору өчен шартлары җитешмәгән...

...Без яңадан Зволенга әйләнеп кайттык һәм беренче эш итеп, Чехословакия Кызыл Хач җәмгыятенең Зволендагы бүлекчәсенә бардык. Ул каберлекнең эчендә урнашкан дип әйтергә мөмкин. Анда безне бүлекчә рәисе Славута Неруда ханым бик җылы кабул итте. Бирегә күмелгән унҗиде мең совет корбанының йөзләгән кенәгәләрдән торган таудай өемен күреп, без таң калдык. Әмма бу исемлек «гади бер формализм» чагылышы гына икән. Монда исемнәре билгеле булган корбаннар бер мең дә юктыр, диделәр. Калганнары бары тик номерлар белән генә бара. Аллага шөкер, әтәйнең исеме бар: «Халимов Назми». Номеры 3912. Туган елы «1905» дип күрсәтелгән.

Кайбер томнарның исем-фамилиясез, бары тик буш номерлардан гына торуын күреп, үзебезгә үзебез ышанмый торабыз. Ярый, көтмәгәндә кузгалып киткән сугышның башында, чигенергә туры килгән чорда, корбаннарның исемнәрен барлап, җирләп торырга мөмкинлек тә булмасын,

ди. Әмма бу да безне аклый алмый. Сугышның, кайда гына булмасын, үз этикасы бар. Ул да булса, ачмы син, әллә тукмы, барча мәшәкатьне читкә куеп, ашык-пошык кашык күтәрәсе урында ашыгып мәет күтәреп, корбаннарны җиргә тапшыру. Әгәр дә безнең 1941 елда мондый мөмкинлегебез булмаган, атаклы шагыйребез Константин Симонов язганча, «некогда хоронить» булган икән, 1945 елда, совет гаскәрләре триумфаль һөҗүм алып барганда һәлак булган солдатның исемен ачыклап күмәрлек мөмкинлегебез булгандыр бит?

Кешелеклелек кенә җитешми. Бары шул гына!..

– Совет гаскәрләре командованиесендә үз корбаннарын, кызганычка каршы, чигенгәндә, 1941-1942 елларда гына түгел, уңышлы һөҗүм итеп барган 1944-45 елларда да исемнәрен ачыкламыйча чокырга ыргытып китү тәҗрибәсе чәчкә аткан булган, – дип ачынып сөйли Славута ханым. – Сугышның тәмамлануына кырык өч ел тулды бит инде. Бу гомер эчендә безнең зиратта яткан совет солдатларының барысын да диярлек ачыклап булган булыр иде. Әмма сезнең илнең Оборона министрлыгы эченә уклау йоткан кебек тынсыз тора... Без инде аларга мөрәҗәгать итеп арыдык... – Славута ханымның тавышы калтырана башлый, күзләреннән яшьләре бәреп чыга. Ул урыныннан күтәрелеп, ниндидер ят төстәге кенәгәләр алып килә. – Менә сез румыннарның ничек акыллы эшләгәнлеген карагыз, – ди ул, аларны актара башлап. – Берәр билгесез, яисә номеры гына калган кеше бармы аларның корбаннары арасында? Аларда барысы да билгеле: исеме-фамилиясе, туган елы-көне, каян армиягә алынган, кайда үлгән, гаиләсендә кемнәре булган...

– Безнең илдән килүчеләр бармы?

– Бик сирәк. Соңгы елларда Советлар Союзыннан нибары җиде кеше туганнарының каберлегенә мемориал такта куйдырып китте...

Инде мәңге кайтмас җиргә киткәч, биредә яткан унҗиде мең совет сугышчысының барысының да истәлек тактасы гына булса да куелырга тиеш иде югыйсә...

Россия, Россия!

Аның каравы, Рәсәй империясе солдатларын миллионлап түшәгән һәм күкрәген дүртәр герой йолдызлары белән бизәгән маршалларыннан көчләп-көчләп, Кызыл мәйдандагы канлы туфракка һәйкәлләр куеп, «полководецлар» ясый...

Әйтегез әле, бер үк кешенең «дүрт тапкыр герой» булуы мөмкинме?

Без Туганнар каберлегенә юнәләбез. «Рухлар сакчысы» Славута ханым алдан бара. Мин аны шулай атыйм. Каберләр буйлап ефәк кебек йомшак яфраклы туя куаклары утыртылган. Славута ханым туктый. Һәм күрсәтә:

– Менә 3912 нче кабер – ди Славута ханым, исемнәрне тулысынча атап. – Әтиегез Нәҗметдин Габделвәли улы Хәлимовның сөякләре менә шушында ята...

Сулдан икенче рәттән икенче кабер...

– Исәнме, әтәй!..

Өшеп киттем.

Без гаиләбез белән бер минут тын тордык. Бер минут тынлык аны кырык өч ел көткәннән озаграк иде. Ул чиксезлеккә тиң иде...

Мин тынычлыгымны югалткан идем.

Гүя чех-словак туфрагында Константин Симоновның «Безымянное поле» дигән шигыре яңгырады:

Не правда ль, мы так и расскажем
Их вдовам и матерям:
«Мы бросили их на дороге,
Зарыть было некогда нам».

Иртәгәсен без яңадан каберлеккә килдек. Арадагы төн йокысыз үтте. Күзләремне йома алмадым. Славута ханым биредә иде инде.

Безнең янибызда Зволен гарнизоны бүлеп биргән тантаналы каравыл да бар иде. Автоматларын аскан егетләр икешәр-икешәр кабернең ике тарафына басты. Каравыл белән аның командиры Львов егете өлкән лейтенант Виктор Фрис җитәкчелек итте. Кайгылы марш музыкасы яңгырады. Мин бу йола вакытында «Смирно»га басып торган совет солдатлары каршында әтәйнең каберенә Түгәрәк Имән төбеннән һәм инәй кабереннән алып килгән туфракларны кушып салдым. Бу минутта без дүртәү идек: мин үзем, хатыным Венера, кызым Зөлфия һәм Түгәрәк Имән. Бушап калган шул ук янчыгыма әтәй кабереннән инәй каберенә һәм Түгәрәк Имән төбенә салу өчен бер уч изге туфрак алдым. Зволен гарнизоны политбүлек начальнигы полковник Кротов миңа автоматлардан залп бирү өчен патроннар тәкъдим итте. Мин, мондый тантаналарны көтмәгән һәм аларга өйрәнмәгән кеше, нишләптер биредә атыш тавышлары яңгыравын теләмәдем. Моңа охшаш сәяхәтләрдә башыңа соңыннан гына килә, тәҗрибәне сорый торган сирәк, тетрәткеч йөрәк сыкрауларына бәйле очраклар байтак була икән ул. Мәсәлән, көтмәгәндә бер фикер килә: сезгә үзегезнеме, әллә икенче бер кешенеме, нәкъ шул секундта фотога төшереп алырга кирәк. Ә кем төшерә? Ничек төшерә? Зволенга – атам каберенә юл ачылу уңаеннан артык йөрәксенеп китеп, күрәсең, башка нәрсәләр турында уйларга онытып, боларны «ваклык» санап (яисә үзебезнең фотоаппаратка артык ышана биреп), бу хакта тирәнтен борчылмаганмын да. Хәзер бик үкенәм. Үзебез төшергән «любительски» кадрларыбыз йә начар чыкты, йә бөтенләй чыкмады. Гарнизоннан махсус фотограф сорап алырга да башка килмәгән. Бу хакта искә төшерүче дә булмаган. Һаман да шул бер дә кирәкмәгән «татар тыйнаклыгы»!

Әтәй каберенә туфрак салган минутларда Пермь егете Юрий Дуданов, Иркутскидан Алексей Шаронов, Күкчәтаудан Андрей Ковалёв тантаналы каравылда басып тордылар. Без аларга Уфадан алып килгән күчтәнәчләребезне һәм минем китабымны бүләк иттек.

Зволенда без тагын да өч көн яшәдек. Вакытыбыз мөмкинлегеннән чыгып, атабыз кабереннән кайтып та кермәдек. Хәрбиләр үтенече буенча мин берничә частьтә чыгышлар да ясадым. Минем белән Зөлфия кызым да үзенең җырларын башкарды. Район, безне кунак иткән хуҗалыклар җитәкчеләренә, хәрби командованиегә җирле газета аша рәхмәтләр белдердек. Китәр алдыннан без тагын да әткәбез каберенә бардык. Безгә аны калдырып китү бик тә... бик тә авыр... бик тә кызганыч иде. Әткәбезнең

биредә аккан каны гүя роза чәчкәләре булып юл читләренә түшәлеп, безне озатып калды.

Без монда күпме дуслар таптык!..

Без аларны Уфага кунакка чакырдык.

3912 саннары безнең өчен истәлекле генә түгел, изге саннарга әверелде.

Миловицедән Уфа тарафларына без кичләтеп кузгалдык. Татра таулары саф алтында йөзә иде. Менә бу чын словак алтыны иде. Без дусларыбыз белән хушлашып кул болгыйбыз. Алар да безгә кулларын селки. Күзләрдә сагыну яше.

Хуш, Словакия, атамның җәсәде яткан түшәк-туфрак!

Хушыгыз, Татра-Татар таулары!

Хуш, әтәй!.. Хуш, хуш, хуш!!!

## Тормыш дәвам итә

Мин Чехословакиядә алган тәэссоратларымны нинди дә булса бер үзәк газетада язып чыгарырга уйладым. Моның өчен иң кулай басма – «Красная звезда» газетасы иде. Поездга утыру белән үк яза башлап, Мәскәүгә кайткач тәмамлап, аны редакциягә кертеп тә чыктым. Татарда «Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигән әйтем бар. Озак та үтми, атап әйткәндә, 1988 елның 7 ноябрь санында, минем «Человечности нашей высоты» дигән публицистик мәкаләм «Красная звезда»да дөнья да күрә. Иң куандырганы шул: берничә ай үтеп өлгермәде, редакциядән минем исемгә килгән хатны җибәргәннәр. Иң көтелгәне: хат эчендәге хатта икән: *«Уважаемый товарищ Айдар Халим. Вашего отца похоронил я. Напишите мне по адресу: «Ставропольский край, Будённовский район, станица Архангельское. Черкасову Тимофею Тихоновичу».*

Тимофей Тихонович дигән адәмзат «Красная звезда»дагы мәкаләмне укыган да, мине табарга ярдәм итүләрен сорап, редакциягә хат язган. Без аның белән даими рәвештә хат алыша башладык. Хатлары мине кунакка чакыру белән башлана һәм кунакка чакыру белән тәмамлана иде. Аның сабый чагында «коммунар» буынның шул кадәр изелгән, эчкерсез, киләчәккә зур өмет белән караган буын вәкиленең, инде килеп, карт кешенең, кәкре-бөкре хәрефләр белән тырышып-тырмашып хат язуы, хатында үзенә генә хас «матур хаталар» җибәрүе миңа аеруча сагынычлы иде. Аларны күрү белән минем күзләремә пылт итеп яшь бәреп чыга... Андый хакыйкать баласы кебек эчкерсез, беркатлы, сөекле хаталарны бик теләсәң дә, ясап булмый. Аның хатларын мин әтәйдән килгән хатлар итеп кабул итә идем... Шулардан өзекләр белән таныштырып китәм:

*«...Я прошу вас, если можно, то сообщите, что отец ваш в каком полку находился. Наш полк 777 стрелковый. 227-ая стрелковая краснознамённая Темрюкская дивизия. Всё это дело с вашим отцом было на моих глазах. Мои товарищи живые все об этом знают хорошо. Жалко его было, как над ним они издевались... Бывший старшина станковых пулемётов Тимофей Черкасов. 14.02.89».*

*«...вы спрашиваете командира нашего батальона, у которого начальником службы связи был ваш отец. Он жил в Москве, если теперь*

*живой – Серегин Сергей Александрович. Если вы его найдете, то спросите, живой ли начальник штаба батальона. Это он с твоим отцом ходил на ту высоту... 05.05.89».*

*«...ведь наша дивизия всегда была на передовой линии огня. Мало кто остался в живых. Я всегда буду вас ждать... 28.08.89».*

*«...Теперь я расскажу о гибели вашего отца.*

*Расположились мы в станице под Модри-Камнем (мы его называли «Мудрый камень») ночью. Дом Лесника был на опушке леса, за станицей. Мы стали наступать ещё днём и он, немец, ушел с обороны. Двое суток мы стояли, держа оборону. На третий день немца тоже нет. Тогда наше командование решило выделить наш батальон в разведку за ним. Это было в январе 1945 года. Было рождество. Чехи говорили, что мы прошли по лесам километров пять, но никак не больше. Места были горные и когда мы стали выходить из леса, смотрим, внизу большой яр, там село, там немцы. Мы хотели связаться с командованием – что делать? Мы тягали за собой кабель и стали звонить. Но связи не было, видимо, провод был порван. И тогда командир батальона послал по делу в полк старшего лейтенанта Олабычева и лейтенанта по связи (это и был, пожалуй, ваш отец, я это точно помню, что он был офицер и был или чуваш, или башкир, в общем не русский) и третий санинструктор. Командир батальона сказал им, чтобы они сразу по ходу проверили провод, где он порван. А мы стали налаживать свою рацию. Дело было к вечеру. Был мороз. Через некоторое время мы услышали выстрелы – это наши ребята попали в засаду. Вернуться удалось только Олабычеву и санинструктору. Они рассказали, что в Доме Лесника были немцы, где они вели с ними бой.*

*Тут мы наладили связь со своими и приказ командования был таков: пробираться с боями не дожидаясь дня, а то если немцы узнают, что нас мало, всех уничтожат, а ведь с нами были ещё и раненые. Мы должны были дойти в 509-ый полк. И мы завязали бой. К опушке леса (к Дому Лесника) мы уже вышли с большими потерями. И вот тут-то мы увидели тело вашего отца. Я не могу описать весь ужас, как он был растерзан. Видимо, они издевались ещё и за то, что был коммунист. Потому, что на груди у него лежал партийный билет.*

*Вот такая была судьба моего товарища-сослуживца. Я салютовал из своего пулемёта когда мы хоронили в Чехословакии, в школе (на митинге) станицы Модри-Камень наших погибших товарищей, в том числе и вашего отца.*

*Вот всё, что я знал о вашем отце. Это было на моих глазах.*

*Немного ещё о себе. В 1986 году однополчане нашей дивизии встречались в г. Темрюке Краснодарского края. Многие, конечно, умерли, но со многими мы повидались. Я был старшиной взвода станковых пулемётов. Всю войну не выпускал из рук пулемёт. В 1941 году был в Иране, взяли мы второй город Тебриз. Был в Германии, Венгрии, Австрии, Польше, Румынии, Чехословакии, Монголии, Японии. Окончил в ликбезе два класса. Только с марта 1943 года до декабря 1945 года провоевал в одной дивизии, в одном полку, в одном батальоне, нигде не отлучаясь. Лежал три месяца в госпитале в Мишкольцах. С марта 1945 года до 25*

*мая 1945 года. Выписался и опять попал в свой полк. Затем – Япония, откуда и демобилизовался домой.*

*Всю жизнь я прожил в родном селе и проработал в совхозе со своей женой.*

*Я с 1915 года рождения.Теперь мы на пенсии... Я инвалид второй группы, в ступне ног так и ношу осколок – память о прошлом. У меня трое дочерей, все замужем. Пятеро внуков, двое правнуков. Старшая дочь – 1941 года, работает в нашем совхозе рабочей, средняя – учитель-методист, преподаёт русский язык и литературу, младшая дочь – медсестрой в детском саду...*

*Дорогой Борис Назметдинович! Очень прошу вас, как получите мое письмо, сразу же ответьте мне. Высылаю свое фото. С уважением к вам, однополчанин вашего отца Тимофей Тихонович Черкасов».*

Черкасов сурәтләве буенча әтәй һәлак булган җир – «Урманчы йорт»лары һәм башкалар нәкъ мин сурәтләгәнчә иде. Сез ул ачыклыкларны – урман «опушкаларын», 503 нче биеклекнең авыл читендә булуларына кадәр аеклык, аныклык һәм ачыклык белән күрсәтелүенә – Черкасов абзыйның баш миенең шул кадәр саф, якты хәтерле булуына игътибар итегез! Биредә шик тудырган бернәрсә дә юк иде. Тау башындагы «Урманчы йорты»нда урнашып алган власовчыларны ул өйрәнелгән гадәт буенча «немецлар» дип атый. Аларның чынлап та немецлар, чынлап та власовчылар, берьюлы барысының да бергә булулары мөмкин. Аларны ачыклау өчен аерым эзләнүләр үткәрергә кирәк. Без әлегә аларның власовчылар булуын гөманлап кына әйтәбез.

Бу хатны укыгач, түземем калмады. Кичектергесез рәвештә Минеральные Воды аэропортына очтым. Нәкъ Тимофей Тихонович өйрәткәненчә барып, Ставрополь краеның Архангельск станицасында яшәп яткан Тимофей абзыкаемны эзләп таптым. Ул үзе өйдә юк, эшендә иде. Шушы яшьтә, икенче группа «янбалит» була торып, фронт яраларыннан әрнеп-сыкрап, ул, җитмеш дүрт яшьлек «совет пенсионеры», ветеран, әле һаман да эшләп йөри! Болар кешеләр генә түгел, шагыйрь Николай Тихонов язуынча, болар кадак кебек нык кешеләр!..

Без очраштык. Урта буйлы, ачык йөзле бик мөлаем кеше. Әүвәлдә, артык дулкынланудан икебез дә телләребезне йоткандай эндәшә алмый тордык. Тимофей Тихонович кочаклый да елый, кочаклый да елый. Ихаталары гади генә, төсле балчык белән сыланган Дон казаклары ихатасы. Берничә төп йөзем куагы, чия, алмагач агачлары. Яшелчәне күп үстерәләр. Әбекәй аякларын чак-чак кузгатып йөреп яткан була. Карты әйтмешли, «Хуҗалыкта хәле барынча кыштырдый». Барлык мәшәкатьләр диярлек Тимофей абзый өстендә. Аңа карыйм да, күңелем ышанмый: шушы кеше минем әткәмне күргән, аның белән бергә дошманга каршы сугышкан, ул аны хәтта үз куллары белән җирләгән, диген! Ышануы да кыен, бу хакта уйланганда, нервылар шартлап сына иде!

Мин аларда икене кундым. Барлык сүз фронт, сугыш, әтәй хәтере турында барды. Тимофей Тихонович хатында язган хәлләрне яңартты. Сугыш шартларында иләнгән хәтер, вакыйгаларга илле елга якын вакыт үткән. Аларны искә төшерү җиңелдән булмады. Сөйләнгәннәргә өстәрлек

нәрсәләр дә юк иде кебек. Сугышны, андагы хәтер-истәлекләрне уйлап чыгарып булмый. Ялганлап та булмый. Ул Бөек Җиңүнең егерме еллыгы уңаеннан булган очрашуда Модри-Каменьны алуда катнашкан дуслары капитан Наумов белән очрашулары турында тәэсирләнеп сөйләде. Без карт белән Будённовскида булдык. Кызы Любовь Тимофеевнада берне кундык. Фотографиягә барып, сурәткә төштек. Икенче кызында да кунакта булдык. Кияве шәһәрнең «Будённовская правда» газетасыннан журналист Н.Назаренконы да чакырган иде. Без яңадан фронт истәлекләренә күмелдек. Бу әңгәмә бераздан газетада басылып та чыкты.

Аерылышу ифрат та авыр булды. Ул мине үзеннән җибәрми һәм үзендә калдыра да алмый иде. Мин исә аны үземә тартып ала алам, әмма үзем белән алып китә алмый идем.

Нидер сизенгәндәй, ул, авыр сугышлар, зур югалтулар шаһиты, мине, гүя улы кебек күреп, һаман-һаман да үзеннән җибәрми иде. Машинага утырып киткәндә, аның күзендә тирбәлгән моңны тасвирларга минем көчем җитми. Ул яралы кош кебек, сынган канатын кагып, бераз очып килде дә, хәле бетеп булса кирәк, бакча рәшәткәсенә сарылды. Мин аны күңеленең изгелеге, башының-акылының сафлыгы, гомумән, сирәк акыллы эзтабар, кешелекле кеше булуы белән Михаил Лермонтовның «Безнең заман герое»ннан Максимычка охшаттым. Авыр туфрагы җиңел булсын иде мәрхүмкәйнең!..

Туган нигеземә әйләнеп кайткач, Тимофей Тихоновичтан килгән хатлар шул безнең очрашу турындагы материал чыккан газетаны, бергә төшкән фотоны алуым-алмавым өчен борчылулардан гыйбарәт иде. Әмма борчылулары һаман да «дивизия тарихы, полкташлар язмышы» тирәсендә кайнаша иде. Менә аның соңгы хатларының азаккы өлеше: *«...Как получишь, Боря, сообщи, чтобо я не волновался. Я всё еще работаю сторожом. Снек нонче выпал хороша, двадцат пят сантиметров, ток что хлеба у нас хорошо уродятся. Всем до встречи. 18 январь 1990 год...»*

Гәүдәсен сугыш иләгән ветеран һаман да булачак иген уңышы турында кайгырта. Нинди бөек, нинди кабатланмас, нинди илаһи буын бу!

Әтәйнең сугышчан язмышы турындагы хикәят әлегә шушы урында тәмамланадыр. Ерак Чехия, Словакияләр аша үтеп, аның эзләре туган Ватаныбызның Каф таулары тарафларында ачыкланды. Бүгеннән башлап, шул якларга юл төшкән саен мин Архангельск станицасына сукмак яңартып, Икенче Бөтендөнья сугышының бөек каһарманы, газизләрдән газизебез, тетрәткеч шәхес Тимофей Тихонович каберенә гаиләбез, авылыбыз, районыбыз, Башкортстан-Татарстаныбыз исеменнән чәчкәләр салырмын, аның балалары, онык-онычкалары белән очрашып, ошбу китапны, нинди телдә һәм кайчан чыгуына карамастан, бүләк итәрмен дип хыялланам. Тимофей Тихонович милләт аермый торган якты бер интернационалист һәм татар халкын үз милләтен яраткан кебек яратучы гражданин иде. Рәхмәт аңа.

Шулай итеп, миңа туган нигеземә, нәкъ кырык өч елдан соң әтәй язмышы турындагы дөрес хәбәрне алып кайтырга насыйп булды дип уйлыйм. Ул безнең барыбызга да, беренче чиратта, аны үстергән, сынаулар тулы авыр юлга озатып калган Түгәрәк Имәнгә кирәк иде.

Без – туганнар һәм авылдашлар, зиратта барыбыз бергә җыелышып, 1988 ел сентябренең кояшлы бер көнендә Түгәрәк Имән һәм газиз әнкәбез кабере туфрагына ерак Чехословакиядә, Татра (Татар) таулары итәгендәге әткәй кабереннән алынган туфракны салдык. Словак туфрагында әтәй белән бергә гүргә кергән Түгәрәк Имән яфрагының мәңгелек матдәсе бар иде. Мондый туганлашу, димәк, әтәй васыяте буенча мәңгелеккә туганлашу чарасы иде.

Мин Түгәрәк Имән төбендә авылдашларыма һәм туганнарыма словак туганнарыбыз күчтәнәч итеп җибәргән шәрабны авыз иттердем. Алар, җыр осталары, словак кардәшләребезгә атап җырулар җырладылар. Безнең туган нигезебез бөтен авылның умарта күче кебек гүләп торды. Кемнәр генә, ничек кенә куанмады, кемнәр генә тәмле аш-сулар белән хушланмады безнең бу кунакчыл йортта? Ул нигездә хуҗабикә булган өч галәми хатын-кыз – картинәм Гайнекамал «карчык», инәм – Минсорур «түти», өлкән агамның җәмәгате Миннур «җиңги»ләргә утызар еллык гомер кишәрлеге булгәндә дә туксан елга барып басмыймы бу нигез?!

Кемнәр генә аяк басмады, кемнәр генә булмады икән биредә? Олы Кәркәледән якын туганым, күренекле дипломат, татар халкының 1917-18 елларда Уфада оешып, кыска гына вакытта эшләп алган беренче Милли Мәҗлес депутаты һәм Милли Мәҗлесне оештыручыларның берсе Габдрахман Рәхимкулов булган биредә. Бу йортта Башкортстанның халык шагыйре, Социалистик Хезмәт Герое Мостай Кәрим, Россиянең, Татарстанның халык артисткасы Нурия Ирсаева, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы Зөһрә Сәхәбиева, Татарстанның халык артисты, фән докторы, профессор Рәгъде Халитов, Татарстанның халык артисты Мөнир Якупов, Башкортстанның һәм Татарстанның халык артистлары Редик Фәсхетдинов, Айдар Галимов, Фән Вәлиәхмәтов, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре, җырчы Асия Әхмәтшина, композитор Вәсим Әхмәтшин, Татарстанның халык язучылары Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев, Ростовтан танылган кинорежиссёр Василий Голубниченко, билгеле кинооператор Семён Эпштейн һәм башкалар, һәм башкалар...

Тормыш дәвам итә. Балаларыбыз бар. Балаларыбыз исән. Балаларыбызның балалары исән булсын!

Иминлек бу нигезгә. Иминлек кенә була күрсен. Йортыбызның әлеге көндә буш торуын вакытлыча дип аңларга кирәк. Димәк, нигезебез безне – балаларыбызны көтә. Корымасын иде ул. Милләткә, тормышка хезмәт итсен иде. Туган нигездә туган телемдә әйтелгән теләкләрем васыять булып та яңгырасын иде.



Марат
Кәбиров

# АВТОМАТ ҺӘМ... ШИГЫРЬ ДӘФТӘРЕ*

ЯЗЫЛМАГАН ПОЭМА

* * *

Тәүдә Сүз булган. Сүз!
Агач ботагында сикергәләп
Йөргән кыргый адәм баласыннан
Җиһан гизәр Кеше ясаган Сүз.
Кешелекнең бөек анасы – Сүз.
Ә Кешелек үсә, алга бара.
Тик күңеле белән ул бит бала
Һәм һаман да бала булып кала.
«Бала күңеле – далада» ди халык...
Зур дөньяда канат каккан кешелек
Ана кебек гади Сүз кадерен,
Гади, ләкин гали Сүз кадерен
Аңлап бетми. Бетми төшенеп.
Кешелекнең бөек анасы – Сүз...
Ә шигърият ул – Сүзнең әнкәсе.
Ул галәмнең чиксез киңлегендә
һәм адәмнең төпсез күңелендә
Адашып йөргән тере авазларны
Сихри бер тәртипкә китерүче,
Аны Сүз итүче һәм шул Сүзгә
Могҗизави гомер бирүче.

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган беренче әдәби бәйгедә «Поэма» номинациясендә икенче урынга лаек булган әсәр.

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе. «Онытма таңнарны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

*Адәм җанын тере итүче көч – Шигърият ул.*

*Яшәү – Җан һәм Шигърият кавышкан чак.*

*Без моны гади тормышта, бәлки, күреп тә, аңлап та җитмибездер. Тик тормышның асылы булган Гади Хакыйкать гадәттән тыш хәлләрдә ныграк күренә, ачыграк төсмерләнә. Гадәттән тыш хәлдә кеше битлекләрен салып ташлый, табигый асылына кайта.*

* * *

Таҗик иле ул чак кайный иде...

Авыр ярасыннан ыңгырашып,
Бөгәрләнгән иде Тау иле.
Күге – сөрем, һавасында – үлем,
Ә җирендә кара кан иде.

Горур таулар бөгелеп төшкән иде
Иңнәренә яткан газаптан.
Таулар бөгелгәндә бөгелмичә
Түзә иде гади солдатлар.

Солдатлар...
Мескен илнең горур солдатлары...
Пяндж буе. Әфган чикләре.
Ил таркалды. Дәүләт чиге бетте.
Солдат йөге генә бетмәде.

Пяндж буендагы сугыш уты
Ике илне бергә актара.
Шул котырган тәмуг уртасында
Әсир булып калды застава.

Рәсәй. Мәскәү.
Ул оныткан безнең заставаны,
Муеныннан ашкан үз эше:
Хәлсезләнеп ауган державаны
Ач эт сыман өзеп бүлеше.

Таҗикстан. Памир. Һәр тау саен
Калкып чыккан яңа түрәләр
Нәфселәрен байрак белән каплап,
Канга манып, илне бүләләр.

Застава бар. Тик Дәүләт юк. Чик юк.
Җимерелгән монда бар чикләр.
Көпә-көндез урам уртасында
Берсен-берсе суя таҗиклар.

Һәм каһәрле сугыш аждаһасы
Корбан йота-йота арый да,
Деликатес көткән кунак сыман,
Заставага килеп сарыла.

Тәмуг эчләрендә тәмуг булса,
Шул буладыр аның мәхшәре.
Егет ава... Кала кара табут...
Автомат... һәм... шигырь дәфтәре...

***

*«Үпкәләмә, синең хатларыңа*
*Вакытында җавап язмасам.*
*Гаепләмә, сине юатырлык*
*Җылы сүзләр таба алмасам.*

*Хатлар монда урабрак килә,*
*Ераграк йөри җылы сүз.*
*Назлы сүзләр шыбырдашып кына*
*Таңнар аттырырбыз әле без».*

*«Яулар арты яу гына да*
*Таулар арты тау гына.*
*Солдат сине тауларда да*
*Яуларда да сагына.*

*Тауларга менеп карадым,*
*Карадым – күренмәдең.*
*Күрдем бары тау артында*
*Тау гына тезелгәнен».*

Монда күпләр шигырь яза иде...
Шагыйрь түгел иде берсе дә...
Гражданкада Пушкин-фәләннәргә
Китмәгәндер, бәлки, исе дә.

Алар өчен, бәлки, шигырь уку
Тоелгандыр артык эш булып,
Шигъри хисләр – йомшакларга гына
хас булган бер сәер хис булып.

Монда күпләр шигырь яза иде...

Ә бер подполковник, чик буеның
Каһарманы – тере легенда.
Минем шагыйрь икәнемне белгәч,
Болай диде шигырь турында:

– Ачы давыл язмыш корабымны
Кайда гына илтеп атмады,

Гомеремнең авыр чакларында
Мине бары шигырь саклады.

Ә ул язган шигырьләрне җыйсаң... –
һәм елмаеп куйды. – Күп инде...
Ул шигырьләр үзем өчен генә,
Яшәү өчен генә бит инде...

* * *

« Үзе өчен, яшәү өчен генә»
шигырь язучылар – азмы алар?!
Күпләр бүген шигырь укымыйлар,
Күпләр бүген шигырь язалар.

Гомерләрнең авыр мизгелләрен
Җиңеп чыгар өчен язалар:

*«Мин бик бәхетсезмен. Чөнки сөйгән ярымны каһәрле Чечня тартып алды. Менә ничәнче ай инде минем өчен дөньяның яме дә, тәме дә юк. Онытырмын дип уйладым, ләкин оныта алмыйм. Сагынам мин сине, ярым, сагынам. Сагышлардан шигырь яза башладым.*

*Сине сагынып үтә ямьле язлар,*
*Сине сагынып үтә көннәрем.*
*Сине сагынып үтте озын кышлар,*
*Кышлардан да салкын төннәрем.*

*Сине сагынып үтә яшь гомерләр...*
*Йөрәк көтә сине, сагына.*
*Сагынганнар кайта еллар үткәч*
*Туып-үскән газиз ягына.*

*Син бәхетем идең... Хәзер инде*
*Гомер буе әрнер сагышым...*
*Йөрәгемне учларыма кысып*
*Киләчәккә китеп барышым.*
*(Тәтешле районыннан*
*И.Фәрвиеваның хаты)*

Их, син, таныш түгел сеңлем,
Юатып ни дип әйтим?!
Ни дип әйтеп, хәлләреңне
Ничекләр җиңеләйтим?!

Газабыңны җиңеләйтер
Чаралар табалмыймын.
Бүлеп алырдай булам да
Бүлепләр алалмыймын.

 Иреннәрең елмайса да,
Ярадыр йөрәгеңдә.
Күрәм яраң әрнүләрен
Күзләрең тирәнендә.

Сер бирмичә үткәрсәң дә,
Иң авыр мәлләреңне,
Үзең генә беләсеңдер
Үзеңнең хәлләреңне.

Иманнәрне бөгәрлек шул
Кичергән газапларың.
Сынмасын гына... Сынмасын
Сабырлык канатларың.

* * *

Түзалмыйча ачы әрнүләргә,
Гомерләрнең авыр чагына,
Кеше Җирдә яшәү көче эзләп,
Шигърияткә килеп сарыла...
Рәнҗеп-елап кайтып, әнкәсенә
Иркәләнгән бала шикелле...

*Чечен сугышыннан кайткан дустым миңа шигырьләрен китерде.*

*Ул – полиция хезмәткәре, әдәбияттан ерак торган кеше иде. Моңа кадәр, дары исен иснәгәнче, ул үземне ихтирам итсә дә, шөгылемне бик өнәп бетерми: «Әзмәвердәй таза ир-егеткә нечкә күңеллелек килешми инде. Ә син шигырь язган буласың. Туган җир, мәхәббәт, дисең... Шигырь язу күз яше түгүгә тиң бит ул», – дип шелтәли иде.*

*Һәм менә шул кеше, Чечен җирендә берничә дустын һәм кара чәчләрен калдырып кайткан узаман, шигырьләрен китерде: «Русча гына язам инде мин. Ошаса, тәрҗемә итеп, берәр татар гәҗитендә бастыр әле». Мин риза булдым һәм теге вакыттагы сүзләрен исенә төшердем:*

*– Шигырь язу – күз яше түгү, ди идең бит. Әллә чеченнар елатып кайтардымы?!*

*Ул озак кына дәшми торды. Вакытыннан иртә агарган чәчләрен учлап, башын аска иеп утырды. Шуннан карашларын күтәрде дә, ачы елмаеп, иңемә кагып куйды:*

*– Ярар, картлач, кичер. Хаксыз булганмын...*

*Кешенең бертөрле тыныч тормыштан ераграк булган саен шигырьгә тартылуын мин инде белә идем. Вак мәшәкатьләрдән, ыгы-зыгылардан торган тормышта кешенең Рухы йоклый. Корсак тутыру өчен рух кирәкми, кесә тутыру өчен дә кирәкми ул. Рух йоклаганда, Яшәү... тулы канлы яшәү туктап тора. Шигърият ул – рухның уяу чагы. Сугышта кеше аягүрә йоклый алмый: йә ул яши, йә үлә. Яуда кешенең рухы һәрчак уяу: нәфрәтләнә, курка, сөя, сагына, җәлли... Һәм җанында шигырь уяна.*

*Сугыш кына түгел, гадәттән тыш хәлләрнең һәммәсе дә гади кешене дә шагыйрь итә ала. Тик чын шагыйрь өчен... Шагыйрь өчен тыныч тормыш яки тынгылык юк.*

*Шагыйрь һәрчак – гадәттән тыш хәлдә.*

*Дустымның иңемә кагып: «Кичер, картлач...» – диюе дә, авыр яу юллары үтеп кайтканнан соң менә шушы хакыйкатьне аңлавы, һич югы аңларга омтылуы.*

*Ә аның шигырьләрен мин тәрҗемә итмәдем. Шигъри ачыш, үзенчәлек юк иде анда. Туган җиргә, сөйгән ярга, әниләргә булган кайнар тойгылар турында гадидән-гади сүзләр, яшәү һәм үлем хакында миллион тапкыр кабатланган фикерләр иде. Күрәсең, гади тормыштан тәмуг казанына килеп төшкәч, моңа кадәр бик санга сугылмаган уй-хисләр дә Шигырь булып, зур яңалык булып тоеладыр. Нишлисең, шигъри сүз әйтү җиңел түгел. Ә Шагыйрь булу тагы да авыррак.*

*– Син Чечнядан бер бик зур әсәр алып кайткансың, – дидем аның шигырьләрен кире биргәндә.*

*– Нинди әсәр? Тәрҗемә иттеңме соң?*

*– Аны тәрҗемә итеп булмый.*

*– Кайсы шигырь соң ул?*

*– Ул шигырь – син үзең.*

«Кайнар нокта»ларда Кеше булып
Калыр өчен күпме көч кирәк!!!
Җирне ялмый явыз сугыш уты,
Әрнү уты тагы да көчлерәк.

Әрнү уты чиксез... Билгесезлек
Томан булып ята юлыңда:
Кая килеп, кая барышларың?
Син ни өчен һәм син кем монда?

Кемлегеңне үзең белмисең дә
Ә беләсе килә. Бик килә.
Үтерәсе килми, байрак үбеп,
Антлар иттем илгә дип кенә...

*«Баш очыңда гына кара болыт...*
*Әҗәл уйный утлы яшен булып...*
*Күктә – матәм төсе – кара болыт...*
*Ә җиреңдә канлы күз яше...*

*Үтерүче буласың да килми,*
*Антларыңны бозасың да килми...*
*Үтерүче буласың да килми,*
*Үзеңнең дә килми үләсе.*

*Үтерүче буласылар килми...*
*Утлы әҗәл җәя колачын...*
*Мин күкләргә, болытларга аттым,*
*Юсыннар дип җирнең гөнаһын.*

*Әткәм-әнкәм, өзелеп сөйгән ярым,*
*Дус-ишләрем, якын туганнарым,*
*Яныгызда кабат булалмамын –*
*Күз яшьләрен түгеп көтмәгез.*

*Сезнең янга мин кайтырмын сыман.*
*Сагынычлы хыял юлларыннан*
*Сезнең янга без кайтырбыз сыман...*
*Ә бу юлы... гаеп итмәгез...*

*Үтерүче буласылар килми,*
*Утлы әҗәл җәя колачын.*
*Мин күкләргә, болытларга аттым,*
*Юсыннар дип җирнең гөнаһын».*

Һәрбер пуля үлем алып килә,
Йөз гомерне өзеп ярыла туп...
Үтерүчеме син, яклаучымы –
Аңлап булмый. Булмый аңлатып.

Ә кулыңда корал...
Ул үлемнән сине сакласа да,
Рухи һәлакәткә юл ача.
Ерткычка да әйләнергә мөмкин,
Күңелеңдә шигырь булмаса.

* * *

*Таҗикстандагы Рәсәй гаскәрләре «боевиклар яшеренгән» дигән сылтау белән Әфганстанның чик буендагы кышлагын «Град» утына тотты. Икенче көнне әфганлылар: «Менә сез гаепсез кешеләрне нишләттегез!» – дип, өзгәләнеп беткән берничә гәүдәне таҗик ягына алып чыкты. Корбаннар арасында биш-алты яшьлек малайның өзелгән башы да бар иде.*

*Бу әфган малаен минем күргәнем юк, тик ул шундый таныш иде. Ул миңа үз улымны, Башкортстанда, әнисе янында калган үз баламны хәтерләтте. Үз сабыегызның өзелгән, канга баткан башын күз алдына китерә аласызмы? Бу баш та сезнең кебек әти-әниләрнең бер газиз баласы иде бит.*

*Әфганлылар мәетләр төрелгән җәймәне көймәгә кире салганда, сабый башы Пянджның бу ярында тәгәрәп төшеп калды. Ике як вәкилләре дә дошмани көчергәнешлек кичергәнгә, аңа игътибар итүче булмады да бугай. Бераздан, әфганлылар китеп югалгач кына, бер офицер Башны күреп алды. Һәм сүгенеп, суга атып бәрде...*

*Икенче көнне таулар артыннан кояш чыкмады.*

*Таулар артыннан канга батырылган Сабый башы чыкты...*

«Мин яшәргә тиеш идем әле...
Мин яшәргә җиргә килгән идем.
Сез яу уртасында булсагыз да,
Мин Балачак дигән илдә идем.

Уйнап кына йөри идем бит мин...
Мин бит уйнап кына йөри идем...
Ниләр өчен тупка тоттыгыз соң
Сез Балачак дигән илне минем?

Ходай әмере алай түгел иде...
Кем әмере соң бу? Кем әмере?..
Җан кыярга кемнәр әмер бирде –
Кайсы аналарның бердәнбере?

Мин яшәргә җирдә тели идем...
Мин яшәргә... Ә сез... тападыгыз...
Кайда минем гомер? Бала чагым?
Кемнәр алды? Кире кайтарыгыз!

Ахмаклыктыр сездән шәфкать көтү,
Үтенепләр сорыйм тик шулай да –
Кайда әнкәм? Кайда туган йортым?
Уенчыклар тоткан кулым кайда?

Мин шуларны эзләп чыктым бүген,
Ярсу Пяндж дулкыннарын ярып.
Кайтарыгыз! Кайтаралмасагыз,
Акланыгыз берәр сәбәп табып.

Сугыш шул бу... Аңлыйм...
Җан да кыела
Һәм коела кан да сугышларда.
Исбатлагыз күзләремә карап
Гаебегез югын минем алда!

Үткәнегез генә түгелмен мин –
Бер өлеше сезнең киләчәкнең:
Җаныгыз булса, җаныгызда яшәп
Аның белән бергә кибәчәкмен.

Жәллим сине, яугир. Син илеңә
Байрак тотып антлар иткән идең...
Солдатлары булу, аһ, авырдыр
Балачакны тупка тоткан илнең.

Китәм сездән. Жәлли-жәлли китәм.
Кичерермен, бәлки, берәр вакыт.
Кабер көтә мине. Ләкин сездән
Котыла алырмынмы җирдә ятып?!

Юк, китмимен. Калам. Яр буенда.
Күпләр, бәлки, мине күрерләр дә...
Кешелеклелек кайтыр, иман кайтыр
Гарипләнеп беткән күңелләргә.

Кабатлыймын Гайсә пәйгамбәрдәй,
(Сезнең пәйгамбәрдәй!): «Үтермәгез!»
Байрак үбеп антлар итсәгез дә,
Пәйгамбәрегезгә төкермәгез!

Әнә, берәү килә... Ул үзенең
Ни кылганын, аһ, аңласа иде...
...Тыңларга да хәтта теләмәде,
Күтәрде дә мине күккә чөйде.

Һәм сүгенеп куйды... Күктә – Кояш...
Ә түбәндә – Пяндж дулкыннары...
Хуш, бәхил бул, чер(е)гән бөек илнең
Мәңге яшәячәк үлек җаны.

...Уйнап кына йөри идем бит мин.
Бетте хәзер уен кайгылары...
Бөек илнең мескен солдатлары,
Арагызда берәр Кеше бармы?!

Кеше бармы? Булса, зинһар өчен,
Күңелегезгә шуны беркетегез:
Корал тоткач, байрак үбеп түгел,
Балаларны үбеп ант итегез!

Балаларны үбеп! Алдыгызга
Шундый сорау тагы басса кинәт
Бөек Ана бүләк иткән җанны
Туптан түгел, таптан саклау кирәк.

Җаныгызны таптан саклау кирәк,
Саклау кирәк сабый каннарыннан.
Бәхетле ил төзү мөмкин түгел
Сабый канын койган җаннар белән.

Сүзләремне, әгәр ишетмәсәң,
Хакыйкатьне укы күзләремнән:
Сез – бәхетсез... Җирдә бәхетле ил
Төзеп булмый бәхетсезләр белән.

Балаларны үбеп ант итегез...
Аналарны... Кем әйтәла кабат
Корылмас дип корал? Борылмас дип
Үзегезнең Аналарга карап?

Хөкүмәткә фәкать коллар кирәк,
Ә халыкка – уллар. Ил уллары.
Мин китәмен... Күктә Кояш кала,
Ә түбәндә – Пяндж дулкыннары.

Шул дулкыннар кебек шук идем мин,
Якты кояш кебек көләч идем.
Дулкыннарга иңәм. Дөньягызның
Иртә таңда баткан кояшы мин.

Тәкъдиремә – шундый өлеш минем,
Бу өлешем белән килешмимен.
Мин яшәргә тели идем әле,
Мин Яшәргә Җирдә тиеш идем...»

* * *

*Бер мәлне мин бер авылда бер абзыйга фатир төштем. Җаваплы кеше алдан ук кисәтеп куйды: «Әфганстанда хезмәт иткән. Холкы бик алама. Силсәвит прсидәтелен дә, колхоз рәисен дә сугып екканы бар. Шуның өчен штраф та түләп чыкты. Бер ипкә килмәгәч килми инде».*

*Ә мин фатирга керәчәк кешемне үзен күргәнче үк ихтирам итә башладым. Сугышны кичергән кешеләрнең тыныч тормышта үзенең үлемсезлегенә ышануын, үзен башкалардан өстенрәк хис итүен мин аңлый идем. Алар, әлбәттә, хаклы түгел. Тыныч тормышның үз кануннары.*

*Мин килгәндә, ул бераз салмыш иде. Кулымны авырттырыбрак кысарга тырышып:*

*– Интеллигент! – дип куйды.*

*Бу сүз миңа авыр ишетелде. Чын мәгънәсендә интеллигент булырлык шәхесләребезнең аз икәнен белгәнгә күрә, бу сүзнең ирония белән әйтелүен җенем сөйми. Яратмыйм. Шуңа күрә мин дә бераз тешләшебрәк җавап бирдем:*

*– Бездә кешене болай каршыламыйлар.*

*Ул тагы нидер әйтмәкче иде, хатыны табынга чакырды. Өстәлдәге сый-нигъмәт, һәм бигрәк тә көмешкә янында минем дә интеллигент булмавым ачыклангач, абзыйның миңа булган ихтирамы бермә-бер артты. Һәм без сөйләшеп киттек. Ул миңа йөрәген ачты.*

«Сайрый да сайрый сандугач тирәктә.
Әрни дә әрни бер яра йөрәктә.
Әрни дә әрни көнен дә төнен дә.
Тик әрнүдән тора сыман гомер дә.
Сайрый да сайрый... Нигә соң сайрарга?..
Әйтерсең лә ул да булган Тауларда.
Сайрый да сайрый... Күңелдә – Тау иле.
Тау илендә кара канлы яу иде.
Үлем чәчеп сайрый иде автомат.
Аһ җан дустым... Аһ якташым...
Аһ комбат...
Бер-бер артлы дуслар гомере өзелә.

Сибелә үлем. Җиргә кайгы сибелә.
Сайрый автомат бер ташның артыннан.
Бар дөньяга чиксез үче бар сыман.

Сайрый үлем. Әхәт ава... Эмиль дә...
(Аның бит ялгыз әнисе илендә...)
Ава Радик... Ислам ава... Иван да...
(Бер ай да юк әле улы туганга...)
Сайрый автомат... Сайрама! Ярамый!
Ир үлеме ил йөрәген яралый.

Сайрый автомат... Үлемгә сусаган...
Мин иплэп кенә шуыштым шул табан...
Сайрый да сайрый автомат. Ярсыган
Бар дөньяга бетмәс үче бар сыман.
Аягымны кинәт нидер көйдерде...
Вакытында мин дә атып өлгердем...

Таш артына автоматтан сиптердем...
Ник күрдем мин ул мизгелне,
ник күрдем?!
Ник алдарак югалтмадым аңымны.
Иги дә иги шул мизгел җанымны.
Кара язмыш нигә шулай кушкандыр?..
...Унбиш яшьлек малай иде дошманым.

Унбиш яшьлек малай бит ул...
Унбиш бит...
Кызлар артыннан йөрергә тиеш бит...
Шул баланы төштә күреп уянам...
Китәселәр килеп китә дөньядан.
Китәселәр килеп китә... Китәлмим...
Үз улымны тома ятим итәлмим.
Борчылу да һәм әрнү дә күңелдә:
Унбиш яшьлек улым бар бит
минем дә...»

* * *

*Яудан яраларсыз кайтып булмый. Бер тән җәрәхәте алмаганнар да мәңге уңалмаслык җан ярасы белән кайта. Ул яра төшләргә кереп интектерә, гомер буе йөрәгеңдә әрни. Ул яра йөрәктән йөрәккә күчә. Таҗикстанга килгән көннәрдә кургаш табутта кайткан дусларым, туганнарым, якыннарым өчен Пянджның аръягында, пуля җитәр ераклыкта гына йөргән әфганлылардан үч алу теләге кабынып-кабынып китә иде. Аларның һәркайсына төзәгеч аша карап, бары тик бер сорау бирә идем: «Син түгелме?» Һәм мондый халәт бер миндә генә дә түгел иде. Яу яраларының йөрәктән йөрәккә күчүе, бәлки, шушыдыр.*

*Ләкин йөрәк бездә генә түгел. Әфганлыларда да, таҗикларда да, чеченнарда да бар ул йөрәк. Алар да бабаларыннан алып сабыйларына кадәр безнең ир-егетләргә: «Син түгелме?» – дип караячак әле.*

Яудан яраларсыз кайтып булмый...
Күпләр бүген күңеленнән елый.
Шатлык кунганда да йөзләренә,
Әрнү уты сүнми күзләрендә.

Бер чәүчәләк бәндә сыман алар,
үксеп-ярсып әгәр еласалар,
Күмеп китәр иде дөньяларны
Мәңге тынмас елау авазлары.
Алар бары күңеленнән елый:

*«Шашып дөнья куа кеше,*
*Нидер җитми һаман аңа.*
*Баш күтәреп карамый да*
*Иңендәге заманага.*

*Шашып мөлкәт җыя кеше,*
*Берсен-берсе сытып-изеп.*
*Кылана ул бу дөньяга*
*Мәңгелеккә килгән кебек.*

*Яхшылыкны бар дип белми,*
*Изгелекне күрми кеше.*
*Мөлкәт өчен... Бер-берсеннән*
*Тик ерткычлык эзли кеше.*

*Җәнҗаллардан туйганмын мин,*
*Ерткычлыктан ялыкканмын.*
*Явызлыкны күп күрдем мин*
*Төпләрендә тәмугларның.*

*Кичерегез, шуңа күрә*
*Буйсынмыйм бу заманага.*
*Миңа мөлкәт кирәк түгел,*
*Тик тынгылык кирәк җанга.*

*Тик тынгылык кирәк җанга*
*Тагы бераз яшәр өчен.*
*Кичерегез мин Ил өчен*
*Бирдем бугай яшәү көчен.*

*Мин бит көчсез түгел идем*
*Алышканда дошман белән.*
*Яшәү көчем калды бугай*
*Яуда ауган дуслар белән.*

*Мин бит гаярь егет идем,*
*Мин бит болай түгел идем.*
*Мин бит болай түгел идем...*
*Нишләттең син мине, илем?!.*

*Синең өчен утлар кичкән*
*Улларыңны оныттыңмы?*
*Үткәнсез һәм киләчәксез*
*Сукмакларга юлыктыңмы?*

*Синең өчен корбан иттек*
*Яшьлекне, саф йөрәкне без.*
*Яраланган йөрәк белән*
*Хәзер сиңа кирәкмибез.*

*Без беркемгә кирәкмибез...*
*Без – бу илнең артык җаны.*
*Ватан аткан тупларның без*
*Мең әрнүле ярчыклары.*

*Мин – илемнең үги улы*
*Буйсынмыйм бу заманага.*
*Мин заманга буйсыналмыйм:*
*Сез – тормышта, мин – ярада.*

*Яраларда яши һаман,*
*Мең яралы безнең җаннар.*
*Безгә кырын карамагыз,*
*Заманага буйсынганнар».*

* * *

Алар бары күңеленнән елый,
Кайда минем яшәү көчем, дип.
«Ярты»ларга килеп сарылалар,
Әрнүләрен басар өчен дип.

Тик җаныңны хәмер баса алмый,
«Яртыларда» батмый яралар.
Әрнүләрдән арынырга теләп,
Күпләр бүген шигырь язалар.

Юк, кәгазьгә аны төшермиләр,
Укымыйлар агай-энегә.
Тик күңелдә шигырь туа, яши –
Җиңел булып кала күңелгә.

Җиңел булып кала. Тик барыбер
Яра яши... яши йөрәктә.
Өннәрендә әрнемичә калса,
Төшләреңә кереп йөдәтә.

Төшләреңә кереп йөдәтә шул
Үткәннәрнең утлы мәхшәре:
Солдат ава... Кала кара кабер...
Автомат һәм... шигырь дәфтәре...

Яугир гадәттән тыш хәлдә яши…

Равилә
Шәйдуллина-Мурат

# ТАУ БАШЫНДА БҮРЕ БАР

РОМАН*

### Уникенче бүлек

Сәүдә өлкәсендә эшлим дисәң, бүре булырга кирәк икән ләбаса. Әгәр өстеңә сикерергә әзер бүреләр өеренә каршы тора алмыйсың икән, тау түбәсенә күтәреләсе дә юк.

Ничә ашханә ачты Асия. Ләкин матур гына эшләп китүгә, түрәләр ниндидер сәбәп тапкан булып, аның урынына үзләренә кирәкле кешене китереп куя бардылар.

КАИ ашханәсеннән куып чыгарылганнан соң да үзенә эш тапты Асия. Әйбәт кенә эшли башлады. Авылдан улын алып килеп, бакчага урнаштырды. Улы да әти-әнисен танып, «әти», «әни» дип дәшә башлады. Инде Шәриф Әкбәрович салган йөрәк ярасы да җөйләнә төште бугай.

Тик менә ашханә директоры Рәшит Габбасович кинәт кенә йөрәк өянәгеннән үлеп китте дә, аның урынына Асия кебек ашханә мөдире булып эшли торган Инара Бариевнаны куйдылар. Чибәр хатын иде Инара. Асиядән сигез яшькә өлкәнрәк, яшел күзле, зифа буйлы хатын. Җитәкче дәрәҗәсенә ирешкәч, Асияне үз кешесе Галина Ивановнага алмаштырды.

Казан каласында туып үскән Инара Бариевна тормышның аяусыз дулкыннарына каршы тора алырлык тәҗрибәле ханым иде. Ике ирдән ике бала үстереп ята, сәүдә өлкәсендә шактый абруе да бар. Тып-тын гына чыгып китте Асия. Чөнки сүз әйтергә җай калдырмадылар. Ханым тауарның күпме калганын тикшерергә дип бухгалтерларны атна саен җибәрә торды. Гаеп табарга ашкынып килгән кешегә исә җитмәүчелек яки артык тауар казып чыгару кыен түгел. Бүген черек тауарны алдым, дип документка кул куярга мәҗбүр итәләр дә, иртәгәсен сиңа тикшерүчеләр килеп төшә.

Беркөнне Инара Бариевна кабинетына дәште дә:

– Синең менә никадәр җитмәүчелегең бар. Хәзер прокуратура чакыртам, – дип янарга кереште.

– Кичә генә шул суммага черек тауар җибәрдегез бит. Бозылган йөземне кешегә сата алмыйм ич инде мин. Сасыган балык-селёдканы да алдап-йолдап кеше кулына тоттыра алмыйм.

– Башкалар сата бит. Син җүнле ашчы булсаң, черек тауардан кәнфит яса. Менә шул чакта булырсың оста!

* Журнал варианты

*Ахыры. Башы узган елның 11, 12 нче, быелның 1 нче саннарында.*

– Мин алай эшли алмыйм, Инара Бариевна. Гафу итегез. Үз теләгем белән эштән китү турында гариза язам.

Инараның яшел күзләре шунда ук гөлт итеп кабынды. Йөзенә шатмөлаем елмаю кунды:

– Әллә кайчан шулай диләр аны, Асия! Нигә бер-беребезнең җанын талкып торырга, ди?

– Сезгә шул гына кирәк иде бит, Инара. Рәшит Габбасович фани дөньяны калдырып киткәнгә кадәр сез башкача сайрый идегез бит. Икебез дә бертөрле вазифа башкара идек. Икебезнең дә эшләр яхшы барды. Сез җитәкче булган бер ай эчендә нәрсә үзгәрде соң?

Бу сорауга җавап ала алмасын белә иде Асия. Шуңа күрә гаризасын Инара өстәленә салды да, ишеккә юнәлде...

Улы Муратны янә дәү әтисе, дәү әнисе янына авылга кайтарып куйдылар. Мондый хәл берничә тапкыр кабатланды: Асиянең яңа ашханә эшен җан-фәрман тырышып җайга салганын карап-күзәтеп торалар да, җылы урынга үз әшнәләрен билгеләп, аны урамга куып чыгаралар. Кеше кадерен белә торган җитәкчеләр очрамады шул Асиягә. Совет сәүдәсендә эшләп чыныккан-каешланган, төрмә-фәләнгә тармаган хезмәткәр нинди генә урынга куйсалар да эшли алыр иде югыйсә. Чөнки ул инде тегермән ташы кебек чарланган, жумба балыгыдай шомарган. Суы ничек кенә болганчык булмасын,  барыбер яшәү җаен табачак.

Әйе шул, гыйбрәт алырлык хәлләр булып торды. Берзаман комбинат директорының алтмыш яшьлек юбилеен бәйрәм итәргә җыендылар. Егермеләп ашханә директоры бергәләп котларга уйлады. Баш вата болар: нинди бүләк алырга?

– Әйдәгез, кечкенә генә телевизор бүләк итик.

– Ә кайдан табабыз?

– Син – миңа, мин – сиңа заманы лабаса. Әле бая гына электр тауарлары кибете директоры кара уылдык, сервелат сорап мөрәҗәгать иткән иде...

– Табарбыз, шәт, – диде Миңнулла. Акча җыйдылар.

Җомга көнне бик шәпләп бәйрәм иттеләр. Барысы да бәхетле иде. Әмма иртәгәсен комбинат директорының өенә тентү килеп төште. Теге нәгъләт төшкән бүләк – кечкенә телевизорны эзләүләре икән. Ришвәт, диделәр. Каян гына белгәннәр диген, ә!

Юбилейга катнашкан директорларның һәммәсенә повестка килеп төшмәсенме! Һич кичекмәстән, фәлән сәгатьтә прокуратурага килеп җитәргә!

Әмма телевизорны таба алмадылар. Бүләк әле хуҗасы өенә кайтып җитә алмаган. Кабинетында да юк. Кая киткән? Гаҗәп бит!

Прокуратура хезмәткәрләре, һәрберсен берәм-берәм чакыртып, сорау ала башлады. Асия дә килде.

– Син телевизор өчен күпме түләдең?

– Бер тиен түләмәдем. Чәчәк кенә алып бардым.

– Син илле сум акча биргәнсең бит. Хәмит әйтте.

– Хәмит әйткәч, аннан сорагыз! Бер тиен дә бирмәдем.

– Ә башка вакытта директорга аена күпмешәр түләп тора идең?

– Что сез! Беркайчан да, беркемгә дә, бер тиен дә түләгәнем юк. Ник әле мин кемгәдер акча түләргә тиеш, ди. Булмаганны...

– Ә телевизор кайда?

– Нинди телевизор? Күрмәдем.

– Банкетта булдыңмы?

– Булдым.

– Юбилейга буш кул белән бардың, что ли?

– Чәчәк бәйләме бүләк иттем, дим. Әнә Лобачевский урамындагы чәчәк кибетенә барып сорагыз. Чегын сакламаганмын.

– Бүләгеңне чегы белән тапшыргансың, ахры?

– Мин тәрбияле кеше, бүләкнең бәясен күрсәтмиләр.

– Әллә сезнең комбинат директорыгыз әүлияме соң? Барыгыз да чәчәк гөлләмәсе генә тотып килгәнсез. Тере килеш чәчәккә күмдегезмени үзен? Кая гына куеп бетерде микән ул гөлләрне?

– Дөрестән дә шәп кеше ул – безнең комбинат директоры. Акыллы кеше! Ришвәт алуы турында беркайчан да ишеткәнем юк.

Бөтенләй тетелеп-хәлсезләнеп чыкты Асия тикшерүче бүлмәсеннән.

Урамга, кичке салкынча һавага чыккач, азрак хәл кереп киткән сыман тоелды. Ул дусты Гөлияләргә таба җәяүләп кенә атлады. Чөнки телефоннан сөйләшергә ярамый, диделәр. Ишекне дустының ире ачты.

Асия килеп кергәндә, Гөлия ниндидер рәсми кәгазьләрне аралап утыра иде.

– Гөлия, исәнме, сөйләшәсе сүз бар. Чыгып керик әле, – диде ул дустына.

Алар кич буе Черек күл паркында йөрде.

– Гөлия, син кайчан булдың тикшерүчедә?

– Кичә. Әллә ничә сәгать утырып кайттым. Ябык кына, йөзе кара янган бер адәм. Сәгатьләр буе җанымны талкыды. Валлаһи, дип әйтәм. Попугай кебек һаман бер сорауны бирә: телевизор кайда, каян алдыгыз? Күпме акча бирдең? Башка вакытта күпме түләп тора идең?

– Ә син нәрсә дидең?

– Чәчәк бүләк иттем, – дидем.

– Мин дә шулай ук җавап бирдем, Гөлия. Билләһи. Соңыннан кабинетыннан куып ук чыгарды. «Все равно найду этот проклятый телевизор. Я с тобой не прощаюсь», ди. Карале, Гөлия, ул телевизор ничек юкка чыкты соң? Без бит аны банкет залында бүләк иткән идек...

Гөлия як-ягына шымчыларча каранып алды да:

– Миңа иртән иртүк хуҗаның кызы Гүзәл килде, – диде. – Безнең өй тулы милиция хезмәткәрләре, ди. Әти һушы китеп егылып ята, кичә директорлар җыелышып бүләк иткән телевизорны эзлиләр, дип елый. Мин шунда ук Монголиядә эшләп, машина алып кайткан Илдарга шалтыраттым да, тиз генә килеп җитүен үтендем. Кичә бик соң кайтылды бит. Ә кайбер ир-егетләребез, туры өйләренә кайтмыйча, ресторанга сугылган икән. Ир-ат халкын үзең беләсең, азрак салып алса, үз башына мажара эзли башлый. Шуңа күрә телевизорны банкет үткәргән җирдә бер бүлмәгә бикләп калдырганнар. Илдар егерме минуттан килеп тә җитте. Кеше-кара күрмәгәндә теге зәхмәт-телевизорны аның машинасына төядек. «Мин аны үзем дә эзләп таба алмаслык итеп яшерәчәкмен», – дип алып китте Илдар. Йа Аллам! Егерме кеше җыелып бер телевизор алдык. Кечкенә генә бит әле үзе! Шушылай ажгырып каныгырлык бүләкмени?

– Аңа күптән бәйләнәләр бит инде.

– Кара әле, Асия! Бүген банкетта булган барчабызга да җыелышып сөйләшергә кирәк. Үзебезнең ресторанда яки ашханәдә түгел, нейтраль биләмәдә очрашыйк. Аккош күлендә! Уяу була күр яме, Асия? Әнә директорыбыз Сәлим Хәлиловичка «шәһәрдән чыгып китмәскә!» дигән кәгазьгә кул куйдырганнар, – диде Гөлия пышылдауга күчеп.

– Җинаятьче тапканнар икән! Гомере буе җәмәгать тукланусы өлкәсендә эшләгән кешене шул рәвешчә юк итәргә җыенулары инде бу, Гөлия. Димәк, аның урыны кемгә дә булса кирәк.

Хушлашып, авыр уйларга чумып кайтып китте Асия ахирәте яныннан. «Нишлисез сез, кешеләр? Ник соң сез бары үзегез хакында гына уйлыйсыз? Янәшәдәгеләрнең чәлпәрәмә килгән язмышы, көтмәгәндә-уйламаганда килеп төшәсе кайгы-хәсрәте бер дә борчымыймыни соң үзегезне?» – дип үрсәләнде күңеле. Бераздан ул банкетта катнашкан «җинаятьче» директорлар янына очрашуга китте.

Асия килгәндә инде барысы да җыелып беткән иде.

– Сәлим Хәлилович бик авыр хәлдә. Аны ничек тә коткарырга кирәк.

– От него не отстанут, его заказали! – диде Юрий Иванович.

– Ни өчен?

– Әлеге бүләк телевизор сәбәп кенә. Ул инде күптән күзәтү астында. Җепнең очын тартсаң, йомгак сүтелә башлый бит. Безнең бүләк аларның эшләрен җиңеләйтте генә.

– Әйдәгез, без аны шифаханәгә салабыз, – дип телгә килде Гөлия.

– Аннан кайчан да бер чыгачак  ич инде ул.

– Бе-лә-ә-әм, лә! –диде Гөлия, сузып. – Аңа башта «үз теләгем белән эштән китәм!» дип гариза язарга кирәк. Ә аннан соң... сары йортка кереп ятарга. Өстенә тәгәрәп килгән хәсрәт тәгәрмәчен шулай гына туктатып була. Инде карьера турында уйлыйсы да юк.

Барысы да гаҗизлектән башларын иеп, уйга калды.

Аккош күлендәге түгәрәк аланлыкта үлем тынлыгы урнашкандай булды. Бары тик ниндидер бер кошның ыңгырашкан шикелле ухылдавы гына ишетелә.

– Бу кошы да тына белмәде инде, – дип, йөрәгеннән кысып чыгарды Асия. – Ә бит Сәлим Хәлилович бик күпләргә булышты. Киңәш сорап, ярдәм өмет итеп килгән бер генә кешене дә кире борып чыгармады. Димәк, кемнеңдер юлына аркылы төшкән. Үз фикерен кыю белдерергә җөрьәт иткән. Берәр дуңгызга «җизни» дип әйтергә теле әйләнмәгәндер бәлки.

– Дуслар, ә нигә сары йорт хакында уйлап карамаска? Это разумный выход из положения,– дип, русчага күчте Рашат.

– Ул йортның хуҗасына кайсыгыз турыдан гына чыга ала? Тик белегез, шактый гына акча да кирәк булачак.

– Табарбыз! Без күбәү, – диештеләр.

Шул рәвешчә, Сәлим Хәлилович, чыннан да, ул йортта бер айлап ятып чыкты.

Ә теге бичара телевизор кайда ята микән, дисезме? Шушы вакыйгадан егерме ел узгач, телевизор кыйссасында катнашучылар ничектер очрашып, дөнья хәлләрен, күргәннәрен-белгәннәрен сөйләшеп, хатирәләрне яңартып

күңел ачтылар. Ул чакта бергә эшләгәннәрнең күбесе лаеклы ялга киткән, ә кайберләре инде бакыйлыкка күчкән иде. Кичәне алып баручы – яшь булса да, ак чәчле, биле учка сыеп бетәрдәй зифа буйлы кыз уртага чыгып басты да:

– Хәзер барыгыз өчен дә искиткеч сюрприз булачак, – дип игълан итте.

Барысы да, әсәренеп, зал уртасына текәлде. Талгын гына музыка агылды. Шулвакыт ике яшь егет сандыкка охшаган әрҗә күтәреп керде. Әрҗәне ачып җибәрүләре булды – барысы да аһ итте. Аннан әлеге дә баягы кечкенә телевизор килеп чыкты. Әле генә шау-гөр килеп, могҗиза көтеп көлешкән кешеләр – Советлар Союзының җәмәгать туклануы өлкәсендә зур хезмәт куйган чал чәчле олпат әфәнделәр һәм ханымнар бер мәлгә тын калды. Моңарчы яңгыраган талгын музыка шундук матәм маршына охшап китте.

Телевизорны инде шактый түгәрәкләнгән Илдар Нурмиевич, үзенең яңа «Мерседес»ына салып алып килгән икән.

– Мондый корсаклы телевизорларның инде беркемгә дә кирәге юк, – дип телгә килде ниһаять кемдер.

Сәлим Хәлилович та юк.

Советлар Союзы да юк.

Милиция дә юк.

Әмма җанда тирән яра калган икән. Кайвакыт, үткәннәрне искә төшереп, сыкрап-сулкылдап куя икән...

Киеренке тынлыкны Миңнулла бозды. Ул Илдар Нурмиевичка озаклап карап торды да, гаять җитди кыяфәт белән сорау бирде:

– Кара әле, Илдар, бу телевизор элек тә шулай корсаклы идеме, әллә сиңа карап шулай түгәрәкләндеме?

Барысы да кинәнеп көлеште.

Затлы лайнерның палубасында утырганда Асия менә шушы хәлне исенә төшерде. Әлеге сагышлы хатирә, офыкта моңсуланып баеган кояш шикелле, хәтер дәрьясына кабат төшеп югалды...

Асия кичке тымызык һавада көзге кебек ялтырап яткан суга карап, дөньяның матурлыгына сокланып лайнер палубасында шактый басып торды. Океан өсте шундый тыныч. Кояш, зур кызыл табак шикелле, океан өстендә эленеп тора. Аның су көзгесендәге чагылышы – тагын бер кояш шикелле! Асиянең әле мондый матурлыкны күргәне юк иде. Берьюлы ике кояш диярсең! Икесе дә янып тора! Әйтерсең лә табигать кояш баю мизгелен су өстендә фотосурәт шикелле саклап калырга тели...

Океанны алсу төскә манып баеп баручы кояш тора-бара әллә офык артына, әллә океанга төшеп юк булды. Асия, иңенә йомшак ефәк шәлен салып, палуба буйлап акрын гына атлап китте. Көне буе әрле-бирле килеп, төрле телләрдә сөйләшеп йөргән кешеләр дә акрын-акрын каюталарына кереп китте. Кичке аштан соң кайсы кинотеатрга, кайсы спорт залына барырга җыена, күрәсең.

Ләкин Асиянең бүген беркем белән дә аралашасы килми иде. Үзе белән бергә ялга чыккан дусларының концерт карарга үгетләвенә дә бирешмәде.

– Юк, минем үзем генә калып, океанны күзәтәсем килә, – дип, каютадан чыгып китте.

Күктә дә, су өстендә дә йолдызлар. Әнә түм-түгәрәк булып тулган ай

күтәрелеп килә инде. Ул, кызарып кояш чыкканчы, күк гөмбәзеннән океан өстенә көмеш нурларын сибеп йөзәр дә йөзәр. Океан өстендәге айлы сукмак балкышы гашыйк күңелләрдә өмет кабызыр, алар, бер-берсенә сыенып, сөюен аңлатыр. Кемнәрнедер кавыштырыр бу сихри нур, кемнәрнеңдер юлларын аерыр...

Асиянең бүген нигәдер җаны урынында түгел, күңеле каядыр ашкына, нидер эзли шикелле. Ул палуба читендәге яшел кәнәфигә барып утырды да күзләрен йолдызларга төбәде.

Киек каз юлы әнә! Исемен дә тапканнар бит! Күңелләрне җилкетеп, яшьлек хисләрен яңарта торган бу исемне гашыйклар куйгандыр инде! Көзен туган илләрен калдырып, җиргә моңсулык таратып каңгылдаша-каңгылдаша китеп барган киек казлар тавышы ишетелгән кебек булды Асиягә.

Хатынның күңелендә табигатьнең шушы сихри манзарасына тиң якты мизгелләр яңарды. Ул янә ундүрт яшьлек кыз бала, мәхәббәтенең бөреләнеп кенә килгән мәлендә, беренче тапкыр, ояла-ояла, Вәкиле янына очрашуга ашыга. Ялантау түбәсендәге туп-тулы айның нуры, агымсу шикелле түбәнгә агыла. Үзен дөньяда иң бәхетле кеше дип санаучы кыз бала куаклар арасыннан тау өстенә карап тора: анда карт имән төбендә сөйгәненең ай нурларына коенып торган сынын күреп ала. Йөрәгенең дөп-дөп типкәнен үзе ишетеп, Вәкил янына йөгерә. Йөзе-бите ут булып яна. «Әле дә ярый көн яктысы түгел», – дип уйлый Асия. Вәкил кызның алсуланып янган йөзен күреп, аптырар иде.

Егет тә аның аяк тавышын ишетеп, йөгерә-атлый кызга таба омтылды.

Асия сөйгәненең күкрәгенә капланып, аның кочагында эреп юкка чыккандай булды.

– Асия, Асия! Килдеңме? Мин син килмәссең дип курыктым.

– Үзең бит, килмәсәң карт имән төбендә кунам, дип куркыттың.

– Мин сине шундый яратам, – диде Вәкил, кызның бөдрәләнеп торган чәчләреннән, ут янып торган битләреннән үбеп.

Асия дәшмәде. Дәшәрлек хәлдә түгел иде.

– Вәкил, ә мин синең йөрәк тибешеңне ишетәм.

– Яратам, мин сине яратам! – дип тибә инде ул, Асия! Мин дә синең йөрәк тибешеңне тыңлыйм, Асия! Безнең йөрәкләр бер-берсе белән шулай аңлашадыр, бәгырькәем.

Алар бер-берсеннән аерыла алмыйча, бер тән, бер җан булып озак басып торды.

– Ишетәсеңме, җаным, сандугачлар ничек моңлы сайраша.

– Бер-берсенә булган сөюләрен шулай сайраша-сайраша аңлата инде алар, Вәкил, чын әгәр! Миңа шулай тоела. Вәкил! Әйдә без синең белән беркайчан да бер-беребезгә хыянәт итмәбез, дип вәгъдәләр бирешик. Менә шушы күпне күргән йөзьяшәр имән шаһит булсын. Ә аннары, күп еллар узгач, без синең белән олыгайгач, инде оныкларыбыз тугач, бергә җыелышып шушы имән агачы янына килеп, вәгъдәбезгә тугры калуыбызны дәлилләрбез.

– Ярар, Асия! Мин сиңа карт имән агачы янында ант итәм. Мин сиңа беркайчан да хыянәт итмәм. Беркайчан да, – дип кабатлады Вәкил, кызның күзләреннән, битләреннән үбә-үбә.

– Мин дә! – диде Асия. Тау түбәсендә күкрәген киереп басып торган карт имән агачы үсмерләрнең яшь-садә хисләренең шаһиты булып, талгын җилдә яфракларын лепердәтте.

Асия белән Вәкилгә ул төнне күктә, Киек каз юлының уртасында алар өчен яңа йолдыз кабынган кебек тоелды.

– Вәкил, син күрәсеңме, әнә күктә яңа йолдыз балкый – безнең йолдызыбыз. Без дә синең белән Киек каз юлы буйлап, кошлар кебек бәхетебезне эзләп, озын юлга чыгарбыз. Ә безнең йолдызыбыз: «Кыйблагызны югалтмагыз! Адаша күрмәгез!» – дип, безне озата барыр, әйеме?

Вәкил, өстеннән пиджагын салып, Асиянең иңенә япты.

– Киек каз юлыннан күпләр бәхет эзләп чыгып киткәндер инде, Асия. Без генә түгелдер. Тик бәхетләрен таба алдыলармы икән?

– Бәхетләрен таба алмыйча калганнарның, адаштырмыйча, юл күрсәтеп торган үз йолдызлары булмагандыр, мөгаен.

– Ә без синең белән адашмабыз, Асия, икәүләшеп, кулга-кул тотышып барырбыз.

Күк гөмбәзен тутырып атылган йолдызлар бүген барысы да бу икәүнең аяк астына коелып бетте ахры. Күк йөзендә бары тик тулган ай гына калды. Ул да Вәкил белән Асиянең бәхетеннән көнләшеп, бу ике саф йөрәкнең бәхетенә сокланып озак кына йөзеп йөрде дә, Ялантау түбәсенә менеп кунды. Ялантау чишмәсенә су алырга төшеп киткән Зөһрәсен көтеп тора ул шулай. Үзе Асия белән Вәкилгә дәшә:

– Мин дә сезнең мәхәббәтегез шаһиты. Зөһрә кыз да шаһит. Өздереп-өздереп сайраган былбыллар шаһит. Әнә, бер-берегезгә, гел бергә булырбыз, дип вәгъдәләр бирешәсез. Әмма онытмагыз: вәгъдә – иман диләр...

Асия моңсу гына елмаеп куйды. Ни гаҗәп: гомеренең шушы иң бәхетле, иң татлы мизгелләреннән һаман көч-илһам алып яши ул... Вакыт-вакыт карт имән төбендәге айлы кичкә «кайтып килә»...

Асия янындагы кәнәфидә чәченә чал төшкән, мәһабәт гәүдәле олпат ир-ат ниндидер фәнни китап укып утыра иде. «Ял итәргә чыккач та эш белән мавыкланмаса соң?» дигән уй яшен тизлеге белән узып китте Асиянең башыннан. Ир-атның китабы инглиз телендә, медицина өлкәсенә кагылышлы, күрәсең. Чөнки кәнәфи янындагы диварга эленгән яшькелт лампадан төшкән ут китап битенә төшә, анда йөзе ямьсез җөйләрдән торган ир-ат рәсемен күреп, калтыранып куйды Асия: «Йа, Аллам! Нинди фаҗигагә юлыккан икән бу ир-ат? Мондый кыяфәт белән Җир йөзендә ничек яшәмәк кирәк?»

Һәм кинәт ханымның йөрәге чәнчеп куйды, баш миен яшен тизлеге белән бер уй көйдереп үтте: унҗиде яшендә күрде ул мондый йөзне. Аның үз йөзе иде ул! Асиянең карашы китап битеннән әлеге олпат ир-атның йөзенә күчте. Аның үзенә таныш кына түгел, күңеленә якын кеше икәнен җаны-тәне белән тойды ул. Туктале, бу Яков Янович бит! Әйе, Ян Михайловичның улы – Яков Янович. Шул үзе ләбаса. Үзен коткарып, яшь гомерен саклап калган Ян Михайловичның улы – Яков!

Ханым бераз каушап калды, күрәсең. Шуңа күрә ул бу галәмәт чибәр, зәвыклы киенгән ир-атка карарга кыенсынды, әмма барыбер ара-тирә күз салгалап, кәнәфиенә чумып, океанга карап баруында булды. Ә ир кеше

беләгендәге затлы сәгатенә күз төшереп алды да, күзлеген савытына салып, шартлатып ябып куйды. Урыныннан кузгалып, китәргә җыенды.

– Яков Янович! – дип аваз салды шулвакыт Асия. – Вы ведь сын Яна Михайловича!

– Да, я сын Яна Михайловича – Яков.

– Исәнмесез, Яков Янович! Ә мин – Асия. Хәтерлисезме Казанны? Җитен комбинатын? Сез әтиегез белән мине дәваладыгыз. Бөтен тәнем пешкән иде.

– Асенька! Здравствуй, Асенька! Хәтерлим, хәтерләмичә мөмкинме соң? – дип, ханымны кочаклап алды Яков. – Без әти белән сине эзләп карадык. Тик таба алмадык. Эшеңнән киткән идең. Сиңа рәхмәтебезне җиткерәсебез килгән иде. Беләсеңме, син үзеңнең сабырлыгың, үҗәтлегең белән исән калып, күпме авыруга ярдәм иттең, Ася.

– Юк, юк! Ярдәм итүчеләр, мине үлемнән йолып алучылар, коткаручыларым – ул Сез һәм Ян Михайлович! Сезгә мең-мең рәхмәт!

Асиянең күзләреннән чишмәдәй яшь ага иде.

– Мин сине танымас та идем, Ася. Син бит кып-кызыл йөзле һәм шундый ябык яшь кыз бала идең. Ә хәзер гаять сөйкемле, чибәр ханым булып җитешкәнсең. Күз тимәсен!

– Сезнең тырышлык белән инде. Әле кулыгыздагы китабыгыз булмаса, мин сезгә игътибар да итмәс идем, чын әгәр. Китабыгызда куркыныч йөзле ир-атны күрдем дә, үземнең шундый чакларым исемә төшеп, күтәрелеп карамакчы булдым. Һәм... шатлыктан йөрәгем атылып чыга дип торам. Мин дә сезне озак эзләдем. Фамилиягезне дә язып алмаганмын, ичмаса... Ә әтиегез Ян Михайлович кайда?

– Ася, әти бит инде ул вакытта ук олы яшьтә иде. Бу дөньядан киткәненә шактый вакыт узды. Тән җәрәхәтләрен дәвалаучы белгеч, бик зур доктор иде әти. Профессор. Ул дәвалаган авырулардан әле дә рәхмәт хатлары килеп тора.

– Яков Янович! Әгәр әтиегез һәм сез булмасагыз, минем йөзем дә шул ир-атныкы кебек булып калыр идеме? Әйтегез әле миңа чын дөресен, мин дә шундый котсыз булыр идемме? – Асия яшьле күзләрен докторга төбәде.

– Ася, әйдә бу турыда сөйләшмик әле. Синең кебек һәлакәткә очраган кешеләр Израильгә бөтен илләрдән килә. Без әти белән икәүләп инде яшәүдән тәмам өметләрен өзгәннәрне, төшенкелеккә бирелгәннәрне дәвалый алдык. Сине дәвалау тәҗрибәсеннән чыгып эш иттек. Димәк, аларга син дә булыштың, Ася! Савыгып, илләренә кайтып китүчеләр сиңа да рәхмәтле булырга тиеш. Без әле дә шул даруларны кулланабыз. Дөрес, хәзер технологияләр башка. Медицина һәрдаим үсештә. Тагын бер кат әйтәсем килә: бу ысул белән дәваланып аякка баскан иң беренче пациентыбыз син булдың, Асенька!

– Рәхмәт сезгә, Яков Янович! Минем матур тормышым өчен, ирем, балаларым, оныкларым өчен рәхмәт. Гомумән, шушы якты дөньяда яшәвем һәм бәхетле булуым өчен рәхмәт.

– Ася, мин сиңа үземнең визиткамны бирәм. Израильгә килсәң, керми китмә. Сез дә телефон номерыгызны языгыз миңа. Мин Казанда еш булам, – диде доктор.

«Күрешербез» дигән өметтә аерылышты Асия үзен коткарган табиб белән.

**Унөченче бүлек**

Ниһаять, малларын урнаштырып бетерде Латыйфа. Актыкка хатынның гаиләсен туендырып тора торган сыеры – Машка гына калды. Ул, гадәттә, көтүдән иң беренчеләрдән кайта, капка төбендә көтү каршылаган хуҗабикәсенә: «Менә, күрәсеңме, болыннардан күпме сөт җыеп, сине сагынып кайттым!» – дигән сыман күзләрен мөлдерәтеп, яратып карап тора. Һай, игелекле мал булды да соң Латыйфаның сыеры Машка! Сөте күп тә, куе да. Өстәлдән сөт, май, каймак, эремчек өзелмәде. Аннан соң гаять акыллы да иде Машка. Латыйфа, сыер саварга чыккач, эч серләрен аңа бушата иде.

– Әй, Машка җаным! Күпме сөт җыеп кайткансың, рәхмәт төшкере! Туендыручыбыз бит син. Син булмасаң, ничек яшәр идек? Эх, китәм бит инде. Сезнең барыгызны да калдырып китәм. Ләкин ярты җаным авылымда кала. Ни әйтсәң дә, гомеремнең, яшьлегемнең иң садә чаклары биредә узды. Җаныма тынычлык таба алмаганда, эч серләремне елый-елый сиңа сөйли идем. Хәтерлисеңме? Син күгелҗем күзләреңне мөлдерәтеп, мине тыңлап тора идең, синең күзләргә дә яшь тула иде. Җәлли идең мине, шулай бит? Әгәр сөйләшә белсәң, юатыр идең, кайгырма дустым, дияр идең... Хәер, вакыт-вакыт мөгрәп тә куясың куюын. «Мин сине аңлыйм, Латыйфакаччаем!» – диюеңдер инде. Мин сүзләремне ахирәтләремә сөйләмәдем, чөнки аларның да дуслары бар. Алар минем кайгы-хәсрәтләремне дөньяга таратырлар иде. «Дус – башка, дошман – аякка!» – диләр бит. Ә син гел миңа тугры булдың. Кибет почмагына «сручны сыер сатам!» дигән игълан элеп куйдым менә. Сатып алсалар, суймасыннар гына инде. Яшь бит әле син, Машка җаным. Әле шаулатып сөт бирә торган чагың. Үзем белән генә алып китәр идем дә бит, кая инде, Галихан күпкатлы йортта яши. Анда сиңа урын юк шул... – Латыйфаның күзенә яшь тулды. Яргаланып беткән куллары белән Машкасының маңгаеннан сыйпап алды. Сыеры да, Латыйфаны аңлагандай, үзен кочаклап торган хатынның битен кытыршы теле белән ялап куйды.

– Әй, җаным, минем күз яшьләремне сөртүеңме инде бу, – дип Латыйфа үксеп-үксеп елады. – Нишлим соң, Машка, ни хәлләр итим?

Хатынның чыгарга дип абзар ишегенә тотынуы булды, капкадан ишелеп ике ир заты килеп керде.

– Апа, сыер сатасың икән! Безгә кирәк иде.

– Әйе, сатам! – диде хатын, аркасы буйлап ниндидер кымырҗык салкын йөгергәнен тоеп. – Сезгә ни эшкә кирәк соң сыер? Асраргамы?

– Безгә биш баш сыер яки үгез кирәк, асрарга инде. Сөт саварга, – дигән булды үзе дә үгез хәтле дәү ир заты.

– Балаларга сөт кирәк бит, – дип куйды колга кебек озыны.

– Алай икән, – дип сузды Латыйфа, – сөт өчен икән. «Үгез булмагае, чурт булсын, балаларга сөт булсын!» дисез инде, алайса.

– Апа, кара әле, кибет чатына «сыер сатам!» дигән игълан элдеңме? Нигә сорау аласың алайса? Әйдә, хәзер үк мөгезеннән аркан белән бәйләп, арба артына тагып алып китәбез сыерыңны. Син дә котылырсың. Акчалы да булырсың.

Әвен хәтле җирән ир белән колга, Латыйфадан рөхсәт-фәлән сорап тормыйча, абзарга таба юнәлде. Машка мескен үзе янында пәйда булган

ят кешеләрне күреп, абзар почмагындагы улакка таба чигенде. Теге адәмнәрнең юаны сыерның авызын ачтырып, тешләрен санады.

– Бер теше юк инде моның. Картая башлаган бу, – диде.

– Нинди карт булсын, ди. Нибары өч бозау анасы. Әле буаз да, – дип каршы килде Латыйфа. – Үзеңә кара: әле кырык яшьләр чамасы гына, ә алдагы тешләрең коелып беткән инде. Әле авызыңны ачтырып карасаң, анда бер тешең дә юктыр.

– Кара әле, каян белдең син минем урт тешләрем юклыгын? Әүлияме әллә син? Безнең нәсел шундый, тешләребез тиз коела.

Колгадай ир шүрәленеке кебек ябык озын бармаклары белән сыерның бөтен гәүдәсен капшап чыкты.

– Бер чеметем мае юк моның. Кара, кабыргаларын санап була. Әллә ач тоттыңмы сыерыңны? Хәммәди, җүнле мал түгел бу, моңа кыйммәт бәя биреп булмас.

– Мин дә шулай уйлыйм, Әскәр, – диде юаны, колгага таба карап.

– Кара әле, Әскәр абзый, – диде Латыйфа. – Әгәр синең үзеңне чишендерсәң, урманда шүрәлеләр куркыр. Хатының синнән куркып чыгып качмыйдыр бит? Минем көненә бер поттан артык сөт бирә торган Машкамны хурлап торган буласың монда. Әйдә, китегез моннан, эшем күп. Иртәгә ирем кайта, калага китәсем бар.

Латыйфаның бу ике адәмнән тизрәк котыласы килә иде.

Хәммәди дигәне, хатынның икеләнеп торганын күреп:

– Сеңлем, тыңла әле безне, тиз генә килешик тә, алып китик сыерыңны, ирең кайтканчы алыш-бирешне бетереп куйыйк, – диде.

Латыйфа озак кына уйланып торды да:

– Ярар, иртәгә сәгать уннарга килегез. Галихан кайтканчы хәл итәрбез, – дип, тегеләрне тизрәк озатты да капканы бикләп үк куйды. Өенә керәсе итмәде, аяклары үзеннән-үзе кабат абзарына, Машкасы янына илтеп куйды. Сыеры Латыйфага борылып карап, кызганыч итеп мөгрәп куйды.

– Му-у! Му-у!

– Менә шулай, Машка җаным! Кешеләр шундый инде алар. Нишлим соң, Машка? Бәхетемне дистә еллар буе көттем бит. Тилмерепләр көттем. Теге гөнаһ шомлыкларын күр инде! Балаларга сөт кирәк, янәсе. Ит комбинатына алып барып сатачаклар инде алар сине, күренеп тора.  Кичер мине, Машка, кичер, – дип, күз яшьләрен сөртеп, урамга таба атлады Латыйфа.

Кызганыч итеп мөгрәгән сыер да хатынга иярмәкче булды.

– Миңа иярмә инде, Машка, әнә анда коры салам җәеп куйдым. Ятып ял ит, – диде хатын.

Машканың күгелҗем кара күзләреннән яшь тамарга тора иде.

«Әй, Латыйфа апа, Латыйфа апа! Адәм балалары – мәрхәмәтсез затлар. Без сезне ничә еллар буе туендырып торабыз. Ә сез, кирәгебез калмагач, безне җиңел генә сатып җибәрәсез, яисә суеп ашыйсыз. Йөрәгегез таштыр сезнең» дигән үпкә-кинә бар иде аның карашында.

Иртәгәсен Галихан сәгать сигезләр тирәсендә үк кайтып җитте. Ә Латыйфаның өчпочмагы пешеп чыккан, өйгә бәрәкәтле хуш ис таралган иде.

– Әй, сагыныплар да кайтам соң үзеңне, карчык. Атна ахырын көчкә җиткерәм. Егерме ел гомеремне синсез – тиңсез уздырганмын...

– Әйдә, сөйләнгән бул инде, – диде Латыйфа, йөзе кызара башлавын тоеп.

– Бер ялгансыз, җаным, чын күңелемнән. Бәлешләреңнең исе капка төбенә үк чыккан, кадерлем, – диде Галихан хатынын кочаклап.

Ап-ак итеп агартылган мич буена хатынның калага алып китәсе әйберләре җыеп куелган.

– Боларны алып китмик, Латыйфа. Казанда кирәге чыкмас. Ял саен авылга кайтып йөрербез. Калдыр барысын да.

– Мин анда нәрсә киеп йөрермен соң?

– Кайгырма, йортта бөтен нәрсә бар. Ә кием-салымны кибеткә чыгып алырбыз.

Серләшә-серләшә, өчпочмак ашадылар. Сөтләп чәй эчтеләр.

– Менә бүген Машкамны соңгы тапкыр савып кердем, – диде Латыйфа, яшьле күзләрен Галиханга күрсәтмәс өчен тәрәзәгә таба борылып.

– Сыерыңны сатмадыңмыни әле?

– Юк әле, бүген килеп алып китәбез, диделәр.

– Нишлисең инде, Латыйфа, башка юлы юк. Игелеген күрсеннәр.

– Алар аны ит комбинатына озатачак. Ә Машкам буаз, – диде Латыйфа, күз яшьләренә төелеп.

Галихан дәшмәде.

Чәйләрен эчеп бетерергә дә өлгермәделәр, капкадан әлеге дә баягы ике ир-ат килеп керде. Юанының кулында аркан иде.

– Әнә, килеп тә җиттеләр, әйдә, Галихан, син ир кеше, бәясен килешегез дә... – дип туктап калды Латыйфа.

Галихан чыгып китте.

Озак та үтмәде, Хәммәди атлы юанының Машканы, мөгезенә аркан салып, абзардан ишегалдына таба сөйрәгәне күренде. Сыерның иялəнгән абзарыннан чит адәмнәргә ияреп чыгып китәсе килми иде, күрәсең. Үзенең бу йортка яңадан беркайчан да кайтмасын җаны белән тоядыр, бахыр, ал аякларын ныклап терәп карыша. Әскәр атлы колга адәм каяндыр таяк табып алган да сыерны ярыпмы яра.

Латыйфаның үзәге өзелде. Сыерын алып чыгып киткәннәрен күрмәс өчен өй эчендә калган хатын түзмәде, атылып-бәрелеп ишегалдына чыкты.

– Ник кыйныйсың буаз малны, гөнаһ шомлыгыннан яралган нәрсә? Иплəп кенә алып чыгып китеп булмыймыни? Әйдә, Машка җаным, әйдә. Бу имансызлар артыннан атла инде син, – дип, юан адәм кулыннан арканны алып, капкага таба юнәлде хатын.

«Му-у! Му-у!» – Сыер Латыйфага борылып карады. Аның яшьле күгелҗем күзләрендәге рәнҗеш менә-менә күз яшьләре булып түгелер кук тоелды хатынга.

Латыйфа сыерын кочып алды. Машкасы җылы кытыршы теле белән хатынның туктаусыз яшьләре агып торган яңагын кабат ялап куйды.

Капкадан чыккач, арканны Хәммәди кулына тоттырды хатын. Артыннан күндәм генә атлаган сыеры, моны күреп, янә карыша башлады. Таяк күтәреп, сыерга таба атлаган Әскәргә:

– Тукта, сукма буаз малга. Хәзер үзем бәйлим, – дип, Латыйфа сүс арканны арба артындагы ыргакка үз куллары белән бәйләп куйды.

– Әскәр, әйдә, юырт, бүген ит комбинаты сәгать икегә кадәр генә эшли, – диде юан.

Кузгалып киттеләр.

«Му-у-у-у-у!»

Сыеры соңгы тапкыр Латыйфага таба борылып карады. Ат шактый гына юыртып китеп барды.

Латыйфа, сыгылып төшеп:

– Ник куасыз ул атыгызны, сыерым буаз дидем ләбаса. Юртак түгел бит, – дип тәкрарлап калды.

Бераздан әлеге караван тыкрык башында ябалдашларын җәеп утырган карт өянке артына борылып, күздән югалды.

Галихан хатыны янына килеп, иңеннән кочып алды.

– Алар бит Машканы суярга алып китте. Галихан, бәгырькәем, ник минем гомерем гел югалтулардан гына тора соң? – дип, иренең күкрәгенә капланды Латыйфа.

Галихан бераз гына уйланып торды да:

– Карчык, әнә, Мәһруй кереп килә, сөйләшеп утыра торыгыз әле. Мин хәзер кайтам, – дип, машинасын кабызып, каядыр китеп барды.

– Ни хәлләрдә, күрше, алып киттеләрме сыерыңны? Кәнсә янында каршы очрадылар. Әй, атларын чаптырып та карыйлар инде. Машкаң, мескен, көчкә өлгерә, – диде күрше хатыны, ахирәтенең ярасына тоз салып.

– Әйе, Мәһруй, алып киттеләр. Сыерым белән бергә җаным да чыгып китте бугай. Миңа рәнҗеп чыгып китте инде Машка. Ит комбинатына сдавайт итәбез, диделәр.

– Хәерсезләр, әйтмичә генә алып чыгып китсәләр иде ичмасам, – диде Мәһруй. – Синеке кая китте соң?

– Белмим, хәзер кайтам, – дип ашыга-ашыга, каядыр китеп барды.

– Ярар, Латыйфа, алай бетеренмә инде син. Сыер сыер инде ул, ә менә мин биредә синнән башка ничек торырмын? Ахирәткәем бит син минем. Эч серләремне сөйләр кешем дә калмый лабаса.

– Алай димә, Мәһруйбикә, атна саен кайтып йөрербез. Өйдән бер нәрсәне дә алмаска кушты Галихан.

– Анысы шулай, машинагыз капка төбендә, теләсә кайчан кайта аласыз. Күпме түбәнлек, хурлык, кимсетелү аша ирештең бәхетеңә, Латыйфа җаным. Мишарабың кеше түгел иде....

– Мәһруй, әрвахлар турында начар сөйләмик әле. Урыннары җәннәттә булсын. Галихан кайтуына өчпочмак пешергән идем. Әйдәле, бергәләп чәй эчик. Әзрәк күңелләр ачылып китмәсме.

Өйгә керәсе иттеләр. Абзар почмагындагы чөйдә Машканы сауганда койрыгын бәйли торган бау эленеп тора әнә. Латыйфа барып, бауны алып иснәп карады.

– Мәһруй, бу бауны үзем белән алып китәм, сыерымны сагынганда иснәп-иснәп торырмын.

Утырып чәй эчтеләр.

– Инде китәргә әзерләнеп беттегезме соң, Латыйфа?

– Әзер инде. Нуриям дә безнең янга калага күчеп киләчәк. Өйне сатмыйбыз. Балалар да шул фикердә. Балачак, яшьлек шунда үтте бит, кызганыч, диләр. Кайтып йөрергә үз әти-әниемнең йорты да бар анысы.

Тик монысы үз нигезем. Кем әйтмешли, балаларымның кендек каны тамган җир. Тәүге адымнарын да шушында атлап киттеләр...

Латыйфа сүзен әйтеп бетерә алмады, урамда машина тавышы ишетелде.

– Әнә, Галихан кайтты да, юл кешесенең юлда булуы яхшы. Без кузгалырбыз инде, Маһруй, – диде Латыйфа.

– Ярар, мин сезне озатырга чыгармын әле. Хәзер Фәттахымны гына ашатып-эчертеп алам да, – дип, урыныннан кузгалды күршесе.

Капка ачылды. Капкадан башта Галихан, аның артыннан Латыйфаның җанын ияртеп чыгып киткән сыеры – Машкасы күренде.

– Машка җаным! – дип, ишегалдына атылды хатын. – Кайттыңмы, бәгърем, качтыңмы ул җәлладлардан?

– Юк, Латыйфа, качмады. Синең ничек тилмергәнеңне күрдем дә үзем кире алып кайттым Машкабызны. Теге адәмнәрне куып җиттем. Акчаларын кире бирдем. Сыер бөтенләй хәлдән тайган. Урманда кортлык бар бит минем. Шуның кырына бер абзар салып куярбыз да, шунда торыр дидем. Син генә газапланма, җаным, син генә бәхетле була күр. Моның өчен барысын да эшләргә ризамын, – диде Галихан. – Кара әле, Маһруй, бер атна гына карап тор әле сыерны. Сөтен үзеңә тотарсың. Киләсе атнада урманда сарай салырбыз да алып китәрбез. Ярыймы?

Латыйфаның шатлыгыннан йөзе балкып китте, күзләрендә сөенеч яшьләре җемелдәде. Үзе генә түгел, Галихан бүләге – гөләп чәчәкләре сибелгән баш яулыгы да нур чәчеп тора кебек иде.

– Ярар, ярар, карап торырмын. Сыерыгызны савып, каймагын, маен әзерләп куярмын, – дип, Маһруй да, күз яшьләрен сөртә-сөртә, өйләренә таба атлады.

Ә Машка сөенеченнән йөгерә-атлый, үзенең абзарына кереп китте.

– Тукта инде, рәхмәт төшкере, мөгезеңдәге бавыңны чишеп алыйм, – дип аның артыннан йөгерде хатын. Галихан килеп кергәндә, ул Машкасын кочаклап, үкси-үкси елый иде.

– Ярар инде, Латыйфа, тукта, – диде Галихан, хатынын кочагына алып.

– Җаным, мин сине гомерләрем буе яратып, тәрбияләп торырмын. Рәхмәт сиңа, минем бәхетем өчен рәхмәт, – дип, иренең күкрәгенә сыенды хатын.

– Сыерым өчен дип тә өстә инде, – диде Галихан елмаеп.

* * *

Галихан чүнник янына тиз арада сарай салып куйды. Башта Машканы алып кайтып урнаштырды, аннары Латыйфа белән чүнниккә юнәлделәр.

– Әйдә, Машкаң янына керәбез. Кичке савымны савасың бар.

– Монда абзар кая соң, Галихан?

– Менә бит, – дип, ап-ак юан бүрәнәләрдән салынган яңа йортка төртеп күрсәтте ире.

– Әстәгъфирулла, бу бит кеше яшәрлек йорт.

– Юк, карчык, бу зиннәтле йортны мин үзебезнең Машкабызга салдырдым.

Латыйфа килеп кергәндә, сыеры яңа чабылган яшел печән ашап тора иде. Хуҗасын күрүгә, улактан башын күтәрде дә аңа таба атлады.

– Менә, күрдеңме, мондый сарай булыр-булмас кешенең төшенә дә керми, – дип, хатын Машкасының башыннан сыйпап куйды.

Галихан авылдан хатынының сыер җиленен юа торган комганын да, кечкенә урындыгын да алып килергә онытмаган икән. Ул, хатынын куандыра алганына чиксез сөенеп, сарай ишеге төбендә елмаеп басып тора иде.

– Кара әле, Латыйфа, сине урманнан, сыерың яныннан үзебезнең фатирга алып кайтып та булмас инде.

– Әйе шул, Галихан, миңа, авыл кешесенә, тансык инде ул мал-туар янында йөрү. Урманы, күле ни тора!

– Әйе, чүнник артында гына гаҗәеп матур түгәрәк күл бар. Әйдә, сыерыңны савып бетер дә, күл буйларын әйләнеп кайтабыз.

– Ярар, Галихан, хәзер, мин тиз генә эшлим дә киләм, – дип, Латыйфа сыер саварга утырды.

Зең-зең-зең-зең... Чиләк төбенә зеңгелди-зеңгелди нечкә җеп – сөт җебе төшә. Латыйфа өчен бу үзе бер моң, бер аһәң. Тора-бара чиләк тула, бу аваз куера-калыная. Мал-туар тоткан кеше өчен сыер саву – үзе бер көй, бәрәкәт авазы. Моны бары сыерлы кеше генә аңлыйдыр. Авыл кешесе генә. Латыйфага ияреп, Казанга шул бәрәкәт авазы килде. Юк, Латыйфага түгел, хатынның бераз соңарган, әмма барыбер үзен эзләп тапкан бәхетенә ияреп килде ул. Әле шуның өстенә, Латыйфа көн саен улын – Вәкилен күрәчәк. Улының гаиләсенә дә, Галия әбигә дә күчтәнәчкә өч литрлы банка белән сөт җибәреп торыр, боерган булса. Рәхәтләндерер күрше-күләнне сөткә, катыкка Латыйфа!

Сөтен сөзеп, савытларга тутыргач, ул ире белән күл буена төшеп китте.

Урманда искиткеч тынлык хөкем сөрә. Кошлар сайравы да, былбылларның, чутылдап, бер-берсенә мәхәббәт аңлатуы да шул тылсымлы тынлыкның бер төсмере шикелле.

Йа, Раббым, Аллаһ табигатьне шундый мөкәммәл яраткан. Тынлыкта оеп утырган күлдә ак, сары төнбоеклар да, күзләрен йомып, уйга талган. Алар күзләренә таң яктысы төшүен көтә. Галихан өстендәге пиджагын салып хатынының иңенә япты. Алар, бер-берсенә сыенып, күл буендагы гүзәллеккә сокланып, тын калды.

Күл өстеннән ак болыттай томан күтәрелеп килә. Томаны да әллә нинди, катлы-катлы, яңа сауган сөт күбеге диярсең. Әнә, бака малае күл читеннән төнбоек яфрагына чулт итеп сикерде дә, чүлкенеп егылып төште...

– Аягы таеп китте бу бака малаеның, – дип телгә килде Галихан.

– Әйе, әйе! Ул да сөйгән яры янына ашыга, ахры.

Икәүләшеп көлеп җибәрделәр.

– Әй, җүләр дә инде без. Карт гашыйклар, унҗиде яшьлек чакка кайттык түгелме? – дип әйтеп куйды Латыйфа.

– Без синең белән, җаным, нәкъ шул чакта аерылыштык. Иң яшь, иң саф гомеребезне аерым уздырдык. Урладылар безнең яшьлегебезне. Әйдә, бик еракта туктап калган яшьлегебезне дәвам итик. Әйтик, бүген без унсигездә, ди. Аннан – унтугыз, егерме... Сизәсеңме, алда нинди озын, матур, бәхетле гомер көтә безне? Шушы бәхетемне югалтырмын дип куркам мин, Латыйфа. Тагын ялгыз калырмын, дип куркам. Син мине беркайчан да

ташлама, яме, Латыйфа? Ни генә булса да, гел бергә яшик. Авыру-сырхаулар безгә дә, балаларыбызга да тимәсен. Бәлки уртак балаларыбыз да булыр әле. Миңа шулай тоела.

– Кит инде, булмаганны... Утыз җиде яшькә җитеп килгәндәме? Әби булгачмы?

– Картның күңеле шарт анын, карчык. Юк димә син,– дип елмаеп куйды Галихан.

Акрын гына эңгер иңә башлады.

Кинәт машина һәм дөбер-дөбер музыка тавышыннан томан эчендә оеп утырган күл дерт итеп сискәнеп китте. Алардан ерак түгел генә зур кара машина килеп туктады да, аннан әвен кебек юан, зур башлы адәм ишелеп килеп чыкты. Аның артыннан чыркылдап көлә-көлә, зифа буйлы, кара чәчләрен иңнәренә тараткан, ап-ак сарафан кигән бер хатын-кыз да пәйда булды.

– Энгель! Музыка куй әле, минем биисем килә. Күр, нинди матур кич. Минем шушы күл буенда аккош биюен биисем килә. Күр әле, нинди гүзәллек биредә! – дип сөйләнде ул.

– Бие соң, биисең килгәч, – диде юан адәм һәм музыка куеп җибәрде. – Тик минем бер шартым бар, канәтем. Син бөтенләй ялангач бие, гәлиш калып чишен.

– Ә кеше күрсә?

– Монда эт тә юк. Син дә мин генә монда. Атәм бит, бу дөньяда без икәү генә!

Хатын-кыз өстендәге киемен тиз генә салып, гөләп куаклары өстенә томырды да, талгын музыка астында, томан эченнән бер күренеп, бер югалып, йөзеп кенә биеп китте.

Латыйфаның авызыннан «аһ» дигән өн актарылып чыкты.

– Кил монда, кабәм, әйдә иркәлим үзеңне, йөрәк маем, – дип, үз янына чакырып алды ир-ат хатынны. Тегесе әвеннең кочагына кереп эреде.

– Әйдә, тизрәк китик моннан. Гүзәл кичнең ямен бетерделәр, оятсызлар, – диде Галихан. Икесенең дә күңеле төште, кәефе кырылды.

Ә Латыйфа исә ире күкрәгенә капланып үкси башлады.

– Тукта әле, нәрсәгә дип шулай өзгәләнәсең кеше өчен? Үз гамәлләре өчен үзләре җавап бирерләр...

– Галихан! Бу хатынның кем икәнен беләсеңме? Минем Вәкилемнең хатыны Сөмбелә бит бу! Улымның тормышын чәлпәрәмә китергән биюче хатын шушы инде.

Галихан шаккатып туктап калды.

– Латыйфа! Әйдә кире киттек. Хәзер сөйрәп алып кайтып, ире янына бастырам мин ул кәнтәйне.

– Кирәкми, Галихан! Ямьсезләнеп йөрмә! Ләкин Вәкилгә әйтми ярамас. Тик мин моны улыма үзем сөйли алмам. Оялам... Сөмбелә өчен оят миңа!

– Латыйфа, мин сиңа баштан ук балаларыңа әти булырмын дип вәгъдә бирдем. Шуңа күрә, Вәкил белән үзем сөйләшермен. Аңа кисәк кенә әйтергә дә ярамас! Көрәш секциясенә йөри. Алла сакласын. Берәр нәрсә майтарып, төрмәгә утыртып куюлары да бар. Ә син тынычлан. Вәкил аның белән барыбер яшәмәс иде.

– Йа Раббым, тагын ниләр күрәсем бар икән? Кичер бәндәләреңне, – дип тынып калды Латыйфа. – Оныгым Кәрим бар бит – Вәкилемнең улы. Ул нишләр? Әтиле ятим булып үсәрмени?

– Син нәрсә, Латыйфа, Вәкилнең шушы фахишә хатын белән торуын телисеңмени? Үз язмышыңны исеңә төшер: балаларым ятим үсмәсен дип, егерме ел буе вәхши ир белән яшәп, яшь гомереңне харап иттең. Мине белми, дисеңме! Авыл җирендә барысы да күренеп тора. Син үзеңне генә бәхетсез иттең, дип беләсеңме? Юк, Латыйфа, син мине дә бәхетсез иттең. Һәм балаларыңны... – Галихан туктап калды. – Ярар, үткән эшкә салават. Әмма белеп тор: Вәкилеңә түкми-чәчми барысын да сөйләп бирәм. Минем ул оятсыз хатынны бәреп үтерәсем килә, валлаһи!

– Әстәгъфирулла, Галихан, Аллам сакласын! Зинһар өчен, андый сүзләр сөйләмә, җаным! Аллаһ күреп тора, барысын да үз урынына куяр. Вәкилне дә кисәт, хатынына кул күтәрә күрмәсен!

– Кайгырма, карчык! Вәкил башсыз егет түгел. Бәлки аның бәхетенә килеп чыккандыр бүгенге хәл? Ә Кәримне үзебез үстерербез. Без синең белән яшь бит әле.

* * *

Галихан абыйсы килеп кергәндә, Вәкил фатир хуҗасының тып-тып итеп су тамып торган кранын төзәтеп маташа иде.

– Әйдүк-әйдүк, әле менә кыстыбыем да әзер, мактап кына йөрисең икән! – дип, картларча гөрләп каршы алды Галия карчык.

Вәкил Галихан абыйсын көтмәгән иде.

– Исәнме, Галихан абый! Авылга кайтып киткән идең. Бер-бер хәл булмагандыр бит? – дип Галиханга борчулы караш ташлады ул. Аннан кулларын юып килеп, кул биреп күреште. – Әни исән-саумы? Нурия ни хәлләрдә?

– Барысы да исән-сау, Аллага шөкер! Тик сөйләшәсе сүз бар иде, Вәкил. Таң атканны көтеп җиткерә алмадым. Туктале, машинам ишегалдында гына тора, әйләнеп кайтыйм әле дидем. Әниең Галия әбигә дә, Кәримгә дә авыл сөте җибәрде менә.

– Әй, онытыплар торам. Машканы алып килгәнсең икән, Галихан абый? Әйтсәң, икәү кайткан булыр идек.

– Әйе, әниең шундый шатланды! Сөенеченнән ни эшләргә белми. Кош тоткан кебек булды. Сыеры белән сөйләшеп сүзләре бетми, малай. Машкасы да, барысын да аңлагандай, күзләрен мөлдерәтеп әниеңә карап тора. Күрсәң бездәге хикмәтне, Вәкил! Латыйфа чүнниккә күченеп китмәсә ярый инде.

Вәкил сизенде, Галихан абыйсы никтер күңелсез. Әмма сүз башларга уңайсызланып, кыенсынып тора сыман.

– Әйдәгез, чәйләп алыйк! – дип кыстады Галия карчык.

Әмма Галихан каршы килде:

– Юк, юк! Әле табын яныннан яңа кузгалдык. Латыйфа гөбәдия пешергән иде. Әнә алып килдем, сез дә авыз итәрсез. Вәкил! Әгәр мөмкинлегең булса, әйдә бүген безгә барыйк әле. Машканың яңа гүрнәчәсен дә күреп китәрсең. Кәрим янына барырга җыенмыйсыңдыр бит?

– Юк, Галихан абый, эшләрем бетте, кранны төзәттем. Кәримне бабасы

янына авылга алып кайтып киткәннәр. Сөмбелә биючеләр белән бер атнага командировкага киткән. Иртәгә кайтырга тиеш, дигән иде әби.

– Алай икән... – диде Галихан. – Командировкага киткән икән...

Чүнниккә барып җиткәнче үк машинасын туктатты Галихан.

– Вәкил, бер сүзем бар сиңа. Әйтергәме, юкмы дип озак уйландык әниең белән. Әйтсәң дә – ай, әйтмәсәң дә – вай. Синең биючең командировкага китмәгән шул,– дип башлады ул. Һәм үзләре күргәннәрне түкми-чәчми Вәкилгә сөйләп бирде.

Вәкилнең йөзе кызарып чыкты. Ул ике кулы белән йөзен каплап, озак кына утырып торды. Аннары машинадан чыкты да, сукмак кырыенда үсеп утырган усак агачына җен ачуы белән китереп типте. Гомерен чәлпәрәмә китергән азгын хатыныннан үч алырга теләгәндәй, усакны кат-кат кыйнады Вәкил. Аннан соң урман ешлыгына кереп югалды.

Озак көтте Галихан Вәкилне. Тик егет күренмәде. Аптырагач, таныш сукмак буйлап эзли китте.

Вәкил түгәрәк күл буенда, кичә Латыйфа белән табигатькә сокланып утырган җирдә калтырана-калтырана елый иде.

Галихан көчле беләкләрен егетнең иңенә салды.

– Галихан абый! Үзе ник шунда кадалып китми, улым бар бит. Кәримем бар.

– Нишләмәкче буласың, Вәкил?

– Аның белән яшәмәячәкмен, анысы факт, – диде Вәкил. – Тик Кәримне ничек итеп үземә алырга? Бирмәячәк бит. Гәрчә ул Кәримне карамаса да. Баланы анадан аермаячаклар. Ул бит баланы бер тапкыр да имезмәде. Кәримне нигездә әби белән бабай үстерә. Төннәр буе өйгә кайтып керми бит ул җилбәзәк нәрсә, Галихан абый. Мин нишләргә дә белмим. Бәреп үтерәселәрем килә. Үземнән үзем куркам кайчак. Тыелып кала алмам шикелле.

– Төрмәгә кереп утырасың киләме? Әниеңне утка салма, Вәкил. Сез ятим булмасын дип интегеп, үз гомерен харап иткән әниең бу хәлләргә түзә алмаячак, шуны бел. Ипләп кенә аңлашыгыз. Улың хакына. Сүз бир миңа, Сөмбеләгә тырнак белән дә чиртмим дип ант ит.

– Ярар, Галихан абый! Синең сүзең дөрес. Ачуым кайнаганга гына әйтүем иде. Ачу килсә, акыл китә бит. Тыныч кына аерылырга кирәк бу адәмнән...

* * *

Вәкил килеп кергәндә, Сөмбелә өйдә иде. Ишекне бабасы ачты. Яңа гына тәпи йөри башлаган Кәрим, Вәкилне күрүгә, ава-түнә әтисенә таба атлады.

– Әт-тә, әт-тә, – диде малай шатланып.

– Әһә-ә, тәпи йөреп киткән бит минем улым,– дип, күтәреп алды улын Вәкил һәм күзләрен, битләрен үпте. – Әтиеңне таныдыңмы, улым?

– Әйдә, өстәл янына утыр! – диде әбисе Сәкинә. – Әле Сөмбелә дә бүген генә командировкадан кайтты. Гәпләшә-гәпләшә чәй эчәрбез.

– Минем биюче хатыным кайдан кайтып төште инде командировкадан? Чит илгә үк чыкмагандыр бит?

– Юк, Ленинградта булдык, диде бугай,– дип кычкырды әбисе Сөмбелә бүлмәсенә карап. – Кызым, син кайда булдың әле, кайсы шәһәрдә? Иреңә әйтеп йөрмисеңмени?

Сөмбелә үз бүлмәсеннән чыкты да Вәкилгә карап, төксе генә:

– Әйттем бит инде, Ленинградта булдык, – диде.

– Әби, бабай, утырыгыз әле. Минем сезнең янга килүемнең сәбәбе... – дип башлады да, бер мәлгә туктап калды Вәкил. – Сөмбелә, син дә утыр, безгә бүген үк бер мәсьәләне ачыклап, нокта куярга кирәк. Син бит командировкада булмадың, Сөмбелә. Шулай бит? Күл буенда ялангач килеш аккош биюен биеп күңел ачтың. Әвен хәтле бер мишәр ире белән... Машина номерын әйтимме? Сиңа үгет-нәсыйхәт бирүнең мәгънәсен күрмим. Ана сөте белән кермәгән икән, тана сөте белән кермәячәк, анысы билгеле. Әмма өздереп әйтәм: мин синең белән яшәмәячәкмен. Тик улымны да сиңа калдыра алмыйм. Кәримне үзем тәрбиялим.

– Син нәрсә, кияү, кеше сүзенә карап, гайбәткә ышанып, хатын аермакчы буласыңмы? Улыңны ятим калдырып...

– Юк, әби, кеше сүзе генә түгел, минем әни һәм Галихан абый үз күзләре белән күргәннәр бу тамашаны.

– Ашыкма әле, Вәкил, кеше ышанмас сүзне чын булса да сөйләмә, диләр. «Аерылам» дигән сүзеңне дә оныт. Күр, улың нинди матур булып үсеп килә! Кызым, әйт әле безгә, бу хәлләр дөресмени? Кодагыйның күзенә генә күренгәндер, бәлки?

– Әби, бабай! Кабат-кабат тикшереп торасы юк. Буласы булган, буявы сеңгән, – диде Вәкил, ачуына буылып.

Сөмбелә кинәт өйне яңгыратып көлеп җибәрде.

– Әти, Вәкил дөресен сөйли. Мин командировкада булмадым. Сөяркәм бар, чыннан да. Инде әллә кайчаннан, Вәкилгә кияүгә чыкканчы ук бар иде. Тик ул өйләнгән кеше. Гаиләсе, балалары бар.

– Ничек?

– Әй җаным, бигрәк беркатлы инде син. Яңа ел кичендә безнең арада берни дә булмады. Сиңа коньяк эчерүемнең дә сәбәбе шул иде. Исерсен дә, берни дә хәтерләмәсен дидем. Ә син... Кәримне бирми, имеш, үз балаң дип беләсеңме әллә син аны? Синеке түгел ул. Әтисе бар аның, ул состоятельный, бай кеше, зур урында утыра. Әмма аның хатыны, гаиләсе бар, – дип кабатлады Сөмбелә. – Ул гаиләсен ташламаячак. Шуңа күрә, аннан балага узгач, хур буласым килмәде. Сиңа кияүгә чыктым. Ә син үзеңне әллә кем дип белдең, ахры. Уйлап та карамадың... Шушы матурлыгым белән сиңа – авыл гыйбадына кияүгә чыгар идеммени? Әгәр авырга калмаган булсам, миннән нинди биюче чыккан... – Сөмбелә җөмләсен тәмамлап бетерә алмады, әтисе урыныннан кузгалып китте дә, ишек яңагына сөялеп басып торган кызының яңагына сукты. Сөмбеләнең борыныннан шаулап кан китте.

– Нишлисең? – дип сикереп торды Сәкинә. – Үз балаңа кул күтәрәсеңмени?

Өйдә купкан кара тавыш Кәримне нык куркытты. Ул алпан-тилпән атлап, әтисе янына килеп, аңа «күтәр әле мине» дигәндәй ике кулын сузып, сыны катып еларга тотынды.

– Хәзер, улым, хәзер! Елама, – дип, Кәримне күтәреп алды Вәкил. Ул инде бу балага җаны-тәне белән береккән иде.

– Әйе, улым, син минеке. Әтиеңнең кем булуында бер эшем дә юк.

Әйдә, киендерәм дә, Латыйфа әбиең белән Галихан бабаң янына алып кайтам. – Вәкил малайның киемнәрен җыя башлады. Шулвакыт Сәкинә әбисе килеп ябышты:

– Кагыласы булма минем оныгыма! Синең балаң түгел, диделәр бит сиңа. Бар, югал күз алдымнан!

– Анасы бер, атасы – мең, дип әйтмәкче буласыңмы?– дип сүзгә кушылды бабасы һәм хатынын читкә этәрде. – Нинди егетнең тормышын җимердең бит, Сөмбелә! Синең урыныңда булсам, Вәкилдән тезләнеп гафу сорар идем. Без барыбыз да аннан гафу үтенергә тиеш. Бар, Вәкил, өеңә кайт. Әгәр Кәримне үзем үстерәм дисәң, синең аңа полный хакың бар. Никахта туган бала ул. Ә мин синең яклы! Кичерә күр безне, кичерә күр!

**Ундүртенче бүлек**

Илдә хосусыйлаштыру мәрәкәсе кайный. Советлар Союзы дәверендә төзелгән яисә патша заманыннан калган тарихи биналар, шул исәптән Асиянең әби-бабаларыннан талап алынган җирләр, завод-фабрикалар – барысы да шәхси кулларга күчә бара. «Әллә тагын утызынчы еллар кайта инде», – дип хафаланып уйлап куйды Асия.

Карап торсаң, исең китәрдәй хәлләр, тамаша! Ата – улны, ана кызны белми. Туганнар сугыша-талаша ата-ана малын бүлешә. Нәрсә булды бу дөньяга? Әүвәл партия әгъзаларын куркытып торган Коммунистлар партиясе дә бер селтәнүдә юкка чыкты. Әллә булган ул, әллә булмаган.

Бары тик партия генә безне туры юлдан коммунизмга китереп җиткерәчәк дип тәрбияләде балаларын әтисе. Ул гомере буе табынган партия исә күз ачып йомганчы гаип булды. Ярый әле, әтисе бу көннәрне күрмәде. Әгәр күргән булса, үзенең ялган вәгъдәләргә ышанып уздырган гомерен кызганып, бу дөньядан үзе теләп китеп барыр иде, мәрхүмкәй. Әтисе җаны-тәне белән ышана иде Коммунистлар партиясенә. Асия дә ышанды. Тик коммунистларның дингә каныгулары гына җанын әрнетә иде. Ни сәбәп? Чисталыкка, сафлыкка, бер-береңә карата мәрхәмәтле булырга, әти-әниләрне рәнҗетмәскә, туганлык җепләрен өзмәскә, мохтаҗларга ярдәм итеп яшәргә өнди торган динебезнең партия әгъзаларына ни зыяны тия соң? Мәчет манарасын кискән көннәрдә йөрәк өянәге тотып, вафат булган Котдус бабасы җиргә ухылдап килеп төшкән манараның аен, кеше-кара күрмәгәндә, өенә алып кайтып, улы Җәүдәткә, оныгы Шәүкәткә тоттырган. «Саклагыз! Соңыннан бу Алласыз, динсез дәһриләр законы бетәчәк, яңа мәчетнең манарасы очына менгереп куярсыз!» – дип васыять әйтеп, мәңгелеккә китеп барган бабасы кемгә нинди зыян салган икән?!

Бабасының сүзләре балачактан ук Асиянең җанына уелып калган. Алар хәзергәчә гомер юлында маяк булып тора. «Кызым! Үсәрсең. Намазга басарсың. Мәчетләр салырсыз. Иманым камил, кызым, син әле әти-әниеңә, җитмеш буын әби-бабаларыңа да дога кылып торырсың. Алласыз, динсез кавем озак яши алмый. Имансыз кавем озак яши алмый ул. Динебез тагын да куәтләнеп кайтачак!» – дигән иде ул. Һәм, әлхәмдүлилләһи, аның әйткәне дөрескә чыкты.

Әнисе исә фани дөньядан туксан яше тулганда, намазлык өстендә, икенде намазын укыганда сәҗдәдә китеп барды.

Барыгызга да, Аллаһ җәннәтләрен насыйп әйләсен! Без үзебез дә догада булырбыз. Балаларыбызга да дин юлыннан тайпылмагыз, намусыгызны югалтмагыз, дип васыять әйтеп калдырырбыз.

***

Асия дә җәмгыятьтәге көнүзәк үзгәрешләрдән читтә калмаска тырышты, үзе җитәкләгән ашханәне хосусыйлаштырырга ният итте. Бергә эшләгән хезмәттәшләрен дә җыеп сөйләште.

– Кызлар, безгә ашханәбезне үз милкебез итәргә, бергәләп сатып алырга кирәк. Үзебез алмасак, кемдер безне коллективыбыз белән сатып алачак, – диде.

– Һай, шикләндерә бу хәл. Без соңгы акчабызны салырбыз да, ә ашханәне башка кешегә бирерләр. Бөтен тырышлыгыбыз юкка чыгар. Юк-юк. Сез кемгә ышанмакчы буласыз, Асия Сәлимовна? – диеште хезмәттәшләре.

– Мин дә каршы, – диде бригадир Нина Максимовна. – Барыбер куып чыгарачаклар безне, ничә ашханәдән кудылар бит инде. Юк, Асия. Мин синең белән егерме ел эшлим. Миңа бу өлкәдәге гадәтләр бик таныш. Ашханәңне синнән тартып алачаклар, әйтте диярсең.

– Әйдәгез, алай булгач, ачык акционерлык җәмгыяте төзик.

– Анысы нәрсә тагын?

– Саткан очракта без үзебез сатып алачакбыз, коллектив белән.

– Башка кеше ала алмыймы?

– Читтән кергән кеше дә сатып алырга мөмкин. Тик ул акчаны бездән күбрәк түләсә генә. Шулай булгач, кызлар, әйдәгез, эшне шуннан башлап җибәрик әле. Ятып калганчы, атып кал, диләрме әле? – Асия әңгәмәне шул рәвешчә түгәрәкләп куйды.

Шулай килештеләр. Әле хосусыйлаштыру механизмын өстәгеләр үзләре дә рәтләп белми иде. Өйрәнәләр генә. Асия дә шулар белән бергә өйрәнде. Һәм беренчеләрдән булып ачык акционерлык җәмгыяте оештырды.

Асиянең озын-озакка сузылган очсыз-кырыйсыз газаплы көннәре, төннәре шул мәлдә башланды. Берзаман аның янына җәмәгать туклану нокталарының иң төшемлеләрен эләктерергә өлгергән Ришат килеп керде. Кул тырнакларына маникюр ясатып йөрүче бу галәмәт чибәр ир Асиягә таныш иде. Өч дус иде алар, Казан уртасындагы иң зур бинаны бергәләп сатып алдылар, аннары Ришат, җаен табып, бер дустын куып чыгарды. Теге мескен әллә кемнәрдән күп итеп акча алып торган булган. Бурычларын күтәреп урамда калды.

– Исәнмесез, Асия Сәлимовна!– дип дустанә елмаеп килеп керде Ришат.

– Аллага шөкер, Ришат, яхшы гына эшләп яткан көн.

– Сәүдә барамы? Күрәм, ишек төбенә чаклы чират тезелгән. Җитешә алмыйсыңмы әллә?

– Җитешәм, клиентларга мин мичтән яңа пешеп чыккан ризык кына ашатам.

– Мичләрең җитми инде алайса.

– Яңаны алырга кирәк. Әлегә акча яклары кысанрак.

– Проблемалар бар, димәк. Шуларны җиңеләйтим дип кердем, Асия. Мин сезне коллективыгыз белән сатып алмакчы булам. Ни диярсең?

– Туктале, диярмен. Ничек килеп чыга инде бу? Син безне сатып аласың

да, без синең колыңа әвереләбез, әйеме? Сездә эшләгән ашханә мөдире: «Асия, ул адәмнең өенә бәрәңгесенә, суганына чаклы әрчеп, турап җибәрәм. Хатыны бер эш эшләми. Мине кол урынына тота», – ди иде. Ә ул үзе Россиянең оста повары, дәрәҗәле, уңган ашчы.

– Юк инде, мин сезне кол итәргә җыенмыйм, кулдаш, ягъни партнёр итеп чакырам.

– Ничегрәк була инде анысы?

– Синең белән бер елга килешү төзибез. Минем акчам җитәрлек. Уптым ремонт ясыйм кафеңа. Шаккатмалы булачак.

– Бер елдан соң, Шамилне куып чыгарган кебек куып чыгарасыңмы?

– Шикләнәсең икән, әйдә, биш елга төзик килешүне.

– Ә биш елдан соң ни була?

– Анда күз күрер.

Телефон шалтырады.

– Асия Сәлимовна! Сезгә Ришат килдеме?

– Әйе, каршымда утыра.

– Сез ул әйткән шартларга ризамы?

– Риза түгел. Нигә мин аның кул астында эшләргә тиеш соң әле? Үзем мөстәкыйль эшли алмыйммы? Инде ничә еллар дәвамында планны үтәп барабыз, тәртип бозулар юк.

– Үзең беләсең, безнең эштә нарушениеләрне теләсә кайчан табарга мөмкин. Әйтик, иртәгә үк сезгә комплекслы тикшерү килеп төшәчәк. Берничек тә котыла алмассың, шуны бел. Эшеңне иртәгә үк тапшырган бул. Аннары бер елга килешү төзеп, яңабаштан эшли башларсың.

Асия телсез калды. Бу адәм үзе генә түгел икән ләбаса. Тагын шул ук хәл кабатлана, димәк. Өстәге хуҗалар белән сөйләшеп, Асияне куып чыгарырга җыеналар түгелме соң? Шамилне дә шулай харап иткәндер инде болар.

Шәһәрнең җәмәгать туклануы тармагын җитәкләүче түрә трубканы куйды. Телефон әле озак кына «пи-пи» дип чыелдап торды.

Асия Ришатның көлемсерәп торган яшькелт-соры күзләренә текәлде. Кинәт җаны өшеп китте. Теге ана бүре күзләре бит бу! «Кем белән көрәшмәкче буласың, Асия? Минем беләнме? Җиңә алмаячаксың. Минем артымда бик зур түрәләр тора», – дип әйткән сыман иде ул мыскыллы караш. Ә бит чыннан да үз максатларына ирешәчәк болар, гаеп табып, җинаять эше ачып, ашханәне ябып ук куячаклар.

– Ярар, иртәгә килегез. Эшемне тапшырырмын, – диде Асия, үз-үзен кулга алып.

Ришат чыгып киткәч, ул үз-үзенә ант итте: «Мин сезнең белән эшләмәячәкмен. Монысы ап-ачык. Һәм дә сезнең колыгыз да булмаячакмын. Әби-бабаларым да, әти-әниләрем дә беркайчан да кол булмаган, горур яшәгән. Иртә таңнан кара төнгә чаклы эшләгәннәр. Яшен суккан карт шомырт агачы төбеннән шытып чыккан яшь үсентеләр кебек, бу дөньяга башларын кыю калкыткан алар. Бәрәкәтле туфракта тамыр җәеп, якты кояш нурларына коенып  аякка баскан нык нәсел без».

Әнә, абыйсы Данир – элеккеге СССРда бары тик икәү генә булган зур заводның берсендә – директор. Асия дә төшеп калганнардан түгел, гәрчә инде ничәнче кат эшсез калу алдында торса да.

Ришат чыгып киткәч, Асия үзе белән озак еллар бергә эшләгән коллективны үз янына чакырды.

– Асия Сәлимовна! «Кешеләрегез белән сатып алам!» диме теге чорсыз адәм?

– Без ишетеп тордык, шулай диде.

– Шунысын гына әйтә алам: аңа кол буласыгыз килмәсә, үз теләгегез белән эштән китә аласыз, – дип җаваплады Асия.

– Ә сез, Асия Сәлимовна, сез кая бармакчы буласыз?

– Белмим, кызлар. Әлегә ни эшләргә дә белмим. Аяз көнне яшен суккан кебек булды бу.

– Китсәк, сезнең белән китәбез, – диеште хезмәттәшләре.

– Ашыкмагыз әле. Үзегез беләсез, эш табулары җиңел түгел хәзер. Гаиләгезне кем туендырыр-киендерер? Сабыр итегез. Инде шәхсән миңа килсәк, бу хәл беренче тапкыр гына түгел бит инде. Бик авыр, куркыныч заманнар килде, дусларым. Мин балаларымны, гаиләмне куркыныч астына куймаячакмын. Шуңа күрә бу эштән китәргә ниятләп торам. Рәхмәт сезгә, кызлар! Шундый матур итеп эшләдек. Әгәр берәрегезне рәнҗеткән булсам, зинһар өчен, гафу итә күрегез.

– Сез нәрсә инде, Асия Сәлимовна! Үзегезгә зур рәхмәт. Һәрдаим булышып тордыгыз.

– Иртәгә Ришат үз бухгалтериясе белән килә. Эшне тапшырырга кирәк.

Кызлар, күз яшьләрен сөртә-сөртә, таралышты.

* * *

Асия өенә кайтып кергәндә, ире балалары белән телевизор карап утыра. Кызы белән улы әниләре кочагына ташланды.

– Иртәгә кафеңны Ришатка тапшырасыңмыни? – дип сорады ире.

– Әйе. Әле сиңа хәбәр итеп тә өлгерделәрмени?

– Беләсең бит, мин дә шул өлкәдә эшлим. «Әгәр китми икән, бик начар булачак, балаларыгыз бар бит»,– дип кисәттеләр.

– Балалар дип куркыталар шул. Югыйсә мин аларга бирешмәс идем.

– Ришатның крышасы Казанда иң кансыз, иң көчле адәм, диләр.

– Анысын беләм лә... – Асия күз яшьләрен иренә күрсәтмәс өчен юыну бүлмәсенә кереп, шаулатып су җибәрде дә рәхәтләнеп елады. Бөтен дөньясына рәнҗеп елады Асия.

Кичке ашны тавышсыз-тынсыз гына ашадылар.

Өйдә яшенле яңгыр алдыннан гына була торган хәвефле тынлык урнашты.

– Берни дә уйламыйча китәргә кирәк, Асия.

– Син балалар янында кайнаша тор әле. Минем берничә кешегә шалтыратып, киңәшләшеп аласым бар иде.

– Айрат абыйгамы?

– Әйе, аңа да, Данир абыйга да.

Асия озак кына уйлап торды да иң элек Айрат абыйсының номерын җыйды.

– Абый, мин ... – дип әйтә генә башлаган иде, абыйсы шундук бүлдерде аны:

– Исәнме, сеңлем. Миңа барысы да мәгълүм. Сиңа китәргә кирәк, сеңлем, иртәгә үк китәргә кирәк. Гаиләңә куркыныч яный.

Асия дәшмәде.

Данир абыйсы да шул ук сүзләрне кабатлады.

– Асия, кит. Балаларыңны, иреңне, үзеңне харап итәрсең югыйсә.

– Абый, әйт әле син миңа, без ни өчен шундый тормышка дучар соң? Башта әби-бабайларны талаганнар, аннары әти-әнине, аннары безне хәерчелектә, ачлы-туклы яшәргә мәҗбүр иттеләр. Инде менә тагын түбәнгә төртеп төшерәләр... Балаларымның үзем кебек ачлы-туклы яшәүләрен теләмим, абый җаным. Күпме түзәргә була! Без шундый мескен кавеммени соң?

– Әллә бүреләр өеренә каршы чыкмакчы буласыңмы, сеңлем? Үтенепләр сорыйм: акылыңа кил...

Асия телефон трубкасын куйганда да абыйсының: «Әлү-әлү, Асия»,– дип дәшкәне ишетелә иде әле.

Асия диванга мендәр атты да, чишенмичә генә менеп ятты. Аның башы авырта, колагында гүя диңгез шаулап тора.

Әниләре янына керәсе килгән балаларны ире туктатты.

– Әниегез арып кайткан, комачауламагыз, ял итсен, – дип ишекне ябып ук куйды.

Нишләргә? Иртәгә эшен тапшырса, тагын кайларга барып башын төртер? Бабасы әйтмешли, баш-аяк чәрдәнкә вакыт. Асия генә түгел, олы хуҗалар да илдә-көндә ни барганын аңлый алмаудан гаҗиз.

Шунысы кызганыч ки, үзе белән дистә еллар эшләгән коллектив кала. Үзәкләрен өзә торган уйларга уелып ята торгач, тирән һәм авыр йокыга талганын сизми дә калды Асия. Ул төш күрде. Ниндидер ап-ак зур корабта йөзәләр, имеш. Ире, балалары янында. Барысы да өрфиядәй җиңел, ап-ак киемнән. Кызы бөдрәләнеп торган чәчләре өстеннән ак эшләпә киеп куйган. Барысы да шундый матур, бәхетле. Кинәт тын диңгез өстендә давыл купты. Дулкыннар, ажгырып килеп, корабны йомычка урынына теткәли башлады. Асия балаларын кочагына алмакчы булды. Әмма кулларын балаларына сузган килеш, чайкалып китеп, палуба идәненә егылды, давыл аны бөтенләй икенче якка таба тәгәрәтеп китте.

Кинәт икенче бер дәһшәтле дулкын аның балаларын палубадан диңгезгә юып төшерде. Балаларының «әни-и-и!!!» дип кычкырган тавышы палуба идәнендә тәгәрәп яткан Асиянең үзәкләрен өзде. Ул өстенә ажгырып килгән дулкын уртасына сикерде.  Бераздан күтәрелеп караса, балалары, бер-берсенә сыенып, ак дельфин сыртында утыра, алар Асиягә кул изи:

– Әни, курыкма! Без исән-сау, – диләр. Кинәт кенә тынычланып калган кораб янәшәсендә зур ак дельфинның йөзгечләренә тотынып, елмаеп-көлеп йөзеп бара Асиянең газизләре. Ире дә янәшәсендә, аны торгызырга теләп, кулын сузып тора...

Асия шыбыр тиргә батып, куркып уянып китте. Сикереп торды да, залга чыгып, әтисе белән шахмат уйнап утырган кызын күзләреннән, битләреннән, чәчләреннән шашынып үпте. Аннан соң өстәл янында дәрес әзерләп утырган улын кочагына алды.

– Нишләвең бу, Асия? Нигә тиктомалдан балаларга килеп ябыштың?

– Шундый куркыныч төш күрдем, әтисе. Котым очты. Балаларымны

югалттым дип торганда, аларны зур ак балык коткарды. Йа Раббым! Ярый әле, төш кенә бу! Өнебездә балаларны югалтырга язмасын. Ярый әле, төш кенә... – Асиянең яңаклары буйлап күз яшьләре тәгәри иде.

– Әни, әни, елама, без исән бит. Әнә абый да, мин дә исән, әтиебез дә исән! – дип, нәни куллары белән әнисенең күз яшьләрен сөртте кызы.

– Аллага шөкер, балакайларым, сез исән-сау. Шуннан да зуррак бәхет буламыни, – дип тынычланып калды Асия.

Ник кенә керде соң әле бу куркыныч төш Асиягә? Башта – балаларын ялмап алган дәһшәтле дулкын, аннары аларны коткарып калган ак дельфин! Дельфин ак буламы икән ул, дип уйлап куйды Асия. Хәер, татар халык әкиятләрендә ак бүре, ак елан бар, димәк, ак дельфин да бардыр...

Бәлки аңа ерак бабалары күкләрдән дәшәдер? «Бирешмә, Асия, бәхетең өчен көрәшергә кирәк. Үзең интегеп ачкан эшләреңне инде ничә мәртәбә ташлап китәсең, аларның рәхәтен җыен оятсыз ертлачлар күрә», – диюләре түгелме?

Чынлап та, Габдрахман хәлфәнең чарлаклы йортына кереп оялаган ялкау, хөрәсән Галәү кебекләр заманы килдеме соң әллә?

Асия уйга калды.

Менә хәзер үзе интегә-интегә эшләтеп җибәргән атаклы кафесына тырнакларына маникюр ясаткан әрсез Ришат кереп утырачак. Шәриф Әкбәровичлар, Тамара Лягиналар, Валентина Сергеевналар шикелле. Асиянең үзе җыйган уңган коллективны, инде дус-туганнарга әйләнгән кызларын урамга куып чыгарачаклар.

Иртәгесен Асия сәгать сигезләр тирәсендә үк эшенә килеп җитте.

Кызлар аптырашып басып тора иде. Барысының да сөмсере коелган.

– Исәнмесез, кызлар! – дип елмаеп исәнләште Асия.

– Асия Сәлимовна, нишлик? Эшли башлыйкмы, юкмы?

Асия үзе дә берни белми иде. Озак кына дәшми торгач, әйтеп куйды:

– Кем әйтте әле сезгә эшләмибез дип? Эшлибез, кызлар! Әйдәгез, көрәшеп карыйбыз! Язмыш дулкыннары кайсы ярга бәреп чыгарасын белмим. Ләкин бирешмәскә, нык булырга кирәк, – диде.

Кызларны шулай юаткан булды, ә эчендә ут дөрли иде. «Йа Аллам, ни эшлисең син, җүләр хатын? Акылыңнан шаштыңмы? Ирең, туганнарыңа китәм дип вәгъдә бирдең ләбаса. Ә үзең, китмим, кафемны бирмим, көрәшәм, дип торасың? Чынлап та җүләр бугай син. Әниең чын дөресен әйткән икән... Ярар, Аллага тапшырдык», – дип, үзен-үзе тынычландырырга тырышты Асия.

Шул ара ишектән шаулап-гөрләп, үз бухгалтериясен ияртеп, Ришат килеп керде.

– Асия, әйдәгез алыш-бирешне башлыйбыз, – диде ул, канәгать елмаеп. Аңа ияреп килгәннәр хатынга текәлеп, хуҗаларының фәрманын көтеп тора иде.

– Исәнләшергә оныттыгыз бугай, Ришат әфәнде. Әллә колларыгыз белән исәнләшүне түбәнлек дип саныйсызмы?

– Ә, онытылган, исәнмесез, Асия Сәлимовна. Әйдәгез, эшне башлыйк.

– Нинди эшне?

– Алыш-бирешне.

– Минем сезгә нидер бирәсем бармыни, Ришат әфәнде? Сез нидер бутыйсыз. Сездән әҗәткә акча алганым да юк шикелле.

Ришат, күзләрен кыса төшеп, Асиягә төбәлде.

– Син минем белән качышлы уйныйсың мәллә? Кичә үзең әйттең иртәгә килегез дип.

– Нигә сез минем белән «син» дип сөйләшәсез? Ә-ә, онытыплар торам икән, әйе, сез бит мине коллективым белән бергә сатып алырга килдегез. Безгә, колларга, «сез» дип дәшә алмыйсыз бит инде, шулаймы?

– Тукта әле, Асия Сәлимовна, бер төн эчендә ни үзгәрде соң? Кичә генә икенче төрле сөйләшкән идек.

– Бер төн эчендә мин үзгәрдем, Ришат әфәнде. Мин үземдә гаярь бабаларымның каны акканын, үземнең көчле, асыл нәселдән икәнлегемне исемә төшердем. Һәм кафены сезгә бирмәскә булдым.

– Хмм... Ну, әйдәгез, алай булгач, сезнең белән ун елга килешү төзик.

– Юк! Мин беркая да китмим. Җитте. Бернинди килешү төземим.

– Асия Сәлимовна, нәрсә ошамый сезгә? Үзегезгә дә эшләргә җиңелрәк булачак лабаса. Шундый авыр эшне сөйрәп бару хатын-кызга бик авыр бит. Һай, авыр.

– Беренчедән, сез миңа ошамыйсыз. Хатын-кыз кебек тырнакларына маникюр ясатып йөргән ир-атны җенем сөйми. Мин – авыл баласы. Безнең Алансуда ирләр ир була белә, хатын-кызны хөрмәт итә. Сезнең шикелле талашып, хатын-кызның мөлкәтен талап алырга йөрмиләр. Икенчедән, миндә сезгә генә каршы торырлык көч-куәт бар. Шуңа күрә, әнә ишек ачык, чыгып китүегезне үтенәм.

– Беләсеңме нәрсә! Мин сине таракан урынына сытачакмын. Җир белән тигезлим мин сине, белеп тор. Бөтен шәһәр егетләре минем кулда. Үзең курыкмасаң, балаларыңны кызган. Бер атна эчендә үтертәм мин синең балаларыңны да, үзеңне дә. Бүгеннән соң гел куркып-калтырап, гел артыңа борылып карап йөр! Күр әле, кемгә каршы сугыш ачкан бит бу юньсез хатын. Миңа, Ришатка каршы! Әйдәгез, киттек! – диде ул яраннарына борылып. – Күрмәгәнен күрсәтәм әле мин бу хатынга, ник туганына үкенерлек итәм!

– Ришат әфәнде, мин сезнең бу сүзләрегезне яздырып алдым әле. На всякий случай, – дип, Асия диктофонын күрсәтте.

Ришат күзләрен тондырып, Асиягә ташланды.

– Бир диктофонны!

– Кызлар! – дип кычкырды Асия. – Керегез әле монда, бер бандит мине таларга ябышты. Милиция чакырыгыз!

Ришат ишеккә таба атлады.

– Моннан соң аң бул, Ришат, әгәр минем яисә минем балаларымның башыннан бер чәч бөртеге генә төшсә дә, сине кулга алачаклар. Биредә сине егетләрең генә коткара алмас. Кулымда улика, вещественное доказательство. Хуш, сау булып тор.

Ришат ишекне каты бәреп чыгып китте.

Ай-яй... Ишекнең ни гаебе бардыр...

– Кызлар, әйдәгез, чәй эчеп алыйк әле. Иртән чәйләмәгән дә идем,– диде Асия көр тавыш белән. Шул минутта эчке калтыравын басып, хисләрен бер йодрыкка җыя алды.

Асия Ришатны ничек яздырып аласы итте соң әле? Ничекләр генә исенә

төште бу диктофон, рәхмәт яугыры? Ихтимал, төшендә балаларының, бәладән котылып, ак балык өстендә йөзеп барганын күрү рухландыргандыр... Каяндыр ак балык, ягъни берәр котылу юлы килеп чыгарга тиеш дип озак кына уйланып ятты бит ул.

Әйе, мондый адәмнәрне башта чыгырларыннан чыгарырга, аннан үз-үзен белештермәслек хәлгә китерергә кирәк. Ә үзең тыныч кына үз эшеңне кыласың. Кайвакыт зирәк хәйләкәрлек зарур. Бүре белән бүре булып улавың хәерле.

Ерак бабаларыңа үзеңнең кем икәнлегеңне исбатлап күрсәт менә. Хәер, шуны исбатлый-исбатлый гомерләр үтеп бара түгелме соң инде?

Асиянең күңеле күтәрелеп китте.

Ришатны күр әле, курыкты бит. Яраланган җанвар шикелле, хатын-кызга, Асиягә ташланды. Кызлар килеп кермәгән булса, диктофонны тәки тартып ала иде. Әйдә шулай шүрләп яшәсен! Әнә бит койрыгын бот арасына кыстырып чыгып тайды. Хәшәп! Асиянең кулында бомба бар хәзер. Кирәге чыкса, шунда ук прокуратурага илтеп тапшыра ала ул аны.

Телефон шалтырады. Югарыдан теге хуҗа шалтырата икән.

– Асия Сәлимовна! Эшеңне тапшырдыңмы Ришатка?

– Юк. Һәм тапшырырга уйламыйм да.

– Син нәрсә, акылыңнан шаштыңмы, үләсең киләме?

– «Балаларыңны үтерәм», – дип янады бит ул.

– Шаһитларың бармы?

– Әйе, Ришатның бухгалтерлары янәшәдә иде.

– Алар аны сатмаячак.

– Әлбәттә. Шуңа күрә мин аның янавын диктофонга яздырып алдым. Кирәге чыгар әле, мин әйтәм...

Трубка тынды.

– Алло, Сез мине ишетәсезме?

– Әйе, ишетәм, Асия Сәлимовна! Бик яхшы ишетәм. Дөрес эшләгәнсез. А то бөтенләй азындылар! Үзләрен дөньяның кендеге дип саныйлар, – дип, Асия яклы булып сөйләнә башлады бу адәм. Аннары: – Сволочь! – дип өстәде. Асия аңлады: соңгысы Ришатка түгел, Асиягә төбәп әйтелгән иде.

– Булмагае! Хамелеон, – дип үзалдына көлеп куйды хатын.

Асия үз коллективын саклап кала алды. Үз гомерендә беренче тапкыр үз урынын әтрәк-әләмнәргә бирмәде.

Ниһаять барып җитте Асиягә! Бәхет өчен көрәшергә кирәк икән. Дөнья җебегәннәрне яратмый. Эчтән ничек кенә курыксаң да, дошманыңа туры кара, күзеңдә куркуның әсәре дә булмасын. Уф! Менә хәзер бераз иркен сулап куярга мөмкин. Аңлашыла ки, Ришат бүтән беркайчан да Асия янына килмәячәк. Үзенең егетләрен дә җибәрмәячәк. Комплекслы тикшерү дә булмаячак. Чөнки аның кулында бер мизгелдә шартлап күпләрне харап итәрлек бомба бар. Асия аны ерак, бик ерак яшереп куячак.

* * *

Лайнер палубасындагы яшел бәрхет кәнәфидә, океан дулкыннары өстендә сикерешкән зур-зур балыкларга, үзләренә ризык эзләп очкан акчарлакларга карап ял итеп утырганда, Асия шул газаплы чорларны исенә төшерде.

Нәкъ ул уйлаганча, Ришат башка күренмәде. Шулай буласы билгеле иде. «Мин – мин микән, мин кем икән!» дип кабарынып йөрүчеләр, үзләренә ниндидер куркыныч янаса, таракан шикелле, тизрәк ярыкка поса.

Асия аңлады: моннан соң ул беркемнән дә курыкмаячак. Һәм эшеннән дә китмәячәк.

Әнә, Инара Бариевна эшләгән ашханәне инде өченче тапкыр сатуга куялар. Алучы юк. Юкса урыны да яхшы, юл чатында. Ал да эшләтеп җибәр! Алмыйлар, чөнки барысы да курка!

Инараны инде әллә ничә тапкыр чакырып сөйләшкәннәр. «Мин бу ашханәдә унөч ел эшләдем. Миңа аны бушка бирергә тиешләр», – дип әйтә икән.

Бушка бирмәячәкләр, билгеле. Инара үз кешесен куяр өчен, Асияне – бер яшьлек бала анасын – эштән куып чыгарган иде. Асия бу хакта берәүгә дә сөйләмәде. Шуңа күрә, югарыдан нәкъ менә Асиягә мөрәҗәгать итүләре гаҗәп хәл түгел. Язмыш рониясе дисәң генә инде...

– Асия Сәлимовна, Сез аның белән эшләгәнсез икән, сөйләшеп карагыз әле. Коллективы белән киңәшсен дә, бергәләп сатып алсыннар. Бәясе дә бик арзан бит, – диделәр Асиягә.

Шалтыратты ул Инарага, үпкә саклый торган гадәте юк Асиянең.

– Ник сатып алмыйсыз ашханәгезне? Юк кына бәягә саталар бит. Сава торган сыерны суймыйлар, Инара, үзегез алмасагыз, башкалар алыр. Коллективтагы ашчылар эшсез калмасын иде, – диде.

– Ә синең ни эшең бар анда? – дип кырт кисте Инара.

– Булышасым килгән иде сезгә.

– Карап карармын, – дип, трубканы куйды Инара.

«Җүнсезнеке гел җүнсез инде. Иплəп кенә рәхмәт әйтеп саубуллашса, ни була иде?» – дип уйлады Асия, күңеле кителеп.

Бер атна вакыт үтте.

Инарадан хәбәр-хәтер булмады. Бераздан комитеттан Татьяна Михайловна шалтыратты:

– Асия, акчаң бармы?

– Долларлар гына бар, совет акчалары юк.

– Иртәгә иртүк акчаларыңны банкка илтеп алыштыр да гариза китер. Инара Бариевнаның ашханәсен сатып алырга кирәк. Инде өченче кат куйдык сатуга. Шундый яхшы ашханәне шалкан бәясенә дә алучы юк. Һич аңламыйм!

– Ярар, Татьяна Михайловна! Тик минем бер шартым бар: Инара китәм дип гариза кертмәсә генә алам. Миңа кеше хакы кирәк түгел. Гәрчә ул ханым кайчандыр мине эштән куып чыгарган булса да...

– Әллә нинди сәер кеше син, Асия. Бөтен кеше сугыша-талаша мал җыя, ә син үзеңне рәнҗеткән кешене җәлләп торасың.

Инара Бариевна гариза кертмәде. Асия бер мең квадрат метрлы ашханәне сатып алды. Һәм ике ай буена бу ашханәгә барып та карамады. Кем сатып алганын белми дә калды Инара.

Нигә үз ашханәңә бармыйсың, дип сораучыларга, вакыты җитмәгән, дип җавап бирде Асия. Дөресен генә әйткәндә, ул Инараның холкын яхшы белә, бу хәл белән килешмәячәк иде ул. Үз әйберләрен җыя торсын дип уйлады.

Бер көнне өендә телефон шалтырады.

– Асия Сәлимовна, Инара Бариевнаның бухгалтеры әле бу. Инара иртәгә беребезгә дә эшкә чыкмаска кушты. Ашханәне Сез сатып алганны белгән ул бүген. Бар булган җиһазларны ватып бетерергә җыена. Ашханәнең астын өскә китерәм, ди. Без барыбыз да эшсез калачакбыз, Асия Сәлимовна. Зинһар, килеп җитегез!

Иртән иртүк, Инараның погром ясыйсы дуслары килеп җиткәнче, Асия дуслары, туганнары белән ашханәгә юнәлде.

– Ачкычларны бир әле, Инара. Үзеңә кирәкле әйберләрне җый да – юлыңда бул. Моның өчен сиңа ике ай вакыт бирдем. Җиткәндер бит? Әйдә, матур гына саубуллашыйк әле синең белән.

Бухгалтерия бүлмәсенә үттеләр.

Инара калтыранган куллары белән, ашыга-ашыга, әйберләрен җыя башлады. Йөзенә кып-кызыл таплар чыкты. Асия, Инара борылган арада, өстәлдән тышына «отчёт проведённых банкетов и поминок» дип язылган амбар кенәгәсен алып, сумкасына салып куйды. Кирәге чыгар, дип уйлады ул. Бу хатын әле Асия өстеннән шикаять язачак. Тикшерүләр җибәреп, үзәгенә үтәчәк.

Һәм шулай булды да.

Унбиш көн эшләп өлгермәделәр, өч тикшерүче килеп төште.

– Хосусыйлаштыру дөрес үткәрелмәгән. Инара Бариевна бу гамәлдән хәбәрдар булмаган, коллектив та берни белмәгән.

Асия исә элекке коллективтан берәүне дә эштән җибәрмәгән, барысын да үз урыннарында калдырган иде.

– Яхшы, – диде Асия тыныч кына. Аннары сәркатибенә дәште: – Залга коллективны җыегыз әле, биш минутка гына!

Аннан тикшерүчеләргә борылды:

– Ә сез коллектив белән үзегез сөйләшегез. Мин чыгып тормыйм.

Әңгәмә озакка сузылмады.

– Коллектив хосусыйлаштыру белән таныш булган. Барысы да шуны дәлилләде! – диде тикшерүчеләр. – Шикаятьтә дөреслек юк.

– Әй, бу комедия Инарага нигә кирәк булды икән? Минем кулымда «гаять кызыклы» мәгълүмат бар. Аның ел буе уздырган банкетлары, поминкалары язылган амбар кенәгәсен әйтүем. Мин тикшереп карадым, алар берсе дә касса аша узмаган. Шуңа күрә сез аңа әйтегез, әгәр тагын бер генә тикшерү җибәрә икән, бу кенәгә прокуратурага тапшырылачак, – диде Асия.

Ә тикшерүчеләргә тамак ялгап алырга тәкъдим итте, әбәт җиткән иде.

Әллә оятларына көч килде, әбәттән баш тартып, рәхмәт әйтеп, саубуллашып чыгып китте тикшерүчеләр. Инара Бариевна турында башка берни дә ишетелмәде.

* * *

Һай, тикшерүләр! Бетмәс-төкәнмәс тикшерүләр! Бурычлар, кагыйдәләр! Санитария таләпләрен үтәү кагыйдәләре диварга язып эленгән әнә. Мәсәлән, йомыркаларны башта аерым савытка – хлор эремәсенә салып зарарсызландырырга кирәк. Аннары икенче савытка күчереп, сабынлы

суда юарга, аннары өченче савытта чиста суда яхшылап чайкарга. Шуннан соң гына йомырканың ватасын ватып, бөтен килеш пешерәсен – пешереп, кешегә ашата аласың. Ашханәгә зур-зур өч кәстрүл куеп, һәрберсен «хлор эремәсе», «сабынлы су», «чиста су» дип билгеләп-язып куярга тиешсең. Боларның барысын да кем генә үти ала икән? Моны ничек кенә тикшереп-күзәтеп бетерәсең? Ашханәңнең ишек төбенә чаклы чират тезелеп торганда бигрәк тә!

Асиянең күз алдына әнисенең сары самавыры килеп басты. Үзен-үзе белә башлаганнан бирле, ул аны Тереклек елгасына алып төшеп, Сөлек күлендә чыгарылган мунчала, ком, зелпе белән ышкып юа иде. Җиз самавыр көзге кебек ялтырап торганчы! Чөнки күрше кызы Нурҗиһанның бүксәле самавыры әнә ничек елык-елык итеп тора, ә синекенең тоткычы астында тонык күгелҗем таплар күренеп тора. Нәрсә, син Нурҗиһаннан кимме әллә... Әле яңа гына җиде яше тулган Асия шул тапларны куллары суелганчы ышкый, бетерә һәм тәки ялтырата иде үз самавырын.

Аннан соң кызлар чистарткан самавырларын киптерергә тезеп куя да, чыр-чу килеп, Тереклектә су коена. Җәй кояшы балаларның елкылдап торган самавырларында ялтырапмы-ялтырый! Күз яуларын алып тора!

Су коенып туйгач, яланаяклы, ямаулы күлмәкле кызлар, көлешә-көлешә самавырларын җитәкләп, кыр казлары кебек тезелешеп өйләренә кайтып китә. Өйдә аларны әниләре көтә. Әй, мактаячак инде әниләре!

– Кызым, балакаем, зур үстең инде, минем ярдәмчемә әйләндең! – дип, башларыннан сыйпап алачак. Дөрес, Асиянең әнисенең алай төчеләнеп торырга вакыты юк. Тик кыз белә: ул әнисенә булышырга тиеш. Әнисенең үзен яратуын болай да тоя Асия.

Туктале, нәрсәгә дип исенә төште соң әле бу самавыр кыйссасы? Йомырка юу турында сөйли иде бит әле. Бер хикмәте бар шул...

Мәктәптән кайтуга, әниләре самавыр куеп җибәрә. Ә капкачының читеннән ап-ак марля кырые күренеп тора. Димәк, әниләре самавыр суы эченә йомырка салып куйган. Бер үк вакытта чәй дә кайный, йомырка да пешә, күмергә дә экономия! Сигез йомырка сыя самавырга. Әтиләренә – ике, ә калганнарга – берәр. И, ул йомыркаларның тәмлелеге!

Әниләре марля өстенә тезеп куйган йомыркаларны самавырдан ала да, салкын суга салып куя. Шулай эшләгәндә, йомыркалар тизрәк әрчелә. Аннары әнисе, бисмилласын әйтеп, бәрәңге кушып пешергән ипекәйне зур-зур телемнәргә кисеп, өстәл уртасына куя. Баздан май, катык, сөт алырга Асияне төшерә. Аннан соң әнисе самавыр капкачы өстендәге көлне өреп төшерә дә, тастымал белән сөртеп ала. Һәм шул мәлне җиз самавырны ялтыраганчы юган кызын мактап алырга да онытмый.

– Һай, кызым Асия! Бу юлы бигрәкләр дә шәп агарткансың самавырны, көзгеләр күк ялтыраткансың, билләһи. Күмер салырга жәлләп торырсың, – дип, кызын үсендереп җибәрә. И, күңеле була инде Асиянең. Алга таба тагын да әйбәтрәк, тырышыбрак юармын дип, эченнән антлар итә кыз. Укытучы әнисенең балаларын кеше алдында мактавы үзенә күрә бер тәрбия алымы булган икән ләбаса. Моны җиде яшьлек кыз хәзергә аңламый әле, үзе ана булгач, кылт итеп исенә төшәчәк бу мизгелләр.

Әнисе самавыр торбасына түбәтәен кигезә дә, аңа бәләкәй чәйнекне

утыртып куя. Ә чәйнектә исә зур кисәктән бераз гына кителеп салынган хуш исле такта чәй пешеп утыра. Түгәрәк өстәл тирәли Җидегән йолдыз кебек тезелешеп, җиде кеше – зур гаилә утыра. Уртада, олы тәлинкәдә – самавырда пешкән сигез йомырка. Үзеңә тиешле бер йомырканы аласың да, өстәл кырыена бәреп, черт итеп ватасың. Әрчеп, чынаяк тәлинкәсенә саласың да, дүрткә бүлеп, өстенә эре, соры тоз сибеп, ипине күбрәк, йомырканы азрак кабып, ашап җибәрәсең! Һәй, җаным! Әнисе самавыр эченә тезеп пешергән йомыркадан да тәмле ризыкны үз гомерендә бүтән ашаганы булмады Асиянең. Инде ашап та булмас! Чөнки әнисе юк инде. Кыз балалар белән елгага алып төшеп, башкалардан көнләшә-көнләшә, юып ялтыраткан җиз самавыр да юк. Инде күптән әллә кая юкка чыкты ул.

Әнисе исән чакта ук, авылда газ барлыкка килгәч, табын түрендә күңелләрне күтәреп җырлап утырган өй күрке – самавырны әлүмин чәйнек алмаштырды. Ә җиз самавыр, хуҗабикәгә үпкәләп, дәшми генә, тын гына гаип булды... Күпме генә эзләп караса да, таба алмады аны Асия. «Кызым, газ кергәч, кирәге калмагач, әтиең аны келәткә чыгарып куйган иде. Күрәсең, берәрсе әтиеңнән сорап алып киткәндер. Аны чегәннәр дә өй борынча җыеп йөрде инде. Йә берәрсе дачасына алып киткәндер. Алай дисәң, берегезнең бакчасында да күренми үзе», – дигән иде бервакыт әнисе.

Асия уйга калды. Нишләп соң шәһәрдә йомырканы хлорлап, аннан сабынлап юып, аннан соң салкын суда чайкап пешерергә кирәк? Ә менә Асиянең балачагында әнисе һәм башка авылдашлары йомырканы кое суы белән юып, самавыр эченә марляга тезеп куеп пешерер иде. Ә йомырка пешкән суны такта чәй өстенә агызып, тәмләп чәй эчәрләр иде. «Менә күрдегезме, мин сезгә чәй дә эчерәм, йомырка да пешереп ашатам, өстәвенә әле җырлап күңелегезне дә күтәрәм», – дип уртада балкып утырыр иде самавырыбыз.

Самавыр эчендә, марляда тирбәлеп пешкән йомырка ашап авырган яисә агуланып үлгән кеше турында ишеткәне юк әле Асиянең. Авыл халкы нәкъ менә йомырка пешкән су белән чәй эчеп сихәтләнгәндер дә әле. Чынлап та, йомырка кабыгында кальций галәмәт күп бит!

Ә шәһәрдә болай: йомырка юыласы савытлар тикшерүчеләр күрсен дип куела, урын биләп тора, ә йомыркаларны краннан агып торган суда бер кат чайкыйлар да пешерәләр. Барлык ресторannarда, ашханәләрдә дә шулай. Әгәр тикшерүчеләр күрсә? Башың бетте дигән сүз!!! Чистый тамаша ясыйлар моннан.

Җәмәгать туклануы тармагында санитария кагыйдәләрен үтәмәүчеләрне республиканың баш санитар табибы трибунадан эт итеп сүгә. Зал тулы халык! Барысы да йомыркаларны хлорга салмыйча, суда чайкап кына пешерүчеләр! Дөрес, араларында гаепсез җитәкчеләр дә бар: йә аларның ашчылары йомырка пешереп ятканда санитар табиб килеп кермәгән, йә алар бу четерекле хәлдән җайлап кына котыла алганнар инде.

Зур залның беренче рәтендә, гадәттә, ир-егетләр утыра. Чөнки алар кыю халык. Ә хатын-кыз җитәкчеләр посыбрак утыра, уртагарак яки арткарак урнаша.

– Карале, Асия,– диде «Тургай» кафесы мөдире Вәсилә. – Мин бу

рейдның буласын белдем. Санитар табиблар килүенә йөз йомырканы хлорга салып куйдым. Аннан соң генераль уборка ясаттым. Бөтен шартын китердем, миңа бернинди гаеп тә язмадылар. Рәхмәт инде Индира дустыма. Шул тирәдә эшли бит, тикшерүләр турында алдан хәбәр биреп тора.

– Андый дусларым юк шул, Вәсилә. Әй, йомыркаларың шулай озак тордымы хлорда? Аларга хлор исе сеңә, ләбаса...

– Син дә эләктеңме әллә, Асия?

– Юк, миндә вак-төяк кимчелекләр генә таптылар. Телгә алып тормаслар, мөгаен.

Ул арада трибунага шәһәр санитария-эпидемия станциясенең баш табибы Сигалова менде. Җентекләп әзерләнгән бу, карашы зәһәр, ап-ак чал чәченә яңа гына причёска ясатып чыккан хәтта. Йөрәкләр кысылып куйды. Кайсыбыз исемен салып таптар бу бүген, дип барысы да аңа төбәлде. Һай, минем фамилиям гына чыкмаса ярар иде, дип барысының да коты очып торды.

Уф-ф-ф! Бу юлы яшен сукмады Асияне. Дәһшәтле давыл читләтеп үтте.

Пенсия яшендәге Гөлнәзирә исемле мөдирне «үтүкләделәр».

– Син – инде үләр вакыты җиткән карт хатын, нишләп кешегә хлорлы суда юылмаган йомырка ашатып ятасың? Ничек оялмыйсыңдыр...

Әй, китте тезеп, китте тезеп... Гөлнәзирәгә бары илле биш яшь. Аны «үтүкләүчегә» исә – алтмыш биш!

Күзеннән мөлдер-мөлдер яшь агып торган хатынны, тәмам кешелектән чыгарып тиргәгәннән соң, «җәза» залыннан, ниһаять, азат иттеләр. Гөлнәзирә ханымны җыелыштан соң ук йөрәк өянәге тоткан. «Башка бер көн дә эшләмисең!» – дигән балалары. Ул икенче көнне үк эшеннән китте.

Баш табибә Сигалова исә алтын йөгертелгән кысалы күзлеген киде дә, карашын залда утыручыларга төбәп, тынып калды. Гөлнәзирәне пешекләп арыды булса кирәк. Баш табибәнең бөтен кешегә дә теше үтми, билгеле. Чөнки тиярга ярамаган хуҗалар бар. Ә Гөлнәзирә кебек яклаучысы булмаганнарны изәргә ярый. Кагылырга ярамаганнарның үчен дә шул мескеннәрдән алалар инде.

– Вы, – диде баш табибә, алдагы рәттә утырган ир-ат җитәкчеләргә карап, – скажите мне, пожалуйста, честно: кто из вас яйца моет? Кто? Я знаю точно, из присутствующих здесь руководителей никто яйца не моет.

Залда уңайсыз тынлык урнашты. Баш табибә, күзлеген салып, залга карап, җавап көтә иде.

Ниһаять, иң беренче рәттән бер ир-ат авазы килде:

– Мы все моем яйца. Каждый день моем, честное слово!

Зал «шартлады»! Әле генә: «Миңа кагылмаса ярар иде!» – дип калтырап утырган җитәкчеләрнең шаркылдап көлүе күк күкрәүгә тиң иде.

– Туктагыз! – дип, трибуна өстәленә китереп сукты баш табибә. Чөнки президиумда утыручылар да тыела алмыйча көлә иде.

– Айрат Мәхмүтович! Сез әйттегезме бу сүзне?

– Әйе, мин. Сез сорадыгыз, мин әйттем.

– Мин сез уйлаган йомырка турында сөйләмим. Сүз башка йомыркалар турында бара.

– Мин дә сез әйткән йомырканы күздә тотып әйттем. А Вы о каких яйцах думали?

– Да-а-а-а, Айрат Мәхмүтович! Телегезгә шайтан төкергән сезнең. Шуңа күрә судан һәрвакыт коры чыгасыз!

«Хлорлы судан!» – дип «чөйләп» куйды кемдер.

Айрат Мәхмүтович дәшмәде.

Зал тагын бер кат шаркылдап көлде...

Баш табибә әйтер сүз тапмады, күрәсең. Трибуна өстәленә җәеп салган кәгазьләрен җыйнап:

– Бүгенгә җыелыш тәмам! – дип игълан итте дә, сәхнәдән төшеп югалды.

– Аллага шөкер, бүгенгә котылдык! – диде халык җиңел сулап...

Ир-атлар җыен тузга язмаган гаеп ташлап җаннарын талкыган әлеге җыелышның бетүен әйбәтләп юып, җаннарын тынычландырыр өчен төркем-төркем булып, рестораннарга таралышты. Ә хатын-кызлар тизрәк өйләренә йөгерде, анда тавык та чүпләп бетерә алмаслык эшләр көтә. Һәм балалары! Ашханәдә эшли торган хатын-кыз балаларын җитәкләп бәйрәмнәрдә йөри алмый. Чөнки бәйрәмдә буфет-фәлән оештырып, һәрвакыт башкаларның күңелен ачасы бар.

Йомырка кыйссасын дәвам итеп, Асия лайнерда кытай ресторанына кичке ашка баруларын исенә төшерде.

– Әйдәгез, бүген кытай ризыкларын авыз итик әле, – диде юлдашы, «Акчарлак» кафесы директоры Розалия.

– Китсәнә, аларның ризыклары таракан да бака, йә диңгез бете... Юк-юк, мин җирәнәм, – дип каршы төште Асия.

– Әйдә, Асия, аерылганны – аю, бүленгәнне бүре ашар, дигәннәр. Коллективтан аерылып йөрмә инде син, – дип тәки күндерделәр Асияне. Киенеп-ясанып, көлешә-көлешә, кичке ашка төшеп киттеләр.

Кытайча кызыл фонарьчыклар белән бизәлгән ресторанда, татар моңына охшаганрак кытай музыкасы агыла иде. Официант бөгелә-сыгыла елмаеп каршы алды. Ун кеше түгәрәк өстәл тирәли тезелешеп утырды.

Официант меню китерде.

– Кызлар! Телләрен дә белмим, ашарга да куркам. Инде әллә ничә кат йә бака, йә диңгез бете ашап адәм хурына калдым. Мин кытай чәе генә эчәм, яшелен, – диде Асия.

– Алай ярамый инде, дустым, кереп утыргансың икән, креветка булса да уртлап куй. – Үгетли белә дә инде бу Розалия.

– Ярар, алайса, креветка китерсеннәр. Төн озын. Ашыйсы килер...

Янәшәдә генә Вьетнам кешеләре утыра иде. Алар үз телләрендә сөйләшә. Никтер барысы да берьюлы сөйли кебек тоелды Асиягә. Өстәлләренә төрле-төрле үләннәр өелгән. Ә сул якта кытайлар утыра. Болары да үз телләрендә бер-берсен уздыра-уздыра әллә сөйләшә, әллә ызгыша – аңламассың.

Кечкенә бала кебек кенә бер яшь кыз рәт араларында җырлап йөри.

Инде сок эчеп, ашый башлаганнар гына иде, кинәт Асиянең күзе кытайлар өстәленә төште. Акрын гына Розалиягә эндәште ул:

– Дускаем, кытайлар ягына күз сал әле.

Розалия күзләрен күтәреп карады да, шаккатты:

– Үләм, Асия, нәрсә ашый алар?

– Йомырка ашыйлар.

– Чебиле түгелме соң йомыркалары?

– Чебиле шул.

Баксаң, кысык күзле, зур борынлы кытай ире йомырка әрчеп утыра. Ә йомырка эченнән иң элек әле туарга өлгермәгән чебинең тәпиләре калкып чыкты, аннары күкәй кабыгына ябышкан йоннары, соңыннан бөтен гәүдәсе күренде. Һәм күз ачып йомганчы чеби теге кытай иренең авызына кереп китеп юк булды. Ир, аны әвәли-әвәли чәйнәде дә, сөякләрен теле белән этеп чыгарды. Ә соңыннан күзләрен йомып, тере килеш кайнар суга салып пешерелгән мескен чебинең тәменнән ләззәтләнеп утырды бугай. Табындашлары да тиздән йомырка кабыгын ватып, дөньяга чыгасы чебиләрне рәхәтләнеп «харап итте». Ә безнең татарлар моңа карап өнсез калды, үз алларындагы ризыкларга үрелергә дә өлгермәделәр.

– Кытай ресторанына барасыгыз килгән иде бит. Кинәнегез инде, – диде Асия, күңеле болганып. Үз алдына китереп куелган урта бармактан зуррак креветкаларны да ераккарак этеп куйды.

«Сволочьлар! Күпме нәни чебешне терелəй пешергәннәр бит!»

Соңыннан Асия, телефонына язып, кытай теленнән тәрҗемә иттерде.

«Бу – кытайларның иң затлы, кыйммәтле ризыгы. Күкәй эчендәге чеби никадәр җитлеккәнрәк булса, бәясе шулкадәр кыйммәтрәк була», – дип тәрҗемә итте телефон.

Бераздан кытайлар өстәленә, зур тәлинкәләргә тезеп, бака кашыклары – устрица һәм лимон китерделәр. Тегеләр лайлалы бака кашыклары өстенә лимон сыга да иреннәре белән суырып ала.

Асия түзмәде:

– Мин китәм. Башка ресторанга кереп ашыйм.

Аның артыннан башкалар да кузгалды.

Шулай итеп, кешеләргә йомырка ашату темасына тагын бер кызыклы төсмер өстәлде. Аш-су остасы Асия мондый хикмәтләрне шактый күрде.

**Унбишенче бүлек**

Советлар Союзы дигән дәүләт таркалгач, илдә үзгәрешләр тамашасы башланды. Әллә асты–өскә килде, әллә өсте – аска. «Алла юк»! – дип шәрран ярып йөргән коммунистларның байтагы партия билетларын, сандык төбенә салып куйды да (что син, кирәге чыгуы бар!), мәчетләргә кереп оялады, имеш, дингә кайтты. Чын күңелдән иманга килүчеләре дә бар иде, әлбәттә. Тик кинәт кенә коммунистлар партиясен, иптәшләрен хурларга керешеп, дини вәгазь сөйләп йөрүчеләре дә шактый иде. Андыйларны белә иде Асия.

Әле кайчан гына партком секретаре булып эшләгән танышы Мөнирнең теленнән хәзер: «Алла теләсә, әлхәмдүлилләһи, иншаллаһ» дигән сүзләр төшми.

– Соң син бит әле кайчан гына авыру хатының өстеннән йөреп, хәмер эчеп, дөньяның артына тибеп яши идең. Ни арада имамга әйләндең? – дип, йөзенә бәреп әйтә аңа кайбер ачы телләр.

«Малаема никах укытырга Мөнир хәзрәтне чакырдым әле», «Әтиемнең кырыгын Мөнир хәзрәттән укыттым. Шундый матур итеп вәгазь сөйли», – дип мактап телгә алучылар да очрап куя.

«Сөйли әлбәттә! – дип уйлый Асия. – Гомер буе ялган, буш сүз сөйләп, теле чарланган бит инде аның».

«Бәлки иманга килгәндер», – ди кемдер.

«Бәлки, бәлки! Тик менә авыру хатыны өстенә яңа хатын алып кайткан», – дип каршы килә икенчесе.

– Гомер буе намазлык өстеннән төшмәгән туксан яшьлек карт сөйләп торды: «Шул мөртәтне имам итеп билгеләгән көнне төш күрдем. Мәчеттән барлык ак күгәрченнәр дәррәү очып чыгып китте. Канат каккан тавышлары гына ишетелеп калды», ди. Мин бит ул имансызның бөтен тормышын беләм. Күпме кеше өстеннән шикаять язып, эшләреннән алдыртты. Бандит бит ул. Чалмалы карак...» – дип сөйләде бервакыт Асиянең бер танышы.

– Ярар, – диде Асия, – бу хәлләрне син генә үзгәртә алмыйсың инде, һәркем үз гөнаһы өчен үзе җавап тотачак.

– Дөнья тәмам буталды. Эшсез калучылар күпме? Кешеләр ничек яшәргә тиеш соң, Асия? Кибет киштәләре буш. Бөтен нәрсә талонга. Балаларга нәрсә ашатырга? Өчәү бит алар минем, өчәү. Ирем эшсез калды, – дип өтәләнде бичара хатын.

Асия дәшмәде. Аның үзенә дә бик авыр иде бу мәлләрдә...

...Ул эшенә килеп җитте дә кабинетына кереп утырды. Телефон шалтырады.

– Асия Сәлимовна, монда бер хатын-кыз килгән. Сезнең белән очрашасы килә. Узсынмы?

– Керсен! – диде Асия, тагын кемдер ярдәм сорап килгәндер инде дип уйлады.

Ишектән илле яшьләр тирәсендәге ябык кына хатын-кыз килеп керде. Әллә кайчан модасы чыккан пәлтә, таушалып беткән кара эшләпә кигән.

– Здравствуйте, Асия.... – Ул бераз туктап торды да «Салимовна» дип өстәде.

– Здравствуйте, – дип сәламләде Асия керүчене. – Утырыгыз, әйдә.

– Сез мине танымыйсызмы?

– Юк шул. Миңа көн буена бик күп кеше килә. Барысын да танып бетерә алмыйм. Әйдәгез, узыгыз, – диде Асия. – Ни йомышыгыз бар иде?

– Ә син үзгәргәнсең, Ася! – диде кинәт ябык хатын.

Асия күзен эш кәгазьләре өстеннән күтәреп, хатынга төбәлде.

Аягына таушалып беткән, пычрак аяк киеме кигән хатын кабинет идәненә җәелгән сары келәм өстендә ыржаеп торучы эзләрен үзе дә күреп алды:

– Гафу ит, Асия, келәмеңне пычраттым, – дип әйтеп куйды.

Асиягә хатынның тавышы таныш кебек тоелды.

Кем соң әле бу? Ябык йөзле, озын буйлы... Һич кенә дә исенә төшми. Чәчен карага буяткан, ә чәч төпләре исә ап-ак, ямьсез булып тора.

– Асия Сәлимовна! Татарстан урамындагы ашчылар әзерли торган училищеда без синең белән бер төркемдә укыган идек. Оксана мин, Ахтина. Хәтерләмисеңмени соң, Ася?

Асия, йөзенә шаулап кан йөгергәнен тоеп, сискәнеп китте.

Оксана?! Асия бөрчекле киҗе-мамык күлмәк өстеннән телогрейка киеп йөргән чакта, затлы күлмәктән, кызыл пәлтәдән, көяз эшләпәдән йөргән Оксанамы?! Авыл кызларының русча белмәвеннән, гади кигеменнән һәрвакыт көлеп-мыскыллап йөргән Ахтинамы?!

Асиянең тамагына төер утырды. Бу хатынны кабинетыннан куып чыгарасы, күңеленә мәңгегә кереп утырган үпкәне, яшүсмер чагында җанына кара кан булып укмашкан ачуны, ниһаять иреккә чыгарып, әллә ниләр әйтәсе килде. Тик үз-үзен кулга алды.

– Онытылган инде, Оксана, барысы да онытылган, – дию белән чикләнде.

– Асия... Сәлимовна, безнең төркемдә укыган кызлар арасында бары тик син генә шундый зур уңышларга ирешә алдың. Калганнар барысы да ничектер югалып калды.

– Юк, Оксана, барысы да түгел. Яхшы гына эшләп, шактый күтәрелгәннәре дә бар.

– Юк, юк, Ася, таких как ты, совсем нет.

– Ә син ничек яшисең, Оксана? Кайда эшлисең, гаиләң, балаларың бармы?

– Ашханәбезне яптылар. Ирем башка хатын янына чыгып китте. Аның әнисеннән калган ике бүлмәле фатирда яши идем балаларым белән. Куып чыгардылар. Хәзер кеше почмагында торабыз. Элеккеге ирем дә эшсез. Алимент та түләми, – дип елап җибәрде хатын.

Эшкә алуымны сорап килгән инде бу бичара дип аңлады Асия.

– Минем штат тулы шул, Оксана. Әйе, бик күп кешеләр эшсез калды шул... Миңа да туганнарымны үземә эшкә урнаштырырга туры килде, – диде Асия.

– Бәлки, савыт-саба юучы кирәктер?

– Миндә эш урыны юк шул, Оксана. Әмма мин сиңа бераз акча бирә алам. Балаларыңа ашарга алырсың! – дип, Асия хатынның кулына шактый гына акча тоттырды. Итагатьле генә итеп озатып чыгарды.

«Хәзер куып чыгарам, унбиш яшьлек чагымда ике ел буе үзәгемә үткән бу кыздан үч алам», – дип гайрәтләнгән хатын исә үзен тыеп кала алуына сөенде. Әйе, әйе, үз-үзен җиңә алуына куанды ул. Бала чагында бабасының: «Кызым! Әгәр кешегә авыр сүз әйтәсең булса, әйтмичә кал, тыел. Иртәгә әйтәм мин сиңа, диген эчеңнән генә. Иртәгә исә бар да башкача күренер һәм син ул сүзне мәңге әйтмәссең», – дигән киңәше тотып калды Асияне. Инде тормыш болай да шактый кыйнаган хатынның җанын нигә кабат талкырга?

Асия, телефон төймәсенә басып, идән юучыны чакырып кертте.

– Паластагы бу эзләрне чистарт әле, сеңлем, – диде. – Тырышып кара, әмма бу таплар бетмәс шикелле тоела, – дип өстәп, кабинетыннан чыгып китте. Бала чагында күргән рәнҗешләр җуела диләр. Шулай микән? Бетә микән? Йөрәккә сеңеп, яшьлеге искә төшкән саен җанын әрнетеп тора түгелме алар?

«Дөнья – куласа, бер әйләнә, бер баса», ди халык. Дөнья ул бер алдын, биш артын күрсәтә дип тә әйтәләр әле. Авыр хәлгә калган, егылган кешегә кулыңны сузып, аякка бастырырга булышсаң, үзеңне рәнҗеткәннәрне гафу итә белсәң генә кеше буласың. Оксана Ахтинага да Аллаһ авырлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм итсен.

* * *

Ул көннең дәвамы да тынгысыз булды. Иртәдән үк тикшерүчеләр килеп, җанына тиде, янгын сүндерүчеләр акт төзеп китте, ут сүндергечләрнең срогы чыккан икән. Башка вакытта ярдәмчеләренең һәрдаим исләренә төшереп тора иде Асия:

– Алай-болай янгын була калса, чыгу юллары ачыкмы? Алла сакласын. Кешеләр янып харап булмасын! – дия иде.

Бу арада хосусыйлаштыру мәшәкатьләре белән йөреп, болар Асиянең исеннән чыгып киткән. Шактый гына штраф түләтәчәкләр, билгеле. Хәерле булсын. Аларны озатып кына җибәргән иде, ни күрсен: ике ир-ат залдан ук ләнгәзләрен күтәреп, ак халатларын киеп килеп керде. Ләнгәзләрендә әле яңа гына сатып алган ризыклар тезелгән. Госторг инспекциясе! Болары да гаеп тапмыйча китмәячәк инде. Үлчәүләр ялгышмыймы? Тауар накладнойлары бармы? Кассир дөрес исәпләгәнме һәм башкалар, һәм башкалар. Асия иң якын кешеләрен каршылаган кебек җылы итеп күреште алар белән. Шулай кирәк.

– Исәнмесез! Әйдәгез, узыгыз! Үлчәүләр кухняда.

Таш кебек катып калган йөзләрендә бер генә мускул да селкенмәде бу икәүнең, үз эшләрендә тәмам чарланган инде болар. Кухня ягына үттеләр, Асия дә аларга иярде. Инспекторлар үлчәү, санау белән мавыкланганда, «тиз арада итәк-чабуларыгызны җыегыз» дип, ашчыларына ым кагып та өлгерде. Хәер, алар инде нишләргә кирәген үзләре дә белә. Ашханәдә су буе чират тезелеп тора, мәхшәр көне, диярсең. Чөнки әлеге минутта берәүнең дә клиентлар турында уйларга вакыты юк. Таяк тыгып болгатылган кырмыска оясы диярсең! Барысы да йөгерешә.

Асия тикшерүчеләрнең ләнгәзләренә күз салды да, тауар чегына карап, алган ризыклар бәясен чагыштырып санап чыкты. Алланың биргәненә мең шөкер, дөрес исәпләнелгән! Аш өстендә йөзеп йөргән дуңгыз майларын кашык белән чүпләп, ак тастымал өстенә салып корыттылар да үлчәп карадылар. Ике грамм ярым җитми икән. «Соң, нәрсәгә дип шулай киптерәсез аны? Китергәндә итнең сүле агып чыга бит. Ул дуңгызларны безгә киптереп китермәделәр ләбаса», – диде Асия эченнән генә.

Тик дәшмәде. Чөнки аның аларга каршы яисә үзен яклап бер сүз әйтергә дә хакы юк. Әнә, котлетлар да кибеп киткән. Димәк, биш граммлап җитмәячәк.

– Котлетларыгызның өстенә азрак кына майлы шулпа сибеп торыгыз! Кипмәсеннәр, – дип кат-кат әйтеп тора ашчыларына югыйсә. Әллә яшьлекләре белән оныталар, әллә тыңлаулары шул чаклы гына.

Асиянең шикләнүе дөрес булып чыкты: котлетларның авырлыгы нәкъ биш граммга ким иде.

– Көнгә ничә данә котлет сатасыз?

– Илле данә.

– Димәк, бер айга бер мең дә биш йөз данә була, – диде өстенә затлы костюм кигән инспектор. – Бер котлетның бәясеннән биш граммының бәясен чутлап чыгарабыз да, бер мең биш йөз данәгә тапкырлыйбыз... Димәк сез бер ай эчендә котлет сатып кына да шактый акчаны үз кесәгезгә салып куясыз, шулаймы? Сезнең эшегезне прокуратурага тапшырырга, ревизия китертеп тауар остатогын тикшерергә кирәк.

– Шулай да сез ун данәне бергә үлчәп карагыз әле. Бәлки алай үлчәгәндә, дөресрәк чыгар, – дип кушылды Асия.

– Бар, Алмаз, раздачадан ун данә котлет алып кил әле, аныңча булсын.

Алмаз дигәне котлетларны зур тәлинкәгә салып китереп тә куйды.

Асия күреп тора: раздачада эшләүче яшь кыз Татьяна котлетлар өстенә шулпа сипкән, чөнки өсләре ялтырап тора. Димәк, котлетлар тиешле авырлыкта булып чыгачак!

Ун котлетны үлчәгәннән соң, Алмаз Андрей Васильевич дигәненә дәште. Анысы дәрәҗәсе буенча зуррак иде булса кирәк.

– А здесь, наоборот, на пятьдесят граммов больше.

– Алмаз, да, больше, потому что они ещё горячие.

– Так и должно быть.

«Әй, җаныкайларым, сез бит үзегезгә ничек кирәк, шулай теркәп куячаксыз. Котлетның сез сатып алганы да шул ук табадан бит инде», – Асия эчтән генә шәрехләвен дәвам итте.

Күңелләре төште тегеләрнең, әйдәгез, цехларыгызны да тикшереп чыгыйк, дип Асиягә ияреп чыгып киттеләр. Болар аштагы дуңгыз маен чүпли-чүпли ике грамм ярым җитмәүчелек тапкан арада, аның бердәм коллективы инде әллә кайчан җыясын җыеп, яшерәсен яшереп өлгерде. Чөнки бу өлкәдә озак эшли алар, мондый тикшерүләрне күп күрде.

Әллә ни зур кимчелекләр табылмаса да, акт төзеделәр: «Единичные летающие мухи» дип язып куйдылар. Чөнки әллә каян гына килеп чыккан бер чебен, үч иткән кебек, Андрей Васильевичның борын тирәсендә безелдәпме безелдәде.

Гөнаһ шомлыгына каршы Гөләндәм исемле идән юучы хатын, Алмаз янәшәсендә, «ипи» дип язылган такта өстендә үзенә әбәткә кыяр турап маташа иде. Андрей Васильевичның үткер күзе бу «җинаятьче»не шунда ук күреп алды.

– «Ипи» дип язылган тактада кыяр турыйлар. Не соблюдается товарное соседство.

«Әйтерсең лә ит янына балык салганнар!» Асиянең түземлеге төкәнде:

– Егетләр! Мондый вак-төякне нигә язып торасыз инде? Телдән генә әйтеп булмыймыни? Кимчелекләребезне сезнең күз алдыгызда ук төзәттек бит, – диде ул.

– Тикшерергә килгәч, акт төземичә китә алмыйбыз без. Чөнки хөкүмәт безгә хезмәт хакы түли. Әгәр язмыйча кайтсак, берни эшләмәгән кебек булабыз, эшебез күренми кала. Ярар инде, әллә ни күп язмадык бит. Штрафы да бик зур булмас, – дип аңлатты Андрей Васильевич.

– Рәхмәт инде, егетләр, безнең авыр хезмәтебезне аңлавыгыз өчен зу-у-ур рәхмәт, – диде Асия, кинаяләп. – Әйдәгез, алайса, бераз ашап алыгыз.

Егетләрне ашатып-эчертеп озатып җибәрде Асия.

Алар чыгып киткәч, кухня ягына үтте. Теге ике грамм ярымга «ким булган» дуңгыз мае әле һаман ап-ак тастымал өстендә тәмам кибеп, ак тирес корты шикелле бөгәрләнеп ята иде. Очы кибеп, корт башы кебек каралып та тора әле.

– Гөләндәм апа, зинһар өчен, бу кортны чүп чиләгенә илтеп сал әле.

– Нинди корт турында әйтәсез, Асия Сәлимовна?

– Әнә, тастымал өстендә ята.

– Корт түгел, дуңгыз мае бит ул. Сало...

– Икесе бер инде аның.

Асия, тәмам хәлдән таеп, бүлмәсендәге кәнәфиенә кереп утырып, уйга чумды.

Әле ике көн элек кенә Зинира исемле тикшерүче бүксәләре бүлтәеп, күгәреп чыккан балык консервлары күтәреп килгән иде.

– Асия Сәлимовна, менә бу консервларны иткә яисә тавык йомыркасына алмаштырып бир әле, – ди.

– Ә боларны кая куярга?

– Сатарсың, кушып җибәргәч, китә ул шунда.

– Сез нәрсә, Зинира, бомбажлы балык консервасы сатып, кешеләрне агулыйммы инде? Ит бирермен бирүен үзегезгә, ләкин боларны Гөләндәм апа чүп чиләгенә илтеп ташласын, – диде Асия.

Зинираның йөзе кара янып чыкты. Ул хатын инде тәмам әмәленнән язган, чөнки бик зур бер түрәнең сөяркәсе, диләр. Кая гына барса да, алырдай әйбер тапмаса, черек тауар булса да кыстырып кайта, дип сөйлиләр. Аннары Асия Сәлимовна шикелле уңган кешеләргә килә дә, черек тауарны майга, колбасага, иткә алмаштырып китә. Үтәми кара син аның гозерен. Икенче килгәндә, ул сиңа: «Единичные летающие мухи»,– дип кенә язмый инде.

Менә шулар арасында кайный Асия. Ә Зинираның сумкасы ике төпле. Тиз генә тутырырмын, димә. Совет сәүдәсендә эшләп, исән калу өчен әллә нинди сурәтләргә керергә туры килә.

Асия арып-талып кайтырга чыкты. Үз уйларына чумып, автобус тукталышына килеп җитәргә дә өлгермәде, каршына җир астыннан калкып чыккандай өч адәм килеп басты. Чәчләре пәке белән кырдырып алынган, өсләренә бертөсле куе кызыл пиджак кигәннәр, муеннарында – аркан юанлыгы алтын чылбыр.

– Асия, сезгә безнең белән китәргә туры киләчәк.

– Кая?

– Әнә, машина тора, күрәсеңме? Машинага утырып сөйләшәсе сүз бар.

– Мин белмәгән-күрмәгән ирләр белән билгесез машиналарга утырмыйм.

– Көчләп сөйрәп алып барганны көтәсең, ахры. Син кем белән тарткалашканыңны беләсеңме соң?

– Белмим һәм беләсем дә килми, – диде Асия үҗәтләнеп. Ә аркасы буйлап кымырҗык салкын йөгерде.

Шунда берсе шактый нык итеп Асиянең беләгеннән эләктереп алды.

– Кычкырып кына кара. Хәзер эчеңә пычак тыгып айкап чыгарабыз. Гаиләң хакында уйла.

Бу машинага утырып китсә, исән калмаячагын Асия бик яхшы белә. Юкка чыгачак. Гәүдәсен дә таба алмаячаклар. Нишләргә? Тукталыш тулы халык. Халык алдында ук кеше үтерә алмый бит инде болар. Ничек кенә булса да игътибар җәлеп итәргә кирәк дип уйлады Асия. Һәм ул: «Китегез, кагылмагыз миңа»! – дип кычкырды да, теге адәмнең кулыннан ычкынырга талпынып, үксеп елап җибәрде.

Шул арада, Асиянең бәхетенә, милиция машинасы килеп туктады да, аннан яшь кенә ике егет килеп чыкты.

– Ни булды, ул кешеләр сезгә нигә бәйләнә?

– Машинага утыртып, үзләре белән алып китмәкче булалар.

– Сез аларны беләсезме?

– Юк, ләкин алар миңа исемем белән дәште.

– Кайда эшлисез?

– Ашханәдә.

– Аңлашыла... Димәк, сез эшләгән ашханәне тартып алмакчы булалар.

– Миңа әлегә бернәрсә әйтмәделәр.

– Машиналары кайда?

Асия машина торган якка төртеп күрсәтмәкче булган иде, әмма машина инде юкка чыккан.

– Кайда торасыз? – дип сорады озын буйлы милиционер, Марсель исемле егет. – Үзегезгә генә кайтырга ярамый. Әйдә, утырыгыз, үзебез илтеп куябыз.

Асия милиция машинасына утырып кайтып китте. Егетләр аны фатирына кадәр озатып куйды.

* * *

Өйдә Асияне ире борчылып каршы алды.

– Бигрәк озак тордың. Ришат белән булган хәлләрдән соң ничектер җан тыныч түгел, – диде ул, хатынының кулыннан сумкасын алып.

– Барысы да әйбәт. Үзең беләсең безнең эшне, тикшерү арты тикшерү. Нәрсә эзлиләрдер?

– Аларның үз планнары бар. Үтәмәсәләр, премияләрен кисәләр.

– Балалар кайда? – дип сорады Асия. – Никтер өйдә тавыш-тын юк.

– Дәрес әзерлиләр. Тиздән укулары тәмамлана бит, контроль эшләр, иншалар...

Асия иренә бүгенге хәлләрне сөйләп торасы итмәде.

– Әллә нинди син бүген, күңелсез, – диде ире.

– Арылды... – Асиянең, чыннан да, җеп өзәрлек тә хәле калмаган иде.

Әмма төне буе күзенә йокы төшмәде аның. Кем булды болар – бүгенге адәм актыклары? Күренеп тора, Ришат кешеләре түгел. Ә кемнәр соң? Вак-төяк көчекләр генә түгел, билгеле. Бигрәк кыю, һавалы кыланалар. Тукталышта ук ачыктан-ачык бәйләнделәр. Ярый әле милиция машинасы килеп туктады. Автобус көтеп торучылар арасындагы фил кадәрле адәмнәрнең ябык кына хатын-кызны каядыр сөйрәп маташуларына исләре дә китмәде. Куркалар, барысы да курка! Көн кебек ачык: бу явызлар болай гына туктамаячак инде. Үз эшләрен ахырына кадәр җиткерергә тырышачак. Укулар тәмамлану белән балаларны каядыр яшерергә кирәк. Тик башта белешәсе иде: бу куе кызыл пинҗәк кигән карачкыларны кем җибәргән? Бәлки кемдер Асияне куркытып алырга гына уйлагандыр? Чөнки берни дә таләп итмәделәр, бернинди шарт куймадылар бит. Димәк, кунак көтәргә кирәк. Ә ничек яшәргә, эшкә барырга, кайтырга хәзер? Бигрәк куркыныч, аңлаешсыз заманнар җитте.

Тукта әле, Асия! Нигә синең үзеңә дә кәттә егетләр эзләмәскә? Болардан да көчлерәкләрне, зәһәррәкләрне, ягъни мәсәлән. Тик каян гына табасыдыр андый «шәп» егетләрне, Асия? Үзеңнең хатын-кыз икәнеңне онытма! Йа Аллам, нинди хәлләргә калдың син? Бәлки эшне Ришатка тапшырырга да, тынычлап яшәргә кирәк булгандыр? Ач тамагым, тыныч колагым дип...

Икенче көнне Асия, эшенә барып җиткәнче, ике автобуска күчеп утырды.

Күңеленә авыр шом, курку сеңде. Теге зур башлы, акай күзле явызның тавышы колагында чыңлап торды: «Кычкырып кына кара, хәзер пычак тыгып айкап алам!»

Автобустан төшкәч тә ялгыз атламаска, кешеләр арасынарак елышырга тырышты. Инде гомере буе шулай куркып яшәр микәнни? Бу хәлдән чыгуның бер җае чыгарга тиештер бит инде?

Эштә бар да гадәттәгечә, ашчылары эшләп тора. Асия, исәнләшеп, кабинетына узды.

Эшне нидән башларга? Кайдан табарга «шәп» егетләрне?

Шулчак телефон шалтырады.

– Асия Сәлимовна, хәерле иртә! Хәлләр ничек? Исән-саумы?

– Барысы да яхшы шикелле.

– Бүген сәгать өчкә хакимияткә килегез әле, сөйләшәсе сүз бар иде, – дип, хушлашып телефон трубкасын куйды әңгәмәдәше.

«Бу кешегә ни кирәк икән миннән? Сөйләшү рәвеше Ришатныкына охшаган. Значит, ноги оттуда растут», – дип, үз-үзенә русчалатып әйтеп куйды Асия.

Аны сискәндереп, телефон тагын шалтырады. Хосусыйлаштыру комитетыннан шалтыраталар икән.

– Асия Сәлимовна, сезгә тиз арада минем янга килеп җитәргә кирәк. Чөнки кафеңны сатуга куялар. Ачык акционерлык җәмгыяте булгач, чит кешеләр дә сатып алырга мөмкин бит, законны беләсең. Кем күбрәк түли, шул ала.

– Нина Михайловна, хәзер үк килеп җитәм. Чөнки сәгать өчкә хакимияткә чакыралар.

– Кем чакыра?

– Әхмәт Сираевич.

– Хәзергә барма әле син анда. Берәр җаен тап, тегеләй-болай дигән бул... Бер-ике көннән барырсың.

Асия, тиз арада җыенып, хосусыйлаштыру комитетына китте. Бик ягымлы итеп елмаеп каршы алса да, йөзе борчулы иде Нина Михайловнаның.

– Асия, утыр әле! – диде ул. Асия Нина Михайловна каршысына килеп утырды. Нина Михайловна, сак кына ишеккә таба карап алгач, пышылдап кына әйтте:

– Миңа хакимияттән чыктылар, кафеңны бик зур кеше сатып алмакчы була, – диде. – Мин бер сүз дә әйтмәдем, ләкин чынлап торып ярдәм итәсем килә сиңа. Бер тәүлек эчендә ачык акционерлык җәмгыятеңне ябык җәмгыятькә әйләндерергә кирәк. Бу бик мәшәкатьле эш, ләкин мин сиңа булышырмын. Моны тиз генә эшләп ташласак, синең объектыңа үз коллективыңнан башка беркем дә кагыла алмаячак.

Асия аңа кичә эштән кайтканда булган куркыныч хәл турында барысын да сөйләп бирде.

– Это его люди, точно, Асия, но ты не сдавайся. Он скорее всего хотел тебя припугнуть для начала.

– Ул явызлар миңа бернинди таләп куймады әле.

– Әйдә, эшкә тотыныйк, Асия Сәлимовна, безнең нибары бер тәүлек вакытыбыз бар.

Асия хакимияткә шалтыратып, түбәнчелек белән гафу үтенде:

– Бүген килә алмыйм, кызганыч ки, һич мөмкинлегем юк. Иртәгә сәгать өчтә сезнең каршыгызда булырмын, – диде.

– Миңа бүген килүегез кирәк. Иртәгә соң була. Каршыма килеп баскан булыгыз.

– Юк-юк, бүген булмый – иртәгә. Өемдә күңелсезлекләр килеп чыкты. Хатын-кыз өчен гаилә беренче урында бит, аңлыйсыздыр... Тагын бер кат үтенәм, гафу итегезче, зинһар, – дип, трубканы куйды Асия.

«Дөрес әйтәсең – иртәгә соң булачак. Шуның өчен дә мин сезнең яныгызга бүген бармыйм, – диде ул үзалдына. Күңеленнән Нина Михайловнага рәхмәтләр укыды.

Ничек итсәләр иттеләр – бер тәүлек дигәндә эшне төгәлләделәр. Нина Михайловна үзенең хезмәттәшен хәтта төнгә дә калдырды.

– Камилә, Асиягә булыш инде син. Әгәр без булышмасак, тагын эшсез калачак. Югарыдагыларның туясы юк. Булдыра алсалар, бөтен дөньяны кабып йотарлар иде. Кеше башыннан йөриләр бит, оятлары да юк, – диде.

Аннан соң Асияне чакырып алды:

– Менә сиңа Ринат исемле егетнең телефон номеры, очрашып сөйләшегез әле. Шәп кеше ул, авыр хәлдә калганнарга һәрвакыт ярдәмгә килә.

– Рәхмәт сезгә! Әллә барысын да ташлап китим микән дигән уй кергән иде инде башыма. Балалар бар бит. Алла сакласын! Әле дә ярый сез ярдәм кулы суздыгыз, – диде Асия, бераз күңеле күтәрелеп.

– Бирешмә, Асия! Без синең белән көрәшеп карыйк әле. Ә балаларыңны кая да булса яшереп тор. Иртәгә үк озат. Чөнки тегеләрнең нинди тозак коруларын белеп булмый, иманнары юк! – дип саубуллашып кайтып китте Асиянең коткаручысы.

Икенче көнне Асия билгеләнгән вакытка хакимият бинасына килде.

Тик Әхмәт Сираевич дигән түрә аның белән сөйләшеп тә тормады, кабинетыннан куып ук чыгарды:

– Бүген синең кирәгең юк инде. Әйткәч үк, йөгереп килергә идең. Ләкин мин синең белән әле хушлашмыйм,– диде.

Асия аңлады: боларның планнары җимерелгән, хәзер сату-алу эшендә бары тик аның үз коллективы гына катнаша алачак. Димәк, ул максатына таба тагын бер адым атлады.

Рәхмәт сиңа, Нина Михайловна. Җир йөзендә мәрхәмәтле кешеләр дә яши, Ходайга шөкер! Тау түбәсенә, тешләрен ыржайтып аны көтеп торган бүреләр өеренә каршы менгәндә, Нина Михайловна кебек намуслы, шәфкатьле кешеләр очрап тора аның янәшәсендә.

Әмма кафесын сатуга куюы булды, Асиянең хезмәткәрләренә: «Безгә бер акциягезне генә булса да сатыгыз, бер акциягә – бер бүлмәле фатир алырлык акча бирәбез», – дип бәйләнеп йөри башладылар. Үзендә бухгалтер булып эшләүче сеңлесенә дә тәкъдим иткәннәр.

Асия тагын Нина Михайловна янына китте.

– Үзеңдә кемнәр эшләвен бик яхшы беләсең, араларында ышанычсызлары да юк түгелдер. Шуларның акцияләрен ун бәягә булса да үзең сатып ал! Бер тәүлек эчендә хәл ит моны. Соңга калма! – диде ул.

Асия дуслары, ире, сеңелләре белән тиз арада башкарып чыкты бу эшне, Аллага шөкер.

Ул гына да булмады, сату-алу билгеләнгән көнне Нина Михайловнага өстән боерык килеп төште: бу объектны сатмаска!

«Мин әлеге сату-алу эшенә каршы килә алмыйм, чөнки аларның бөтен документлары да тәртиптә. Бәйләнерлек сәбәп юк. Әгәр сатудан алсам, Асия Сәлимовна прокуратурага язачак»! – дип каршы килгән Нина Михайловна.

Теге Ринат атлы егеткә шалтыратыр вакыт та җитте дип уйлады Асия.

– Ринат, миңа сезнең номерны Нина Михайловна биргән иде.

– Сез Асия Сәлимовнамы?

– Әйе. Сезнең белән очрашасы бар иде...

Ринат озын буйлы, пөхтә киенгән, ачык чырайлы егет булып чыкты.

Озак кына сөйләшеп утырдылар.

– Асия! – диде егет. – Кафеңны сатып алырсың да, барысы да тынычланыр, дип уйлыйсыңмы? Һич юк. Алга таба сиңа яклаучы кирәк булачак.

– Кайдан табыйм соң мин яклаучы?

– Ә мин сиңа үз егетләремне җибәрермен.

– Йа Аллам! Кайчан бетәр икән инде бу тамаша?

– Кайгырма, кайчан да булса тынычланырлар.

Икенче көнне үк килеп җитте Ринатның егетләре. Сөйләштеләр-килештеләр. Кыска гына күрсәтмә бирделәр хуҗабикәгә.

– Асия, әгәр сиңа кем дә булса килеп бәйләнсә, менә бу телефон номерын бир! – диделәр.

Бу егетләр дә теге көнне тукталышта бәйләнгән адәмнәр кебек үк киенгән иде.  Әмма болары – аның яклаучылары. Нигәдер бик тәртипле булып күренделәр алар Асиягә. Аңлашылды ки, болары да шул ук хезмәттә: илдәге чуалышлардан файдаланып, үзләренә җим эзләүчеләр.

Асия бер айлап тыныч кына эшләп йөрде. Балаларын инде ике айлап күргәне юк. Андый-мондый хәвеф-хәтәр дә күренми кебек, үзе дә тынычлана төште.

Җәйнең уртасы җитте. Кошлар инде сайраудан туктаган. Яфраклар да май аендагы шикелле ачык яшел төстә түгел,  әле алда озын җәйләр бар дип лепердәшми. Эссе кояш нурларында әлсерәгән кебек, кара-кучкылланып торалар. Асия акрын гына парк буйлап атлап килә иде. Кинәт аркасы белән ниндидер авыр күз карашы тойды. Әйләнеп карыйсы итте.

Каршында теге вакыт машинага сөйрәгән такыр башлы егетләр тора иде.

«Беттем!» дигән уй Асиянең баш миен көйдереп үтте.

– Әйдәгез, ханым, менә шушы эскәмиягә утырып торыйк әле бераз, сөйләшәсе сүз бар иде.

– Сезгә әйткән идем шикелле: сезнең белән сатулашырга вакытым юк минем, – диде Асия, әмма шулай да, вакытны сузарга теләп, акрын гына эскәмия читенә килеп утырды. Як-ягына теге кәттә егетләр урнашты.

– Асия Сәлимовна, сез кафены сатып алдым да, эшем бетте, дип уйлыйсыз инде. – Теге чакта Асияне беләгеннән тотып, машинага таба сөйрәүчесе бу юлы матур гына сүз башлады. – Син без уйлаганча йомшак түгел икәнсең ләбаса. Каты чикләвек булып чыктың. Эшләреңне бездән алда эшләп куясың. Әмма котыла алмассың.

– Сез кем соң? Миннән сезгә ни кирәк?– дип сорады Асия. Тел әйләндерерлек хәле булмаса да, тавышы көр чыкты үзенең.

– Кем икәнлегебезне тиздән белерсең. Син кафеңны без әйткән кешегә сатарга тиешсең. Әгәр каршы киләсең икән, зиратта кабер казылган, тере килеш күмеп куячакбыз. Тере килеш, ишетәсеңме?

– Егетләр, беләсезме, сезгә нишләргә кирәк хәзер? – диде Асия, үҗәтләнеп. – Менә сезгә телефон номеры, тотасыз да шалтыратасыз. Алар рөхсәтеннән башка кыл да кыймылдата алмыйм.

Егетләр әлеге номерга озак кына карап торды, йөзләрендәге чамасыз тәкәбберлек күзгә күренеп кимеде.

– Тыңлагыз әле мине, – диде Асия, кыюлана төшеп. – Бу өлкәдә ничәмә-ничә еллар эшләү дәверендә мин бик күпне күрдем. Сезнең кебек шәп егетләр миндә дә бар. Хәтта Казанда гына да түгел, кемнәр икәнен дә сезгә әйтә алмыйм. Бик сөйләшәсегез килә икән, әйдәгез, без сезгә стрелка, ягъни очрашу урынын билгелибез. Үзем дә килермен. Курыкмасагыз, сез дә килегез. Я не дам вам задавить себя, как таракана; соколом взлечу, расстреляйте, если сможете – дип, русчага күчте Асия. Каян теленә килеп тора диген мондый сүзләр! – Ә хәзергә сау булып торыгыз, миңа өйгә кайтырга кирәк, – дип өстәде ул.

– Кая ашыгасыз? Балаларыгыз өйдә юк бит.

– Кайттылар, барысы да өйдә, – дип ялганлады Асия. – Сез мине казып куйган каберегез белән дә, балаларымны юк итү белән дә куркытмагыз. Апагызның сездән куркыр күлмәге күптән тузган инде, – дип, урыныннан кузгалып китте ул. Тукталышка килеп җиткәнче, теге егетләрнең күз карашын җилкә чокыры белән тоеп барды.

Ринат егетләре биргән телефон номерында нindидер хикмәт бар иде, әлбәттә. Тик Асия аны белми иде. Ә теге бугайлар моны белә, күрәсең, шуңа күрә шүрләбрәк калдылар. Мин батыр, мин көчле, дип мактанма, синнән дә көчлерәкләр бар, диләр бит.

Ринат егетләре икенче көнне иртүк килеп җитте.

– Асия Сәлимовна, эшләр катлаулы, Мәскәүдән зур кешебезне кайтармыйча булмый, чөнки сезнең эшне без генә хәл итә алмыйбыз, – диде алар.

* * *

Бер көнне санэпидемстанциядән кайтып керүенә ашханә ишегалдында ике зур ят кара машина күреп сискәнеп китте Асия. Машиналар кара-каршы куелган, ике якта да озын кара күн пәлтә, кара эшләпә кигән бишәр кеше басып тора.

Асия Ринат җибәргән кешене танып алды. Димәк, Мәскәүдән дә кайтканнар. Кире борылып, ашханәгә икенче ишектән килеп керде ул.

– Кызлар! Сезгә өч минут вакыт бирәм, тизрәк чыгып китеп юк булыгыз. Эш киемнәрегезне дә салып тормагыз! Алгы ишектән чыгыгыз.

– Әле генә ике зур казан камыр куеп җибәрдек бит, Асия Сәлимовна.

– Камырга берни булмас. Сезгә үзегезне коткарырга кирәк. Алла сакласын. Ишегалдында куркыныч кешеләр җыелган! Зинһар өчен, барысын ташлагыз да югалыгыз.

– Ә Сез?

– Миңа беркая да китәргә ярамый, кызлар. Ни булса – шул. Ахыры хәерле булсын! Язмыштан узмыш юк.

Кызлар чыгып киткәч, Асия кухняда казаннар куя торган урындык читенә утырып үксеп елап җибәрде.

«Нинди язмыш бу, Асия? Казанга килгән көннән башлап бу тормышта үз урыныңны табар өчен көрәшәсең. Инде кәттә егетләр белән стрелкага йөрер көнгә калдыңмы? Үзеңне көчле дип саныйсыңмы? Гаиләң, әти-әниең турында уйла», – диде акыллы Асия.

«Үзең интегеп, хәерчелектә яшәгән кебек, балаларыңның да шулай яшәвен телисеңме? Әгәр дөреслек өчен көрәшәм дип тотынгансың икән, туктап калма, ахырына кадәр бар!» – дип җавап бирде сәер, хыялый Асия.

Шулвакыт өстәл өстендәге камыр кабарып, идәнгә шуышып төште дә, Асиянең күз алдында кабара-кабара зурая барып, бөтен идәнне тутырды. Казандагылары да күтәрелеп, ташып чыкты. Идәнгә, болыт кебек, ап-ак камыр җәелде!

Ә егетләр кермәде дә кермәде. Асия исә таш сын шикелле кузгалмыйча утырды да утырды. Күпме вакыт үткәндер – Асия сизмәде. Әллә инде аның өчен вакыт агышы тукталдымы? Алай дисәң, стенага эленгән ак сәгатьнең келт-келт итеп секундларны, минутларны санаганы ишетелеп торды.

Берзаман кинәт ишек ачылган тавыштан сискәнеп китте ул. Ишектән аңа таныш булмаган ике ир-ат килеп керде. Асия күз яшьләренә чыланган керфекләрен күтәреп аларга карады.

– Моннан ары, Сезгә, кайда гына эшләсәгез дә, беркем дә тимәячәк. Курыкмыйча, тынычлап яшәгез, – диде кыскарак буйлысы.

Соңыннан аңлаттылар: Мәскәүдән кайткан егет белән бу кыска буйлы ир-ат «Матросская тишина» төрмәсендә бергә утырганнар. Алар дөньясының язылмаган законнары буенча, Мәскәү кешесенә тияргә ярамый икән.

Икенче көнне Асияне янә хакмимияткә чакырдылар.

– Асия Сәлимовна, Сез үзегезнең шундый дәрәҗәле кешеләр белән дус булуыгыз хакында нигә миңа әйтмәдегез? – дип Әхмәт Сираевич карашын аңа төбәде.

Аһ, тагын шул ук күзләр!!! Явыз Мишараб атып үтергән баласын эзләп, Асия каршына килеп чыккан бүре күзләре һаман эзәрлекли Асияне!

– Миңа игътибар беләнрәк карагызчы, – диде Асия. – Кемнәр белән дус булуым турында уңга-сулга, шул исәптән сезгә сөйләп йөри торган җүләр хатынга охшаганмынмыни? Әллә нинди органнарда бик югарыда утыручы дусларым да бар әле! – диде Асия, гәрчә «әллә нинди органнарда утыручыларны» бөтенләй белмәсә дә.

Ә Әхмәт Сираевич ышанды. Соңыннан Асиянең үзеннән курка башлады. Ахырдан гына белде Асия, ул чакта теге ике кара машинада автоматлар да әзер торган икән. Кара-каршы атыш башлануы бик ихтимал булган. Үзен дә, гаиләсен дә зур куркыныч астына куеп, үз эшен, үз коллективын саклап кала алды Асия.

Рәхмәт Нина Михайловнага, рәхмәт Ринат исемле егеткә. Соңыннан Асия аларга, рәхмәт йөзеннән, хәйран гына акча да тәкъдим итте. Алмадылар.

– Игелек акча белән бәяләнми, Асия, – диде Нина Михайловна. Шул вакыйгалардан соң Нина Михайловна да, Ринат та аның якын дусларына әверелде...

* * *

Йөзен тозлы океан җиленә каршы куеп лайнерда йөзеп барганда, бар тормыш юлын исенә төшерде, сәер, хыялый Асия.

Җитен комбинатында фаҗигагә тарганнан соң, Асиянең төшләренә кереп, авыртуны баса торган даруның тәэсире беткән арада, кызның тәнен азау тешләре белән умырып-умырып каезлаучы ана бүре язгы кояшта челтәрләнгән Ялантау болыны буйлап бик еракка китеп барган иде шикелле. Әмма болганчык заманнар, хосусыйлаштыру мәрәкәсе башлангач, кабат кире кайтып, Асиянең төшләренә кереп йөдәтә башлады ул. Бу юлы ул Асиягә тими, аның газизләренә – балаларына ташлана иде. Гүя үз баласының үчен алардан алырга омтыла. «Синең балаңа мин тимәдем, балаңны тунаган явызның үчен ни өчен миннән аласың»? – дип үкси иде Асия төшләрендә. Уянып киткәч тә, сикереп торып, балалары бүлмәсенә йөгерә иде. Аларның тыныч кына йоклап ятканын күргәч: «Аллага шөкер, исәннәр, төш кенә булган»! – дип сөенә иде.

Ана бүре кергән соңгы төшен ап-ачык хәтерли Асия. Ана бүренең баласы исән, имеш! Һәм алар икәүләп, уйнаклый-уйнаклый, Урыстау өстендә бөдрәләнеп үскән агачлар арасына кереп югалды...

Дөньяда үз урыныңны табар өчен көрәшә-көрәшә гомеркәеңнең узганын сизми дә каласың икән шул. Асиянең әби-бабалары, әти-әниләре дә гел сыналып яшәгән. Ә менә балалары, оныклары гомеренә нинди сынаулар туры килер икән? Ярабби, аларның тормышы безнекеннән әйбәтрәк булсын иде. Ул күргән куркыныч хәлләрне алар күрмәсен иде. Әнә дөнья нинди матур! Иксез-чиксез океан-диңгезләре, урман-күлләре – бары тик тынычлап яшәргә генә кирәк! Тик адәмнәргә һаман нидер җитми! Нәрсә кирәк сиңа тагын, адәми зат? Аллаһ сиңа игелекле гомер итәр өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырган. Тыныч кына, матур гына итеп яшә. Мал асра, иген ик, завод-фабрикаларда эшлә, рәсемнәр яса, көйләр чыгар... Малны хәләл көчең белән табарга тырыш син, кеше булсаң!

Ни аяныч, әмма кешелек әле һаман хәрәмне хәләлдән аера алмый. Югыйсә һәрдаим кисәтеп тора дөнья. Менә бит, әллә нинди авыру чыгып, күпме кеше мәңгелеккә күчте. Дөньяны йотарга теләгән Ришатны да ковид илле җиде яшендә үк алып китте. Бакыйлыкта барыбызны да кылган гамәлләребез өчен гадел хөкем көтә. Анда сине тиешле җәзаңнан кәттә егетләр алып кала алмый. Ришвәт биреп тә котылып булмый ул мәхкәмәдән. Дөньялыкта дөрес яшәргә, үзең киткәч, кешеләр сине гадел, игелекле кеше иде дип телгә алырлык, урыны оҗмах түрләрендә булсын дип дога кылырлык итеп матур яшәвең хәерле.

Лайнер кайсыдыр ил тирәсеннән узып бара, күрәсең. Еракта, бик еракта болытлар арасыннан күкселләнеп күренгән таулар түбәсендә зур-зур корылмалар шәйләнә. Океан өстеннән берсен-берсе куа-куа дулкыннар йөгерешә. Акчарлаклар сөенечле авазлар чыгарып озата бара. Алар су өстендә сикерешкән балыкларны да бик оста каптыра. Исең китәрлек. Офыктан күзләрен алмыйча палубада озак кына уйланып утырудан тәм таба башлады Асия.

Суны ерып барган лайнер артыннан тирән буразналар уелып кала. Яшьлегендә йөрәгенә уелып калган хатирәләр дә шулай: һич көтмәгәндә

җаныннан актарылып чыга да, Асияне кабат-кабат туган ягына – Казанына, Алансуына кайтара.

Җитен комбинатында булган фаҗигадән соң, ул бик озак дәваланды. Кием кия алмый интекте, чөнки яшь тире бик тиз җәрәхәтләнә иде. Киҗе-мамык тукымадан тегелгән йокы күлмәге генә киеп йөрде Асия, анысының да җөйләрен тышкы якка әйләндерә иде. Урамга да чыкмады. Әнисе эшләп йөрде, ә ул өйдә моңаеп утырды. Оят, билләһи. Ул бит үзен-үзе белә башлаганнан бирле әти-әнисенә булышып үсте. Ә монда кырык ике яшьлек әнисе йөгерә-йөгерә эшләп йөри, ә унҗиде яшьлек Асия күзле бүкән шикелле тик утыра. Китап укып арыгач, кулына каләм алды кыз. Болай гына, эш югында эш булсын дип кенә уйлаган иде. Ләкин мавыгып китте, үзенең балачактан күңеленә сеңеп калган уй-хисләрен дәфтәр битләренә төшерә башлады. Бастырып чыгарырга түгел, билгеле, көн үтсен дип кенә. Әнә, шулкадәр бирелеп яза ки, әнисенең олы якка кергәнен дә абайламый калган.

– Әй, кызым, сөбханалла, кулыңа каләм алгансың. Сихәтләнә башлавың инде бу, балам! Аллага шөкер! Күрәсеңме, йөзеңдәге кызыллык кимегәннән-кими бара. Инде бераз тулыланып та киткәнсең. Тиздән яңадан элеккеге матур Асиягә әйләнерсең. Яз син, кызым, матур язасың бит, сәләтең бар, – дип, Асиянең күңелен күтәреп чыгып китте әнисе. Кызның җанына җыелган уй-хисләре, бөреләнсә дә, чәчәк ата алмый калган мәхәббәт сагышлары каләменнән дәфтәр битенә үзеннән-үзе тама да тама. Сөю хисләре, хыянәт ачысы вакыт-вакыт озын керфекләренә күз яшьләре булып эленеп тора...

Кемне шулай үзәкләрең өзелеп сагынасың син, Асия? Хыянәтче Вәкилнеме, әллә кыен чакта сөйгәнеңне алмаштырган кебек тоелган, затлы-матур киенеп, гел елмаеп, дөрес итеп сөйләшә торган ыспай Газизнеме? Асия белми әле. Хәзергә каләм очыннан йөрәк түренә җыелган хисләре генә тама да, күзләреннән яшьләре ага.

Ишектән кемдер керде. Асия борылып караса, дусты Нурия икән. Кочаклашып күрештеләр. Сагынышканнар иде. Нурияне күрмәгәненә инде биш айлап вакыт үткән. Башта изоляторда ятты, аннан соң авылына кайтса да, кеше күзенә күренерлеге юк иде аның. Үзенең кып-кызыл йөзеннән, тәмам тире белән сөяккә генә калган гәүдәсеннән оялды ул.

Нурия Асиянең әнисе аркылы хәл белергә килергә рөхсәтне әллә ничә тапкыр сорап караса да, кыз:

– Әни, мине бер кеше дә мондый кыяфәттә күрергә тиеш түгел,– дип кырт кисте.

Ә бүген Нурия рөхсәт-фәлән сорап тормыйча килде дә керде.

– Асия җаным, шундый сагындым үзеңне, кайчаннан бирле күрешкәнебез юк, – диде ул шатланып. – Аллаһның биргәненә мең шөкер, исән-сау калгансың, йөзеңдә дә бернинди пешү эзләре шәйләнми. Синең бу хәлләргә юлыгуыңны әни дә, абый да, хәтта Галихан абый да авыр кичерде. Әни намазга утырган саен, Аллаһка ялварып, синең савыгуыңны сорады. «Күз генә тиде инде ул балага, башка берни түгел. Хараплар гына булды», – дип, күз яшьләрен түкте. Ә абый исә: «Әни, әгәр мин Асия янына барсам, ул мине гафу итәр микән?» – ди. «Мин аны нинди генә кыяфәттә булса да...» – дип сөйли башлаган иде дә, әни туктатты: «Ул балада синең кайгың юк, улым, Асия үлем белән көрәшеп ята лабаса»! – дип, абыйны ачуланды.

– Миңа шулай язгандыр инде, Нурия дускаем! Гөнаһларым өчен җавап бирүемдер.

– Кит әле, нәрсә сөйләп торасың, нинди гөнаһың булсын ди синең?

– Гөнаһсыз кеше булмый, ә мин үземнең дөрес булмаган гамәлләремне үзем беләм, – дип, дустына күтәрелеп карады Асия.

Нурия шундый матур иде. Өстендә – ап-ак җирлеккә кыңгырау чәчәкләре төшкән күлмәк. Билләре өзелеп тора. Чәчләре дулкын-дулкын булып иңенә агып төшкән, күзләреннән кояш түгелеп тора сыман. Елмайганда, бит урталарында нәни генә чокырчыклар пәйда була.

– Син шундый матур, сылу, дускаем, күзләрем генә тия күрмәсен, сөбханалла! – диде Асия, сокланып. – Әниеңә охшап калгансың.

– Галихан абый да: Нурия, син бит әниеңнең адашып калган яшьлеге, ди. Сиңа караган саен үземнең егерме яшьлек чагыма әйләнеп кайтам, ди.

– Алар ничек яши соң? Калага күчеп киткәч, әниең авылны бик сагынмыймы?

– Сагынырга өлгермидер, ял саен авылга кайтып йөриләр бит. Алар күбесенчә урмандагы йортларында яши. Беләсеңме, Галихан абый белән кавышкач, әни нык үзгәрде бит ул. Аларның кыяфәтләрен күрсәң, унсигез яшьлек егет белән кыз диярсең! Әйтерсең иңнәренә бәхет кошы килеп кунган. Тик абый гына ялгыз калды. Әни шуңа бик кайгыра.

– Ник ялгыз? Улы туды, дип язган идең түгелме?

– Язган идем дә... Исең-акылың китәрлек хәлләр бар бездә, Асия. Әни абый турында уйлап, борчылып, акылыннан шаша инде ахры. – Нурия абыйсы белән Сөмбеләнең тормышы, күл буендагы галәмәтләр турында дустына түкми-чәчми сөйләп бирде.

Озак, бик озак дәшмичә торды Асия. Аннары телгә килеп:

– Балалары бар бит, Нурия, баласы хакына булса да кичерсен иде инде хатынын. Улы ятим кала бит, – дип, күз төпләренә җыелган яшьләрен сөртеп алды.

– Әй, ул биючегә ышансаң... Үзе дә абыйга сөйләп биргән: «Бигрәк тә беркатлы инде син, Вәкил. Яңа ел кичендә синең белән минем арада берни булмады. Авылга кайтканда ук көмәнле идем, әмма баланың әтисе өйләнгән кеше, балалары бар. Ул беркайчан да миңа өйләнмәячәк. Шуңа күрә коньякны махсус алып кайттым да сиңа эчердем, ә син берни аңламый калдың. Бала синеке түгел, әтисе бик зур кеше аның, булышып торырмын, дип вәгъдә бирде. Мин сиңа баланы бирмәячәкмен», – дип ачыктан-ачык сөйләп биргән.

Нурия дәвам итте: «Вәкил чыгып киткәч, әтисе Сөмбеләгә: «Балаңны безгә калдырасың, ә үзеңнең дүрт ягың кыйбла», – дип, кызын куып ук чыгарган. Аннары хатынын кыздырырга тотынган: «Атаклы биюче була, дип мактанып, бер эш эшләтмичә үстергән кызың кеше арасына чыгарлыгыбызны калдырмады, – дигән. – Кодагыйның, кияүнең күзләренә ничек күренергә? Алар дөнья бәһасе кешеләр ләбаса. Ә син авыл гыйбадлары дидең. Минем кызыма нинди генә егетләр табылмас иде, имеш. Әнә йөрсен инде күл буенда кеше ирләре алдында ялангач аккош биюен биеп», –дип, ишекне шартлатып ябып чыгып та киткән ди Сөмбеләнең әтисе.

Әй, Асия, абый хурлыгыннан нишләргә белмәде. Үз-үзен харап итәр,

дип тә курыктык. Ярый әле, янында Галихан абый булды. Ул үзенең акыллы киңәшләре, үгет-нәсыйхәтләре белән саклап кала алды абыйны. Кыскасы, Яңа ел кичендә абый сиңа хыянәт итмәгән, Асия. Кичерә алсаң, кичер инде син аны. Ул бит биюче хатыны белән җүнләп яшәмәде, ни чарадан бичара гына килеп чыккан хәл бит инде бу. Син бик авыр хәлдә ятканда, абый әйтте: «Асия нинди генә кыяфәттә калса да, мин аны яратып яшәр идем», – диде...

Кызлар бер-берсенә карап тын калды... Чөнки Асиянең күңел халәтен аңлатып бирердәй сүзләр, гомумән, дөньяда юк иде.

Нуриянең бу тынлыкны бозасы килде:

– Ә мин озакламый кияүгә чыгарга җыенам, унсигез тулды бит инде.

– Ә институтка укырга кермисеңмени, Нурия? Гаилә корырга иртәрәк түгелме?

– Юу-ук, Зөфәр әйтә, көзгә туй итәрбез, ди. Ул миннән биш яшькә зуррак. Әти-әниләре белән таныштырды инде. Әйбәт, гади кешеләр. Галихан абый әйтә: «Минем фатирда торырсыз, без әниең белән барыбер урманчылыкта яшибез. Латыйфаны сыеры яныннан алып кайтыр хәл юк. Шуңа күрә бер дә кайгырмагыз, үзегез эшли башлагач, кооператив фатир алырсыз»,– ди. Бигрәк әйбәт кеше бит ул безнең Галихан абый. Әнине шундый ярата инде. Өрмәгән җиргә дә утыртмас иде, билләһи. Безгә дә Зөфәр белән шундый тормыш насыйп итсә иде Аллаһ дип телим. Безнекеләр сиңа бик күп сәлам әйтеп, тизрәк савыгуыңны теләп калды, Асия.

– Галихан абый да кайткандыр инде. Җомга көнне әнине кайтарып куйды да китеп барды. Урманчылыкта эшләре күп. Бүген әнине кайтып алырга тиеш, – дип саубуллашып, өйдә «Красная Москва» хушбуе исләрен калдырып чыгып китте Нурия.

– Бәхеткәйләрең генә булсын инде, дускаем! – дип озатып калды кызны Асия. Аның да үзе генә калып, Нурия сөйләгәннәрне күңеленнән яңабаштан үткәрәсе килә иде. Башка сыймаслык хәлләр! Ясалма ефәк күлмәк, пластмасс төймәләр ябыштырылган ак туфлиләр кигән шул Сөмбелә Асиянең бәхет канатларын сындырды, үзенең каралган намусын агартырга теләп, Вәкил белән Асиянең мәхәббәт күбәләген үтерде, кадак үкчәләре белән бу икәүнең җаннарын тишкәләп бетерде... Нигә без моңа юл куйдык, Вәкил?

* * *

Әллә авыл һавасы килеште, әллә үзен өзелеп яраткан әнисенең назы дәва булды – Асия бик тиз аякка басты. Әүвәлге хәленә кайтты. Урамга да чыгып йөри башлады. Йөзендәге кызыллык та бетте, бит урталары матур гына алсуланып тора.

– Аллага шөкер, – диде әнисе, – инде тәмам терелдең, кызым. Тиздән калага китәр чагың да җитә. Син киткәч, кыен булыр инде безгә, кызым, барыбыз да өзелепләр сагынырбыз инде сине.

– Әни, бер дә кайгырма, атна саен кайтып йөрермен. Әй, әни, мин бит бу якты көннәрне күрермен, дип уйламаган да идем. Менә бит, Аллаһ ярдәме белән, аякка бастым, – дип, әнисен кочып алды Асия.

– Әле кичә Нурия дә кайтты. Латыйфаны да күргән идем. Алар ду килеп,

туйга әзерләнә. Машиналарында чибәр генә бер егет тә бар иде. Мөгаен, булачак кияүләредер...

– Шулайдыр. Көзгә туй итәбез, дигән иде Нурия.

– Бигрәк яшь бит әле ул, унсигездә генә. Институтка керәсе итмәгән инде алайса. Гаилә булгач, укуы кыен инде ул, бала-чагасы туа башлый.

– Үзләре беләдер инде, әни.

– Вәкилнең биючесе дә улын алып, каядыр китеп барган, диләр...

– Әни, ник әле син миңа тора салып Вәкилнең Сөмбеләсе турында сөйлисең? Аларның үз тормышы.

– Болай гына, сүз иярә сүз чыкканнан гына әйтүем, – дип тынып калды әнисе.

Болай гына әйтми әнисе. Асиянең төннәрен күз яшьләре түккәнен сизеп тора ул.

– Шәһәрдән хат язучы егеткә дә җавап язмыйсың, кызым. Газизгә, диюем.

– Әни, ә син аның исемен каян беләсең?

– Бәй, конверт тышына язылган бит, Габдуллин Газиз, диелгән.

– Чөнки нинди җавап язасын белмим әле.

Әнисе дәшмәде. Әңгәмә өзелеп калды.

Асия хәзергә алдагы тормышын күз алдына да китерә алмый әле. Казанга барып нишләр? Эшкә кая керер? Газизне күрәсе килерме? Бәлки Вәкилне кичерер? Күңелен капма-каршы уйлар телгәләде. Кабат югарыга талпынасы килде Асиянең. Үземә язган хак юлларны ачсаң иде, йа, Ходаем!

***

Өйлә вакытында, кояш кебек балкып, Нурия килеп керде.

– Асия, исәнме, дускаем! Менә хәзер син чынлап та элеккеге сөйкемле Асиягә әйләнгәнсең. Күз тия күрмәсен. Сөбханалла! – дип, Асияне кочып алды ул. – Безнең туйга шаһит булып барасың бар, онытмадыңмы? Чөнки синнән дә якынрак ахирәтем юк минем, Асия! – Нурия бәхет күгенең җиденче катында йөзә сыман иде.

Ишектән әнисе килеп кергәч, Нурия, исәнләшеп, сүзен дәвам итте:

– Мин Асияне Урыстау түбәсенә алып менәргә дип килдем әле, – диде. – Зөфәр белән кайткан идек. Галихан абый кайта алмады. Ә Зөфәр өйдә әнигә булыша. Ишекнең тупсасын алмаштыра. Алтын куллы минем Зөфәрем, эшли белмәгән эше юк. Әйдә, Асия, киен, юкса өй тавыгына әйләнерсең.

– Ярый, Нурия, хәзер киенәм. Урыстау итәкләрен, челтер чишмәләрен шундый сагындым! Гел төшләремә керделәр, – диде Асия.

– Барыгыз, бар, күңелләрегез ачылыр! – дип, кызларны озатып калды әнисе.

Урыстауга таба җитәкләшеп атлады кызлар. Тереклек елгасы аша салынган басмадан чыкканда, Асия:

– Нурия, кулыңны бир әле, нигәдер башым әйләнеп, егылып төшәрмен сыман, – дип кулын дустына сузды.

Инде җәй уртасы җиткән. Көне җылы, җиләс. Әнә Тереклек елгасының көмештәй суында үрдәкләр йөзә. Алар кинәнеп суга чумып ала да, канатларын җилпеп, бәбкәләрен күзли. Бөдрә таллар елгага су эчәргә иелгән. Яр буйларында сары төнбоеклар дымлы күзләрен кояшка төбәгән.

Агачлар арасына посып кошлар сайрый. Өздерәләр генә! Асиянең ундүрт яшьлек вакыты, беренче мәхәббәтенең бөреләнеп кенә килгән чагында, Вәкилнең, көчле куллары белән күтәреп алып, аны аргы ярга чыгарып куйганы күз алдына килде. Аннан соң да өч еллап гомер узып киткән. Бер генә тапкыр да күрешмәделәр. Шул өч ел эчендә шатлыкларын да, газапларын да аерым-аерым кичерделәр.

Аларның сөюенә шаһит булган Тауасты чишмәсе исә җырлый-җырлый ага да ага.

– Таныйсыңмы мине, чишмә, онытмадыңмы иңнәренә көянтә аскан яланаяклы кызны? Таныйсың...

– Дустым, әйдә, чишмә суында битләребезне юыйк әле, – диде Асия. – Гөнаһларыбызны, кайгы-хәсрәтләребезне Мишәгә, Чулманга, Иделгә, ә аннары диңгезгә агызып алып китсен. Җаннарыбызда бары тик шатлык-сөенечләр генә калсын!

Инде унсигез яшьләрен тутырган кызларның җаннары җырлап тора. Алар, көлешә-көлешә, көмештәй саф чишмә суында юынды. Аннан соң йөгерә-атлый, баскычларны санный-санный, түбәсе болытларга тиеп торган Урыстауга күтәрелде:

– Бер баскыч, ике баскыч... утыз тугыз баскыч...

– Әйдә, Нурия, биредә туктап торыйк. Мин чишмәдән көянтәләп су ташыганда менә шушы ташка утырып ял итә идем, – диде Асия. Шул чакта кабатлый-кабатлый менгән шигъри юллар да исенә төште:

Иңнәремә киселгәндә
Чиләкләр авырлыгы,
Таллар кебек сыгылмаска
Җитте лә сабырлыгым...

Янә кузгалып киттеләр. Асия таныш баскычлардан очып кына менә шикелле.

– Бер басма... Ун басма... Утыз басма...

– Менә Урыстау түбәсенә – безнең балачак иленә менеп тә җитәбез, – дип, аска таба борылып караса, янәшәсендә беркем дә юк икән бит. Нуриядән җилләр искән! Теге чакта ана бүре сагалап торган баскычка җитеп килә түгелме? Куркып-шомланып күтәрелеп караса – яр өстендә Вәкил басып тора иде!



Рəмилə
Майорова

# БЕР ТАМЧЫ МОҢ ҖИТМИ...

## Каләмгә эш бетмәс

Мин кабат йокламыйм бу төндә –
үреләм тынгысыз каләмгә,
Белгәнгә чиремнең дәвасын –
хисләргә юл куям галәмгә.

Мин таныйм җанымның сызуын,
хисләрнең көчешен күзәтәм.
Аһ хисләр! Сез шундый илһамлы,
сулкылдап тамасыз үзәктән!

Җыелып җаныма, бер мәлгә
күзләрдән яшь булып агасыз...
Кай ара укмашып, каләмнән
кәгазьгә сүз булып тамасыз!..

Аһ хисләр! Кай ара алмашып,
талкыйсыз сез минем җанымны.
Эссегә, суыкка саласыз,
тән буйлап йөгертеп канымны.

Аһ хисләр! Шатлыктан исертеп,
күкләргә чөясез күңелне!
Шул күккә ал кояш элдергән,
нур чәчкән үзегез түгелме?..

Язамын. Йокыда юк гамем,
һавада ярымай атына.
Шигырем йолдызы Күгемнән
ук булып кәгазьгә атыла.

Рәмилә МАЙОРОВА (1988) – *шагыйрә. «Өмет бар туар көннәремдә», «Сөю хәбәре» шигырь җыентыкларының авторы. Казанда яши.*

Мин язам хисләрне тугарып,
сүзләрне төшерәм кәгазьгә.
Күңелдә бимаза җим бирер
тутыкмас тынгысыз каләмгә...

Мин кабат йокламыйм бу төндә...

## Моң тамчысы

Дөньяның шау-шулы тавышы
томалый колаклар элпәсен.
Кешелек дигәне – битараф,
намусы саңгырау, күрәмсең.

Дорфа сүз һәм тупас җөмләләр
куптара күңелем ярасын.
Урын юк бер тирән сулышка –
йозакта йөрәкләр авазы.

Миләрдә мең арба мәгълүмат,
чүп тулган кешелек аңына.
Мескен рух аксаган, ахрысы –
туктаусыз абына-абына...

Эх!.. Кинәт көй булып бер тамчы,
бер бөртек моң тамса җаннарга!
Сузылыр ул күңел түренә,
юнәлер ул сүрән аңнарга.

Юл алыр туп-туры йөрәккә,
уятыр йоклаган хисләрне.
Тәндә дә җанлану сизелер,
моң ачар тарихи серләрне.

Бер тамчы моң җитми күңелгә,
Бер тамчы моң җитми җаннарга,
Бер тамчы моң кирәк аңнарга –
Тормышны кабаттан аңларга...

## Мин зур үскәч...

«Мин зур үскәч кем булырмын икән?»
балачакта шулай уйлыйбыз.
Иртәгәне уйлап, бүгенгенең
үтеп киткәнен дә тоймыйбыз.

Кичә генә кебек сабый чагым –
дәү әниле, рәхәт чакларым:
«Үскәч күлмәк алам әнигә» дип,
Йокламыйча уйлап ятканым...

«Бишкә укып, кеше булам» диеп,
Тырышканым истә мәктәптә.
Ышанасы килми, дистә еллар
Бер мизгелдә үткән, әлбәттә...

Сизелми дә исә вакыт җиле:
Көннәр, айлар, еллар үтәләр...
Еллар үтсен! Ник соң алар бездән
Якыннарны алып китәләр?!.

Без – сабый чак, алар – өлкән иде,
Маяк иде безгә, ут иде.
Менә үстек. Хәзер кулда – маяк...
Тик таянган иңнәр юк инде...

Аксакаллар, матур акъэбиләр,
Мөгаллимнәр, остаз, шәхесләр...
Сезне сагына күңел, кабатланмас
Без – укучы булган дәресләр...

Балачакта зур буласы килеп,
Хыял канатында үсәбез.
Ашыкмыйча яшәү кирәклеген
Үсеп җиткәч кенә сизәбез.

Яшәешнең аның үз кануны.
«Еллар үтә» диеп көрсенмик!
Бүгенгедә яшик! Иртәгә дә
Бәхет тулы таңнар көтсен дип!

## Башка сулыш

Мин үземә бүген рөхсәт бирдем
һәм тукталдым... сулыш алырга.
Мин үземә бүген максат куйдым
асылыма таба барырга.

Сулыш алдым бар булмышым белән,
һава тыны үтте үзәккә.
Бик таныш бу онытылган халәт,
Кызыксынып, хәлне күзәтәм:

Бәхетемне сулыйм – һушым китә,
сулыйм сагынуларым, сагышны...
Шатлык катыш сулыш алган чакта
үзгәрә күк күзләр балкышы...

Ачу катыш усаллыкны сизеп,
узып китмик чит-ят күргәндәй.
Җан һавага, иркен тынга мохтаҗ –
сулыш алыйк, әйдә, тирәнрәк!

Сулыш алыйк... һәм тамырлар буйлап
Йөгерешсен һава шарлары.
Иркенәеп калсын фикер сөреш,
чистарынсын күңел ярлары...

Җаннар гына түгел, буыннар да
Йомшаруга сусар чак бүген.
Сүзләр белән түгел, хисләр аша
бушанасы килгән чак минем.

Тәмен тоеп, үз кадерен белеп
ашыкмыйча типсен йөрәк тә.
Яшәү – бәхет! Үз юлыңны табып
яши алсаң рәхәт бигрәк тә!

## Күзләреңдә күңелеңне күрәм

Күзләрдә чагыла җаныбыз халәте,
кичерә күңелләр төрлесен...
Карашлар күрсәтә, тәгаен, дөресен.
Күзләр бит – күңелнең көзгесе.

Аларда – тирәнлек, аларда – матурлык,
Аларда чын тормыш чагыла.
Күңелгә сыймаган моң-зарлар, кайчакта,
Күзләрдән яшь булып агыла...

Аларда – ышаныч, аларда – бар өмет:
Күзләргә хыяллар сарылган...
Күңелгә сыймаган шатлыктан, күзләргә
Бәхетле елмаю ягылган...

Күзләрдә – борчулар, уйлану, сызулар...
Күңелкәй, боекма, түз генә!..
Карашка чытырдап ябышкан өметкә
Җитәр күк бер җылы сүз генә...

Күңелләр бик нечкә, әйтерсең бәллүрдән.
Кителә күрмәсен читләре.
Кагыла күрмәсен дорфа кул, дорфа сүз –
Кертмәгез күңелгә читләрне!

## Алга атла

Тагын бер кат! Әйдә, тагын бер кат!
Тирән сулыш ал син һәм сула!
Ышан шуңа: егылганнан соң да
торып басып, атлап китеп була!

Тагын бер кат! Әйдә, тагын бер кат!
Күз яшьләрен җиңең белән сөрт тә,
кара алга – күрәсеңме анда
күпме яуланмаган үрләр көтә.

Тагын бер кат! Әйдә, тагын бер кат!
Бар көчеңне йодрыгыңа тупла!
Бу юл таныш сиңа, аны үтсәң,
ихтыярың тагын да нык була!

Тагын бер кат! Әйдә, тагын бер кат!
Үз-үзеңә – тезләреңә таян!
Кузгалырга кирәк киләчәккә –
авыртса да әле калеб яраң.

Тагын бер кат! Әйдә, тагын бер кат!
Уйларыңны, хисләреңне барла!
Абынулар була, иң мөһиме –
торып бас та, атла алга таба!

## Хуҗасы кем?

Сүзне көчле, диләр. Әйтегезче!
Аның көчен кемнәр үлчәгән?
Сүзне явыз, диләр... Ул соң кемне
Җәберләгән икән? Көчләгән?

Сүзне матур, диләр. Әйтегезче!
Аның матурлыгын кемнәр күргән?
Сүзне җылы, диләр. Бүлешегез!
Туңган тәнне кемнәр сүзгә төргән?

Сүзне тирән, диләр. Әллә кемдер
Сүзгә чумып, чыга алмый яткан?
Сүзне тәмле, диләр. Әллә берәү
Ризык диеп авызына капкан?

Сүзне әче, диләр. Әйтегезче!
Әчесеннән кемнәр йөзен чыткан?
Сүзне ялкын, диләр. Әллә бармы
Очкыныннан дөрләп янгын чыккан?

Сүзне агу, диләр. Кемдер әллә
Аннан зыян күргән, тилергән?
Сүзне дәва, диләр. Бармы берәү
Сүзне кабул итеп терелгән?

Сүз әшәке, диләр. Әйтегезче!
Кем каралган аның кереннән?
Сүз – табышмак, диләр. Кемнәр икән
Баш ватканнар аның сереннән?

Сүзне авыр, диләр. Бармы берәү
күтәрә алмый җиргә бөгелгән?
Сүз куркыныч, диләр. Куркуыннан
Туган җирдән бармы сөрелгән?

...Җир йөзендә сүз бәһасен һәркем
Белеп, аңлап яши диеп саныйм.
Нигә сүзләр төрле төсмер ала?
Шигырь аша җавап биреп карыйм:

Төрле калыпларга керә сүзләр,
Төрле мәгънә ала, үзгәрә.
Хуҗасы кем – сүзе шундый була,
Хикмәт – хуҗа әйткән сүзләрдә.



Айзирәк
Гәрәева-Акчура

# КУЕНЫҢДА НИ БАР?*

ХИКӘЯ

Дөнья аларны куарга керешкәнне белгәнгәме, һәр көнне, һәр мизгелне мөмкин кадәр тәмләп сузмакчылар. Әнә шәһәр мәчетеннән җомга намазы бетәр-бетмәс, яшьрәкләр урамга ташыды, ә картлар, мәчет чәйханәсеннән күләгәлерәк урын барлады. Аннары җәмигътән каядыр ашыгып китүчеләргә: «Барыгыз, барыгыз, тизрәк булыгыз! Куыгыз дөньясын! Тоттырыр микән! Анысын инде безнең яшькә җиткәч белерсез», дигән кебек хикмәтле генә карап калдылар. Көн кызуыннан бераз зарланышып алгандай итсәләр дә, кояш астында чәй ташып, карачутырга әйләнгән җитез чәйче малайның подноска берьюлы 10-15 нечкә билле филҗан[1] чәй тезеп китергәнен сабыр гына көттеләр. Килгәч, бәләкәй-бәләкәй йотымнар белән, әкрен генә эчтеләр. Дөньясы ашыкмасын әле куарга...

Мәчет юлга терәлеп диярлек торганга күрә, алгы якта ачык һавада чәй эчәрлек кулай, иркен урын калмаган, шуңа күрә чәйханә, тәһарәтханә ян тарафтарак урнашкан. Шунда ук бераз мәчет артына табарак китсәң, җеназаханә бар. Аулаграк урын булгангамы, җеназаханәнең бердәнбер тәрәзәсе өстендә, дивар почмагында кошлар остасы карлыгач тырышып та куйган: чыбык-чабык ташып оя үргән, нык торсынга балчык белән сылаган. Тәрәзәдә исә скотч белән ябыштырылган кәгазьдә кояшта уңа башлаган язу күренә: «Карлыгач оя корган, тәрәзәне ачмагыз». Җилдән җитез бу кошларның ихатага оя коруын бәхет китергәнгә юраган төрекләр өчен болай язып торуның бер кирәге дә юк кебек инде. Алай да кисәтү – саклык билгесе. Шунысы да бар бит әле: карлыгач оясын ялгыш кына да туздырырга ярамый, югыйсә үзең өйсез калырсың, диләр. Астан караганда

[1] Филҗан – төрек чәй стаканы.

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган әдәби бәйгедә «Хикәя» номинациясендә беренче урынга лаек булган әсәр.

Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА (1978) – *язучы, журналист; «Тешле кояш» китабы авторы. Төркиядә яши.*

чынаяк төсле балчык оядан кагылгысыз кошның ак түше күренеп-күренеп ала, ара-тирә каядыр очып-урап килә. Үз оямда – үз көем, дип яшәү шулайрак була, күрәсең.

Җитмешне узган, тәбәнәк һәм җиңел гәүдәле Мөнир карт һәр атнада җомгага шушы олы юл өстендәге яшел мәчеткә килә. Әллә ни ерак яшәми. Аның тере җаннардан аерылмаган, әмма рухларга якын торган үзгә халәте салмак йөрешеннән үк сизелеп тора. Мәчет дивары буйлап биеккә үрмәләп үскән йөзем агачы төбендә чәй эчеп утырырга бер татарны очратса, Аллаһыдан килеп ирешкән җомга бүләгедәй итеп кабул итә. Төрекләр әйткәнчә, йөзем йөземгә карый-карый карала, ә татар картлары чәй эчә-эчә җанлана. Элек-электән мөһаҗир татарлар шәһәрнең бу тирәләрендә шактый яшәгәнгә, җомга намазына байтак туплаалар иде. Ләкин ул су кебек агып киткән елларда алар да дөнья куа иде шул: кырык кат тир түгә-түгә корып җибәргән күн эшкәртү, зәркәнчелек кебек остаханәләренә, гомер итәрлек ризык биргән кибетләренә, күбесе, әлбәттә, авылдан чыкканнарны шәһәрләштергән шикәр заводына йөгерә иде.

Ә хәзер... Ике-өче килсә, рәхмәт укырсың. Аннары шәһәрдә мәчет җитәрлек, һәркем үз өенә якынракка бара. Мөнир карт көтә дип, бирегә йөрсеннәрме?! Бу мәчет ачылганга җитмеш елдан артык, ул җитмеш елда татарларның кайсы кая китеп бетмәгән инде. Фани дөньядан бакыйлыкка күченгәннәре никадәр! Беркемнең әлегә кадәр мәңге яшәтә торган әбелхәят чишмәсеннән суны кушучлап, чөмереп эчкәне юк, хәтта ярты тамчысын йотканы юк.

Кайчак шәһәрнең тар урамнарын махсус урап йөри. Вай-вай... Балчыкташтан салынган, акбур белән агартылган бакчалы өйләр, кая югалып беттегез?! Берәм-берәм иштеләр, урыннарына бишәр, хәтта олы юл читләрендә җидешәр катлы йортлар калыкты. Гөрләп үскән бакчалар юкка чыкты, тирә-як таш булды. Шәһәрдә һәр апартманның – подъездның – үз исеме. Аларны укып барганда таныш татарча атамалар очратса, хуҗаларын чакырып чыгарырдай җилкенә. Җаек, Идел, Сакмар, Урал... Кайчандыр, димәк, биредә татарлар яшәгән, апартманнар аларның мөһаҗирлектә алган яңа фамилияләрен менә шулай саклый.

...30-35 яшьләрдәге, җыйнак кына сакал җибәргән, кыска чәчле, бераз кысык күзле, аксыл тәнле, озынрак, ябык кына бер мосафир кулындагы чәен Мөнир карт утырган агач өстәлгә куйды. Арка букчасыннан планшетын чыгарды. Шуннан соң бераз читтәрәк торган урындыкны өстәл янына этеп утырды.

– Әссәламегаләйкум, – дип, ябык гәүдәдән һич көтелмәгән калын, гөрелдәп торган тавыш белән сәлам бирде һәм, җавап көтми, планшетыннан нидер карый башлады.

Уйларындагы татар чордашларыннан аерыла алмый торган карт бераз сәерсенеп китте. Каршында ата-бабаларының яшьлеген хәтерләткән, моңа кадәр биредә бөтенләй очратмаган мосафир утыра иде:

– Вәгаләйкемәссәлам, – дип җавап биргәч үк, – кайсы мәмләкәттән килдең? Казаннанмы? – дип, татарча сорашырга кереште.

Бүгенге Русия татарларының никадәр аз сүзле икәнен, сөйләшкәндә сорауларга җавап биреп торуны, гадәттә, кирәксенмәүләрен, аралашуга

әллә ни атлыгып тормауларын һәм күбрәк русча сөйләшүләрен каян чамалап бетерсен, җавап көтте. Мосафир хәтта, чит илдә тора салып, татарча сорау бирелгәнгә аптыравын йөзенә чыгармады, бары тик карт җавап көтеп карап торганга, «әйе» дигәндәй баш какты.

Чынлыкта бит бик кызык иде. Чит илдә гомереңдә беренче мәртәбә күргән кеше синең татар икәнеңне аңлап алсын, җитмәсә татарча эндәшсен әле... Бу арада мосафирның чит илдә татар телен ишетүенә инана алмаган баш мие күзәнәкләре ут капкандай төрлесе төрле якка чабышты. Мөселманлыкта шәкерт булып йөргән көңелендә буыннардан буыннарга мөгаллимлек иткән ил тәрбиясенең киеренкелеге сизелде. Ә бәлки, каушады гына?! Юк, аның бары төзелеш сыйфаты, хасияте үзгә. Русча сөйләшкән туристлардан биш метр ераклыкта йөрсә дә, әле генә төрек мәчетендә намаз бетүгә эченнән догаларын, теләкләрен русча укып утырган татарлардан иде ул. Өстәвенә, ярымцифрлашканнардан.

Ә Мөнир карт беркая ашыкмады. Мәмләкәттән – ата-балалары җиреннән килгән мосафир белән очраштырган Раббысына, тавыш-тынсыз, бары иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кымшаткалап, ярты сәгатькә якын шөкрана кылып утырды. Шушы шөкрана тулы мизгелдә бер карт кына түгел, аның белән бергә оясыннан ара-тирә башын чыгарып-чыгарып, тирә-юньне күзәткән карлыгач, чәйханәне тышкы дөньядан аерып торган таш диварга тезелгән аксыл-коңгырт күгәрченнәр, «үзгәреш бармы?» дигәндәй, чырык-чырык килеп ара-тирә очкан чыпчыклар, хәтта 70 еллык мәчет, мосафирның сөйләшүен көтте төсле. Төймә күзле бер күгәрчен, түземлеге төкәнде, өстәлләренә үк килеп кунды. Муенын боргалап, ялт-йолт каравыннан ук барысы аңлашылды. Җитәр, сөйләш! Бер тавыш-тын чыгар!

Ир планшетыннан башын күтәрде, әле әрсез күгәрченгә, әле тын гына утырган өстәлдәшенә карады. Йөзендә елмаю күренде. Карт тиз-тиз тел очындагы сорауларын тезде:

– Әти-әниең исәнме? Әйбәтме?

– Исән-сау.

– Атың ни, улым?

– Илнур.

– Алай... Туристлар элек безгә килмиләр иде. Син каян килеп чыктың?

– Мин эш белән йөрим.

Мосафир, шуны раслагандай, тавыш чыгарып алган планшетына киредән капланды. Инде күгәрченнәр өерләре белән килеп, өстәлне бассалар да, аны эшеннән аера алмаслар кебек.

Мөнир карт янә шөкер кылды. Менә бит, татарчасы бар икән! Әйбәт кенә аңлаштылар! Йөрәк турысын-куенын сыйпап куйды. Мосафир мәшгуль утырганда, чәйчегә эндәште, тегесе ялт кына бушаган касәләрне алып китте, яңаларына чәй тутырып китерде. Ул арада мәчет картлары берәм-берәм кузгала башлады, плитә җәелгән җирлеккә бәргән таякларның тык-тык тавышлары ешаеп аерылды. Карт чәйне мосафир алдынарак этеп:

– Озаккамы? – дип сорады. Ни гаҗәп, егет планшетыннан аерылды.

– Берәр ай чамасы торам әле, – диде. Берничә йотуда чәен бушатты. Планшетын арка сумкасына тыгып куйды һәм картны аптырашта калдырып, нәкъ төрекләр төсле:

– Мөсәгыйтегез олса, качтым, – диде. Ягъни, «рөхсәт итсәгез, китәм».

– Киләсе җомгада кил.

Мосафир җавапка, ни әйе, ни юк димәде, янә елмайды. Мөселманлыкта йөргән шәкерт күңеле кисәтеп тора лабаса: ачык йөз, елмаеп сөйләшү – садакага тиң. Карасу-зәңгәр төстәге букчасын аркасына асты да мәчеттән ераклашты.

Аңа чыннан кызык иде. Менә хәзер китмәсә, ныграк ачылып китеп сөйләшсә... Ипи-тозлык татарчасы белән исәнлек-саулык сорарлык төрекчәсен кушканда, рәхәтләнеп гәпләшер! Әмма нидер, үзе дә аңламады, бу «кызык» белән кызыксынуны киртәләде, тизрәк китәргә, таныш түгел шәһәр урамнарында адашырга этәрде. Инсаннары, сүзләре, мөнәсәбәтләре белән бөтенләй башка үз дөньясына инанычы нык аның. Бары тик, әлеге дөнья тышында калганнарны яратыргамы, алардан качаргамы, ераклашыргамы, якынаергамы – һәрвакыт төгәл бер карары юк. Карары, гадәттә, ихтыяждан чыгып туа.

Мөнир карт өчен бер атна искитмәле озын тоелды. Һәр көн иртәнге намазын кылганда, мосафирның җомгага килүен Аллаһтан сорады. Намаздан соң үзалдына:

– Мәмләкәттән килгән... Нәкъ безнекеләргә охшап тора, татарчасы бар барын, никтер аз сөйләшә... Элеккеләр дә күп сөйләшмәс иде, – дип сөйләнде. Ятагына барып утыргач, якында гына торган өстәл өстеннән калын дәфтәрне хәтерләткән, шактый таушалган китапны үрелеп алды. Битләре коелып китмәсен өченме, ипләп кенә ачты, тигезле -тигезсез юллар булып яткан, иске имляда язылган җөмләләрне, дога әйткәндәй, көйләп укыды, ни гаҗәп, теленнән гарәпчә калимәләр түгел, татарча сүзләр төште.

«Аллаһым кичерсен, буш җирләргә шушы михнәтле юлыбызны кыскача аңлатып, язып барам. Күңелемне, һәм аятьләр укып юатам, һәм шулар арасына түгәм. Авылдан чыгып киткәч, Кырымга поезд белән айга якын килдек. Менә шулай, Кырым җирләрен күрергә насыйп итте. Инде икенче ай үтеп бара. Күп вакыт җәяү йөрибез. Бер җиргә тукталсак, яныбызга килеп-китүчеләр күп була. Кайберләре безнең ерактан килүебезне белеп алса, хәзер җирлек җитәкчеләренә, әллә кемнәргә шикаять итәргә торалар. Шуңа күрә беркем күрмәсен өчен, юлларны чуалтырга тырышабыз. Көндезләрен урманнарда кача-поса агач төпләрендә утырабыз, төннәрен тик тормыйбыз, җәяүләп китәбез. Шушы Кырым җирен исән-имин үтеп, Кара диңгез буена барып җитәргә Аллаһым насыйп итсә иде, белмим, ул көннәрне күрербезме?..»

Мөнир карт икенче битне ачты, бераз тын алды. Җыерчыклы кулы белән ачкан битне сыпырып куйды, шуннан соң кабат укуын дәвам итте.

«...Киткән вакытыбызда урын өстенә калган әтиебез Аллаһым ярдәме илә безне озатыр өчен капкага кадәр килде. Гыйлемле, мәшһүр затлар, әүкате бар кешеләр өчен мәҗлесләр җыйган йортыбыз янында кырыс холыклы әтиебез, бетәшкән, ябык гәүдәсе белән бердәнбер кызына сыенып басып калды. Фатихасын алып киттек, аның гозерен Аллаһым биргән гомерем беткәнчегә кадәр аяк астына салмам, кардәшләремне ата кебек кайгыртырмын. Әмма бичара апам, ялгыз башың, карт атабыз белән ничекләр михнәт тулы дөньяда баш чыгарсың?! Әүвәле юк, ахыры юк, бер сәләмә дөнья бу... Һәр таң атканда, шуларны уйлыйм, сезнең белән саубуллашып аерылышкан

көнне искә төшереп сызланам. Үзәгем өзелә, әллә нинди караңгы, күңелсез уйлардан арынырга теләп, шушы юлдашымны укыйм, күңелемне түгәм. Сиңа Аллаһтан ярдәмнәр сорап догалар кылам. Ул сәхәрдәге кебек синең сөйләшүеңне беркайчан теләгәнем юк иде, шул капка төбендә безне озаткан яшьле күзләреңне яшергәнче, телгә килеп: «Мине калдырмагыз! Мине дә ияртеп алып китегез!» дисәң иде. Ә син әтиебезгә ябыштың. Югыйсә әтиебез, бик камил зат, безгә көч-куәтен янә бер күрсәтеп, синең китүне хуплады. Санаулы көннәрем калды, диде. Безнең өйдән исән-сау чыгып китүебезне күрергә теләде. «Бүгенге заманда Аллаһыга күңел биргән, гавам өчен хезмәт итүне мәсләк иткән, мәдрәсә-мәчет әһеле булганнарның нинди мәшәкатьләргә һәм михнәтләргә дучар икәне мәгълүм. Улым, җан кошына мескен адәмдер кафәс... Еракларга очыр җаныңны! Туганнарыңны сакла, харап итмәсеннәр. Син аларның өлкәне, гакылың, гыйлемең бар, иманың нык, алып кит аларны. Әүвәлгеләр китте, алар янына китегез, табыгыз юлын», – диде. Аның бөтен теләге, бәлки соңгы теләгедер дә, безнең исән-саулык. Әмма, Миңзифа апа, сине барыбер тыңлата алмады. Әти миңа ышанды. Мин исә, шушы галәмәт озын, михнәтле юлда 16 яшьлек туганымның чыдамлыгына гаҗәпкә калам, 25 яшьлек туганыма рәхмәтләр укыйм, ул үз гаиләсен кайгырта, минем гаиләмә дә күз-колак. Алар миңа түгел, мин аларга таянам төсле, чөнки уемда мөшкел хәлдә калган бичара, кадерле һәм сөекле туганым Миңзифа апа... Карт атамның капка төбендә борынгылар сүзен искә төшерүе... Хәтергә уелган кадәре шул.

Җан кошыга мескин адәмдер кафәс[2],
Гакълыңа килгел, фәкыйрь, сән бер нәфәс[3]...
Ятма, торгыл, үтте, күргел кафилә[4],
Бирмәгәйләр хисса һәргиз гафилә[5]...
Басмагыл юлыга рәһбәрсез кадәм[6],
Башсыз юлы, үзе булгай көл-гадәм...
Рәхмәтең дәрьясыдин биргел өлеш,
Тугры юлга биргел имди хуш йөреш...»[7]

Укый-укый ятлап бетергәнгә, кайсыбер сәхифәләрне күңеленнән сагышлы бер көй белән әйтте. Гүя, таң якынлашып килгән мәлдә, ниндидер бер урман читендә, серле аксыл зәңгәр төстәге томан күтәрелгән аланлыкта ташка аркасын терәп утырган, арып йоклаган юлдашларын каравыллаган бабасының йомшак тавышы ишетелде.

«Юлыбыз никадәр авыр икәнен аңлатып бетерергә, язып бетерергә кулымдагы Коръәни-Кәриминең буш җирләре җитмәс. Һаман олы туганыбызны калдырып, дөрес эшләдекме дия, йөрәгем сызлый. Дәгъвалы хисләрем заманны каргый, бик мөкатдәс нәрсәләрдән ераклашабыз төсле. Ераклашкан саен, балачактан бирле өебездә күргән инсаннарның кайчак ыгы-зыгы куптаруы, кайчак ипле генә нәсыйхәт тыңлаулары, аш ягында пешкән камыр ризыклары исе, кайнар чәй тәме, түшәк-ятак урыннарының пөхтәлегенең кадере арта бара. Болар барысы тормышыбызның бик вак нәрсәләре тоелганга күрә, болай язуым ваклык төсле. Туган өемнең ышаныч-куәт бирүен ничек аңлатыйм...

[2] Кафәс – читлек.
[3] Нәфәс – сулыш, кыска вакыт.
[4] Кафилә – кәрван.
[5] Бирмәгәйләр хисса һәргиз гафилә... – бирмәсләр өлеш һич тә гамьсезләргә.
[6] Басмагыл юлыга рәһбәрсез кадәм... – юлга җитәкчесез, башлыксыз аяк басма.
[7] Шигырь сүзләре - Мөхәммәдьяр, «ТӨХФӘИ МӘРДАН»нан.

Аллаһым кичер, шул солтан җирләренә барып җитүебезне өмет итеп, кирәгеннән артык сабырсызланам, тәкъдиремнән качып котылырга тырышам, ахры. Сабырсызлыгым өчен бер җәза төсле, юлыбызның очы-кырые күренми. Тизрәк барып урнашсак иде, тизрәк сине кайтып алу җаен тапсак иде. Аннары, бер заман җитәр, барыбыз бергә кире кайтырбыз, Аллаһы боерса. Ләкин әле һаман Кырым җирен узып китә алганыбыз юк. Алдан хәбәрләшеп куйган берничә адәм бар иде, аларны туры китерә алмадык. Көн саен яңа бер карар кабул итү хәлендә калабыз. Нишлик, башка чарабыз юк. Кире кайтырга уйласак, кайтып җитә алмабыз. Бәлки Кырымда калыргадыр? Әмма бер таяныр кешебезне, ышаныр бер танышыбызны юлда очрата алган юк. Алар да безнең кебек кайсы кайда, типкедә йөри, ахры. Диңгезгә күпкә якынрак булырга тиеш, үзебезне шулай юатабыз...»

Чираттагы сәхифәсен ачканда карт, дулкынланудан, китабын аздан гына идәнгә төшереп җибәрмәде.

«Диңгезгә җиттек! Ерак түгел авыл кешеләре белән кача-поса сөйләшеп, яхшы гына түләү бәрабәренә безгә ярдәм итәрлек берничә адәмне таптык. Кара диңгез буенда көймә яллалык. Кырым җиреннән аерылып, яр буеннан ераклаша баруыбыз авылдагы капка төбен искә төшерде, диңгез дулкыннары Миңзифа апаның яшькә тулган моңсу зәңгәр күзләрен хәтерләтте. Капка төбендә әйтелгән бәхиллек сүзләрен кабатлыйм. Бәхил бул, әти! Бәхил бул, Миңзифа апа! Бәхил булыгыз!

Аллаһыма мең шөкерләр, көймә белән Трабзон шәһәренә исән-имин чыктык. Трабзонда идарәче кебек кешеләргә хәлебезне аңлаттык. 300дән артык чакрым ераклыктагы Самсунг тарафына юлладылар. Анда татар мөһаҗирләре бар, диделәр. Анда 15 көн-фәлән тордык. Тирә-як таулык, чәчәр-урыр өчен басулык җир юк. Җир булмагач, нишлик, китәргә теләдек. Безне Төркиянең үзәгенә таба, Бурса шәһәренә караган Карачабәй җирләренә юлладылар. Самсунгтан 800 чакрым ераклыкта, диделәр. Менә шулай, солтан җиренә баскач та, газаплы-михнәтле юлыбызның очы-кырые күренми әле. Безнең кебек ары сугылып, бире сугылып йөргән татарларны очраттык. Кайберләре белән бер төркемгә әйләндек. Кемнәр кайда ничек тукталган, сораша-сораша бераз мәгълүмат тупладык. Аннары барлы-юклы мал-мөлкәтне кабат җыйдык һәм Карачабәйгә киттек...»

Мөнир бабай шулай һәр көн, китапка кулдан язылганнарны, бәлки инде гомерендә йөзенче мәртәбәдер, укый-укый, җомганы көчкә җиткерде.

Көн-төн интернет аша милек сату эшендә кайнаган Илнур өчен җомга бик тиз җитте. Үзе яшәгән кунакханә каршындагы мәчеттә ара-тирә намаз кылды. Җомгага янә шунда, ләкин соңлабрак керде. Ул чыкканда инде карт нәкъ үткән атнадагы кебек чәй эчәргә хәзерләнгән, әмма уе гына чәйдә түгел кебек, һәр чыккан кешегә күз салып утыра иде. Көтә, димәк.

Дүртпочмаклы экран дөньясыннан тәүлек дәвамында эш, акча, дус казанган кеше өчен мәчет каршында көпә-көндез чәй эчү, болай гына, планшетсыз утыру акылга сыймаслык бер гамәл тоелды. Бүлмәсеннән ашыгып чыкканга күрә эш коралын алырга онытты. Тизрәк бүлмәсенә кайтасы иде, уңайсызланды. Карт аны күрүгә чәйчегә эндәште, тагын бер чәй китерергә боерды. Егетләрчә җитезлек белән мәчеттән сөйләшә-сөйләшә чыгып барган берничә кешегә хәбәр салды:

– Татар мосафирым бар! Мәмләкәттән килгән!

Тегеләре ихластан елмайды, 60 яшьләрдәгесе аерылып калды. Төрекчә:

– Күзебез айдын олсун! – дип, яннарына килеп утырды. Ягъни, «Теләгәнебезгә кавыштык, хәерле булсын!» – аннары татарчага күчте: – Ни хәл, Мөнир абый? Әйбәтме?

– Әйбәт кенә. Менә, мосафирыбыз бар. Казаннан килгән.

– Шулаймы?! Мин Салих булам.

Мосафир белән кул бирешеп күрештеләр. Бабай таныштырып торды.

– Аты Илнур, әти-әнисе мәмләкәттә икән, саулар. Үзе эшкә килгән.

Ир күзләрен чекерәйтә төшеп карап алды.

– Хәзер килгән-киткән күп инде, Мөнир абый, – дип, бераз саграк кеше икәнен сиздереп куйды.

– Алай дисеңме...

Аннары утырыр утырмас яңа танышын онытты төсле. Мәхәллә хәлләренә күчте.

– Кара, Мөнир абый, кичә җеназага бара алдыңмы соң?

– Җеназа бар идеме?

– Теге, авылда бабалары кибет тоткан Курыкмас Фәйзинең абзыйсы бар иде бит... Исемен оныттым...

– Ә-ә-ә... Фәхриме? Шул вафат иткәнме?

– Юк. Шуның олы кызының кияве татар иде, шул мәрхүм, авылга алып кайтканнар. Әтисе Юзгат тарафыннан килгәннәрдән иде. Алар Истанбулда яшәделәр. Белмисеңдер?..

– Беләм. Нигә белмәскә?! Ул бит безнең авыл килене Шәмсиянең абыйсы була. Яшьрәк чакта бәйрәмнәрдә күрешә идек. Тукта, ул бит әле яшь! Җитмеш тә юктыр.

– Йөрәктән, ди, теге ковид белән чирләгән булган, ди.

– Алай дисеңме?! Зәхмәт! Күпме кешене харап итте. Мәүли дә шуннан китте, Җәффар да... Мәкамнәре нур булсын, Аллаһ рәхмәт әйләсен.

– Амин. Иртә киттеләр шул. Нык кына йөргән җирдән. Абзый, син элеккеләрне әйбәт хәтерлисең бит.

– Хәтерлим! Вай-вай, әүвәле шундый картлар бар иде! Мәмләкәттән килгәннәр барысы эреләр, гайрәтлеләр! Бишмәт кияләр иде. Бишмәт кигән картлар иде, кайсы берсен сөйлим... Безне, бала-чаганы яңгыр килә башласа: «Күкри бабай килә, качыгыз!» дип куркыталар иде. И-и-и... Шуңа ышанып куркып кача идек... – Салих Мөнир картны бүләргә кыймады, тыныч кына чәй эчүен дәвам итте. – И-и-и... Әүвәлге картлар... Йөз чакрым түгел, мең чакрымны җәяү үтәрлек картлар бар иде. Бер картлар бар иде, бер картлар! Вай-вай, акылың хәйран калыр! Авылда берсе атына арбасын җиккән, шуннан өеннән хатынын, баласын алып чыгып утырткан, Казанга кайтып киткән! Сагынуга, җирсүгә түзә алмаган. Карс шәһәреннән, Азәрбайҗан аша ат белән мәмләкәттәге авылына кайтып килгән. Казанда мәдрәсәдә укыган, гыйлемле иде. Вай-вай, аңлата иде кайтуларын, кире килүләрен... «Моннан кире кайтырга җыенганда атыма: «Җәһәтрәк кылан, кире әйләнеп кайтасы да бар!», – дип шаярткан идем, фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килдеме, кабат чыгып киттек Казаннан. Кая анда яшәү, инкыйлабчылар басып алган бөтен җирне!» – дия иде... Ә бер заманнар,

җир тетрәгәч, Төркиядәге татар авылында өйләргә шактый зыян килде бит. Бер татар картының өе ишелгән икән, дәүләт хезмәткәрләре килгән. «Ничек ярдәм итә алабыз?» – дип сораганнар. Бу: «Ихтыяҗы булганнарга ярдәм итегез. Өйне үз кулларым белән салып керермен», – дип әйтә икән. Ихтыяҗы булганнарга дигән, үзенең бер дә ихтыяҗы юк кебек...

Салих аның акрын гына кеткелдәвенә кушылып көлде. Аннары:

– Мөнир абый, әнә, теге урамда, – ул кулын сузып, мәчетнең уң тарафындагы тар урамнарга күрсәтте, – ике кибете бар иде. Көнбагыш, коры җимеш сата иде. Без бала чакта йөри идек. Әллә кем абзый...

– Гайфулламы? Бер күзе кысык булганга «Кысык күз» дип йөртteләр аны.

– Әйе, әйе! Шуның торыны өйләнә, ди. Бу атна соңында туй ясыйлар. Авылдан бөтен кешене чакырган. Син дә кил, Мөнир абый!

– Кайда була икән соң?

– Шәһәр паркында, яңа ачылган ресторанда.

– Ерак икән, анда ук барып җитеп булмас. Картайдык инде...

– Ни картаю! Авылдагы 90 яшьлек Нәзифә апа әйткәндәй, туйдан тукмак та калмый. Үзе дә йөреп тора, машалла.

Илнур боларның гәпләшүен башта тыныч кына күзәтте. Аннары уйга калды. Кем үлгән, кем өйләнә – берсен белми, нигә кирәк болар?! Картлар үткәненә тотынган, яшьләр – киләчәккә. Китәргә, таныш түгел шәһәр урамнарында адашырга. Адашу халәте маҗарасын татырга. Әнә карт ничәнче мәртәбә инде куенын капшап куйды, эсседә, кояш астында утырганчы, өенә кайтса әйбәтрәк тә соң... Ярый, беренче булып үзенә китәргә кирәк.

– Мөсәгыйтегез олса, качтым, – дип, янә төрекчә саубуллашты. Аны карт татарча:

– Киләсе җомгада күрешербез, – дип озатты.

Мосафир «ачык йөз садакасын» елмаю аша мулдан өләште дә юкка чыкты.

Карт өенә кайткач, пөхтә итеп җыештырылган бүлмәсенең тәрәзәсен ачып куйды, өс-башын алыштырды. Ачык тәрәзәдән озын-озак итеп сузылган азан тавышы яңгырап керде, карт акрын гына икенде намазына әзерләнергә кереште, тәһарәт алырга юнәлде. Намазын кылып бетергәч тә утырган урындыгыннан торырга ашыкмады. Бераз дисбе төймәләрен чикте, аннары өстәлгә куйган китабына үрелде. Һәм укуын дәвам итте.

«Карачабәй җирләренә килеп җиттек. Казан татар мөһаҗирләрен урнаштыру турындагы рәсми кәгазь эшләре тәмамлангач, җирләрне күрсәттеләр. Җир дип өмет иткәнебез, сазлык икән, черкиләр шул сазлык өстендә кара болыт кеби. Чарасызлыктан башыбызга килгәннәрдән, озак-озын юл газапларыннан тәмам йончып беттек. Тегеләй уйладык, болай уйладык, яшәмәле җир түгел.

Юлга әллә никадәр масраф чыкты, мәмләкәттән китергәннәр бетте. Бездән алда килгән татарлар киңәше белән, кире Бурсага килдек, солтаннан ярдәм сорап яздык. Бездән күпме кеше килгәнне белештеләр. Уналты кеше булуыбызны җиткердек. Шуннан соң унҗиде «сары лира» күндерделәр. «Сары лира» дигәне Солтан Мәхмәт бишнең тәхеткә менүенә ун ел тулу мөнәсәбәте илә басылган 7,2 грамм авырлыктагы алтын тәңкәләр иде.

Аллаһыбызга мең шөкерләр әйтеп, солтанга озын гомерләр теләдек. Бик сөендек. Исән-сау гомер итә башлавыгызга өмет килде. Әмма бер әйбергә игътибар иттек. Бер алтын артык иде. «Ялгыш җибәргәннәр» дигән уйга килдек. Башкалар хакына керә алмыйбыз, ап-ачык. Башкалар хакын ашаудан Аллаһым сакласын. Безгә кадәр Төркиягә килеп урнашканнардан, этиемнең кардәше Бурсага солтан хакимияте кешеләренә бер алтынны кире тапшырырга китте. Тегендәгеләр: «Бу заманда бу кадәр дөрес адәмнәр бармы?!» – дип хәйран калганнар. Үзләре озак та үтми кире унҗиденче алтынны кабат китереп бирделәр безгә. Аннары Искешәһәрдә поезд станцияләре тирәсендәге мәхәлләдән җир күрсәттеләр. Бу юлы башка борчуга төштек: «Поездлар еш йөри, тегеннән-моннан килүчеләр күп. Коммунистлык тиз килер бирегә. Иң яхшысы, без агар суы булган җир сорыйк, шундыйрак бер урынга урнашыйк». Шуннан соң безнең кебек үк мөһаҗир карачайлар корган megaүрт авыл уртасына, туган ягыбызны хәтерләткән елга янындагы җирлеккә урнаштырдылар...»

Янә җомга җитте. Бу юлы Мөнир карт намазны мосафиры белән бер рәткә басып кылды, чәй эчәргә янына башка кешене чакырырга ашыкмады. Бары егетне кайгыртты, чәй китертте.

– Минем бабам Шакирҗан исемле. Аның этисен белмим, әнисенең исемен беләм. Кем әле?.. Ни... Китапка язылган. Бабамнар мәмләкәттән өч кардәш чыкканнар. Берсе әле бала икән, өйләнмәгән, ул ияреп килгән. Юлда, Кырым туфракларында күп зәхмәт чиккәннәр. Этием аңлата иде. Галәмәт кыенлыклар күргәннәр, мескеннәр. Инкыйлабчылардан качканнар, авылда кала алмаганнар инде. Дин бетә дип, динчеләрне харап итәләр дип чыгып киткәннәр.

Карт 120 еллык, кулдан кулга, буыннан буынга күчә килгән, мөһаҗирлек шаһитен иплəп кенә куеныннан чыгарды.

– Бабам Шакирҗан бу Коръәнне үзенең куенында яшереп китергән. Ни кара урманда, ни такыр юлда онытып калдырмаган, ни сулар кичкәндә җуймаган. Коръән-хафизлыгы көчле иде, иске төрекчә белән Коръәннең чит-читләренә башларыннан кичкәннәрне язып барган. Кайчан, ничек авылдан чыгып киткәннәрен. Кемнәр белән очрашканнарын. Кемнәр белән мөһаҗирлектә йөргәнен, Төркиядә авыл салганнарын. Әүвәлге картларны язган... Бабамның хатирәләрен Коръән саклый. Бер гасырны кичте инде. Башта этием кулында иде, аннары миңа күчте. Хәлем әйбәтрәк көннәрдә рухларына багышлап хәтем чыгам, шөкер. Алай да... Ана карыныннан килдек базарга, кәфен алдык, китәбез мизарга. «Үлсәм-нитсәм, хатирәләрем», – дип, Коръәнне сакларга балаларга әйтеп куйдым...

Илнур шактый тузган, һәр бите, һәр буш җире иске имлада язылган җөмләләр белән тулы басма китапны бер ачты, бер япты. Бабай өчен никадәр кадерле ядкарь булуын чамалады, аңлады. Кебек.

– Баштарак мәмләкәт белән хат алышып торганнар, элемтәләр өзелмәгән. Безнекеләр көннәрдән бер көнне кайтырбыз, дигәннәр. Соңрак килгән мәктүпләр белән өметләре киселә барган. Фотоларда күренә, мәмләкәттә калганнар гел утырып төшкәннәр, ә мондагылар – аякта. Үзара шулай аңлашканнар. Кем рәхәт һәм тыныч яшәсә... Мөселманлык өчен газап чиктермәсәләр... Дин сәбәпле золым кылмасалар... Аякта төшсен. Киресе, икән, утырып. Әй, дөнья,ниләр бар! Ниләр булды!

Сәламнән соң бер сүз эндәшмәгән, алай да картның сөйләнүен ипле генә тыңлап утырган егетнең, ниһаять, теле ачылды:

– Мөнир абый, чәйләрегез өчен рәхмәт. Иртәгә Казанга китәм.

– Бабам мәмләкәтне бик сагынды, кайта алмады. Әтиемә, миңа да күрергә насыйп итмәде. Шушы мәмләкәттән килгән Коръән кайтсын. Балаларым өчен истәлекләрне төрекчәгә әйләндереп күчердем, тапшырдым. Ә бу китапны... Казанга алып кайт.

Юл кешесе мондый хикмәтле йөк белән йөри алмас. Әле юлда тикшерәнитә калсалар, ничек кенә бәйләнерләр. Шуңа күрә китапны алмаска карышты. Әмма карт үз сүзеннән кире кайтмады.

Илнур Коръәнне икенче көнне, юлга чыгып китәр алдыннан, мәчет эчендәге башка китаплар торган киштәгә куеп калдырды. Изге китапны укырга өйрәнүчеләр киштәсе иде, ахры. Соңгы елларны гына нәшер ителгән төрле-төрле Коръәннәр тезелгән, зурысы, кечесе дигәндәй... 120 еллык мөһаҗир Коръән алар арасында төссезлеге, искелеге белән бөтенләй күзгә чалынмас кебек. Борынгылыгы, тарихилыгы, хатирәләре белән бергә киштәнең бер почмагына сыенып калды.

Һәр нәрсәнең тормышта бер кыйммәте бар. Бу кыйммәт бары тик аңар ихтыяҗ туганда уртага чыгар, диюләре хак. Илнур бер ел тулар тулмас, кабат шушы ук мәчеткә килде. Мәҗбүр. Хәзер аның хассияте мөһаҗирләр оныгы хатирәләренә якынрак, чөнки күчмә халәт кичерә.

Теге вакыттагыча, акрын гына чәй эчеп утырганнардан Мөнир картны сораштырды, «Аллаһының рәхмәтенә кавышты», – диделәр. Ашыгып, мәчеткә керде, китаплар торган киштәне карады, эзләгәнен таба алмады.

Нигә хәзер юлларга аны?! Вакытында картның гозерен ике дә уйлап тормыйча киштәгә күмдең. Китапны тапсаң, хәзер бу гозерне үти алырсыңмы?! Ярымцифрлашкан аңы бәхәскә керде, үзенекен тәкрарлады: «Дөнья алдынгы технологияләр эрасына аяк басты, яңа буын язмышында Мөнир картның бабалары күргәннәр кабатланмас, технологик заман юл куймас, иртәгә-бүген барысы хәл ителер әле».

Мөнир карт белән чәй эчкән агач өстәлгә килеп утырды, җеназаханә тәрәзәсендәге карлыгач оясы күзенә чалынды. Аста – җеназаханә тынлыгы, өстә – оя тулы тереклек, чырык-чырык иткән кошчыклар тавышы.

Шул ук вакытта картның соңгы сүзләре колагында яңгырагандай тоелды.

– Минем әнием аңлатыр иде, бабамнарның телсез кардәше калган. Чикләр ябылгач, хатлар бөтенләй киселгән. Телсез кардәшләренең хәлен белә алмый дөньядан кичтеләр. Бәлки, шул телсез кардәшләренең балалары, оныклары бардыр, чөнки аның кияүгә чыгуы турында хәбәрне алганнар. Бер Аллаһ белер, ничек яшәгән. Бабам куенында саклап китергән Коръән апасыныкы бит, юлга чыгар алдыннан ул биргән аны. Кайтсын ул мәмләкәткә, кайтсын...

Мөнир карт барысын хәтерли иде. Ә яңа мөһаҗирлек зиһеннәргә нинди эзләр салыр?! Балалар, җир читенә китүләренә карамастан, татарча сөйләшеп, дога кылып, бабаларын искә алырмы?! Яңа мөһаҗир куенында тормыш юлының иң кыен, хәтәр, көтелмәгән борылышларын кичкәндә, авырлыклардан йолып, упкыннарга очудан саклап кала алырлык, торыннарына кадәр барып җитәрлек бер көч бармы?! Илнур Мөнир карт төсле куенын капшап куйды. Куены буш дисә... Буш түгел. Авылга кайткач

әбисеннән ишеткәннәр белән тулы: «Бабамның үги әнисе бик тәрбияле, бик мәрхәмәтле, әмма телсез булган, диләр. Минем аны үземнең күргәнем булмады, мин туганда үлгән иде инде. Бабам, беренче хатыны үлгәч, өч бәләкәй баласы белән тол калган. Күрше авылда телсез хатынның беркемсез, ялгыз яшәгәнен ишеткән. Кемдер кызганган, ди, кемдер электән атасын белгән, ди. Кыскасы, барган да алып кайткан. Зифа әби бабайны һәм аның ике туганын үз әнкәләреннән ким бакмаган дип сөйләнәләр иде. Син, улым, тап ул картны, сөйләш. Бәлки Зифа, шул Миңзифадыр...»

Теге вакытта, мосафир киткәнгә берничә атна узган иде, мәчет имамы җомга намазыннан соң сүз алды:

– Җәмәгать, таралышмый торыгыз әле. Ике белдерүем бар. Беренчесе, күрше мәхәлләгә кагылышлы. Җәмигъләрен сүтмәкчеләр, мәхәллә халкы аптырашта. Бер тиле коега бер таш атса, кырык акыллы чыгарта алмаган, диләр бит. Шуның кебек, берсе, мәчеткә терәтеп: «Минем җирем, ничек телим, шулай кулланам», – дип, 3 катлы күңел ачу-сәүдә йортын салып куйды да, җәмигъ ихтыяҗларына кирәкле эшләр башкару кыенлашты. Шикаятьләр килә икән. Эш шунда ки, хәзер мәчетне сүтеп, мәхәлләдәге җир белән бәйле һәр мәсьәләне хәл итмәкчеләр. Белеп торыгыз, дип, әйтүем, күрше мәхәллә халкы риза түгел, бик нык аптырашта.

Намазга җыелганнар гөрләшеп алды. Адәм баласына һаман җир җитми! Менә галәмәт заманнар җитте! Җаһиллек![8] Имансызлык! Хәзрәт, кулын күтәреп, сөйләшүне туктатты, кабат сүз башлады:

– Тагын бер белдерүемне тыңлагыз. Намаз кылучылар арасында татарлар бардыр. Берегез Коръәнен онытып калдырган. Бактым, бик иске китап. Петербургта басылган. Эчендә иске төрекчә язулары бар. Кыйммәтле язулардыр дип төшендем. – Имам кулындагы Китапны өскә күтәреп күрсәтте. – Без башта Коръән укырга өйрәнүчеләр китергәнме, дигән идек. Сораштырдык. Юк, икән. Коръән кемнеке, яныма килсен. Хәзергә сүзем тәмам.

Мәчет ишек төбендә үк диярлек торган Салих, Коръәнне элегрәк күргәне булганга күрә, тиз танып алды. Чыгарга ашыккан халыкны ерып, араларыннан бәрелә-сугыла, хәзрәткә таба ашыкты.

– Хуҗасы, Аллаһ рәхмәт әйләсен, абзыем була. Күптән түгел бакыйлыкка күчте. Олы кеше, аерылырга теләмичә, гел үзе белән йөртер иде. Куенына кыстырып, мәчеткә алып килер, шуннан укып аңлатыр иде.

– Әфәндем, җеназаханә тәрәзәсен ачтырмаган, ике тарафына язу ябыштырган, шулай итеп карлыгачларның оясын саклаган абзыймы әллә ул?!

– Әйе, әйе!

– Аллаһ рәхмәт әйләсен!

– Амин. Хәзрәт, китапны миңа бирсәгез, күз карасыдай сакলармын. Балаларына әманәт итәрмен.

Салих китапны сак кына куенына тыкты һәм мәчеттән чыгу ягына таба атлады.

Тәрәзә өстендәге йомры балчык оядан дөнья кочагына талпынган дүрт кошчыкның бер-бер артлы башлары күренде.

---

[8] Җаһиллек – наданлык.



*Раян Шакиров Арча районы, Яңа Кенәр авылы егете. Бүгенге көндә Биектау районының Дөбьяз авылында яши. Ул – Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр хуҗалыгы көллияте студенты. Унынчы сыйныфлардан башлап, шигырь язу белән мавыга. «Беренче шигыремне бишенче сыйныфта яздым», – ди яшь автор. Ул Казанның Дизайн һәм технологияләр көллиятендә үткәрелгән «Көмеш каләм» бәйгесендә көчен сынап карый һәм беренче урынга лаек була. Шунда жюри әгъзасы, шагыйрь, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рафис Корбан аның шигырьләрен, фикерләү рәвешен ошатып, үзен редакциягә кунакка чакыра. Әлегә яшь каләм иясенең шигырьләре күп түгел. Шулай да күңелендә әдәбиятка карата мәхәббәт, алга таба иҗатта үзен табу омтылышы сизелә. Без дә аңа уңышлар телик. Хәерле сәгатьтә!*

Раян
Шакиров

# ЯШӘЕШЕҢ – КАЛӘМ ЧАРЛАУ...

## Остазыма мәдхия

Гыйлем эзләп сусаганда
Каян табыйк икән җавап?
Кичен күккә караганда
Кайсы якны алыйк сайлап?

Сорау томан күтәргәндә,
Давыл чыгарганда хата,
Хәлдән таеп арган мәлдә –
Фикер сазлыкларга бата.

Якты йолдыз очрагачтын
Күзләребез тапты сукмак.
Остазым, син юлны ачтың,
Синең сүзең гүя кочак!

Эндәшүең – игътибар, наз.
Күзләреңнән тоям серең.
Остазым, һәр карашыңнан
Гыйлем нуры балкый синең.

## Тормыш төрлелеге

Көзен агач яфрак коя,
Хәлсезлеккә бирешкәндәй.
Кеше кәефсезлек тоя,
Күңел кылы өзелгәндәй.

Авырлыклар төшкән чакта
«Кыен, – дибез, – сулыш алу».
Йөрәк кага, кысыла тын,
Тәнгә йога ару-талу.

Әмма күзләр үтә бит ул,
Гөлләр яңа чәчәк ата,
Агач яңа яфрак яра –
Кыштан соң яз кире кайта.

Гел бертөрле булса тормыш,
Ямен белмәс идек аның,
Барса да йөрәктә сугыш,
Язын – бөре бирер талың.

## Сирень чәчәге

Язлар җитү белән галәм
Матур киемнәрен кия.
Чәчәк атып, берәм-берәм,
Сирень хуш ис бөрки, сибә.

Һәм тарала хушбуй сыман
Һәр тарафка күркәм исе,
Һәммә кеше көтеп алган
Җылы язның хак билгесе.

Мәхәббәт тә уяна шул
Әкияти сихри истән.
Әллә нишли йөрәк түре
Яңа туып килгән хистән.

Алтынга да алмаштырмам
Сирень чәчкәләре ямен.
Искәртә ул һәр яз саен
Тәүге яшьлек язы тәмен.

## Матурлык нәрсә ул?

Матурлык нәрсә икән ул?
Каян табыйк икән аны?
Нигә туймый аны куллар?
Гел эзләнә кеше җаны?

Шундый сораулар аша да,
Табылмасмы матурлык?
Ел арты еллар узса да,
Уяналмас төнбоек.

Күзгә генә күренми ул,
Тапмассың аны алай.
Ябык йөрәккә сизелми,
Җан уйнатмаса курай.

Садә, күркәм йөрәкләрдә
Һәр тарафта матурлык.
Бар Җиһан ямьле, мөлаем,
Килгәндә дә авырлык.

Килбәтсез булып күренми
Салам бөртеге хәтта.
Күңел кәефе сүрелми,
Давыллар булган чакта...

## Тормыш китабы

«Укымыймын, дустым, китап,
Яратмыймын ул шөгыльне», –
Дип әйтерсең. Ә чынлыкта
Алдаларсың үз-үзеңне.

Ачу саклап та йөрерсең,
Сүзләр сызып, күктә очып.
Башкаларны тиргәрсең син,
Гафләтеңнең билен кочып.

Өтер саен алырсың тын,
Нокта белән көн тәмамлап.
Һәр яңа көн – яңа җөмлә,
Яшәешең – каләм чарлау.

Кемнекедер сиксән битләп,
Берәү укый тик утызын.
Кем – китабын ачмый китә,
Сала алмый тәү авазын.

Бирешмә, дип кыенлыкка,
Тормыш китабың эндәшә.
Һәрбер көннең ямен күреп,
Бар мәгънәсен той, шат яшә!

## Ачы мизгел

Тормыш барышында имеш,
Җитә, диләр, тик бер мизгел.
Башың аска игән килеш,
Елау булыр синең фигыль.

Яшь тамызып, күзең уып,
Бар бәхетне читкә куып,
Яши генә башлар мәлдә,
Калырсың көн санар хәлдә.

Нурлар да үрелгән сыман,
Яфракларның арасыннан.
Мизгел арасында болыт
Бар өметне ата кырып.

Күңел белә: алда кояш,
Юллар чаты бозлы көндә.
Күңел яше сеңгән караш
Кала серле тау битендә.

Өскә менгән саен анда
Үлән яшелләнә бара,
Ачы җилләр уйнаганда,
Таллар әрсезләнеп кала.

Иң очында ул зур тауның
Кояш та яктырып көлә.
Якты көннең булачагын
Йөрәк, сизеп, алдан белә...



*Данил Макеев (1964) – язучы, тәрҗемәче, мөхәррир, Саха (Якутия) Республикасының атказанган журналисты. Россия Язучылар берлеге һәм Якутия Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы.*

*Якут АССРның Усть-Алдан районы Танда авылында туган. Якут дәүләт университетының филология факультетын (1990) һәм Ерак Көнчыгыш Дәүләт хезмәте академиясен тәмамлаган. «Кыым» газетасында хәбәрче, Усть Алдан олысының Тит-Ари мәктәбендә якут теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән. Шулай ук Вилюйск олысының Кулят мәктәбендә директор урынбасары, «Мүрү саһаргата» олыс газетасының баш мөхәррир урынбасары, Усть-Алдан олысы хакимиятендә Киңкүләм мәгълүмат чаралары һәм кинематография бүлеге начальнигы, вазифаларында хезмәт куйган. Якутск шәһәренә күчеп киткәч, «Вся Республика-Республика бүттүүнэ» газетасының баш мөхәррир урынбасары, «Эдэр саас» яшьләр кушымтасының мөхәррире, «Саха сирэ» газетасының хатлар бүлеге мөдире булып эшли. 2012 елдан «Чолбон» әдәби журналында, 2015–2020 елларда – баш мөхәррир. Хәзерге вакытта шунда ук баш мөхәррир урынбасары. Җиде китабы бар.*

Данил Макеев

# БОЗ СӨҢГЕСЕ

ХИКӘЯ

Иртәдән үк Ньукулай[1] карт ишегалдыннан күтәренке кәеф белән керде. Март кояшы яктысыннан кинәт өйдәге караңгылыкка эләккәч, ишек уемы тирәсендә тукталып калды. Тасма урынына түбәсеннән үк кереш белән әйләндерелгән колакчынлы бүреген салып, тезләренә суккалап какты, ишек яңагын кармалап, якындагы кием элгечен эзләп тапты, баш киемен шунда элеп куйды. Кәкрәйгән бармакларын хәрәкәтләндереп, әкрен генә курткасының сәдәфләрен ычкындырды, капшана-капшана, анысын да шунда урнаштырды.

Әкренләп күзләре күнегә башлады, ул ишек янындагы йомшак урындыкка утырды, мышный-мышный, киез итекләрен салып, йон башмаклар киде. Шуннан соң карт иелгән җирдән уң кулы белән тезенә таянып, сулы белән кием шкафына тотынып торып басты. Чатанлый-

[1] Ньукулай – Ньукуус – бер үк исем (якутларда иркәләп, баласытып дәшү).

чатанлый, аш-су бүлмәсенә чыкты, һәрчак электрга тоташкан чәйнектән кайнар су агызып алды.

Көннәр озая төшеп, салкыннар сабырлангангамы, карт ишегалдында саф һавада тыныч кына йөрүне гадәткә кертте. Бүген исә яздан хәбәр килде: түбә почмагыннан беренче боз сөңгесе асылынып төште. Борынгы җырдагыча, якты, бәллүр тамчылар тып-тып тамды. Ньукулай аларны күреп, чиксез куанды: инде туксанынчы кышының карын да эретергә язган ласа, кем белә, ә бәлки әле яшел чирәмгә басып, хозурланып йөрүләр дә насыйп булыр...

Өлкәнәйгәч, адәм баласы һәр яңа көнне Тәңре бүләге дип кабул итүчән. Кышын ул көннәр озаеп, төннәр кыскарганчы яшәргә хыялланды, хәзер исә, боз сөңгесен күреп, көттереп килгән җәйләренең дә таулар аръягында түгеллеген чамалады. Кышкы хыялы чынга ашса, бик тиздән ул кар астыннан чыккан кара җиргә аяк басар, ылыслы агачларның җанга үтеп керерлек әчкелтем исен иснәр, ә яз кояшының җылысы исә, бөтен тәненә таралыр. Тамчылар бүген – унынчы мартта тама башлады, димәк, бер айдан – унынчы апрельгә карлар эреп тә бетәр.

Кайнар чәен эчкәндә, карт хатирәләр дөньясына чумып, балачагында балаган түбәсеннән сузылып төшкән боз сөңгесен күз алдына китерде һәм җәй җылысын сеңдергән җиргә яланаяк баскан чагын исенә төшерде. Сугыш чоры иде ул. Унөче генә тулган иде. Малай-шалай гына булуга карамастан, шундый уйлар башыңа килсен әле!

Алар колхоз үзәгеннән еракгарак яшәделәр, мал карыйлар иде. Сугышның өченче кышында аның сигез яшьлек Аксю исемле сеңлесе ачлыктан бакый дөньяга күчте. Биш яшьлек Аныска да аягын көчкә сөйрәп атлады. Әтиләре яуга китте, әниләре көне-төне колхоз сыерлары янында булды. Балаганда алар берничә гаилә бергә тордылар. Балалар, хатын-кызлар, әлбәттә... Алтмыш яшьлек Тулламмыкы карт – бердәнбер ир заты, хуҗалык эшләрен алып барды, утын-печән китерүдә булышты. Унөч яшьлек Ньукуус нәкъ шушы боз сөңгеләрнең түбәләргә эленгәнен исе китеп күзәткән көндә аларның ашарларына бетте. Суга он болгатылган ботканы озаккарак җиткерергә тырышып, тагын да сыегайта төшеп пешерделәр. Бәхеткә сыерлары бозаулады: сөтле, соратлы[2] булдылар. Чыкмаган җанны шул саклады. Кешеләрнең ачлыктан гаиләләре белән үлеп бетүләре хакында өлкәннәр пышылдашып кына сөйләште.

Көннәрдән бер көнне балык тоту нияте белән Охоносой һәм Лепсей исемле ике карт килеп кермәсә, шулай көчкә җан асрарлар иде, мөгаен. Шулай ук ачлыктан йончыган картлар чаналарына балык тоту җайланмаларын – сак-куйур, кылдан ясалган соскыч, боз тишкеч-сөймән һәм көрәкләр куеп, хәлсезлектән алпан-тилпән атлап, чакрым ярым юл үттеләр.

Сорат белән тамак ялгап алгач, каен гөмбәсе чәе эчтеләр һәм йокларга яттылар. Иртән картлар өйдән алып килгән онны суга болгатып тамак ялгап алдылар, шул чакта Ньукуусны да үзләреннән калдырмаска уйлаштылар.

Былтыргы корылык элек балык тоткан күлне төбенә кадәрле киптерде,

[2] Сорат – катык

шуңа алар кечкенә болын уртасындагы, яшәгән җирләреннән ике чакрым ераклыктагы Анагасыннах күленә барырга җыендылар. Күңелләрендә, монысы шактый саекса да, кибеп бетмәде бит әле, шуңа балыгы да качмагандыр, бу байлыкны күл безнең белән дә бүлешми калмас, дигән зәгыйфь өмет елтлап алды.

Алар, өчәүләшеп, печән ташучылар салган чана юлы буйлап атлады. Ярга җиткәч, Лепсей белән Охоносой юнәлешне тәгаенләде. Монда балык тотарга туры килгәне юк, шуңа озак киңәшләшкәннән соң, бәкене көнбатыштагы култыккарак кереп тишәргә булдылар. Бәхеткә, юл да туңган күл өстеннән уза икән. Казлардай тезелешеп, шул якка юнәлгәндә, Охоносой тирә-юньне күзләп алды. Аннан:

– Кай тирәдәрәк тишү уңышлырак дип уйлыйсыз, ә? – дип, җавап ишетергә теләгәндәй Лепсейга төбәлде.

– Их, белсәм икән... – диде Лепсей, як-ягына карангалап. – Без вак табыш эзләп йөрүчеләр генә. Әллә ничә бәке тишеп булмас. Бәхетебезгә балыклы урын очраса гына инде.

– Балык үрчегән җирдә кар көрпәгрәк була дип ишеткәнем бар. Боз да үтә күренүчән, имеш. Шундыйрак җирне эзләп карыйк мәллә соң?

– Юлның сул ягыннан башлыйк алайса, – дип, Лепсей, тирән карга кермичә генә, беренче эш итеп чанага бәйләнгән көрәкне чишеп алды. Аннан, картлар, бер читкәрәк китеп, тездән каты кар көртләрен изә-изә, көрәк белән бозны чокыдылар һәм: «Шул урыннан карап карыйк» дигән фикергә килделәр. Ньукуус та алар тишәсе бәке урынын чистартырга булышты. Охоносой бияләйләрен салып, боз өстенә ташлады, кулына сөймәнне алды, аны агач футлярыннан салдырды, баш бармагын тидереп, үткенлеген тикшереп карады, учларын төкерекләп, аны зәңгәрсу бозга кадады. Яшенә карата сүлпәнлеге сизелсә дә, сөймән белән оста эш итүе күренеп тора иде. Ул шул арада бер сөям тирәнлегендәге, кисмәк зурлыгы чокырны казып та ташлады. Тик озак эшли алмады, тыны кысылганга, сөймәнен кулдашына тапшырды. Бу мәлдә Ньукуус ватык боз кисәкләрен көри иде. Аңардан эш коралы Лепсейга күчте. Алар шулай өчәүләшеп бәкене шактый тирәнәйттеләр. Тирәнәйгән саен бозны ватуы кыенлаша барды, Ньукуус арыды.

Бер-берсен алыштырып, бозны көрәп, өскә чыгардылар. Ниһаять, боз чокыры төбендә дым пәйда булды. Охоносой шулчак курткасын салып боз өстенә ташлады да күлмәкчән калып, бар көчен туплап, сөймәнне бәке төбенә кадады. Тик тишектән су урынына, саркылып, пычрак ләм агып чыкты.

– Абау! Монда бөтенләй су юк икән бит! – дип әйтеп салды ул.

Лепсей да бәкегә күз ташлады, аның да кәефе кырылды:

– Их!.. Димәк, күл шактый саеккан, – дип уфтанды.

Алар, тирәли тезелешеп, озаклап, бәке төбенә текәлеп тордылар. Ньукуус, картлар тишеп бетергәч тә, сак төшерәсе дә балыкларны сөзеп аласы гына кала, дип уйлаган иде, ләмне күргәч, гарьлектән күзләренә яшь эленде. Озак сүзсезлектән соң, Охоносой:

– Инде нишлисе?.. Су кимегән икән, без дә күлгә яраклашыйк, балык качкан якны карыйк, бәлки бераз эләгер дә, – дип куйды.

– Тик аның кай тирәдә кышлавын белмибез бит, – дип авыр сулады Лепсей.

Беренче бәке еракта калды. Алар башка җиргә тукталып, тагын кар ата, боздан чистарта башладылар. Әйтеп бетергесез арыдылар. Эш тә акрын барды. Бәкене көчкә тиштеләр. Тик монысыннан да сары күбекле су гына саркылды. Бер-берсен алмаштыра-алмаштыра картлар бәке төбен киңәйтте. Ньукуус тишекле соскыч белән бозларны җыеп, читкә ташлап торды. Аның да көче төкәнде, куллары гүя камчы бавына әйләнде, бозлы соскы белән селтәнүгә үзе дә шул якка очып төшә язды. Бик озак азапланганнан соң сак-куйурны бәкегә батырырга мөмкинлек туды. Охоносой агач сак-куйурны яссы такта кисәгеннән ясалган терәкнең тишегенә кертте һәм җайланманы боз астына төшерде дә әйләндерә башлады.

– Әй, монсында да бик сай булып чыкты бит әле, сак бәке төбен кырып торуын беләә, – дип куйды.

– Тагын юкка интеккәнбез, димәк, – дип сөйләнде Лепсей.

Охоносой әйләндереп, бәке төбеннән эш коралын тартып чыгарды. Аңа пычрак ләм ябышкан иде. Моны күреп, барысының да кәефе кырылды. Чанага утырган көенчә, картлар, сүзсез генә тәмәке көйрәтте. Ньукуус исә сөймәнгә таянып басып торуын белде. Аның ачлыктан эче бьгырдый, башы әйләнә, тәмәке төтене исеннән косасы килә иде. Ул җебегәнлеген күрсәтмәс өчен картларга арты белән борылып басты һәм күлнең күзләрне камаштырырлык аклыгына төбәлеп торды. Көн уртасы булгангамы, язгы кояш бит алмаларын җылытты.

– Ньукуус, оныгым, кил әле монда, утыр әле яныма! – Охоносой янә курткасын салып, бәкедән турап чыгарылган боз өеме өстенә ташлады. – Әйдә, ял итик тә тагын чокып карарбыз.

Малай янына килеп утыргач та, карт тагын сүз башлап карады:

– Хәзер инде бәке урынын Ньукуус сайласын. Малай кешегә Күкләр ярдәм итми калмас... Балыклы җирне ул тапса гына...

Липсей шатланды.

– Чынлап та, без икебез дә оттырдык. Хәзер син урын сайла, улым, – дип, башлыгын төзәтә төшеп киде.

Ньукуусның йөрәге какты, битләре янды. Ул гомеренең иң мөһим сәгате сукканлыгын чамалагандай булды. Күз алдында, яулыгын бәйли-бәйли, әнисенең текәлеп карап торуы, сеңлесенең өйдә калырга күндерергә тырышкан чагы чалымлангандай тоелды. Гүя Анысканың борчу тулы күзләре белән очрашты һәм нигәдер ашыга-ашыга, яу кырына җыенган этисен хәтерләде...

Алар сүзсез шактый озак утырдылар. Ньукуус йөзенә чыгармыйча гына картларның: «Кузгалыйк мәллә соң?» дигәнен көтте. Аннан үзе дә шулай озак хәрәкәтсез утыруларына борчыла башлады. Тәвәккәллекләре җитмәгәнгә газапланып бетте. Ниһаять, Охоносой:

– Торыйк, җәмәгать! – дип куйды.

Көтелгән хәбәр булса да, ул Ньукуусны сискәндерде, малай бар көчен туплап, урыныннан кузгалырга тырышты, тик аяклары гүя мамыкка әверелгән иде. Янәшәсендәге бозга кадалган сөймәнне терәк итәргә теләп, аңа ябышты һәм егылып китте.

– Аһ, балакаемның аяклары өшегән түгелме?!

Лепсей карт култык астыннан күтәреп торгызып бастыргач та, малай тирән кар көртенә ава язды, аксаклый-чатанлый алга атлады. Ньукуус кинәт туктап хәл алмакчы булды, шулчак артына борылып карады, һәм үзенең берничә генә адым атлаганын күреп гаҗәпкә калды.

Картлар аның эзе буйлап килә, Охоносой сөймәнне иңенә салган, Лепсей исә сыңар кулына тишекле соскы тоткан көенчә, чана сөйри иде. Тагын бераз титаклагач, Ньукуус туктап калды. «Менә шушында!» – диде ул һәм хәлсез аяклары белән карны көрәргә тотынды. Картлар да аның белән тигезләште, алар тын алырга курыккандай басып тордылар. Тирән итеп сулыш алдылар да шунда ук күрсәтелгән урынны чистартырга керештеләр. Охоносой янә курткасын салып ташлап, кулына сөймәнне алды.

Алар чиратлашып, шактый тирән бәке казыдылар, аны боздан арындырдылар. Эштән чыгып беттеләр. Ньукуус чокыр кырыена чүгәләде, ул тәмам йончыган, аяклары да, куллары да калтырый иде.

– Оныккаем, кил әле яныма, болай утырсаң, аякларың шешенер, – диде Охоносой, курткасын җәеп, малайга урын әзерләгәндә. Ньукуус авырлык белән күчеп утырды, гүя аяклары итегенә өрелеп тулган иде. Кояш нурлары иркәли-иркәли, аның аркасын җылытты. Малайның гел шулай, тагын да берни эшләмичә, тыныч кына утырасы килде. Тик күз алдында кәгазь кебек ак йөзле сеңлесе Анысканың сурәте пәйда булуга, кинәт айнып китте. Картлар да йокымсырап утыра иде. Ньукуус, чайкала төшеп, вак боз кисәген эләктереп авызына капты. Тамак төбен суык өтеп алгач, чарасыздан йөткерә башлады.

Йокымсыраган Охоносой башын күтәрде:

– Болай ярамас, бөтенләй йокыга оюыбыз ихтимал. Лепсей, әйдә, торыйк та тикшереп карыйк әле без, – диде. Ул тезләренә таянып алга талпынды, өченче талпыныштан соң гына көчкә торып басты.

Кулындагы сөймән әкрен генә боз тишә башлады. Алар янә чиратлашып эшләделәр. Инде көчләре бетеп, хәлләре киткәндә, бәке саргылт су белән тулды. Шуннан алар озаклап һәм бик авырлык белән бәкене киңәйттеләр. Ньукуус, гадәттәгечә, бозны көрәп торды.

Соңгы мәртәбә боз кисәкчекләрен җыеп, печән эскертедәй олы өемгә ташлаганда, туң ярмалар арасыннан чәнти бармак зурлыгындагы ит кисәге чалымланды.

– Балык! Балык! – дип сөрән салды малай һәм соскысын ташлап, аны эләктереп тә алды.

– Чынлапмы?! Тукта, дәшми тор! – Охоносой Липсей сузган ятьмә таягын агач пластинкага беркетте.

Куйур суга күмелгәч тә пластинка бәкегә аркылы ятты, аның озын башы картның сул аягы астына туры килде, балык тоту җайланмасы исә кулында әйләнеп торды.

Ниһаять, шактый көч куеп әйләндергәч, һәм боз астындагы суны болгатып бетергәч, Охоносой егермеләп зәңгелә, бер кәрәкә эләккән ятьмәне тартып чыгарды.

Беренче табышны кар өстенә сибеп җибәрде дә ятьмәне янә бәкегә

төшерде. Ньукуус балыкларны җыйды, Лепсей чанага бәйләнгән капчыкны чишеп алып килде, аның авызын тотып торды.

Охоносой бу юлы сак-куйурны үз күчәре тирәсендә озаграк әйләндерде, шуңа карамастан, табыш азрак эләкте. Алар куйурны Лепсей белән алмаша-алмаша әйләндерсәләр дә, тоткан балыклары зәңгелә һәм биш кәрәкәдән артмады, ә болар кечкенә коштабакка да сыешлы иде. Шулай да инде өмет уянды, кайдадыр якында гына балык күче үрчеп ятадыр кебек тоелды. Тик тагын бер бәке тишәрлек мөмкинлекләре юк иде инде. Әйе, бик әз эләкте, соңыннан сак бөтенләй буш чыкты. Ачлыктан эчләре бызырдады, куйур торган саен әкренрәк әйләнде. Алар, бүгенгә туктап, үзләре белән алып килгән бөтен әйберләрен шунда калдырып, иртәгә яңа көч белән эшне дәвам итәргә карар кылдылар. Балыклы капчыкларын күтәреп кайтыр юлга кузгалдылар. Ньукуус, монысына да өйдәге балалар бик шатланачак, дип уйлады, шунлыктан картларның алдына чыгып, тизрәк атларга тырышты.

Хәлсез аякларын көчкә сөйрәделәр.

Балаганга кергәч тә барча күзләр аларга төбәлде. Хатын-кызлар тиз сизенде: балыкчылар тикмәгә интегеп йөргән, шуңа алар карашларын идәнгә кадап, үз эшләрен дәвам итүне мәгъкуль күрделәр.

Охоносой сүзсез генә чишенде, уң яктагы чиләкне алып, шуңа балыклы капчыкны әйләндереп салды. Чиләк янына балалар йөгерешеп килде, Олена түти исә, күз ачып йомганчы мич артына кереп югалды.

Чәй эчкәндә, Тулламыккы картка, балыкчылар, берничә бәке тишүләре, беренче һәм икенчесенең уңышсыз булуы, өченчесеннән генә бераз эләгүе турында сөйләделәр. Картлар сөйләшкәнгә колак сала-сала, хатын-кызлар мичкә ут тергезде, әңгәмәне куертып, чуенда балык пешерәсе иттеләр.

Балаган эченә акылны чуалтырлык пешкән балык исе таралды. Мондый тәмле ис ач кешенең хәлен тагын да катлауландырырга сәләтле икән. Истән Ньукууcның башы әйләнде, укшыды, туктаусыз эче быгырдады, үтереп ашыйсы килгәнгәме, авыз кырыеннан селәгәе агып төште.

Арык тәнле балалар да шул халәттә иде. Алар күзләрен алмыйча, өчаякка эленгән, учакта кайнап торган чуенны күзләде. Балык пешкән арада хатыннар балаларны сыек ботка белән сыйладылар да катгый рәвештә йокларга яткырдылар. Ньукуус олыларның бу кыланмышын һич аңлый алмый азапланды. Ике яшь ярымлык Банника да:

– Ә без балык асыйбызмы? – дип сорап куйды.

Әнисе, еларга җитешеп:

– Юк, балакаем, сез балык ашамыйсыз... Тотып кайтучылар ашасын аны, – диде дә кызны күтәреп ятагына илтеп салды.

Бу сүзләр Ньукуусны исәңгерәтеп җибәргәндәй тоелды, ул сеңлесенең зур итеп ачылган күзләрен күреп имәнеп китте, кызганудан үзенең дә яшьләре тәгәрәп төште. Ул арада хатын-кызлар балыкларны өч савытка бүлеп салды, кашыклар да куйдылар. Ньукуус һәм ике карт кымшанырга курыккандай, хәрәкәтсез утыра бирде. Балаганда эч пошыргыч тынлык хөкем сөрде. Тынлыкны Иринаның чыелдык тавышы бозды:

– Охоносой, Лепсей, Ньукуус... Бу балыкны бөтенебезгә бүлсәк, беребез дә туймаячакбыз, ашказанын котырту гына булыр. Әгәр дә сез ашап куеп,

бераз хәл җыйсагыз, бәлки иртәгә балык күченә туры килерсез... Бөтен өметебез сездә бит...

Шуннан соң хатын-кызлар балаган дивары буенча тезелгән ятакларына таралышты, ә Тулламыккы карт толыбын эләктереп, ишегалдына чыгып китте.

Охоносой һәм Лепсей бер-берсенә карашып алды, аннан балаларга артлары белән борылып, әкрен генә өстәл янына елыштылар. Ньукуус кымшанырга куркып, кадаклангандай басып торды. Әнисе аның беләгеннән эләктерде дә өстерәп диярлек өстәл янына китерде. Малай көчсез кулларын тезләренә куеп, Охоносой ирексезләп, кулына кашык тоттырганчы, дәшмичә генә балыклы тәлинкәсенә төбәлеп утырды. Аннан соң, карт, як-ягына каранып:

– Аша, синең көч туплавың кирәк безгә, – диде.

Ньукууска нигәдер, аяк-куллары богауланган шикелле тоелды. Шуны сизепме, әнисе янә улы янына килде, аны иңнәреннән кочып:

– Ньукуус, аша, улым... Аныска һәм минем хакка...

Малай шуннан соң гына кашыгына үрелде. Тәлинкәсен ялт иттерде, күзләрен яшь каплагангамы, бер тәмен дә тоймады, исерек кешедәй чайкалып, үкси-үкси ятагына килеп ауды.

...Ач балалардан һәм хатын-кызлардан качарга теләгәндәй, сүзсез генә, алар, иртә таңнан күлгә юнәлделәр. Кичәге бәкедән ераккарак юл салдылар. Чынлап та өчесенә дә бераз хәл кергән иде.

Яңа бәкедән бу юлы су бик тиз бәреп чыкты. Охоносой учларын төкереклэп, бар көченә бозны ваклый башлады һәм тишектән шаулап су күтәрелде. Шул арада өч-дүрт кәрәкәнең алтынсу корсагы ялтырап китте.

Лепсей кулына соскыч тоткан көенчә:

– И сөекле анакаем! – дип кычкырып җибәрде дә йөзтүбән ауды. Ә Ньукуус бәкедәге кәрәкәләрнең карасу сыртларына төбәлеп торды, шулчак авызында тоз тәме тойганда, нигә гел елыйсы килгәнен аңлагандай булды.

***

Икенче көнне Ньукуус түбәдән асылынып төшкән боздан тып-тып тамган бәллүр тамчыларга учларын куйды һәм ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Әтием, безнең хәлләр яхшы... Ә син анда дошманнарны катырак кыйна, яме! – дип пышылдады.

**Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА** *тәрҗемәсе.*

# ИҖАТЫ – МИЛЛӘТНЕҢ ЙӨЗ АКЛЫГЫ

## АЙРАТ СУФИЯНОВ ЛИРИКАСЫНА БЕР КАРАШ

Айрат Суфиянов иҗаты белән танышлыгым дүрт-биш ел элек интернет аша башланды. Әсәрләренең интернетка чыгарылган кадәресе белән танышып кына да мин аның көчле лирик булуын тоемладым, ике арадагы фикер-хисләр уртаклыгын тойдым. Шагыйрьнең «Кылычлы җил» (2006), «Таң калып багам таңнарга» (2022) китаплары, 2020 елгы әдәби альманахта, төрле матбугат басмаларында дөнья күргән әсәрләре белән танышкач, аның татар әдәбиятын бизәп торучы шагыйрь булганлыгына ныклап инандым.

Айрат Суфиянов Чаллы каласында яшәп иҗат итә. Бүгенге көндә ул – татар әдәбиятында танылган һәм зур урын тоткан каләм иясе. Аның иҗаты хакында А.Хәлим, Ф.Бәйрәмова, Ә.Ситдыйкова, Д.Заһидуллина, С.Якупова, Р.Рахман, Л.Гыйбадуллина кебек мөхтәрәм әдипләрнең һәм тәнкыйтьчеләрнең уңай һәм җылы фикерләре бар.

Мин үзем теге яки бу әдип иҗатына бәя биргәндә, «ул беркемне дә кабатламый» дигән сүзләргә сак карыйм. Бернәрсә дә буш урында тумый. Һәр әдип традицияләрдән файдалана, аның иҗатында гасырлардан килгән тотрыклы үзгәрешсез әхлакый кыйммәтләр, образлы фикерләү алымнары урын ала. Монда иң мөһиме – аларга авторның иҗади якын килүе. Айрат Суфиянов та уй-теләкләрен, фикерләрен гомуми әдәбиятта кулланылган алымнар, шәкелләр белән яңгырата. Лексик, стилистик чаралар; троплар – шагыйрь боларның һәрберсеннән кичерешләренең табигатенә, иҗади ниятенә, фикеренең асылына ярашлы рәвештә файдалана. Шул ук вакытта аның үзенә генә хас метафоралары, чагыштырулары, эпитетлары, сөйләм конструкциясе, строфика, ритм, рифма тудыру чаралары бар. Жанрлар мәсьәләсендә Айрат Суфиянов лирикасын тәгаен генә ачыклау катлаулы. Чөнки кайчандыр классик саналган жанрлар үзгәреш кичерә, синкретик табигатькә күчә баралар. Монда шагыйрь иҗатында Көнчыгыш һәм гомумтөрки поэзиянең мәдхия, кыйтга, хикмәтле сүз, фәрд кебек поэтик жанрларына тартым әсәрләр бар дип чикләнергә туры килә. Автор үзе өч дистәгә якын әсәрләренең жанрын робагый дип күрсәтә. Фәлсәфи әсәрләрен Аурупа әдәбиятындагы элегия (сагышлы шигырь) дип аталган жанр кысаларында карарга була.

Әдәбият фәнендә поэтика төренең пейзаж, гражданлык, сәяси, фәлсәфи күңел лирикасы кебек жанрлары күрсәтелә. Без исә бу төшенчәләрне тема, проблема, пафос, мотив мәгънәләрендә дә кулланырга булдык. Әлбәттә, әдип иҗатын болай бүлгәләү шартлы (максаты: шагыйрьнең идея-эстетик эзләнүләре хакындагы фикерләрне гомумиләштерү). Чөнки бер үк әсәрдә берничә теманың, мотивларның урын алуы, аларның бер-берсенә керешеп китүе, берсе нигезендә икенчесе туу күренә. Күптөрле мәсьәләләр бергә төйнәлә, укмаша. Аларны бер-берсеннән аеру да кыен. Бу әдәби иҗат процессына, аеруча поэзия өлкәсенә хас күренеш.

Айрат Суфиянов лирикасы – идея-тематик (мотив, пафос) җәһәттән караганда, бай әдәби дөнья. Аның әсәрләрендә күптөрле проблемалар күтәрелә. Шулай да шагыйрь иҗатында гражданлык һәм сәяси мотивлар аеруча киң яңгыраш ала. Шушы фикер уңаеннан, Гаяз Исхакыйның «Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте

илә» мәкаләсе искә төшә. Бөек әдип шагыйрьләрне «шәхси кабилиятләренә, иҗади фикерләү үзенчәлекләренә, җәмгыять белән мөнәсәбәтләренә карап», икегә бүлә. Ул болай дип яза: «Беренчесе – индивидуалист табигатьле, шәхси уй-кичерешләрен генә үзәккә куючы бәйләнмиләл шигырьләр тудыручы авторлар. Икенчеләре исә – үзләрен тирә-юньнең, мохитнең бер өлеше хис итеп, шуның бөтен күңел алышуларына үзенең йөрәк тибүе белән катнашып, үзенең шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь яратучылардыр». Икенче төркемгә ул Габдулла Тукайны кертә. Г.Исхакый, безнең чорда яшәсә, Тукай рухын дәвам итүчеләр рәтенә Айрат Суфияновны да өстәр иде.

Айрат Суфиянов каләмен яшүсмер чактан ук тибрәтә. Әдәби иҗат белән ныклап ул яңа гасыр башында шөгыльләнә башлый. Бу чор татар дөньясында милли уяну, кузгалу нәтиҗәсендә беркадәр хокукларга ирешүдән соң, аларны сакларга тырышу еллары булып тора. Тарихи-сәяси вазгыять моның мөһим икәнлеген сиздерә башлаган иде инде. Милләтне үзаңга һәрдаим очкын өстәп торсаң гына яшәтеп була. Моны аңлаган һәр каләм иясе милләтне рухи яктан ныгытуга үз өлешен кертергә тырышты. Сәяси аңы һәм тарихи тоемы көчле А.Суфиянов та шушы сафта атлады.

Ни кызганыч, хокуклар таләп иткән заман узды. Заман гына түгел, кешеләр дә бик нык үзгәрде. Милли яссылыкта янәдән ирешелгәннәрдән чигенү, өметләрнең тормышка ашмавыннан ачыну, чарасызлыктан бәргәләнү дәвере килде. Айрат Суфиянов әсәрләре менә шушы яңа шартларда халыкка рухи көч булып яңгырый башлады. Ул бу вазифаны максатчан дәвам итә. Лирикасының гади кешегә хөрмәт, әхлакый сафлык белән сугарылган булуы, лирик геройның, башкаларның кайгы-хәсрәтләрен аңлап, үзен шулар урынына куеп каравы (эмпатия сыйфаты) белән дә күпләрне үзенә тарта.

Айрат Суфиянов – үз-үзенә югары таләпләр куйган шәхес. Милләтпәрвәр һәм гуманистик табигатьле шагыйрь башкаларда да шушы сыйфатларны күрергә тели. Автор буларак, битараф, гамьсез җаннарга гаепләү авазы ташлый. Ничек инде күрәләтә кешелеккә чиксез бәла-каза китергән явызлыкны яклап була? Күпчелек кешеләр үзләре кебек үк бәхетле, тыныч яшәргә теләгәннәрнең бүгенге хәсрәтенә нигә битараф соң? Кешене ак белән караны аермый, хакыйкатьне аңламый торган дәрәҗәгә кем җиткерә? Татар кешесе, иң беренче чиратта, үз илен, үз телен кайгыртырга тиеш ләбаса. Ә ул күбрәк читләрнең, алай гына да түгел, аларның үзебезгә үк дошмани булганнарның мәнфәгатьләрен кайгырта. Нигә югалуга таба адымнар ясалганны, күренеп торган милли фаҗигане сизми, яисә аны «безгә шулай язгандыр инде» дип кабул итә? Адәм баласына, дөньяга мәңгегә килгән кебек кыланып, кирәкмәгән кыйммәтләр артыннан чабу, комсызланып байлык артыннан куу нигә кирәк? «Өстә торам» дип, үзен әллә кемгә санап, Аллаһы Тәгаләдән узып тәкәбберләнгән кемсәләр «җәзасын алмабыз» дип өметләнәләрме? Шагыйрьнең менә шушы күренешләргә, иҗтимагый психологиягә йөрәге әрни. Чынбарлыкның бөтенлеге бозылудан бәргәләнгән лирик герое болар арасында үзен ялгыз хис итә.

Айрат Суфиянов әсәрләренә мөнәсәбәттә ара-тирә «авторның тәнкыйди уй-хисләре хәрәкәткә, ягъни алгарышка юл күрсәтү дәрәҗәсенә күчә алмый, лирик геройда укучы күрергә теләгән көч-куәт сизелми, күңел төшенкелеге дә еш яңгырый» дигән фикерләр ишетелеп ала. Алар өлешчә хаклыдыр да. Әмма әлеге рухи халәтнең илдәге шартлар белән бәйле икәнлеге, бүгенгенең сәяси кайтавазы икәнлеге аңлашылып тора бит. Мондый төшенкелек мотивлары кара реакция елларында Тукай, Дәрдемәнд, Гафури кебек шагыйрьләрнең иҗатында да урын алган. Укучы буларак, минем үземә шунысы әһәмиятле: аның хисләрендә ясалмалылык, халык язмышын кайгырткан булып кылану, үзен «кәттә» шагыйрь итеп танытырга теләү юк. Уй-тойгылар ихластан түгелә. Лирик геройның аһ-зарлары, әрнү-бәргәләнүләре... Алар – намуслы һәм вөҗданлы йөрәкнең сулкылдавы.

Айрат Суфиянов – реалист шагыйрь. Шул ук вакытта ул үзе күрергә теләгән идеалга да омтыла. Әмма чынбарлык үтә кырыс. Идеал һәм чынбарлык бәрелешеннән үтә оптимистларның да романтик хисләре вакыт-вакыт юкка чыга. Минем уйлавымча, хәтта шагыйрьнең хис-тойгылары, алар идеалга омтылыш кына булып яңгыраган очракта да, бик зур әхлакый иҗтимагый кыйммәт булып торалар. Намуслы, вөҗданлы кешеләр, гәрчә бүгенге көндә азчылыкны тәшкил итсәләр дә, үзләренең ялгыз булмавын тоялар. Халыкның милләт буларак яшәеше, җәмгыятьнең әхлакый сафлыгы, гаделлеге өчен сүз куәте белән көрәшүче шагыйрь иҗатыннан юаныч алалар.

Алда искәртелгәнчә, Айрат Суфиянов лирикасында гражданлык һәм сәяси мотивлар зур урын алып тора.

«Җавап көтеп» шигыре – шул рухтагы күпсанлы әсәрләрнең берсе. Автор без яшәгән заманның иҗтимагый-психологик сурәтен тасвирлый. Шигырьнең һәр тезмәсендә заман чынбарлыгына бәя биргән, тирән фикерләрне, мәгънәләрне сыйдырган үткен метафоралар урын алган. Сөйләм тизлеге, темпоритм югары. Автор әсәрен строфаларга аерып торуны да кирәк дип тапмый сыман. Ярсу хисләрен, уй-тойгыларын бер-бер артлы тезә генә. Тирә-юнебездә «буынсызлык чире йокканнар», «бөркәнчекле монафыйклар», үзләре «кылкойрыклылар», «эчтән шашып, тышка ташмый гына, уңай мохит көтеп ятканнар», «койрык болгый-болгый яраша» белгән аумакайлар артканнан-арта бара. Заманның хаосы антитеза алымы белән көчәйтелә:

*Асты-өскә килгән замананың*
*Түбәнлеге бүген биектә.*

Кайберәүләр дәүләт башлыгына «каты кул» кирәк, диләр. Ил тарихында булган хәлләрдән мәгълүматлы автор катгый фикерен яңгырата: мондый каты кул ул – тиран. Ил белән тиран идарә итә икән, иң беренче чиратта, баш имәгәннәр, гөнаһсызлар терәп атыла. Тәхет тирәсен барыбер шул ук аумакайлар, ялагайлар чорнап ала. Дөрес, заман узгач, бу тиранның гамәлләре тәнкыйтьләнә башлый. Әмма «дөреслек ыштанын кигәнче, ялган ярты дөньяны урап кайта» дигән гыйбарә бар. Зирәк укучы авторның нәкъ менә шушы фикергә этәрүен чамалый. Бу әсәре белән автор дистә еллар дәвамында халык дошманы исемлегендә йөргән, күпләре атылган, еллар үткәч акланган М.Солтангалиев, Г.Ибраһимов, Г.Алпаров, Ш.Усманов, Г.Рәхимов, Г.Гобәйдуллин, Х.Туфан кебек милләтнең асыл затларының һәм миллионнарча корбаннарның язмышларын искә төшерә.

Автор риторик сорау белән мөрәҗәгать итә:

*Табигый юл үсешеннән кеше*
*Йөз чөерә икән никләргә?*
*Сорау юллап, дөньялыкка багам,*
*Җавап көтеп карыйм күкләргә...*

(Ахыргы юл Айрат Суфияновның үзенчәлекле фәлсәфәсенә игътибар сорый. Бу хакта сүз соңрак кузгатылыр).

«Заман – көзге» әсәрендә дә заманның сурәте урын алган. Автор аны риторик сорау алымы белән башлый да аннан «вакыт холкы» тасвирына күчә. Әлегә холыкка бәя афористик символик яңгырашта бирелә:

*Кем аңлаган серле вакыт холкын*
*Элек гөл булганны көл итә.*
*Көл булганны олы бәһа биреп,*
*Чыгы тамып торган гөл итә*

*Орлыкларын барлап кибәгеннән*
*Аерып ул җилдә җилгәрә.*

Лирик геройга вакытның менә шундый гаделлеге кирәк. Ләкин, ни кызганыч, вакыт ашыкмый. Заман үз эшен эшли тора. Адәм баласы бинахакка хөкем ителә. Ләкин аның бәхетсезлегендә һич тә заман гаепле түгел. «Адәми зат боза чынбарлыкны». Бу фикер градация алымы белән яңгырый: «тыелганга кулны суза-суза» җирдә гөнаһ кылганыннан, гамәленнән шулай «төссезләнә, хиссезләнә заман, салкынлана, көйсезләнә заман».

«Чәчәк чәчәккә тиңләнер» лирик парчасында да хиснең сәбәбе – бүгенге яшәештә гаделлек юклыкка әрнү. Бу әсәр нибары дүртьюллы ике строфадан тора. Аның беренчесендә хис сәбәбе, икенчесендә юану яңгыраш алган. Күләме ягыннан бик җыйнак булса да, фикер янәшәлек һәм метафора алымнары белән катгый өздереп әйтелә:

*Һәркемгә дә үз бәһасен*
*Бирәчәк әле күкләр.*
*Чәчәк чәчәккә тиңләшер,*
*Йолкып ташланыр чүпләр.*

«Кем аера?» әсәренең эчтәлеген киләчәк өчен борчылу хисе тәшкил итә. Әлеге хиснең сәбәбе – кешенең көннән-көн ныграк колга әверелә баруы. Әсәрнең башына автор эпиграф куя. Кешегә тиң күке образы әхлакый-сәяси эчтәлекле әсәргә фәлсәфи аһәң өсти:

*«Дөнья гомере озынмы?»*
*«Өч көн» дип тынды күке.*

Төп текст ике өлешкә бүленгән. Беренче өлештә автор кешенең ни өчен кол хәленә төшүе хакында уйлана. Шагыйрь фикеренчә, кара көчләрнең кешене колга төшерүендә һәм аны кол итеп файдалануында, изүендә төп корал – ул мәкерле ялган. Кешенең аңын томалап, явыз көчләр аны җинаятькә тарталар. Әлеге фикерләр «акылың ауланылса» дигән казык сүз белән гомумиләштерелә:

*Кемдер синең куллар белән*
*Әгәр, җинаять кылса,*
*Каршылыксыз, кол булырсың,*
*Кагылырсың, сугылырсың,*
*Акылың ауланылса...*

Явызлык идарә иткән шартларда «акылың ауланмасын» өчен таяныч, кыйбла, маяк кирәк. Кешенең кыйбласын дөресләп, вөҗдан-намус сагында торучы көч – ул иман. Соңгы юлларда антитеза алымы кулланылган. Автор монда төсләр каршылыгына нигезләнгән метафорик сурәтләр белән эш итә. Ак кар – сафлык, кара күләгә – ялган символы:

*Ак кардагы күләгәмне*
*Куалыйм... яланаяк...*

«Чор һәм без» әсәрендә лирик геройның күңел кылы «хәвеф гимнын, кайгы көен уйный». Кеше гомеренең очсызлануында, адәм балаларының бер-берсенә карата ерткычлыгында бәндә үзе гаепле, чор түгел.

*Без саташсак, чор саташа.*
*Без ут ачсак, чор ут ача.*
*Ялганласак, ул ялганлый.*
*Яманласак, ул ялганлый.*

Бәндә – табигатькә мөнәсәбәттә аеруча үтә ерткыч, җимерүче корткыч. Ул, аның гармониясен бозып, тереклекне, матурлыкны юкка чыгара. Авторның җан авазы, фикерләренең катгыйлыгы синтаксик корылышта, һәр тезмәдә сигезле үлчәм белән

өзек-өзек итеп яңгыратуда, янәшәлек алымы белән бирелгән метафорик сурәтләрдә сизелә:

*Канатлары хәлсезләнсә, очып барган күбәләкнең, / Тын алышы авырлаша, / Кайдадыр саф күзәнәкнең; «Кызыл шәүлә чык күзендә. / Ыңгырашып күк йөзендә / Канга батып кояш чыкты...*

Соңгы строфада «төнбоек» сурәте әсәрнең эстетик тәэсирен тагын да көчәйтә:

*Без боектык, көн боекты.*
*Хәтерләтмик таңсыз калган,*
*Яшькә чәчәп сулыш алган*
*Ачылмаган төнбоекны.*

Шагыйрь даими рәвештә тагын бер зур хәсрәтен яңгыратып тора. Ул да булса – авылларның бер-бер артлы юкка чыгуы. Әлеге проблема бик күп әсәрләрдә урын алган. Бу хәсрәт тә гражданлык һәм сәяси мотивлар белән өретелгән. Шул ук вакытта алар күңел лирикасының күркәм үрнәкләре булып тора.

«Яшәргә нечекләр?» шигыре тирән сагыш хисе белән сугарылган. Бу әсәрдә бетә барган авыл сурәте гәүдәләнә. «Гөр килеп яшәгән болынлы», «болында колынлы» авыллар өстеннән «гасыр давылы узган», «Вакыт агышы туктаган, урамнар кешесез шомланып тын калган», «хуҗасыз йортларда йозаклы ишекләр», авыл кешеләре «төп йортка җыелганнар». «Тотрыксыз ил-көндә үлем дә яшәрә»: зиратларда картлар кебек үк яшьләр дә күп ята.

Лирик герой бу хәлләрдә үзен дә гаепле саный:

*Бәхетемнең тамырларын өзеп*
*Киткәнемә соңрак төшендем.*

Ул үз-үзенә ачынып сорау бирә: «Мин гомер буена үкенү колымы?» «Гомер буена» казык сүзе лирик геройның кичерешләренә хас булган даими сызлануны ассызыклый.

«Офыклар артында авылның иң соңгы колыны» сурәте әсәрнең башында бирелеп, ахырында кабатлана. Бу сурәт беренчесендә номиналь эчтәлекле сыман булса, икенчесендә, символик метафорик яңгыраш алып, фокуска әверелә.

«Сагындым» – шагыйрьнең күңел лирикасын тәшкил иткән күркәм парчаларның берсе. Әсәрдә күңел лирикасына хас шәхси мәгълүматлар (әткәсенең үлеме, газиз әнкәсенең озак чирләп ятып, вафат булуы, абыйсының, энесенең җир йөзеннән иртә китүе) урын алган. Бу әсәрне шагыйрь якыннарын җирсеп язган. Лирик геройның туган җиргә чиксез мәхәббәтен, аның дәрәҗәсен билгеләгән үзенчәлекле сурәтләр күзәнәкләргә үтеп керә, күңелдәге иң нечкә кылларны тибрәтә. Метафораларга, һәр сүзгә мәгънә тыгызлыгы хас.

*Сагындырды; җәй энәсе теккән*
*Күлмәгем дә вакыт урлаган.*
*Урлаган да, мине һич төкәнмәс*
*Югалтулар белән «зурлаган».*

«Бер йотым су», «Хат» әсәрләре күңел лирикасы жанрында иҗат ителгән.

Аларда да лирик геройның шәхси тормышы, язмышы белән бәйле хис-кичерешләре урын алган. «Хат» әсәренә сюжет элементы кертелгән. Лирик герой утыз биш ел элек әнисе язган хатны таба. Шушы хәл хиснең үкенечтән торган эчтәлегенә сәбәп була. Лирик герой әнисе исән чакта аңа хатларны сирәк язган. Хис дәрәҗәсе экспрессив сүзләр ярдәмендә көчәйтелә бара: Тынга ялкын капты / Яңакларым буйлап кайнар яшем акты / Йөрәк дөп-дөп какты. Алты үлчәмле вәзен, хисләрне өзек-өзек итеп яңгыратып, йөрәге үксеп елаган лирик геройны күз алдына бастыра. «Бүген җавап язсам, Кем тапшырыр аны?» Үкенеч тәүбәгә ашыктыра. Лирик герой бары шуның белән юана.

«Бер йотым су» – югары лирика өлгесе булып саналырга хаклы әсәр. Лирик герой

хыялында туган ягына, туганнары янына кайта. Хыял көче аның күңелендә балкыш уйнатып ала:

*Хис-тойгылар өчен туган якта*
*Җим табыла, им-том табыла.*

Шагыйрь җанына үткәндәге иң бәхетле ямьле көннәр ургып керә: тургай моңы сеңгән тугай, шул тугайда яңгыраган балачакның шат авазы, былбыл булып, өзеп сайрый-сайрый тәрәзәдән кергән бакча, тере этисе, кочаклап каршы алган әнисе, туып үскән йорт, өстәл өстендә шат очкыннар чыгарып утырган кайнар самовар, ишегалды, анда ханбикәләр кебек җырлап йөргән унбиш тавык... Әлеге үтә гади сурәтләр авыл табигатендә үскән һәр укучыга якын, кадерле, изге. Һәр сүз зәвыклы, төгәл, акыл белән сайланган. Авыл – шагыйрь күңеле өчен мәңге бетми торган рухи көч, илһам чыганагы. Ул шуннан йотымлап, илһам суы эчә.

*Әйтерсең лә бик сусаган чакта,*
*Бер йотым су эчтем йотлыгып.*
*Кысыр куанычым – сакау күке*
*Күк-к-к, күк-к-к килеп торды тотлыгып.*

Сакау күке образы әсәрнең драматик аһәңен тирәнәйтә. Чөнки лирик геройның бәхетле халәте бары хыялда гына.

Айрат Суфиянов шигъриятендә пейзаж лирикасының да үтә матур өлгеләре бар. Әлеге әсәрләр нәфислекне тоярга, күрергә өндиләр. «Язны котлап» әсәрендә табигатькә гаять игътибарлы лирик герой образы тереклекнең һәр күзәнәген тоя. Шигырь тукымасында урын алган сынландырулар җылы, ягымлы хисләр белән өретелгән: «Яшен күзле җилләр шаяра», «Саф татарча безли бал кортлары». Искиткеч «нечкә дөнья», чәчкә, үләннәр, аларның гармониясе, табигатьнең шушы матурлыкта кабат тууы лирик геройга көч бирә.

«Киек казлар» шигырендә табигать сурәте – кеше җанының хәрәкәте. Шагыйрьнең халәтенә тәңгәл күренешләрне үтә зәвык белән сурәтләгән бу әсәре җырлап тора.

Кайсы хисне генә җырламасын, һәр шагыйрь аны фәлсәфә белән сугара. Ул монда үзенә кадәрге рухи байлык белән эш итә, үз ихтыяҗларында файдалана, үзгәртә. Бу – иҗат дөньясына (гомумән, яшәешкә) хас күренеш. Чөнки һәр җирдә, һәр чорда кешелекнең үсеш тарихы бер: адәм баласы туа, эшли, яши, көрәшә, явызлыкка тап була, гашыйк була, ялгызлык, хыянәт ачысын кичерә һ.б. Айрат Суфиянов иҗаты бу гомумилектән чыгарма түгел. Анда Тукай да, Дәрдемәнд тә тоемлана. Әдипнең табышы – әлеге яшәештәге күренеш-хисләрнең яңа мәгънә төсмерләрен табу, аны үзенчәлекле алымнар белән гәүдәләндерү, традицион мотивларын яңа шартларда дәвам итү. Шагыйрь иҗатының фәлсәфи бер хасияте – күңеленең Коръән Кәрим нурларына омтылуы. Әсәрләрендә күп кенә сурәтләр, фикерләр изге китап белән бәйләнешле. Кеше – бу җирнең кунагы гына; аның җаны абсолют вакыттан аерылган хакыйкатьнең бер кисәге. Адәм туфрактан яралган һәм туфрак булачак. Үз асылы белән кабат кушылачак.

Шагыйрь яшәешнең мәңгелек кыйммәтләре хакында тирән фикер йөртә, аның мәгънәсе турында уйлана. Төшенкелеккә бирелгән халәтендә язмыш мотивын алга чыгара.

«Кайтыр» әсәрендә шагыйрь адәм балаларының үлем алдында табигый тигезлеге идеясен үткәрә. Үлем – барысын да тигезли торган кодрәт.

*Кызганудан мәхрүм үлем*
*Һәркемне дә куя батырып.*
*Дөнья кендегедәй йөргәнне дә,*
*Иңдерәләр җиргә яткырып...*

Хикмәт башкалардан өстә торуда, данда, дәрәҗәдә түгел, кешенең үзеннән соң ни калдыруда.

Гөл калырмы бездән, тузгып көлме?

Автор афористик яңгырашлы шундый риторик сорау бирә. Гаделсезлек хөкем сөргән дөньяда, еллар үтсә дә, дәрәҗәсе, байлыгы кимеми торган бер көч бар. Ул – шигърият.

*Әүвәле сүз булган... Шагыйрь генә*
*Гаделлекнең йөрәк хәтеренә,*
*Үткәннәрдән кайтыр яктырып.*

«Сулар төпкә китә» әсәре шигъри симфония кебек язылган. Ул өч өлештән тора. Һәр өлештә сабыр төбе – сары алтын әйтеме төрле вариантларда рефрен итеп кабатлана. Ул хис хәрәкәтен күрсәтә. Беренче өлештә ул «Сабырлыкның төбе алтын, дидем» рәвешендә бирелгән. «Каеннарның майлы канлы төтен сеңгән күлмәге», «замананың майлы кара төтен сеңгән күлмәге» лирик геройны бер ялкынга, бер салкынга сала. «Җаннарны соң ничек коткарырга?» Чарасызлыктан шундый риторик сорау яңгырый. Икенче өлештә заман фаҗигасе сурәтләре тагын да тулыландырыла. Түбәндәге юлларда шагыйрьнең иң зур явызлыкка – Җир йөзендә барган туктаусыз орышларга нәфрәте чагыла:

*Мөмкинме соң мәңге җиргә янап*
*Җирдә яшәү кылыч уйнатып?*

Өченче өлештә кешегә инде җавап, үч галәмәтләре искәртелә: «нәфрәтләнеп вулкан ата таулар», «ташлар оча комдай вакланып» , «сулар төпкә китә, җир ярыла»... Әлеге янәшәле кабатлаулар белән табигатьнең күренеп торган үче күрсәтелә. Ләкин ул үчне сәбәпсез алмый. Кешелекнең явызлыгыннан табигать шулай соңгы чиккә килеп җиткән. Ул инде соңгы сулышын ала сыман. Автор халык әйтемен тагын кабатлый «Сабыр төбе – сары алтын», дидем. Нишләп соң ул өстә ялтырый?» Әсәрнең буеннан-буена кулланылган сынландырулар, көчәйтелгән кабатлаулар, экспрессив сүзләр лирик геройның тирән хәсрәтен күрсәтәләр.

Айрат Суфиянов иҗатына гомумиләштереп күз салсак, барча тематик-проблематик фикерләрне стиль итеп берләштергән бер үзәк мотив буйдан-буйга бара. Ул да булса, иҗат кешесе буларак, авторның үз образы, аның каләменең вазифасын, максат-ниятен күрсәтергә омтылышы. Шигърият – Аллаһы бүләге. Ләкин шагыйрь дөньяга очраклы гына килми. Аның Аллаһы Тәгаләдән йөкләнгән бурычы бар. Айрат Суфиянов та, шагыйрь буларак, бары иҗатта гына табигатенә туры, килешле яшәешен таба.

«Серле абага» әсәрендә нәкъ менә иҗат дөньясы үзәк тема итеп ниятләнгән. «Чәчәк аткан серле абага» метафорасы төп фикерне асылташ кебек балкыта. Бу сурәттә шагыйрь образы, аның иҗаты җанландырылган. Шагыйрьнең «чәнечкеле чынлык төргәген» сүткән, «кош илһамын йөрткән» йөрәге, дөрли-дөрли янган уй учагы, юкка чыкмас өчен карышып, «яшим» дигән тойгысы чиксез иркенлектә:

*Үләннәрнең тамырына төшә,*
*Наратларны коча җил булып,*
*Абагалар белән исәнләшә,*
*Дәшә төнгә ханлы ил булып...*

«Уңыш» шигыре аһәңе белән Тукайның «Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым» юлларына аваздаш. Дөньяның гаделсезлегеннән әрнү хисе «Җирдә яшәп зур уңышка ирештем» тезмәсен кабатлау белән көчәйтелә:

*Җирдә яшәп зур уңышка ирештем*
*Үзгәрмәде фани дөнья ...бирештем...*

*Хаклык, аклык кайтавазы шәүләсен*
*Эзли-эзли сүнәрмендер, күрәсең...*

*Көйгә салдым челтерәвен инешнең.*
*Бу дөньяга вакытлыча тукталган,*
*Азмы-күпме гыйбрәт туплаган*
*Саташулы төшкенәмен имеш мин...*
*Җирдә яшәп зур уңышка ирештем...*

«Яна шагыйрь» әсәрендә автор шигъриятьнең үлемсезлеген раслый. Заман хуҗалары синекдоха алымы белән сурәтләнә. Шагыйрь образы антитеза чарасы ярдәмендә аларга каршы куела:

*Язмыш түбәнгә тартса да,*
*Каласы килә үрдә...*
*Тук елмаеп, кукрайганнар,*
*Майга батып сукрайганнар,*
*Утырсалар да түрдә,*
*Бакыйлык сулышы иңгән*
*Шагыйрь үлемсез гүрдә!*

«Гомер учагы» – шагыйрь иҗатында әдәби яктан камил һәм үткен фикерле әсәрләрнең берсе. Лирик геройның күңеле борчулы, сагышлы. Кинәт сихри балкыш ачылып китә: ул табигатьнең яме, матурлыгы – каеннарның яшел кочагы, кәккүк тавышы, хыялында саф татарча дәшкән урман кызы – шагыйрь күңеленең учагын дөрләтеп җибәрә. Аның борчулы хисләре, сагышы гомум тормышның мәңге тынмас шатлыгына күчә:

*Үрли-үрли аяз күкләргә,*
*Дөрли гомеремнең учагы.*

«Җиңелмәс» лирик парчасында шагыйрьгә куелган таләпләр темасы үзәктә тора. Шагыйрь булу – күкләр биргән бөек вазифа. Яну-көю, гаделлек, хаклык, матурлык өчен көрәш-тартыш, теләсә нинди шартларда да вөҗданыңа, намусыңа тугрылык – аның асыл сыйфатлары. Матур ялган белән укучы күңелен алдау – рухи җинаять. Ачы булса да, иҗатта хакыйкать авазын яңгыратырга кирәк.

*Үз халкына тугры калса,*
*таяныч та таба алса,*
*давылларга юлыкса да,*
*Каршы торыр, чигенмәс.*

Айрат Суфиянов – татар әдәбияты мәйданына үзе яшәгән чорга кирәкле булып килгән лирик шагыйрь. Аның фикри офыклары киң, хыял канатлары колачлы, зәвыклы әсәрләре бүгенге авыр, ыгы-зыгылы вазгыятьтә күңеленә ямь таба алмаганнарга юлдаш булып тора. Алар көннән-көн катлаулана, табигый яшәү хокуклары чикләнә барган шартларда намуслы, вөҗданлы затларның җан авазы булып яңгырый һәм милләтнең йөз аклыгы булып тора.

**Лилия ХӨСНЕТДИНОВА**

# БЕР КАРЛЫГАЧ ЯЗ ЯСАМЫЙ

Мин милли тәрбияне ата-аналарны тәрбияләүдән башларга булдым, чөнки бүгенге укучыларның ата-аналары – «югалган буын». Алар мәктәптә русча гына белем һәм тәрбия алганнар. Урта һәм югары уку йортлары турында сөйләп тә торасы юк. Шуңа күрә мин ата-аналарның гомуми җыелышына җентекләп әзерләндем дә.

Директор чыгыш ясаганнан соң, сүз алдым:

– Татарстанда татар теле – дәүләт теле, – дидем русчалап. – Биредә утыручы ата-аналарның 80 проценты – татар милләтле. Үзем – татар теле укытучысы. Шул сәбәпле, туган телемдә чыгыш ясасам, гаҗәпләнмәссез дип уйлыйм.

– Хөрмәтле милләттәшләрем! – дип дәвам иттем сүземне. – Болгавыр заманда яшибез. Кызганыч, җәмгыятебездә эчүчелек, наркомания, җинаятьчелек, фахишәлек кебек тискәре күренешләр көннән-көн ныграк тамыр җәя. Әлбәттә, сәбәпләре бихисап. Әмма шуларның берсе, һичшиксез, милли тәрбиянең ике аякка да аксавы, туган телебезнең кадере китүе. Ә бит иман да, тәүфыйк та балага балдай татлы, ана сөтедәй сихәтле Туган тел белән, халкыбызның бишек җырлары, тылсымлы әкиятләре, зирәк мәкаль-табышмаклары, җор мәзәкләре белән керә.

Шунда алдагы рәтләрдә утыручы бер ханым кыбырсый башлады:

– Какая бестактность! Какое неуважение! – дип ярып салды ул. – Мы сейчас уйдем из зала.

Икенче бер ханым ялт итеп аңа борылып карады һәм:

– Сез русча сөйләгәндә, без тыңлыйбыз бит, – диде. Ә мин, эчтән пружина кебек тартылсам да, берни булмагандай, чыгышымны дәвам иттем, балаларга туган телдә белем һәм тәрбия бирүнең өстенлекләрен дәлилләр китереп исбатладым, аннан соң сүземне рус телендә дәвам итүгә күчтем:

– Когда-то татарский был языком дипломатии, – дидем, карашымны теге ханымга юнәлтеп. – Он такой же прекрасный, как и русский. Великий русский поэт А.С.Пушкин владел татарским. Если не верите, почитайте его произведение «Путешествие в Арзрум». Там есть такая фраза: «Я стал стучаться в дверь. Вышел хозяин. Я попросил воды сперва по-русски, а потом по-татарски. Он меня не понял. Удивительная беспечность! В тридцати верстах от Тифлиса и на дороге в Персию и Турцию он не знал ни слова ни по-русски, ни по-татарски».

Я вам прочитаю отрывок из письма русского поэта М.Ю.Лермонтова с Кавказа: «Начал учиться по-татарски, язык, который здесь, и вообще в Азии, необходим, как французский в Европе...»

Сүземне болай йомгакладым:

– Мы, татары и русские, живём и трудимся бок о бок.

Как говорил великий татарский поэт Г.Тукай «нанизаны на единую нить...» Следовательно, нам нужно взаимопонимание, взаимотерпимость, взаимоуважение, знание обоих языков. Закон о двуязычии принят. Его нужно уважать и выполнять. А если он кого-то не устраивает, одна ласточка весну не делает.

Чыгышымның соңгы җөмләсе хезмәттәшләрем арасында афоризмга әверелде. Милли мәсьәләләр буенча кытыршылык чыкканда: «Бер карлыгач яз ясамый», – дип кенә җибәрәләр иде.

Шул вакыйгадан соң милли мәгариф буенча урынбасарга ата-аналарның гомуми җыелышында башка сүз бирмәделәр. Мин дә аптырап калмадым. Мәктәптә татар сыйныфлары бар бит әле! Анда укучыларның ата-аналары өчен саф татар телендә җыелышлар уздыра башладым. Зал ораторны тын да алмыйча тыңлый, бала тәрбияләүдә халык педагогикасы ысуллары аларның йөрәгенә май булып ята. Җыелышта укучыларның өлгерешенә, аның сыйфатына төпле анализ ясала, уку алдынгылары, төрле олимпиадаларда җиңүчеләрнең исемнәре санап чыгыла, бала тәрбияләүдә уңышка ирешкән эти-әниләргә рәхмәт белдерелә. Балалар тарафыннан оештырылган концерт ата-аналар күңеленә аеруча хуш килә. Кыскасы, залда утыручыларның кәефләре күтәрелә, күңел кыллары тибрәнә.

Район үзәгендәге башка мәктәпләрдә андый тәҗрибә юк. Хәтта бер урынбасар, әллә көнләшүдән, әллә үзенең булдыксызлыгыннан йөрәге янып әйтеп ташлады:

– Ул җыелышларыгызның берәр файдасы бармы соң?

Мин үз колакларыма үзем ышанмыйча, аңа карадым – бу сүзләрне милли мәгарифкә җитәкчелек итүче кеше сөйлиме?

– Татар теленең кулланыш даирәсен сез нинди ысуллар белән киңәйтәсез соң? Аны ничек дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткермәкче буласыз? – дип сорауга каршы сорау бирдем мин. – Алдынгы тәҗрибәгез бар икән, рәхим итеп, уртаклашыгыз...

Теге авызына су капты, чөнки аның мәктәбендә андый тәҗрибә юк иде... Ә «бестактный» ханым белән булган вакыйганың әкияттәгедәй матур дәвамы бар. Берничә ел узгач, шулай бервакыт, тирән уйларга чумып, урам буйлап атлаганда, «Исәнмесез!» дигән тавышка башымны күтәрдем. Каршымда авызы колакларына җиткән Саша (мәгълүм ханымның улы) басып тора иде. «Хәлләрегез ничек?» – дип сорады ул саф татарча һәм күрешергә дип, ике кулын сузды. Нефтьчеләр институтында укый икән. Татар кызына гашыйк булган. Хәзер егет бик тырышып, татар телен өйрәнә. Күңелем сөенечемнән күкләргә ашты.

Әлеге очрашудан соң бер-ике ай вакыт үткәч, почта бүлекчәсенә баргач, күзем кәнәфидә чират көтеп утырган бер ханымга төште. Сашаның әнисе түгелме соң бу?!

– Здравствуйте, Нина Васильевна! – дип, беренче булып сүз каттым. Ханым куырылып калды (соңгы елларда юлда очрашсак та, бер-беребезне күрмәмешкә салышып уза идек). Шунлыктан мин аны кеше алдында хур итәргә җыена дип шикләнә иде бугай.

– Встретила Вашего сына, – дип дәвам иттем сүземне ачык йөз белән. – Он повзрослел, возмужал, поздоровался со мной на моём родном языке. Спасибо Вам, что вырастили такого замечательного сына...

Бу сүзләрне тирә-якта барлык кешеләр дә ишетеп торды. Ханымның йөзе балкып китте:

– А как же, я сама постоянно твержу сыну: «Выучи татарский язык», – диде ул, күгәрчендәй гөрелдәп.

Икебез ул көнне чөкердәшә-чөкердәшә туйганчы сөйләштек, дустанә аерылыштык.

Тышта ягымлы, мәрхәмәтле яз тантана итә, өздереп сандугачлар сайрый, баш очында карлыгачлар бөтерелә иде...

**Дания РӘҮПОВА,**
*педагогик хезмәт һәм журналистика ветераны,*
*җәмәгать эшлеклесе,*
*Бөгелмә районының Карабаш бистәсе*

# *Шәриф Камалның тууына – 140 ел*

*2024 елның 27 февралендә язучы, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Шәриф Камалның (Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев) тууына 140 ел тула. Язучының бай архивы Татарстан Милли музее фондында саклана. Аның бер өлеше Милли музей филиалы – Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры экспозициясендә дә тәкъдим ителә.*



*Шәриф Камал (сулдан уңга), Кави Нәҗми һәм виртуоз гармунчы Фәйзулла Туишев. Ф.Туишев фатирында 1936 ел.*




*Казанның татар мәктәбе (хәзерге 80 нче мәктәп) укучылары белән очрашу. 1940 ел.*



*Шәриф Камал совет республикалары язучылары арасында. Уңнан икенче – Әхмәт Фәйзи. 1940 ел.*



*Сталино (Донецк) шәһәрендә татар телендә чыккан «Пролетар» газетасы редакциясе хезмәткәрләре белән. 1937 ел.*



*Татар дәүләт театрында Шәриф Камалның иҗат юбилеена багышланган кичәдә чыгыш. 1940 елның марты.*



*Язучы гаиләсе (сулдан уңга): хатыны Хәят, кызы Зәйнәп, кияве Ефрем, Шәриф Камал. 1930 нчы еллар ахыры.*

*Сәхифәне* **Айдар ШӘЙХИН** *әзерләде.*

# ИДЕЛ-УРАЛ ЯЗУЧЫСЫ ШӘРИФ КАМАЛГА ХАЛИТ ЗИЯ УШАКЛЫГИЛНЕҢ ЙОГЫНТЫСЫ*

Яңарыш чоры төрек әдәбияты белән Идел-Урал татар әдәбияты арасындагы мөнәсәбәтләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарларның милли ихтыяҗлар контекстында үз мәдәният учаклары дип санаган «берсе аша икенчесенә үтелгән бүлмәләр»дән гыйбарәт Шәрыкның иң үсеш алган үзәге Истанбулга йөз тотулары нәтиҗәсендә зур импульс алган.

1552 елгы зилзиләдән соңгы зур җимерелү гасырлар буе дәвам иткән кабат тетрәнүләр белән коточкыч мирас югалтуларына сәбәп була. Татар дәүләтчелегенең бетүе бар яктан да инкыйразга китерә. Культурадан алып әдәбиятка кадәр, белем бирүдән алып фәнгә кадәр милләтне аякта тоткан бөтен өлкәдә ми селкенү кичергән татар мәдәният хәтере олы юл алдында торган башлангыч мәктәп баласы кебек Кышкар, Эстәрлебаш һәм Каргалы мәдрәсәләрендә тернәкләнә башлый. Диннәрен саклау хакына Бохара мәдрәсәләренә киткән татар халкы шул юлда җитлеккән күпсанлы голәма һәм имамнар аша үз теләгәннәренә ирешә. Соңрак татар җәмгыятендәге парадигмалар, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Исмәгыйль Гаспралы кебек яңалыкчы зыялылар тарафыннан үзгәртелеп, татарларның дөнья белән интеграциясен тәэмин итә. Казан, Оренбург, Уфа, Троицк һәм Буби кебек шәһәр һәм авыллардагы яңа мәдрәсәләр татар җәмгыятенең яшәү өчен көрәштәге эчке динамизмының көчен күрсәтә.

Россия мөселманнары арасындагы җәдитчелек хәрәкәтенең чыганагы Кара диңгез аръягыннан килә дип санаган рус ориенталисты Николай Иванович Ашмарин «Татар әдәбияты хакында»[1] дигән хезмәтендә, татарлар Россиядән алынасы яңалыкларны «руслашу» буларак күрүләре өчен мәкруһ дип исәплиләр, шуңа күрә күзләрен «солтан Төркиясе»нә текәп торалар, дип раслый. 1868 елдан башлап Истанбулга студентлар җибәрә башлаган Идел-Урал төбәге зыялылары, үз төбәкләрендәге мәктәпләрне дә «истанбуллылаштырып», Европа стилендәге мәктәпләрдә белем алган төрек зыялыларында булган кебек үк башка бер формациядә җитешкән татар укучыларының формалашуын һәм шуның нәтиҗәсе буларак, яңа татар әдәбиятының тууын әзерлиләр.

1907 елда Истанбулда укыган татар студентлары саны – 25 кә[2], 1908 елда – 54 кә[3], 1909 елда 67 гә җитә[4]. Татар әдәбиятының әйдәп баручы язучылары Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), Мөхәммәт Садыйк, Муса Акъегетзадә, Фатих Кәрими, Габдрахман Сәгъди, Йосыф Акчура, Нәҗип Гасри, Зыя Насыйри, Габдулла Шинаси, Хәлим Сабит, Мәхмүт Алмаев, Габдрахман Кәрәм һәм Шәриф Камал Истанбулда белем алалар.

Яңа татар мәдрәсәләрендә һәм Истанбулда җитешкән яшь буынның таянырлык үз ресурсларыннан мәхрүм булулары аларга, Истанбулдагы кардәшләреннән әдәби әсәрләр алып, үз китапханәләрен булдырырга юл ача. Татар мәдрәсәләрендәге шәкертләр потенциалы китап сәүдәсенең җанлануына сәбәп була. 1905 елгы революциядән соң

* Искәрмә: Бу мәкалә Истанбул университетының Социаль белемнәр институтында 2015 елда яклапган «Яңарыш чоры төрек әдәбиятының 1860–1917 еллар арасында Идел-Урал татар әдәбиятына йогынтысы» исемле докторлык диссертациябездән файдаланып язылды.

[1] Ашмарин Н., Татар әдәбияты хакында, тәрҗ. Әхмәтзәки Вәлиди, Оренбург, Вакыт матбагасы, 1913, Б. 5-6.

[2] «Harici Haberler-Türkiye», Yuldız, 19 İyi 1907, No:112, S.3.

[3] Әмирхан Р. Иманга тугрылык, Казан: Татарстан китап нәшр., 1997, Б. 179; Габдрафикова Л. Р. Повседневная жизнь городских татар в условиях буржуазных преобразований второй половины XIX – начала XX века, Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2013, С. 48.

[4] Гаяз Исхакый. Әсәрләр. 6 том, Казан: Татарстан китап нәшр., 2005, Б. 190.

Истанбулда басылган китаплар Казан, Уфа, Оренбург, Эстәрлетамак, Троицк һәм Орск кебек шәһәрләрдә ачылган татар китап ширкәтләре тарафыннан Идел-Урал төбәгендә күпләп таратыла. Яңарыш чоры төрек язучыларының бөтен әсәрләренең бу дәвердә Идел-Урал төбәгендә укылганын бу ширкәтләрнең «Әсамии көтүб» дип аталган реклама брошюраларында күрергә мөмкин. Төрек язучылары Зия Паша, Намык Кәмаль, Әхмәт Митхәт әфәнде, Шәмсетдин Сами, Мөаллим Наҗи, Абдүлхак Хәмит, Мирач Мурат, Әхмәт Расим, Хөсәен Рәхми, Хөсәен Җахит, Мәһмәт Рауф, Җәнап Шаһабетдин һәм Халит Зия Ушаклыгил кебек язучыларның төп әсәрләре «Әсамии көтүб»ләрдә урын алган.

Шуңа бәйле рәвештә озын һәм нәтиҗәле гомере белән төрек әдәбиятында тирән эз калдырган Халит Зия Ушаклыгилнең (1865–1945) күп кенә әсәрләре Казанда һәм башка татар мәдәнияте үзәкләрендә сатыла. Шулар исәбендә «Бер үленең дәфтәре»[5], «Нәмидә»[6], «Фәрди вә шөрәкясы»[7] һәм «Мәнсур шигырьләр»[8] әсәрләре бар.

Истанбулда укыган яшь татар язучылары Халит Зия Ушаклыгилнең киң таралган шигырьләрен һәм хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итәләр. Габдрахман Сәгъди Истанбулда укыган чагында «Шура» журналының җиде чыгарылышында үзе бик зур әһәмият биргән Халит Зияның «Mezardan Sesler» шигырьләр җыентыгын «Кабердән тавышлар» исеме белән татар теленә тәрҗемә итә.[9] Галимҗан Ибраһимов, Габдрахман Сәгъдинең «Мохтасар кавагыйде әдәбия»сенең басылып чыгуын хәбәр иткәндә, аны «Кабердән тавышлар»ның тәрҗемәчесе итеп тәкъдим итеп,[10] бу тәрҗемәгә зур игътибар бирүен күрсәтә. Габдрахман Сәгъди бу тәрҗемәләрне 1912 елда 37 битлек бер китап рәвешендә дә бастыра[11]. Халит Зияның «Мәнсур шигырьләр» китабындагы «Cenk»[12] хикәясе Шәрифзадә Габдулла тарафыннан 1912 елда «Шура» журналында «Сугыш» исеме белән тәрҗемә ителә һәм басылып чыга.[13] Халит Зияның тагын ике хикәясе, Истанбулда укыган Г(абдрахман) К(әрәм) тарафыннан тәрҗемә ителеп, «Аң» журналында дөнья күрә. «Bir yazın tarihi» («Бер җәйнең тарихы») җыентыгындагы «Zevrak'la Ebru»[14] хикәясе «Зәүрак илә Әбру»[15], «Defter-i natamam»[16] хикәясе, «Язылып бетмәгән дәфтәрләр»[17] исемнәре белән басылып чыга.

1913 елда Фатих Кәримигә язган хатында Галимҗан Ибраһимов Халит Зияның «Нәмидә», «Фәрди вә шөрәкясы», «Маи вә сияһ» кебек нәфис һәм назик романнарының татар язучылары өчен үрнәккә лаек әсәрләр булуын язып үтә[18]. Бу контекстта Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» белән Халит Зияның «Маи вә сияһ» романнары арасындагы охшашлыклар үзенә игътибарны җәлеп итә[19].

Төрек әдәбиятында Көнбатыштагыча аңлашылган беренче зур романнар язган Халит Зия Ушаклыгил – төрек прозасының иң бөек исемнәреннән берсе. Ул романга һәм хикәягә китергән яңалыклар аның замандашларына һәм соңрак килгән төрек язучыларына тирән йогынты ясаган. Аның иҗаты төрек әдипләре белән генә

[5] Шәрык китапханәсе. Әхмәд Исхак, Орск шәһәре, Шура, 1909, № 4, арткы тышлык; Әсамии көтүб 1910–1911, Оренбург, Кәримов Хөсәен вә рәфикъларының матбага ширкәте, 1911, Б. 10; Борадәран Кәримовлар көтепханәсе мөкәммәл әсамии көтүбе, Казан, Литотипография Т. Д. Бр. Керимовых, 1913, Б. 60.
[6] Шәрык китапханәсе. Әхмәд Исхак, Орск шәһәре, күрсәтелгән хезмәт; Әсамии көтүб 1910–1911, күрсәтелгән хезмәт, Б. 10.
[7] Борадәран Кәримовлар көтепханәсе мөкәммәл әсамии көтүбе, күрсәтелгән хезмәт, Б. 56.
[8] Борадәран Кәримовлар көтепханәсе мөкәммәл әсамии көтүбе, күрсәтелгән хезмәт, Б. 63.
[9] Халид Зия, мөтәрҗиме Габдрахман Сәгъди. Кабердән тавышлар, Шура, 1910, № 7, Б. 199-201, № 8, Б. 232-234, № 9, б. 261-263, № 10, Б. 294-296, № 11, б. 332-334, № 13, б. 398-401, № 15, Б. 447-460.
[10] Галимҗан Ибраһимов. Әдәбият агымы, Шура, 1911, № 22, Б. 680.
[11] Халид Зия, мөтәрҗиме Габдрахман Сәгъди. Кабердән тавышлар, Уфа, Шәрык матбагасы, 1912.
[12] Halid Ziya Uşaklıgil, Mensur Şiirler – Mezardan Sesler, İstanbul, Özgür Yayınları, 2002, s.96-100.
[13] 'Ушаккыйзадә Халид. Сугыш, тәрҗ. Шәрифзадә Габдулла, Шура, 1912, № 19, б. 604-605.
[14] Halid Ziya Uşaklıgil, Bir Yazın Tarihi, İstanbul, Özgür Yayınları, 2005, s. 101-107.
[15] Халид Зия. Зәүрак илә Әбру, тәрҗ. Г. К., Аң, 1916, № 23, Б. 359-361.
[16] Halid Ziya Uşaklıgil, a.g.e., s.108-124.
[17] Халид Зия. Язылып бетмәгән дәфтәрдән, тәрҗ. Г. К., Аң, 1916, № 18, Б. 284-286, № 19-20, Б. 302-310.
[18] Гыйлажев Т. Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте, Казан: Татарстан китап нәшр., 2008, Б. 221.
[19] Һүсәйин Барган. Яңарыш чоры төрек әдәбиятының 1860–1917 еллар арасында Идел-Урал татар әдәбиятына йогынтысы (докторлык дисс. кульъязмасы), Истанбул, 2015, Б. 378.

чикләнмичә, татар әдәбиятының әйдәп баручы язучыларыннан Шәриф Камалга да йогынты ясаганы аңлашыла.

Шәриф Камал (1884–1942) үзен яңа татар әдәбиятында 1909 елдан башлап язылган кечкенә хикәяләре белән таныта. Аеруча аның хикәяләрендәге тел һәм өслүб үзенчәлекләре һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Дәрдемәнднең 1908 елдан соң шигърият өлкәсендә метафоралары һәм образлары ярдәмендә тудырган яңа шигыре, теле һәм әдәбияты замандашлары тарафыннан файдалы бер агым буларак бәяләнгән.[20] Шәриф Камалның «Хикәяләр төркеме» (1914) китабында әдәбияттагы бу файдалы агымның хикәядәге формасын чагылдыруда зур йогынтысы булган. Утыз бер хикәя урын алган бу китапны тәкъдим иткәндә, түбәндәгечә башлый: «Бу кечкенә һәм гүзәл хикәяләрне яратып укымаган һәм аларны укып ләззәт алмаган кем бар?»[21] Җамалетдин Вәлиди һәм Галимҗан Ибраһимов кебек әдәбиятчылар бу хикәяләрне уңай бәялиләр. Барлык аспектларда диярлек Халит Зия Ушаклыгил хикәяләре белән кисешкән Шәриф Камалның бу хикәяләренә нәкъ Галимҗан Ибраһимов беренче булып игътибар итә.

Габдрахман Сәгъди, үзенең «Татар әдәбияты тарихы»нда Шәриф Камалга багышлаган сәхифәләрдә аның хикәясен аңлатканда, нәкъ Халит Зия Ушаклыгилнең хикәясен аңлаткан кебек кабул ителә. Совет чорында Шәриф Камал һәм Халит Зия Ушаклыгил иҗатындагы бу кисешүләрне һәм охшашлыкларны ачыклау авторлар өчен дә, бәяләүчеләр өчен дә сәяси санкцияләр керткәнлектән, Советларга кадәр Галимҗан Ибраһимовның бу ике әдипкә карата фикерләре белә торып игътибардан читтә калдырыла. Бу якынлык фәкать 1990 еллардан соң гына тикшеренүче һәм язучы Тәүфыйк Әйди тарафыннан кабат көн кадагына куела.[22]

Шәриф Камал 1884 елның 27 февралендә Пенза губернасының Инсар өязе Татар Пешләсе авылында туган. Аның әтисе авылның имамы була. Башлангыч укуын тәмамлагач, булачак язучы 1896 елда авылларыннан ерак түгел урнашкан Ләбәжә мәдрәсәсенә укырга китә. Мәдрәсә башында ун ел Бохарада укыган Йосыф хәзрәт тора. Мәдрәсәгә бер «җәридә» килә һәм Мисыр, Һиндстан, Истанбулдан хәбәрләр бирә.[23] Бу «җәридә» Кырымда чыга торган «Тәрҗеман» газетасы була. Шәриф Камал дүрт ел укыган бу мәдрәсәдән китә һәм тимер юлда эшче булып хезмәт куя. Ул Украинадагы күмер шахталарына эшкә барганда, үз сүзләренә караганда, аз булса да бу «җәридә»гә иярә.[24] Ярым-ярты калган белемен тәмамлау максаты белән Ш.Камал 1901 елда рәсми булмаган юллардан Истанбулга бара. Паспорты булмау сәбәпле, ул процедура таләпләрен үтәп, рәсми рәвештә кая да булса теркәлә алмаса да, дарелмөгаллиминдә тыңлаучы сыйфатында бер ел дәресләргә йөри. Аның абыйсы Гыймади Камал да, Истанбулда һәм Мисырда белем алып, Петербургта мәчет имамы була. Г.Камал соңрак Көнбатыш Кавказга ахун итеп билгеләнә һәм Ростовка китә.[25]

Татар мәдрәсәләрен бетергән татар шәкертләрен бернинди юл белән дә дәүләт университетларына кабул итмәгән Россиянең бу бюрократик алымнарына берни дә әйтә алмаган Гали Халит кебек әдәбият тарихчылары Шәриф Камалның Истанбулда рәсми югары уку йортына алынмавын бер золым кебек күрсәтә[26].

Шәриф Камал бераздан Истанбулдан Каһирәгә күченә. 1906 елда «Нур» газетасында инглизчәдән тәрҗемәләре аның монда инглиз телен дә өйрәнгәнен күрсәтә. 1905 елгы Рус революциясе вакытында ул Петербургта татар мәдрәсәсендә укыта.

Татар матбугатында тәүге тапкыр Шәриф Камалның исеме 1905 елның 2 сентябрендә Петербургта чыга башлаган «Нур» беренче татар газетасында яңгырый. Петербург имамы Гатаулла Баязитов тарафыннан нәшер ителгән бу газетада шулай

[20] Габдрахман Сәгъди, Тел вә әдәбият мәсьәләсендә файдалы агым, Шура, 1912, 10, Б. 614.
[21] Хикәяләр төркеме, Вакыт, 16 октябрь 1914, № 1610.
[22] Тәүфикъ Әйди. Кардәшләр кочагында, Аваз нәшрияты, Казан, 2000, Б. 369.
[23] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр, Казан: Татарстан китап нәшр., 2004, Б. 20.
[24] Шәриф Камал. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 26.
[25] Асия Хәсәнова. Камаллар кавеме, Сөембикә, 1999, № 5, Б. 14.
[26] Татар әдәбияты тарихы, Т. 3, Б. 316.

ук Ризаэддин Фәхретдин һәм Фатих Кәрими язмалары басыла. Шәриф Камал бу авторлар белән 1909 елдан соң Оренбургта «Вакыт» газетасында очрашачак. Аның инглиз теленнән «Гөнаһ шомлыгы» дип аталган тәрҗемәсе[27] «Нур»да басылып чыга. Фельетон рубрикасында яңа жанр буларак «Әфгале милләтә бер имкян» исемле язмасы басыла[28]. Соңрак шул ук газетада «Инде»[29] һәм «Хакы бар»[30] кебек Шәриф Камалның Истанбул төрекчәсендә диярлек золымнан мазлумнарның күз яшьләре турында сөйләгән шигырьләре басыла башлый. Әдипнең «Инде» шигыре түбәндәгечә башлана:

*Ниләр күрсәтте ниләр…*
*Фәләк бу бәндәләргә:*
*Кысты, яньчеде, таптады,*
*Аягы илән басты.*
*Никадәр залим яһу!*
*Бу халкның кара каны*
*Мәзлумнарның күз яше*
*Зур диңгез тәшкил итте,*
*Кайнады өсте, асты.*
*Куркыныч дәһшәт, я Рабб!*[31]

Соңрак «Нур» газетасында Шәриф Камалның «Сада» исемле рисаләсенең чыгачагы хәбәр ителә[32]. «Казан мөхбире» чыга башлагач, ул анда да шигырьләр бастыра башлый[33].

1909 елның 15 апрелендә «Шура» журналында Шәриф Камалның Намык Кәмальдән «Әң әдна лотфеңә җан вирмәя мөштак икән сад-хәйф бәни җәүриңлә үлдердең, бәким агъяра алдандың»[34] икътибасын эпиграф итеп алган «Уяну» исемле беренче хикәясе нәшер ителә[35]. Хикәянең дәвамы шулай ук журналның уникенче санында басылып чыга[36]. Намык Кәмальдән алынган һәм хикәянең эчтәлеге белән дә кисешкән бу цитата Совет чоры басмаларында чагылдырылмый.

Бу хикәя күпләрнең игътибарын җәлеп иткән кебек, журналның хуҗасы шагыйрь Закир Рәмиевнең да күз уңыннан читтә калмый. Бертуган Рәмиевлар Оренбургта «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы тирәсендә әдәби түгәрәк булдырырга тырышалар. Пенза губернасындагы туган авылы Пешләдә мөгаллимлек иткән[37] Шәриф Камалны Оренбургка чакыралар. Шулай итеп, хикәячегә иҗат өчен юл ачыла[38].

1910 елдан «Вакыт» белән «Шура»да бухгалтер булып эшли башлаган Шәриф Камал бераздан «Вакыт» газетасының бүлек мөхәррире итеп билгеләнә. Шәриф Камал 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр газетада эшли. Бу чорда ул бик күп хикәя бастыра[39]. Соңрак бу хикәяләр китап итеп нәшер ителә. «Вакыт» матбагасында Ризаэддин Фәхретдиннән соң иң күп китап бастырган кеше Шәриф Камал була. Тәртибе белән санаганда, аның «Козгыннар оясында» (1910), «Хикәяләр төркеме» (1914) һәм «Акчарлаклар» (1915) хикәя китаплары басылып чыга[40].

«Сәрвәте фөнун» мәшһүр төрек журналы шигырендә һәм хикәясендә табигатькә булган карашны Закир Рәмиев шигырьләрендә һәм Шәриф Камал хикәяләрендә

[27] Шәриф Камал. Гөнаһ шомлыгы, Нур, 25 февраль 1906, № 24.
[28] Равил Әмирхан. Иманга тугрылык, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1997, Б. 265.
[29] Шәриф Камал. Инде, Нур, 24 май 1906, № 38.
[30] Шәриф Камал. Хакы бар, Нур, 11 май 1906, № 40.
[31] Шәриф Камал. Инде, Нур, 24 май 1906, № 38.
[32] Игълан, Нур, 12 июнь 1906, № 49.
[33] Шәриф Камал. Катык чүлмәге, Казан мөхбире, 26 декабрь 1905, № 16.
[34] Шәриф Камал. Уяну, Шура, 1909, № 8, Б. 254.
[35] Шәриф бин Камал. Уяну, Шура, 1909, № 8, Б. 254-255.
[36] Шәриф Камал углы. Уяну, Шура, 1909, № 12, Б. 379-384.
[37] Татар әдәбияты тарихы, Т. 3, Б. 317.
[38] Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар, Казан, Татарстан китап нәшр., 1968, Б. 92.
[39] Шәриф Камал. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 10.
[40] Бертуган Рәмиевләр, Казан: Рухият нәшр., 2002, Б. 73-75.

күрергә мөмкин. Сәрвәтефөнунчыларда булсынмы, бу ике татар язучысында булсынмы табигатьнең төсләре һәм тавышлары бертөрле күренүе һәм ишетелүе – бу тәэсирләшүнең күрсәткече. «Сәрвәте фөнун» әдипләренең табигатькә булган карашларында Абдүлхак Хәмиттә беренче йогынтысы күренгән Ж.-Ж. Руссоның фикер рәвеше, парнасизм һәм реализм тәэсирләре үзен тагын да ныграк сиздерә.[41] Сәрвәтефөнунчылардагы «рухы кяинат» төшенчәсен татар язучылары Дәрдемәнд һәм Шәриф Камалда да күрергә мөмкин. Бу ике татар язучысының табигатькә караш нокталары пантеистик караш буларак бәяләнүе[42] сәрвәтефөнунчыларның «рухы кяинат» турындагы күзаллаулары белән туры килүен күрсәтә.

Әхмәт Митхәт хикәяләренә ияргән Фатих Кәримидән аермалы буларак, Шәриф Камалның хикәяләрендә «дәрес бирү» максаты көтелмәгәнлектән, хикәя геройларындагы трансформацияләр, кинәт килеп чыккан «ислахы нәфес» буларак түгел, ә вакыт һәм эчке конфликтларның бер нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Шуңа күрә Халит Зия һәм Шәриф Камал хикәяләрендә хисси-эмоциональ процессларны бөтен нечкәлекләре белән биргән анализларның[43] җентекле булуы күзгә ташланып тора. Фатих Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе»ндәге Әхмәт Митхәтнең «Çingene» («Чегән») кебек хикәяләреннән килгән «табигатьне тамаша итү тәме»[44] Шәриф Камал хикәяләрендә Халит Зиядан килгән реалистик тасвирлар, рәссам күзе белән башкарылган декор, әйберләр һәм табигатьне сурәтләүләре белән[45] өслүбкә дә йогынты ясаган эстетик зәвыкка әверелә. Ш.Камалның хикәяләре татар әдәбиятында Әхмәт Митхәт хикәясеннән Халит Зия хикәясенә күчешнең беренче адымнары була. Бу ике төрле күзаллауның эзләрен телләрендә һәм өслүбләрендә дә күрергә мөмкин. Фатих Кәрими белән Шәриф Камал хикәясе арасында Гаяз Исхакыйның натурализмга нигезләнгән реалистик хикәяләре дә бар. Габдрахман Сәгъди, хикәяләрендәге төрлелек һәм әдәби татар теленең эшкәртелүе ягыннан Гаяз Исхакыйның Шәриф Камалдан шактый артта калганын белдереп, Шәриф Камалны «классик әдип» диюне урынлы дип саный[46].

XIX гасыр француз язучылары Гюстав Флобер, Альфонс Доде һәм бертуган Гонкурларның төрек язучысы Халит Зияга йогынтылары билгеле.[47] Халит Зияның реализмы күп яктан югарыда телгә алынган француз авторларыннан килә. Аның әсәрләрендәге вак детальләргә игътибары, тышкы дөньяга карата үҗәтлеге, геройларның рухи дөньялары белән бәйле анализлары бертуган Гонкурлардан килсә, сайланган сүзләр ярдәмендә үҗәтлек белән аерым бер атмосфера булдыру теләге Альфонс Доцедан килә[48].

Халит Зия романнары һәм хикәяләрендәге бу үзенчәлекләрне Шәриф Камал хикәяләрендә дә күрергә мөмкин. Шәриф Камал хикәя геройларының индивидуальлекләре белән автор өслүбе арасында, Халит Зия хикәяләрендәге кебек үк,[49] тыгыз бәйләнеш бар. Шәриф Камал да, Халит Зия хикәяләрендә булган кебек, үз хикәяләрендә караңгы һава булдырырга, геройларның күңел халәтләрен һәм психологик кичерешләрен[50] купайтып күрсәтергә, табигать тасвиры аша аерым атмосфера булдырырга тырыша. Табигать һәм табигатьтәге җан ияләре яшәештәге хәлләргә шаһит була. Табигать һәм табигать күренешләре еш кына герой белән бергә елыйлар. Тормышның үзәк өзгеч һәм борчулы яклары, гадәттә, табигать белән

[41] Mehmet Kaplan, «Tabiat Karşısında Abdülhak Hamid», Türk Edebiyatı Üzerine Araştırmalar 1, 9. Baskı, İstanbul, Dergâh Yayınları, 2009, s. 307.
[42] Татар әдәбияты тарихы, Т. 3, Б. 323.
[43] Ömer Faruk Huyugüzel, Halit Ziya Uşaklıgil, İkinci Baskı, Ankara, Akçağ Yayınları, 2010, s.82.
[44] Orhan Okay, Batılılaşma Devri Türk Edebiyatı, İstanbul, Dergah Yayınları, 2010, s.84.
[45] Ömer Faruk Huyugüzel, a.g.e., s.82.
[46] Габдрахман Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1926, Б. 272.
[47] Gül Mete Yuva, Modern Türk Edebiyatının Fransız Kaynakları, İstanbul, Yapı Kredi Yayınları, 2011, s.255.
[48] Ahmet Hamdi Tanpınar, «Halit Ziya Uşaklıgil (Mai ve Siyah ve Aşk-ı Memnu)», Edebiyat Üzerine Makaleler, Yedinci Baskı, İstanbul, Dergâh Yayınları, 2005, s.290.
[49] Ömer Faruk Huyugüzel, a.g.e., s.105.
[50] Җамал Вәлиди. Казан: Җыен нәшр., 2010. Б. 321.

бергә бара. Ай, кояш, йолдызлар, кошлар, мәче башлы ябалаклар һәм каргалар – вакыйгаларның шаһитлары[51]. Хикәяләрдә йә шомлы бер тынлык, йә җил, давыл, ябалак һәм карга тавышлары барысы бергә каплап алган табигать күренешләре герой күңелендә булган негатив торышны визуаль һәм ишетү белән күрсәтү өчен бер пейзаж тудыра[52].

«Сәрвәте фөнун» әдәбияты рухындагы романнар белән хикәяләр тематикасының һәм геройларының тулы мәгънәдә җирле (төрекнеке) була алмаганы һәм төрек җәмгыяте тормышының кызулыгын колачламавы тәнкыйть ителгән. Бу тәнкыйтьләр белән бергә Халит Зияның кечкенә хикәяләрендә Истанбулның кайбер эчке урамнарында яшәгән фәкыйрь кешеләрнең реаль тормыш манзараларын уңышлы чагылдыра алуы да ассызыкланган[53]. Халит Зияның аеруча 1897–1899 елларда «Икдам» һәм «Сабах» газеталарында язган бу кечкенә хикәяләре социаль яктан авырлыклар кичереп яшәгән шәхесләрнең тормышыннан кисемнәр тәкъдим итә. Болар еш кына җәберләнгән хатын, яшь кызларның бәхет турындагы хыяллары һәм шул хыялларының өзелүе, караучысыз калган яки үлгән балалар, ярлы һәм мохтаҗ кешеләр һәм ярдәмгә мохтаҗ ирнең авырлыклары көчле кызгану хисе уятырлык шәкелдә бер атмосфера тудырып аңлатылган темалар[54].

Халит Зия белән Шәриф Камалның хикәя сюжетларының да үзара кисешүе күзәтелә. Халит Зияның «Kırk para» («Кырык акча»)да тасвирлаган фәкыйрь ирне Шәриф Камалның «Җимерелгән звоног»ында, Халит Зияның «Kırık oyuncak» («Җимерелгән уенчык») һәм «Son çocuklar» («Соңгы балалар»)да тасвирлаган вафат булган балаларның кайгысын Шәриф Камалның «Ата»сында, Халит Зияның «Yırtık mendil» («Ертылган яулык») һәм «Daire-i istintak» («Сорау алу даирәсе»)ндә тасвирлаган җәберләнгән хатыннарны Шәриф Камалның «Уяну» хикәясендә күрергә мөмкин.

Шәриф Камал хикәяләрендәге сюжетлар һәм геройлар, Халит Зия хикәяләрендәге сюжетлар һәм геройлар кебек – төрле өметләр һәм хыяллар белән тормыш диңгезенә атылган, әмма өмет-хыялларының өзелүе сәбәпле, ялгыз калган кешеләрнең тормышларын ачып бирә[55]. Бәхет эзләгән бу игелекле кечкенә кешеләр бергә булганда, эчләрендәге хәсрәтләрен яшерү өчен елмайсалар-көлсәләр дә, ялгыз калгач, һөңгер-һөңгер елыйлар[56].

Ш.Камалның «Козгыннар оясында» исемле беренче хикәяләр җыентыгы басылып чыккач, Мәхмүт Мәрҗани, әсәрнең исеменә карап, анда иске мәдрәсәләрдәге шәкертләрнең яки качакларның яшерен урыннардагы тормышы турында сүз бара дип уйлаган булса, гүя язмыш рониясе буларак бер почмакта онытылган кешеләрнең көнитеше белән очрашкач, шакката һәм әсәрнең асылда «Онытылган җаннар» дип аталырга тиешлеген әйтә[57]. Шәриф Камал күмер шахталарында эшләгән Шәриф әфәндened эчке халәтен реалистик сурәтләр белән күз алдына китереп бастыра. Татар әдәбиятында «Козгыннар оясында» хикәясе белән беренче тапкыр эшчеләр темасы күтәрелә[58]. Ләкин бу, Габдрахман Сәгъди сүзләренчә, идеологик яктан якын килү түгел. Ш.Камал хикәяләрендә баштан ук фәкыйрьлек, күңел төшенкелеге, горбәт һәм ялгызлык кебек хәлләр сәбәпле килеп чыккан газаплар, авырлыклар, ыңгырашулар һәм депрессияләрне күрергә мөмкин[59]. «Буранда» булган кебек, өч ел хәрби хезмәттән соң үлем түшәгендә яткан әнисен күрергә ашыккан Мостафаның каршына чыккан

[51] Габдрахман Сәгъди. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 274.
[52] Татар әдәбияты тарихы, Т. 3, Б. 323.
[53] A. Hamdi Tanpınar, Yahya Kemal, İkinci Baskı, İstanbul, Dergâh Yayınları, 1982, s.86.
[54] Ömer Faruk Huyugüzel, a.g.e., s.98-103.
[55] Ömer Faruk Huyugüzel, a.g.e., s.103.
[56] XX йөз башы татар прозасы, Казан: Мәгариф нәшр., 2002, Б. 178.
[57] Гыйлаҗев Т. Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте, Казан: Татарстан китап нәшр., 2008, Б. 25-26.
[58] Гыйлаҗев Т. Ш. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 26.
[59] Җамал Вәлиди. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 322.

кышкы җил бу очрашуга киртә сала. «Сулган гөл»дә унтугыз яшендә гаилә бәхетенең ни икәнен дә белмәгән кызның көндәш итеп кияүгә бирелү фаҗигасе тасвирлана.

Балыкчыларның авыр тормышы турындагы «Акчарлаклар» дип аталган озын хикәясендә дә горбәт, фәкыйрьлек һәм ялгызлык проблемаларын күрергә мөмкин. Ләкин Шәриф Камал бу хикәясе белән, йогынтылардан ерак булып, үзенең сәнгать осталыгының югарылыгын күрсәтә. Совет чорында язуын дәвам итсә дә, татар әдәбияты тарихына ул «Акчарлаклар» авторы буларак кереп кала.

Шәриф Камал татар әдәбиятына китергән тел һәм өслүб – татар әдәбиятында моңарчы беркайчан да кулланылмаган тел һәм өслүб ул. Әдипнең бу үзенчәлекле теле һәм өслүбе күп кенә татар язучыларының һәм тәнкыйтьчеләренең игътибарын җәлеп итә. Аның кемнән тәэсирләнү ноктасында төрек әдәбияты һәм Халит Зия иҗаты белән яхшы таныш Галимҗан Ибраһимовның билгеләве кысаларында күрсәтелгән адрес Халит Зия Ушшакыйзадә булган[60].

Шәриф Камал иseme белән «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналында 1909 елдан хикәяләр бастыра башлаган чакта, бу исемнең Йосыф Акчураның псевдонимы була алуы фаразлана. Болай фаразлануда Казан, Оренбург һәм Уфаның әдәби даирәләренә бик үк билгеле булмаган бу исемнең хикәяләрендәге тел һәм өслүбнең «сәнгатькяранә» өлгергәнлек дәрәҗәдә булу белән бергә, моңарчы татар телендә ул кадәр киң урын алмаган госманлы вокабулярны Шәриф Камалның үзенә хас аерым бер шәкелдә куллануы. Габдрахман Сәгъди Шәриф Камалның бу теленә һәм өслүбенә «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы йогынты ясаган[61] дип әйтсә дә, Шәриф Камал Оренбургка «Вакыт» газетасына эшләргә килгәнче үк язылган «Уяну» һәм «Козгыннар оясында» хикәяләрендә Халит Зияның тел һәм өслүб үзенчәлекләрен күрергә мөмкин.

Татар телендә эквивалентлары булуга карамастан, Ш.Камалның беренче хикәяләр җыентыгы «Козгыннар оясында» госманлычадагы кайбер кушымчаларны һәм сүзләрне куллануы Мәхмүт Мәрҗани тарафыннан тәнкыйть ителгән[62]. Шәриф Камалның госманлы теле йогынты белән кулланган сүзләренә үрнәк итеп, Габдрахман Сәгъди түбәндәгеләрне санап киткән: «Һәлә, интикам, умыз, улдыкча, пәрһизкяр, әсәре мөлаямәт, дил-күшә манзаралар, әнзары хыяллар, анчак, парлак, раушан, шөйлә ки, хосулә кәтирәҗәгенә, шөбһә билә, мөбһәм, мөстәһзиянә, дәфгатән, имдад намына, мәшум, лисан, гаддаранә, иҗра, димаг, рабыт, җәмгыяте бәшәрия, тәвәҗҗүһ, тәхәммүл, тәһлил».

Тәэсир нәтиҗәсе буларак кулланылган мондый сүзләрне һәм тәгъбирләрне Габдрахман Сәгъди «игенлек уртасындагы зарарсыз үләннәр» белән чагыштыра. Алар белән әсәрнең зыян күрмәгәнен әйтә[63].

Халид Зияның романнарында һәм хикәяләрендә кулланган күпсанлы сыйфатлар һәм аллегорияләр[64] белән тулы «сәнгатькяранә өслүб»енең йогынтысын Шәриф Камалның бигрәк тә башлангыч чор хикәяләрендә берникадәр күрергә мөмкин. Шәриф Камалның беренче хикәяләреннән берсе булган «Сулган гөл»[65] Халит Зияның «Solgun Demet» («Сулган гөл бәйләме»)[66] белән күп кенә аспектларда кисешә. Ике хикәянең дә, исем охшашлыгы белән бергә, тел һәм хикәяләүдәге охшашлыкларны да күрергә мөмкин. Халид Зия романнарында һәм хикәяләрендә киң кулланган һәм хикәяләүнең авырлашуына юл ачкан «субъектив тасвирлаулар»дагы чагыштырулар[67] Шәриф Камалның бигрәк тә беренче хикәяләрендә бик еш очрый. Халит Зияның «Solgun Demet»тәге «төннең кара сулышы», «күренмәгән кул», «бәхетнең ял итү урыны»,

[60] Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр, Т. 5, Казан: Татарстан китап нәшр., 1978, Б. 207.
[61] Габдрахман Сәгъди. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 272.
[62] Гыйлаҗев Т. Ш. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 26.
[63] Габдрахман Сәгъди. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 272.
[64] Mehmet Kaplan, a.g.e., s. 391.
[65] Шәриф Камал. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 27-38.
[66] Halit Ziya Uşaklıgil, Solgun Demet, İstanbul, Özgür Yayınları, 2006, s. 17-26.
[67] Olcay Önertoy Halit Ziya Uşaklıgil Romancılığı ve Romanımızdaki Yeri, Ankara, Kültür Bakanlığı Yayınları, 1995, s. 177.

«бәхет чәчәкләре», «хыянәт төшләренең күләгәсе», «хушлашу исе», «туңган үле сулыш», «сулган сәгадәт»[68] кебек субъектив тасвирлаулары Шәриф Камалның «Сулган гөл»ендә «татлы өметләр», «ләззәтле хыяллар», «яшь бакчачының былбыллары», «кара кадәр», «кара урман», «моракабәдәге җил тегермәннәре»[69] шәкелендә каршыбызга чыга. Моңарчы татар прозасында күренмәгән һәм Шәриф Камал белән башланган бу төр тапталмаган гыйбарәләргә Габдрахман Сәгъди дә игътибар итә һәм «үлемнең куркыныч бармаклары», «мөтәфәккир урманнар», «дәһшәтле бер куәт» кебекләрне үрнәк итеп китерә[70].

Халит Зия «Solgun Demet»тә, начар һава торышын көчәйтү өчен, төн караңгылыгында җилгә каршы улаган этләргә[71] ихтыяҗ тойса, Шәриф Камал исә хикәясендә кызыл кан кызыллыгындагы таң вакытында көтү-көтү булып очкан каргалар һәм аларның кычкырышуларын куллана[72]. «Сулган гөл»дәге яшь кыз Камәр белән «Solgun Demet»тәге Пәрвиннең икесенең дә язмышында «алданганлык», «ялгызлык» һәм «бәхетсезлек» уртак булуы һәр ике хикәянең дә сюжет линияләренең охшашлыгын күрсәтә.

Шәриф Камалның прозаик шигырь стилендә уңышлы үрнәкләр биргән Халит Зияга бу яктан да ияргәне аңлашыла. «Гаетне котлыйм»[73] кебек шигыре белән бергә «Гөлчәһрә», «Гает көнне», «Бәйрәмдә еламыйлар, бәгърем» һәм «Эч пошулы» кебек хикәяләре бу жанрның мисалларын искә төшерә. Болар тормышның проблемалы яклары алдында күңелен тынычландырырга теләгән геройның метафизик ялварулар белән вөҗданын тынычландырырга тырышкан хикәяләр.

Шәриф Камалның бу жанрдагы хикәяләре Гали Халит кебек татар әдәбиятын тикшерүчеләр тарафыннан, дини хисләре булган өчен толстойчылыкта гаепләнеп, хөкем ителә[74]. Бу чор әдәбият тарихчыларының чын сәнгать әһелләренә кара ягу, кимсетү кебек якын килүләре милли мирасны пәрдәләү өчен кулланылган бер ысул. Язучылык горурлыгы басым астында изелгән өчен болай да тыйнак табигатьле Шәриф Камал Совет чорында тагын да ныграк үз эченә бикләнә. Аның 1937 елгы фаҗигаләрдә зыян күрмәве, Сибгат Хәким белдергәнчә, аның сабыр һәм юаш холыклы булуы сәбәпле, дошманнары булмавында. Ш.Камал 1938 елда латин хәрефләре белән басылган «Сайланма әсәрләр» китабына язган сүз башында нахак тәнкыйтьләрне кире кагу өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли[75]. Шәриф Камал бүген дә «Акчарлаклар» әсәре авторы буларак, татар әдәбиятының иң әһәмиятле язучыларыннан берсе булып кала. Аның татар басмаларындагы язмалары, бигрәк тә «Вакыт» газетасында чыккан язмалары тупланып, җыентыгы төзелергә тиеш. Шәриф Камал моңа һичшиксез лаек.

Халит Зия Ушаклыгил һәм Шәриф Камал хикәяләрендәге уртаклыклар Галимҗан Ибраһимовның: «Без бервакыт госманлы әдәбиятына шәкерт идек. Ул вакыт бездә госманлы тәэсире бар иде»[76] дип белдерүенең исбаты булган кебек Яңарыш чоры төрек әдәбиятының йогынты географиясен дә күрсәтә.


**Һүсәйин БАРГАН,**
*Истанбул*

*Төркекчәдән* **Ринат СӘФӘРОВ** *тәрҗемәсе.*

[68] Halit Ziya Uşaklıgil, a.g.e., s.17-26.
[69] Шәриф Камал. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 27-39.
[70] Габдрахман Сәгъди. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 274.
[71] Halit Ziya Uşaklıgil, a.g.e., s. 19.
[72] Шәриф Камал. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 38.
[73] Гаетне котлыйм, Вакыт. 28 октябрь 1913, № 1331.
[74] Татар әдәбияты тарихы, Т. 3, Б. 322.
[75] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр, Казан: Таттосиздан матбугат әдәбият секторы, 1938, Б. 5-6.
[76] Галимҗан Ибраһимов. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 231.

# ФРАНЦУЗ ТЕЛЕНДӘ НӘШЕР ИТЕЛГӘН «ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ПРОЗАСЫ АНТОЛОГИЯСЕ»НӘ (ПАРИЖ, 2021) КҮЗӘТҮ

Европада татар әдәбияты белән кызыксыну бармы? Француз телендә Парижда басылган «Хәзерге татар прозасы антологиясе» бу сорауларга җавап булып тора.




«Франциядә татар әдәбиятына кызыксыну бар, әмма алар өчен әлегә без ерак планета кебек. Татарлар турында гомуми күзаллау булса да, тарих һәм әдәбият аша танышу бик аз дәрәҗәдә. Халкыбыз турында белгертүнең иң үтемле мәдәни юлы – әдәбият. Укучыга бүгенге авторлар кызык, шуңа күрә әлеге проектларны башкарып чыктык», – диде китапның төзүчесе Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, язучы Ленар Шәех.

Антологиянең сүз башын галим Тимур Мөхетдин язган. «Бу китапта бүгенге көндә җиң сызганып иҗат итүче алты язучының өчәр хикәясе урын алган. Галимҗан Гыйльманов, Фирүзә Җамалетдинова, Ркаил Зәйдулла, Ленар Шәех, Айсылу Имамиева һәм Рөстәм Галиуллин», – дип белдерде Ленар Шәех үзе.

Француз теленә тәрҗемә ителгән татар прозасы ни турында соң? Игътибарны антологиядә урын алган Айсылу Имамиеваның «Мәчет» хикәясенә юнәлтик. Хикәядә авылда иман йорты булдыру вакыйгасы һәм аның Кадрия исемле кызның күңеленә ясаган тәэсире сурәтләнә. Укытучы әнисе белән булган хәл һәм мәктәп газетасында мәчет төзелү турында мәкалә урнаштырганга шелтә белдергән кешенең бу шатлыклы көнне котлап чыгыш ясавы аша икейөзлелек проблемасы бирелә. Кадрия күп җирләрдә булып, нинди генә затлы мәчетләр күрмәсен, авылдагысының бусагасын атлап кергәндәге хатирәләр иң яктысы булып кала.

А.Имамиеваның «Төпчек бала» хикәясенә «Бар дөньяны афәт, сугыш чорнап алса да, аналар барыбер яшәү турында уйларга мәҗбүр» дигән эпиграф куелган. Баласы дөньяга килер алдыннан гына иренең кара тамгалы хәбәре килгән ананың чарасызлыгы, ялгыш адымнан кире кайтуы сурәтләнә. Сугыш темасы «Хәбиб бабай хатирәсе»ндә дә дәвам итә. Тарих турында уйланулар һәм Беренче Бөтендөнья сугышында булган аяныч хәл. Әйе, һавада дары исе килмәгәндә дә сугышта адым саен куркыныч сагалый. Берничә атна эчендә шаян яшьлекләрен урта яшьлек ир-ат кыяфәтенә алыштырган Хәбиб белән Зәйнине ни көтә? Җыентыкта урын алган хикәяләрнең өчесендә дә ретроспекция алымы кулланыла, хәзерге заманда барган сыман тоелган вакыйгаларның инде үткәндә булганлыгы ачыклана.

Галимҗан Гыйльмановның «Бүреләр һәм Иохann Себастьян Бах» хикәясендә Мәскәүдәге затлы залларда чыгыш ясаган өметле музыкант егетнең әбисе авылына кайтып җиткәндә генә бүреләр көтүенә очравы сурәтләнә. Кыргый җәнлекләр моңлы итеп җырлаган яисә уен коралында уйнаган кешегә тимиләр дигәнне ишеткәне булган егет скрипкада

Бахның сонаталарын уйнарга карар кыла. Ә бүреләр утыра бирә... Татар авылы янындагы бүреләр татар көен көтәдер дигән уй белән егет үзе белгән бердәнбер татар көе «Туган тел»не исенә төшерә. Могҗиза була: ерткычлар таралыша. Бу хикәясендә язучы ата-аналарның, үзләре дә шәһәрләшеп, балаларын төрле яктан үстереп тә, туган телләрен өйрәтүгә тиешле игътибар бирмәве турында уйлана һәм татар моңының көчен раслый. «Лифтта» хикәясе укучыны иркен басу юлыннан тынчу лифтка күчерә. Язучы, язылып беткән романына нокта куя алмый утырганнан соң, җилләнеп керергә ниятләп чыгып китә һәм лифтта бикләнеп кала. Вакытның төгәл күрсәтелеп, ике сәгать ярым эчендә геройларның үз-үзен тотышлары аша характерлары ачылуы күз алдына сәхнә әсәрендәге шикелле ачык килеп баса. Ябылып калуга һәркем якыннарына булган ачу-үпкәсен белдерә башлый. Кемдер «2»ле алган улына, кемдер исереп кайткан иренә, үзен кибеткә җибәргән хатынына, «кунак» килгәч куып чыгарган энисенә. Нindидер котылгысыз фаҗигагә эләгеп, бар тормышын күз алдыннан үткәргән шикелле, һәркем ялгышларын аңлап үкенә, чыккан очракта бөтенләй башка мөнәсәбәт күрсәтер идем дип сөйли башлый. Тагын бер сәгатьтән лифт ишеге ачылуга барысын да ишек төбендә газизләре каршы ала. Лифттагы матур сүзләр – чынбарлыкта буш сүзләр генә. Автор позициясе хикәяләүче теле белән җиткерелә: «Иман үзгәрә, холык үзгәрми, диләр. Дөрес икән».

«Сынау – сыналу ул» хикәясе гомере буе авылда яшәгән Хәбибрахман картның, нигезен кадаклап, уллары янына шәһәргә китүе хакында. Үткән тормышы, балалары турында уйланып утырганда ул янындагы диндар кыяфәтле картка игътибар итә. Сөйләшеп китәләр, Хәбибрахман карт өч улыннан икесенең берсенә килүе белән бүлешә, уртанчысының зур фатирда яшәвен, аны чакырмавын аңлата. Әңгәмәдәше балаларын сынап карарга тәкъдим итә. Бай уллары сынауны үтә алмый, ә уртанчысы бөтенләй башка яктан ачыла. Игелекле һәм акыллы уйларга бирелгән Хәбибрахман картның бу халәте озакка бармый: аның үзен дә олы сынау көтә. Бу хикәядә аталар һәм балалар, туганнар мөнәсәбәтләре, байлык – ярлылык һәм әсәрнең исеменә үк чыгарылып куелган кешенең сыналуы мәсьәләләре күтәрелә. Бөтен шәһәрне бер итеп яшәгән, бар өмете аларга багланган улларының мөнәсәбәте үзгәрүе, теш табибы булган улының исә энисенең тешләрен карый алмавы да аяныч.

Антологиядә Ленар Шәех хикәяләре урын алган. «Бал бабай» оныкчыгына бабасының «Миннән истәлек булыр. Мөселманлык – татарлыкны саклый торган бердәнбер сыйфат ул», – дип, бөти тапшыруыннан башлана. «Колхозлашу чорында туган авылларыннан ятим ителеп, ваз кичтерелеп куылулары, этисенең «кара эшләпәле» кешеләр белән каядыр китеп югалуы; Бөек Ватан сугышы, әсирлек... Ашкынып туган якка кайту һәм тагын ун елга төрмәгә эләгү» – үз гомерендә нинди генә сынау аша үтмәгән, бал кортларында гына юану тапкан картның йөрәге кызы Нурлыбикәнең рус егетенә кияүгә чыгып, Себергә китеп баруын, оныкларының бер кәлимә татарча белмәвен, яраткан оныгы Илгизнең рус кызына өйләнергә җыенуын күтәрә алмый.

«Ике тарих» хикәясе «Кемгә, нәрсәгә сатылырга? Ни өчен?.. «Сатылу» сүзенең асылында ни ята? Ул гел начар гына буламы?..» дип башлана. Ике тарих – йөргән кызы ташлаган егет һәм балалары ташлап киткән карчык. «Ике вакыйга. Икесендә дә – гади кешеләр, безнең язмыш. Тормышыбызны бәхетле һәм үкенечсез итеп үткәрү, һәр гамәлне күңел теләгәнчә башкару үзебездән тора».

«Йөрәккәем янганга...» ГЭСлар төзелү сәбәпле, авылларны күчерү фаҗигасен күңелдән үткәрә. Үгетләүләргә карамастан, шунда калган гаилә авылның йөрәге булып яшәвен дәвам итә.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, язучы Ркаил Зәйдулланың антологиядә урын алган «Ак эт» хикәясе өеннән халык өзелми торган, беркем дә яшен белмәгән Җантай әби турында. Имеш, төнлә бу карчык ак эткә әверелә дә урамда берәр

кыз-хатынны эзләп йөри икән. Шуның аяк арасыннан үтеп китсә, тынычлап җан бирәчәк икән. Бу ышану кешене әсир итә.

«Мылтык» хикәясе заманында шәп аучы булган ирнең мылтыгын табып алып, ауга чыгарга җыенуы турында сөйли. Ә янына сеңлесе килгән авыр хәлдәге хатыны үзен терелтергә сәләтле булган дәва өмет итә.

Рөстәм Галиуллинның «Боссоойко» хикәясендә язучы якут дустыннан ишетеп белгән Боссоойко турында язарга ниятләп Саха иленә бара. Саха халкының каһарманы булган, гаделсезлеккә каршы гади халыкны яклап көрәшкән татар егете Гыйззәтулла Рәхмәтуллин була ул. Гыйззәтулла батыр дастан каһарманнарыдай сурәтләнә, тулы көчкә ия булуы – 100 пот – 1600 кг күтәрә алганлыгы әйтелә.

«Тимер капка артында» ирексез ирекле кешеләр – хәзерге заманда төзелештә аз хезмәт хакына эшләүче төрле милләт һәм ил вәкилләрен сурәтли. Аларны исемнәре белән түгел, номерлары белән генә атыйлар, эш барышын тикшерергә килгән хуҗаның күз алдыннан да алып куялар. Китәргә теләсәләр дә, башка эш табу мөмкинлекләре юк, шул сәбәпле һәр кушканны үтәргә әзер булып тора алар. Үзе тирәли маймыл сыман сикереп йөгерешүләренә сөенгән түрәнең дә шатлыгы озакка бармый: аның да «алтын номерлы» каршысына басасы бар.

Фирүзә Җамалетдинованың «Буранда» әсәре дә чиксез ана мәхәббәтенең көчен раслый. «Мизгелләр... Язмышлар мизгелләрдән тора... Дөнья үзен узарга тырышканны яратмый...» – дип, ачы хакыйкатьне кабатлый язучы. «Яралы күгәрчен» хикәясендә ир үзен сыңар канатлы, сыңар күзле ак күгәрченгә тиңләп, хатыны һәм кызы белән кабат кавышырга тели: «Очар өчен кешеләргә дә ике канатлы булу кирәк икән шул». Монда да «Мизгелләр! Бөтен хыялларыңны үзгәртеп, кирегә борып куярга да сәләтле шул алар. Алга карап барган җиреңнән капма-каршы якка, кирегә таба юл алганыңны сизми дә каласың...» Язмыш. Ялгызлар. Сабырлык...

«Кеше күңеле – кара урман» хикәясе авылга шатлык һәм ямь биреп торган, җүләррәк саналган Фәтхерахман – Пәттери хакында. «Җанында мәхәббәт бар» диләр аның турында. Һәрвакыт ярдәмчел була, еллар үтсә дә үзгәрми, Гүзәлия исемле укытучы кызны көтеп яши ул. «Үзең сөенер өчен башкаларны да сөендерергә кирәк шул. Шатлык бит ул – сине хуплаучылар бар дигән сүз. Исәрләр өчен дә әлеге төшенчә үзгәрми икән...» «Язмышны үзебез язабыз дисәләр дә, үзебез генә язмыйбыз бугай шул аны...» дип нәтиҗәсен ясый хикәяләүче.

Бу хикәяләрдә гомумкешелек кыйммәтләре раслана, вакыйгаларда милли үзенчәлекләр дә чагылыш таба. Француз телендәге «Хәзерге татар прозасы» антологиясе әдәби җәүһәрләрне туплаган җыентык. Бәрәкәтле гамәл дәвамлы булсын иде!

**Ралина ХӘБИРОВА,**
*Казан федераль университетының 1 курс студенты, «Рухият» фәнни түгәрәгенең кураторы*

## Әдхәт Синугыл хаты

*5.04.1992*
*Ташкент*

Марсель сабакташ!

Сине чын күңелдән азатлык яулап алуыбыз шатлыгы белән тәбрик итәм! Син бу тәбрикләүгә шактый лаеклы әдип бит. Күпчелек татар язучылары ул-бу булмагае дип, юрган астында йодрык күрсәтеп ятканда, син үзеңнең туры атып тидергән мәргән укларың белән дошманнарның кара йөрәгенә үтергеч ударлар ясадың!

Син үзеңнең бу җәсүрлегең белән мине үзеңә гашыйк иттең. Мин моңарчы синең шактый кыю һәм каһарман йөрәкле татар угланы булуыңны белми яшәгәнмен икән. Кешеләр авыр вакытта сынала дигәннәре рас икән ләбаса!

Афәрин, мең яшә, Марсель!

*Тирән ихтирам белән, уртак шатлыгыбызга сөенеп, Ә.Синугыл.*

## Рәис Зарипов хаты

*2.02.1993*
*Яр Чаллы шәһәре*

Хөрмәтле Марсель әфәнде!

Үткән елның 21 ноябрендә «Шәһри Казан» газетасында Карл Венингнең «Казанны алу» картинасы һәм шуңа карата Сезнең «Табарга иде» исемле мәкаләгез җанны тетрәткән иде.

Шушы көннәрдә миңа Чувашстан республикасындагы Шыгырдан авылында яшәп ятучы татар эмигранты Минһаҗ ага Измайлов янында булырга туры килде. Шушы картина хакында да сүз чыкты. Ул шушы картинаның кечкенә карточкасын эстон татарларының (апалы-кызлы) альбомында күреп кала һәм сорап алып, Германиядә күбәйтә. Шул фотоларны татарлар яшәгән бар илләргә дә диярлек җибәрә. Ул инде «Шәһри Казан»га да әлеге фото эләккәндер дип ышана.

Минһаҗ аганың әйтүе буенча, картинаның Эстониянең Тарту шәһәре галереясендә саклануы мөмкин. Әгәр дә вакытыгыз булса, шушыларны күз уңыннан төшермәсәгез иде.

*Ихтирам белән, Рәис Зарипов, Чаллыдагы «Таң йолдызы» газетасы корреспонденты.*

**P.S.** «Шәһри Казан»ның 22 гыйнвар санында Әхмәтҗанов иптәшнең «Ыкның теге ягында» исемле бик акыллы мәкаләсе дөнья күрде. Уфа губернасы җирләрен (татар җирләрен) 1919 елда түгел, 1922 елда гына Кече Башкортстанга куштылар.

## Җәмит Рәхимов хаты

*3. 08. 1994*
*Лениногорск*

Марсель якташ!

Сөйләшкәнчә, гыйнварда миңа 60 яшь тула. Шул хакта киңәшкәндә, син искә төшергән буенча мин үземнең архивларда йөрү маҗаралары хакында бер әйбер яздым менә. Шактый озак утырылды. Карап чыгу һәм аның язмышын хәл итү хәзер синең кулда.

Алтмыш яшь димәктән, Әлмәт бүлеге кушуы буенча мәрхүм Рафаил абый минем

иҗат турында бер нәрсә язган иде. Без аны Разим белән автор үзе исән вакытта ук карап чыктык һәм икебез бердән: «Бик йомшак язылган», дигән фикергә килдек. Аңардан инде артыгын көтеп тә булмый иде – соңгы вакытта бик бирешкән иде мәрхүм. Без үзебезнең фикерне Рафаил абыйга әйтергә кыенсынып йөрдек, аны эшләүнең хәтер калдырмый торган юлларын эзләдек. Безнең исәп буенча, автор килешкәндә, Разим аны ныгытып сипләргә һәм киңәйтергә тиеш иде. Әмма без сузып йөргән арада Рафаил абый язмасын сиңа җибәреп өлгергән икән. Разим шалтыратып, синең белән киңәшергә, безнең шик-шөбһәләрне әйтергә тиеш иде. Тик ул да эшне сузды һаман. Шул арада Рафаил абый үлеп тә китте. Хәзер инде нишләргә дә белгән юк. Син бер акыллы киңәш бирсәң? Разим язса, әйбәт мәкалә килеп чыгасы иде, әлбәттә. Чөнки ул мине һәм минем иҗатны яхшырак белә.

Кыскасы, Рафаил абый мәкаләсен дә, минем бу язманы да үзең хәл ит. Һәрхәлдә 1995 елның беренче санында журналда минем исем-фамилия телгә алынса, күңел булыр иде.

*Сиңа исәнлек-саулык, тормышыңда һәм иҗатыңда уңышлар теләп һәм алдан ук (исән булсак!) минем гыйнварда булачак кичәгә чакырып, Җәмит.*

## Фәния Чанышева хаты

*17 март, 1998*

Хөрмәтле туганнар!

«Казан утлары» журналы хезмәткәрләре!

Сезнең күптәнге абунәчегез буларак, журналның һәр санын көтеп алам, айның 3-4 көнен аңа багышлыйм. Бу юлы да 1998 елның икенче санын башыннан азагынача укып чыктым. Яраткан шагыйрем Фәнис Яруллин шигырьләрен, аның турындагы М.Шабаевның мәкаләсен (гәрчә аны элек укыган булсам да) укыдым. Ялкытмый торган, йөрәктән чыккан сүзләр! Һәр икесенә дә рәхмәт.

Марсель Галиевның «Догалы еллар»ын бик яратып укыдым. Изгелекле, игелекле хезмәт бу. Бер тында мавыгып укыла. Андагы шәхесләрнең күпчелеген күреп йә укып белгәнгәдер, күрәсең, күңелемә бигрәк тә ятышлы булды. Матур хис, изге тойгылардан тукылган әсәр. Язучыларның эчке дөньясын ача торган, аларны халыкка якынайта, яраттыра торган тойгылардан туган әсәр, дияр идем. Журнал тоташы белән гел изгелектән тора.

Элекке елларның бер санында Марс Шабаевның язмалары чыккан иде. Ул чакта да фикеремне язып җибәрәсе килгән иде, ничектер калды, онытылды. Ул чакта да шундый ук тойгылар кичергән идем. Анда аеруча Хәсән Сарьян турындагы истәлекләр тетрәндергән иде. Ничәмә еллар элек укылган «Бер ананың биш улы» дигән повесть әле дә онытылмый. Ә бит һәр укыган әсәр хәтердә уелып калмый.

Бу санда Рәдиф Гаташ шигырьләре үзе бер ләззәт бирә. Беркемгә дә охшамаган, берәү белән дә бутамыйсың аларны. Мәңге яшь, мәңге гашыйк, мәңге мәҗнүн булып калсын ул. Мәхәббәте булмаса, шагыйрь дә юк бит инде.

«Синдәйләргә – ихлас җанга авырдыр?

Раббым, шундый шагыйрьләргә сабыр бир!»

«Иңрәү» повесте да мавыктыргыч кына. Журналның бу саны гел изгелектән тора дигән идем инде. Н.Нәҗми турындагы белешмәләр дә, сурәтләр дә күңелне җылыта.

Г.Исхакыйны халыкка кайтарудагы эшләрне дә сиземләмәү мөмкин түгел. Ә.Галиевның «Бер һәйкәл тарихы» да кызыклы, бөек рәссамга мәхәббәт белән сугарылган.

Нәҗибә Ихсанова турындагы мәкалә-очерк та, Ф.Хөсни турындагы истәлекләр дә Шамил Маннап, якташым Илдар Юзеев мәкаләләре кешегә изгелек, олылау, зурлаудан тора, югарыда әйтелгән шул ук фикерне раслыйлар.

Иң кызыгы шул: журналны ике көн укыгач, өченчесендә үземнең фамилиямә тап булдым. Башта ышанмыйчарак тордым әле. Шулай да «Казан утлары» кебек олпат журналда исememне күрү (яшермим!) шактый күңелле булды. Рәхмәт, туганнар. Моны кайсыгыздыр хәстәрләгән бит инде.

Исән-сау эшләгез, гомер юлыгызда шатлыклар күп булсын!

*Барыгызга да туганлык сәламе белән, Фәния Чанышева.*

**P.S.** Журналның һәр санын яратып укыйм. Сезнең әдәби-мәдәни тормыш белән танышып барам. Монда бик күп язучыларның әсәрләрен күрсәтеп булыр иде, кемнедер онытып калдырудан куркам. Бу хат Сезгә игътибарыгыз өчен рәхмәт тойгысыннан язылды, бигайбә! Хушыгыз!

## Газиз Кашапов-Үзиле хаты

*18.02.1991*
*Чаллы шәһәре*

Марсель дус!

Сүземне Олы Рәхмәт белән башлап җибәрәм. РӘХМӘТ! ТУФАНГА РӘХМӘТЕҢӘ РӘХМӘТ! «Агыла да болыт агыла»ны рәхәтләнеп укып чыктым. Соңгы араларда минем җанга мондый ук тәэсирле, мондый ук игелекле әйбер укырга туры килмәгән иде әле. Ниһаять, акыллы, төпле сүз әйтүче табылды. Дөрес, мин үзем дә, каршылыклары һәм гаять олы тоткарлыклар чыгу ихтималы булуга карамастан, бер әйбер язган идем, тик үзең беләсең бит инде, ята әле ул, ятар ятар да кире кайтыр. Һәр әйбер теге яки бу дусның кәефеннән тора...


Әмма дә ләкин Туфан турында шундый сүз әйтүең синең үз шәхесеңне дә бик югары күтәрә. Бирсен Ходай, иншалла, игелеге дә булыр әле.

Үзем Туфан турындагы романны бетергән идем, тик әлегә машинкадан алып булмый, сузалар да сузалар. Үз ихтыярыңдагы нәрсә булмагач, нишләмәк кирәк... Хәер, мин ышанам: аны тиз генә бу елларда чыгарып булмастыр, ахрысы... Шулайрак сизелә, шулайрак...

Өйдә эшләп булмый, язасы килгән нәрсәләр бик күп. Туфанның икенче китабын да эшлисе иде. Тик... күңел тынычлыгы юк, шул җанны ашый, кимерә. Ә тирәмдә кешеләр миһербансыз... Юк, уйлый күрмә, зарлануым түгел бу. Түзә беләбез инде без. Казанга күчәселәр килә, әмма бер генә яктан да җай чыгарып булмый. Шулай итеп булмастыр да инде ул...

*Сиңа иҗатыңда олы уңышлар, гаиләңдә иминлек теләп, Газиз Кашапов-Үзиле.*

# ӘДӘБИ СКАНВОРД

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ... По (Америка язучысы) | | | | | | |  | | |
| | | | | Музыкаль юнәлеш | | Язучы ... Камалов | | | | |
| | Татарстандагы елга | | | | | | | | | |
| | | | | Язучы ... Вергазов | | Татар халык җыры | | | | |
| | | | Публицист ... Медведев | | | | | Казанда чыккан сатирик журнал (1908-1909) | | Кечерәйтү ярдәмендә ясалган сурәтләү чарасы |
| ... Гәрәй (эстрада артисты, сатирик) | | ... Урманче | | Гайсин, Баян, Әхмәдиев | Шагыйрь Ян Райнисның милләте | | Образ, характер | | | |
| | | | | Күрәзәлек итү | | | | | | Әхсән Баян поэмасы |
| | ... Руставели | | | | | | Себерне яулаган казак атаманы | | | |
| | Шагыйрь Ренат ... | | Максат, токтан юл, юнәлеш | | | | | Габдулла Тукай шигыре | | Маргарита Алигер поэмасы |
| | | | | | XVII йөз голланд рәссамы | | Шәехзадә Бабич туган авыл | | | |
| | ... Боровик (рус язучысы) | | Текә биек ярлы диңгез култыгы | | Тар, озын тукыма | Шагыйрь Әхмәт ... | Проспект | | Кәрим Тинчурин драмасы | |
| | | | | | | | | | | |
|  | | | | | | | Дедал улы / Дөрес, хак | | Кордильер тауларының көньяк өлеше | |
| | | | | Иран телле борынгы кабилә | | | | | | |
| | | | | | | | | Нурислам Хәсәнов романы | | Язучы ... Мөхәммәдиев |
| | | | | ... Казакова (рус шагыйре) | | Шагыйрь Госман ... | | | | |

**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *«Гөлҗамал», «Йолдызым», наза, «Фидая», Халиди, Верди, Сафин, Лир, «Ант», Хисам, «Аврора», «Нана», авар, Малаяз, Юныс, Наил, арат, Майн, «Ана», Ом, төс.* ***Өстән аска:*** *Наум, АМО, «Идел», рам, Аралбай, Гыйматдинова, ТНТ, Траян, Ләлә, Арзамас, Расих, акын, Ларин, «Юлдаш», Зариф, саен, абыз, диван, Мамин, Марс.*

*Роза Хафизованың тууына – 95 ел*

# ЙӨРӘКЛӘРГӘ «ЯЛКЫН» САЛГАН ЯЗУЧЫ



Февраль ае – балалар язучысы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Роза Хафизованы (1929–2005) искә алу фасылы. Быел аның тууына 95 ел тулды.

Татарстан Язучылар берлегенең рәсми сайтында аның турында мондый мәгълүматлар урын алган:

Роза Сәет кызы Хафизова 1929 елның 6 февралендә Бөгелмә шәһәрендә туа. Лениногорск районы Сарабиккол авылы мәктәбендә – җиде сыйныф һәм Иске Шөгер урта мәктәбендә унны тәмамлаганнан соң, 1947–1951 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә белем ала. 1951–1952 елларда Төмән өлкәсенең Тобол шәһәрендәге татар урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Р.Хафизованың шуннан соңгы хезмәт юлы журналистика белән бәйле. «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре»), «Сталин байрагы» (Чистай), «Төзелештә» газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. Мәскәүдә Югары партия мәктәбенең журналистика бүлегендә укып, шунда аспирантураны тәмамлап кайткач, 1962–1986 елларда, ягъни лаеклы ялга җиткәнче, ул республика татар балалар журналы «Ялкын»ның баш редакторы хезмәтендә була.

Р.Хафизова – үзенең әдәби иҗатын тулысынча диярлек балаларга багышлаган язучыларның берсе. Аның нәниләр өчен әкиятләре һәм тәрбияви эчтәлектәге хикәяләре тупланган «Кыңгыраулар җыры» исемле беренче китабы 1967 елда басылып чыга. Авторның «Курай-малай маҗаралары» (1969), «Кирлемән» (1970), «Кашкарыйлар озын гомерле» (1975), «Әкиятләр» (1976), «Без әле кайтырбыз» (1977), «Сак-Сок тавышы» (1987), «Киек Каз Юлы» (1988), «Актәпи ник моңая?» (1991), «Карурманданиләр булмас» (1999), «Актәпи» (2004) кебек китаплары яшь укучылар арасында популярлык казана.

Р.Хафизова яшьләргә, өлкәннәргә атап язган проза әсәрләре («Мәхәббәт бар ул», «Таң билгесе», «Зөләйханың сәгать чылбыры» повестьлары, шулай ук хикәяләре, лирик парчалары), туган ил, туган җир, мәхәббәт, ялгызлык, дуслык кебек әхлакый категорияләргә мөнәсәбәттә үзенең уй-хисләрен чагылдырган лирик шигырьләре белән дә укучыларга таныла.

Укучыларыбыз өчен без журнал сайтына Роза Хафизова иҗатына багышланган тапшыру урнаштырдык. Анда сез язучының балачак хатирәләрен, Дания Нурлы укуында «Күңел күзе» дигән хикәясен ишетерсез. Тапшыруның авторы Дания Гайнетдинова, режиссёры – Рамил Һидиятулла, тавыш операторы – Гөлнара Хикмәтуллина. Ания Гыйбадуллина алып бара.

*Нияз Акмалның тууына – 70 ел*

# МИН ҮЗЕМНЕ ӘДИП ИТЕП ТОЯМ...



Күренекле шагыйрь, прозаик, публицист, Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты Нияз Акмалның (1954–2007) тууына 70 ел.

2002 елда «Үзем турында үзем» исемле мәкаләсендә ул болай дип язган иде:

«Миннән еш кына проза, шигырь, юмор-сатира жанрларында ничек берьюлы эшли алуым турында сорыйлар. Кайсы жанрның миңа «җиңелрәк бирелүе» турында кызыксыналар. Шигырьме, прозамы, янәсе. Бу хакта минем сүзем бер, фикерем бер: жанр минем өчен иҗатның бер төре, формасы-калыбы гына. Үз хәл-халәтем нинди булуга карап, күңелем белән сизенеп, әйтәсе сүземне-фикеремне, сурәтләремне шул калыпка салам мин. Ягъни билгеле бер жанрга. Шуңа күрә Нияз Акмал шагыйрьме, прозаикмы кебек сорауларга көлеп кенә карыйм, үземне әдип итеп тоям...»

Исеме матбугат битләрендә озак кына онытылып торган әдипнең берничә әсәре бу айда юбилее уңаеннан газета-журналларыбызда күренеп алды. Татарстан радиосы исә шагыйрь исән вакытта ук язылып, радио фондында саклланган язмаларны эфирга әзерләде. Болар – Нияз Акмалның үз укуында һәм артистлар башкаруында шигырьләр; балалар өчен язылган «Серле кайтаваз» повесте буенча радиоспектакль; Ренат Таҗетдинов башкаруында «Күгәрчен сөте» повестена нигезләнгән моноспектакль һ.б.

Нияз Акмал Татарстан радиосы белән даими хезмәттәшлектә яшәде, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укыган елларында биредә практика узды һәм шуннан башлап, ул әзерләгән тапшырулар, төрле вакыйгалар уңаеннан ясаган чыгышлары һәрвакыт яңгырап торды. Юбилее көннәрендә без аның 1970 еллар ахырына караган, әмма бүген дә актуальлеген югалтмаган бер публицистик чыгышын эфирга бирәбез.

Шагыйрьнең вафатыннан соң да аның иҗатын пропагандалаучы, исемен мәңгеләштерергә омтылучы игелекле затлар табылды. «Чаллы-ТВ» телеканалы «Йолдызлар балкышы» сериясеннән әдипнең иҗатына һәм тормыш юлына багышланган документаль фильм төшерде. Казанның Актёрлар йортында, Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында, Чаллының үзәк китапханәсендә, Сарман районының Үзәк мәдәният йортында иҗат кичәләре үткәрелде. Радиобыз фондында әлеге чаралардан алынган язмалар кадерләп саклана. Шагыйрьнең 70 еллыгы уңаеннан әзерләнгән яңа тапшыруларда исә каләмдәшләренең, аның белән аралашкан, үзен якыннан белгән кешеләрнең, иҗатын сөючеләрнең фикерләре, истәлекләре урын алды.

Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган тапшыру исә Нияз Акмал шигырьләреннән һәм аларга язылган җырлардан төзелгән әдәби-музыкаль композиция белән башланып китә. Аннары шагыйрьнең үз укуында берничә шигырь һәм Айдар Хафиз язмасында «Элемтәче турында баллада» ишетерсез.

Әдипнең якты рухын дога белән искә алып тыңлыйк.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУ

Алда зур вакыйга – Россия Президентын сайлау тора. Ул өч көн – 15, 16 һәм 17 мартта була. Сайлау кампаниясе барышында Россиянең хәзерге Президенты Владимир Путин кандидатурасына теләктәшлек күрсәтелеп, сайлаучылардан 2018 ел белән чагыштырганда 3 мәртәбә күбрәк имза җыелды. Татарстан Республикасы да сайлауга актив әзерләнә. 15, 16, 17 мартта Татарстанда 1 Үзәк, 65 территориаль, 2727 участок сайлау комиссиясе эшләячәк. Вакытлы 45 участок хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, тикшерү изоляторларында, Г.Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортында, «Казан-1» тимер юл вокзалы бинасында урнаша. «Быелгы сайлауның нинди тышкы сәбәпләр шартларында узуын беләбез. Татарстанда сайлау эшчәнлегенә тыкшынуларга, вазгыятьне тотрыксыз итүләргә юл куелмас», – диде ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов хәзерге Президентның Татарстаннан ышанычлылары белән очрашуда. Анда ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты, Путинның ышанычлысы сыйфатында Татарстанда тиешле эш алып барачагын әйтте. Казанда Россия Президентын сайлауга күзәтчелек буенча иҗтимагый штаб ачылды. Республикада берничә мең күзәтүче әзерләнәчәк. 2024 – Гаилә елы уңаеннан «Гаиләбез белән сайлауга» проекты гамәлгә ашырыла, районнарда «Татарстан – казанышлар республикасы» дип аталган автобуслар марафоны үткәрелә. Сайлау кампаниясе вакытында «ИнформУИК» проекты кулланыла, ягъни йорттан йортка йөреп сайлаучыларга хәбәрләр ирештерелә. Сайлауларда блогерлар да актив катнашачак.

### ИСКӘ АЛУ

Фронтовик шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 115 ел тулу уңаеннан искә алу чаралары узды. Ул яшәгән Миславский урамындагы 8 нче йорттагы истәлек тактасына чәчәкләр салынды. Шушында ук Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин каһарман әдипкә һәйкәл куелачагын хәбәр итте. Эскизы әзер. Урыны да билгеле. Һәйкәл Яшьләр үзәге каршындагы скверга куелачак. Чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе урынбасары Разил Зиннәтуллин, Ф.Кәримнең оныгы чыгыш ясады. Искә алу чаралары ТР Милли музеенда Фатих Кәрим иҗатына багышланган шигъри-музыкаль кичә һәм экскурсия белән дәвам итте.

* * *

Фронтовик-шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 115 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе Калининград шәһәренең А.Леонов исемендәге китапханәсендә дә булып узды.

***

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә язучы, җәмәгать эшлеклесе, Гражданнар сугышы каһарманы Шамил Усмановның тууына 125 ел тулу уңаеннан «Сынган канат» дип аталган театраль-музыкаль кичә булды. «Сынган канат» дип аталган пьесаны драматург Хәбир Ибраһим әдәби кичә өчен махсус язды. Режиссёры – Лилия Әхмәтова. Рольләрдә Г.Камал театрының яшь артистлары уйнады. Кичәдә әдәбият галиме Фоат Галимуллин Ш.Усмановны язучы итеп кенә түгел, көчле публицист, журналист буларак та ачты, аның татарча сөйли торган радиога нигез салуын әйтте.

### «ЯЗУЧЫ»НЫҢ БЕРЕНЧЕ КИТАБЫ

Татарстан Язучылар берлегендә эшли башлаган «Язучы» нәшриятының беренче китабы басылып чыкты. Бу басма – мәшһүр авар шагыйре Рәсүл Гамзатовның (1923–2003) «Минем Дагстаным» кыйссасы. Аны рус теленә – Владимир Солоухин, татар теленә Нәсим Акмал һәм Лилия Фәттахова тәрҗемә иткән. Китап Р.Гамзатовның тууына 100 ел тулу уңаеннан чыгарылды. Узган гасырның 70 нче елларында нәшер ителеп, дөньяның бик күп телләренә тәрҗемәдә киң яңгыраш алган басма татар телендә беренче тапкыр басылып чыкты.

### ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Төркиядә Татар шигърияте антологиясе басылып чыкты. Җыентыкка 12 татар шагыйре – Дәрдемәнд (Закир Рәмиев), Сәгыйть Рәмиев, Габдулла Тукай, Хәсән Туфан, Һади Такташ, Муса Җәлил, Саҗидә Сөләйманова,

Илдар Юзеев, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт әсәрләре кергән.

Антологиянең җаваплы мөхәррире – галим-тюрколог, филология фәннәре докторы, Эгей университеты галиме Мостафа Өнәр.

### Х.ХАЛИКОВНЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Әтнә районы Яңа Шашы Мәдәният йортында балалар шагыйре, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Хәкимҗан Халиковның тууына 90 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, язучылар Рифат Сәлах, Гөлүсә Батталова, Рәхимә Арсланова, Рәсимә Гарифуллина, галимә Ләйлә Минһаҗева, Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясе җитәкчесе Айсылу Галиева, Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Айрат Каюмов чыгыш ясадылар. Әдипнең хатыны Нурия ханым, кызы Лилия, бертуган энесе Мөхәммәтҗан ага, оныклары да Х.Халиков турында хатирәләр белән уртаклаштылар.

* * *

Балалар шагыйре Хәкимҗан Халиковны Казандагы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә дә искә алдылар. Аның тууына 90 ел тулуга багышланган кичәдә укучылар шагыйрьнең шигырьләрен укыдылар, җырларын җырладылар. Чарада язучылар Илсөяр Иксанова, Ләбиб Лерон, Вакыйф Нуриев, Рифат Сәлах, Дания Нәгыйм, Хәкимҗан аганың хатыны Нурия ханым һ.б. чыгыш ясады.

### К.ТИМБИКОВА УКУЛАРЫ

Чистайда язучы, публицист Кояш Тимбикова VII төбәкара фәнни-эзләнү укулары булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, язучы Фирүзә Җамалетдинова, «Казан утлары» журналы редакциясенең бүлек мөхәррире, шагыйрь Фәнил Гыйләҗев катнашты һәм чыгыш ясады.

### БАТУЛЛА ЯКТАШЛАРЫ ЯНЫНДА

Зәй районында күренекле якташ язучылар белән очрашулар, әдәби кичәләр үткәрү традициясе бар. Әнә шундый күркәм чаралар циклы быел Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла белән башланып китте. Аксакал әдип районның Баграж, Түбән Биш, Куш-Елга, Аксар, Югары Шепкә, Имәнлебаш авылларында үз әсәрләрен яратып укучылар, якташлары белән очрашты, мәктәпләрдә милли әдәбият, татар тарихына багышланган дәресләр бирде.

### «БЕЗ СИНЕҢ БЕЛӘН, ТӨРКИЯ!»

2023 елда Төркиядә җир тетрәү вакытында һәлак булганнар истәлегенә багышлап төрле төрки илләрдә, республикаларда күп кенә шигырьләр иҗат ителде. Азәрбайҗан Язучылар берлеге шагыйрь Сәлим Бабуллоглы җитәкчелегендә шул шигырьләрне сайлап, азәрбайҗан теленә тәрҗемә итеп, «Без синең белән, Төркия!» дип аталган антология нәшер итте. Анда татар шагыйрьләре Ркаил Зәйдулла, Рүзәл Мөхәммәтшиннарның да шигырьләре бар.

### ТӘРҖЕМӘЧЕЛӘР ИГЪТИБАРЫНА

2026 елның апрелендә бөек татар шагыйре, әдәби тәнкыйтьче һәм публицист Габдулла Тукайның тууына 140 ел тула.

Г.Тукайның күп кенә шигырьләре тәрҗемә ителгән. Тик әле һаман да тәрҗемәчеләрнең кулы тимәгән әсәрләре бар. Аның байтак публицистик һәм тәнкыйть язмалары үз тәрҗемәчесен тапмаган.

Юбилейга әзерләнгәндә Татарстан Язучылар берлеге белән «Казан альманахы» журналы Г.Тукайның рус телендә укучыларга барып ирешмәгән әсәрләрен тәрҗемә итү максатында конкурс игълан итәләр. Аның максаты – бөек татар шагыйренең иҗатын тагын да популярлаштыру, әдәби тәрҗемә өлкәсендә яңа талантларны ачу.

ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Г.Тукай әсәрләренең рус телендә күп томлыгын әзерләү башланды. Конкурста җиңүчеләр әлеге проектта үз тәрҗемәләре белән катнашу мөмкинлеге алачак. Бәйге «Шигырь» һәм «Публицистика» номинацияләрендә үткәрелә.

Тәрҗемә өчен шигырьләрнең текстлары (оригиналда һәм хәзерге әдәби телдә) сүзгә сүз тәрҗемәдә, ә мәкаләләрнең татар телендәге төп нөсхәсе бирелә.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

25 февральдә язучы-прозаик, саллы әсәрләре белән журналыбыз укучыларының күңелен яулаган авторыбыз, дустыбыз Равилә Шәйдуллина-Муратның юбилее.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ «На вершине горы обитает волк», мемуары А.ХАЛИМА «Папа, мама, сколько мне лет?»,*
*рассказ А.ГАРАЕВОЙ-АКЧУРЫ «Что у тебя за пазухой?»; поэма М.КАБИРОВА, стихи А.СУФИЯНОВА, Р.МАЙОРОВОЙ.*
*«Новые имена»: стихи Р.ШАКИРОВА.*
*«Литература родственных народов»: рассказ Д.МАКЕЕВА «Луч надежды на ледяных осколках» в переводе Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ.*
*«Литературная критика»: статья Л.ХУСНУТДИНОВОЙ о творчестве А.Суфиянова.*
*«Публицистика»: статья Д.РАУПОВОЙ.*
*«140 лет со дня рождения Шарифа Камала»: фотоархив. Подготовил А.ШАЙХИН.*
*Статья Х.БАРГАНА в переводе с турецкого языка Р. САФАРОВА.*
*«Обзор книги»: отзыв Р.ХАБИРОВОЙ к «Антологии современной татарской прозы» на французском языке.*
*«Памятные письма»: письма А.Синугыла, Р.Зарипова, Дж.Рахимова, Ф.Чанышевой, Г.Кашапова-Узиле М.Галееву.*
*Сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 95-летию Р. Хафизовой и 70 -летию Н. Акмала.*
*Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: улица Баумана г.Казани. Фото И.АБРАМОВОЙ;*
*поэтесса Р.АРСЛАНОВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by R.SHAYDULLINA-MURAT «A wolf abides on the top of the mountain», memoirs by A.KHALIM «Dad, Mom, How Old Am I?»,*
*story by A.GARAYEVA-AKCHURA «What's tucked behind your belt?»; poem by M.KABIROV, poems by A.SUFIYANOV, R.MAYOROVA.*
*«New names»: poems by R.SHAKIROV.*
*«Literature of kindred peoples»: story by D.MAKEEV «Glimmer of Hope on the Ice Grains» translated by F.ZAMALETDINOVA.*
*«Literary criticism»: article by L.KHUSNUTDINOVA about the creation work by A.Sufiyanov.*
*«Publicism»: article by D.RAUPOVA.*
*«140 years since the birth of Sharif Kamal»: photo archive. Prepared by A.SHAIKHIN*
*Article by H.BARGAN translated from Turkish by R.SAFAROV.*
*«Book review»: review by R.KHABIROVA of the «Anthology of Contemporary Tatar Prose» in French.*
*«Memorable letters»: letters from A.Sinugyl, R.Zaripov, J.Rakhimov, F.Chanysheva, G.Kashshaf Uzile to M.Galeev.*
*Scanword. Compiled by R. ABDULLAH.*
*«Priceless voices»: articles for the 95th anniversary of R.Khafizova and the 70th anniversary of N.Akmal. The column is led by N.AKMAL.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Bauman Street in Kazan. Photo by I.ABRAMOVA;*
*poetess R.ARSLANOVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Бауман урамы.
*И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә Рәхимә АРСЛАНОВА.